8(05)

# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ-1975

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1975

## Бу санда

**Г. МӨХӘММӘДОВА.** Яшьлек көннәре. Повесть . 3
**Ә. БАЯНОВ.** Кышкы чәчәкләр. Поэма . . . . . 90
**Б. КАМАЛОВ.** Җир хакы — ир хакы. Хикәя . . . 105
**Р. БАТУЛЛА.** Җитмеш җиде пәһлеван. Әкият . . 112

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . . 119
**М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ.** Солдат хатлары . . . . 122

БӨЕК ҖИҢҮГӘ 30 ЕЛ

**С. ШАКИР.** Полк комиссары . . . . . . . . . 133
**Н. КРАВЦОВА.** Багеровога таба . . . . . . . 140

М. ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

**М. РӘХИМКУЛОВА.** Җәлилнең «Хөсәения» чоры . 145
**И. ИЛЬЕНКО.** Үлемсез дуслык . . . . . . . . 146
**М. МОХТАРОВА.** Шагыйрь тормышыннан бер сәхифә . . . . . . . . . . . . . . . 148

КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

**Я. АБДУЛЛИН.** Каюм Насыйри иҗатында мораль-этик мәсьәләләр . . . . . . . . . . . . . 150
**Ә. КӘРИМУЛЛИН.** Каюм Насыйриның «Таң йолдызы» проекты . . . . . . . . . . . . . 157
**С. АКБИЕВ.** Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаев . . . . . . . . . . . . . . . . 162

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ПОРТРЕТЫ

**Н. ХИСАМОВ.** Заман һәм шагыйрь . . . . . . 168

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ФӘЙЗУЛЛА. Таң шәһәре . . . . . . . . . . 179
Ә. МӘХМУДОВ. Шагыйрәнең «Фал китабы» . . 181

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

З. НУРИ. Төн трагедиясе... Шигырьләр . . . . 183
А. ДУБИН. Мәзәк хәлләр . . . . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-69.

Баш редактор: Зәки Нури.

Редколлегия: Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/XI-1974 ел. Басарга кул куелды 30/XII-1974 ел. ПФ 05899. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91544 экз. Заказ Ю-311.
Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары», 1975.

**Гөлсем Мөхәммәдова**

# ЯШЬЛЕК КӨННӘРЕ

**2**



Шәкертләр җыелып бетмәгәнлектән, укулар әле башланмаган иде. Шуның өчен иртә намазга тормаска, туйганчы йокларга булдылар. Ләкин иртүк кемнеңдер үгез кебек үкерүеннән бөтен мәдрәсә уянып китте.

— Ни булды икән? — дип урыннарыннан калыктылар, куркынып колак салдылар.

Бу тавыш Галимҗаннарга янәшә чаршау артыннан ишетелә иде. Күп тә үтмәде, әшәке сүз әйтеп сүгенгән, шаркылдап көлешкән, дөбер-шатыр иткән аяк тавышлары ишетелде.

Шәһит сикереп торып утырды:

— Анда ниндидер кызык бар! Әйдә карыйк әле! — дип, Галимҗанга төртте. Иптәше җавап биреп өлгергәнче, чаршауның читен күтәреп, башын сузды. Күрше бүлемдә кичә эскәк белән сакал-мыекларын йолкыган егет түшәк өстендә, биленә кадәр ялангач килеш, куллары белән култык асларын угалый-угалый, белгән ни бар ләгънәтләрен әйтеп сүгенеп-тиргәнеп утыра иде.

— Илаһым, сират күперен кичә алмыйча егылып төшегез дә тәмуг утында яныгыз! Аллаһы тәгалә сезгә якты көн күрсәтмәсен! — диде дә, ата-бабасын калдырмыйча, әшәке сүзләр тезеп китте.

Иптәшләре шаркылдашып көлештеләр. Берсе:

— Пишкадәм дигән атың бар, ә үзең, урыс кебек, култык астында йон үстереп йөрисең! Сакал-мыегыңны йолыкканчы, култык асты йоннарыңны йолкыр идең,—диде.

— Култык асты кешегә күренми ич, ә менә сакал-мыек үсеп китсә һәркемгә күренеп тора! — дип сүз кыстырды икенчесе.

Мәдрәсәдә күпме шәкерт булса, барысы шушы чаршау тирәсенә җыелган. Шаулашалар, ыгы-зыгы киләләр, алгарак үтәргә, ни булганын үз күзләре белән күрергә тырышалар.

Ике бармак киңлегендәге каешны буйга ярып ясалган ике телле камчысын тотып, Заһидулла хәзрәт килеп керде. Ул мәдрәсәнең назире булса да, аңа ни өчендер «хәзрәт» дип эндәшәләр иде. Ул — Вәли мулланың уң кулы. Мәдрәсәдә низам-интизамны[1] саклау бөтенләе

Ахыры. Башы журналыбызның беренче санында.

[1] Низам-интизам — эчке тәртип.

белән аның кулына тапшырылган. Заһидулла хәзрәт камчысын селтәп, бер шартлатып алды да:

— Ни бар монда?! — дип кычкырды.

Шәкертләр тынып калдылар. Хәзрәттән курка иде алар. Ул күп тикшеренеп тормый, камчысын гына уйната. Өелешеп торган шәкертләрне ыра-ера чаршау эченә керде. Анда биленә кадәр ялангач утырган пишкадәм Галине күреп, ачуы тагын да кабарды.

— Бу нинди мәсхәрә! Оятың бармы! — дип җикереп, камчысын күтәрә башлады.

Пишкадәм, куркып, тиз генә юрганына уранды, рәнҗүле тавыш белән зарланырга кереште:

— Мин йоклап ятканда, Гобәйдулла култык астыма керосин сөртеп, ут төрткән. Әлегә кадәр әрни, чыдар хәлем юк.

Галинең әләкләвен ишеткәч, Гобәйдулла тиз генә кулына түгәрәк ясинын алды. Ясинны күргәч, Заһидулла хәзрәтнең камчы күтәрергә кулы бармас дип уйлады ул, чөнки ясин корьәннең иң хөрмәтле сүрәсе; бу сүрә адәм баласы дөньяга килгәндә аны каршы алырга, дөньядан киткәндә озатырга тиеш икән.

Гобәйдуллага түгәрәк ясинны язарга кичә көндез кендек әбисе Мәрфуга тутай тапшырып киткән иде. Ул зур бер табак кәгазь өстенә агач фәргабә[1] белән түгәрәк сызып, шул сызык буена корьәннән ясин сүрәсен күчерә башлаган иде. Күчереп бетергәч, кәгазьнең буш калган урта җирен түгәрәкләп кисеп алачак. Шул рәвешчә күчерелгән ясинны шәкертләр «түгәрәк ясин» дип йөртәләр. Дөньяга яңа килгән баланы әнә шул түгәрәк уртасындагы тишектән уткәрәчәкләр. Имеш, бу — аны күз тиюдән, җен зәхмәте кагылудан һәм башка авырулардан саклый икән. Түгәрәк ясин Мөхәммәтгариф байның якын көннәрдә бәбиләргә тиешле яшь хатыны өчен кирәк икәнен белгәч, Гобәйдулла, гадәттәгедән артыграк бәя куеп, алты тиен өстенә ике күкәй дә сораган иде.

Чыннан да, Гобәйдулланың кулында түгәрәк ясинны күргәч, Заһидулла хәзрәт камчысын кире төшерде. Күзләрен акайтып, Гобәйдуллага усал бер караш ташлады да тирә-яктагы шәкертләргә:

— Монда сезгә ат кәмите бармы?! Хәзер үк юк булыгыз! — дип акырды.

Заһидулла хәзрәтнең камчысы уйнамавы түгәрәк ясин сәбәбеннән генә түгел иде. «Ясинны куй!» — дип бер кычкырса, әлбәттә, Гобәйдулла аны өстәл өстенә куярга мәҗбүр булыр иде, шуннан соң хәзрәт шәкертне теләгәнчә ярыр иде. Ләкин мәдрәсәнең баш мөдәррисе Вәли мулла аңа зуррак шәкертләрдән ун-унике кешене баз казырга җибәр дип кушкан иде. Ә мәдрәсәгә әле шәкертләр килеп бетмәгән, зур шәкертләр санаулы гына иде. Хәзер бу итагатьсезгә суксаң, аркам авырта дип сылтау итәчәк тә бармаячак. Барса да эшләмәячәк. Хәзрәт шуларны уйлады. Ачуын басарга тырышып:

— Әрәмтамакланып ятканчы, зур шәкертләрне җый да Вәли мулла җәнабларының йортына бар. Миңлебай суфига әйт: келәттән кирәкләр, балта, пычкы бирсен. Анда баз казырга, утын кисәргә кирәк булыр. Мөдәррисегезгә эш күрсәтсәгез, хәер-фатихасын алырсыз, саваплы[2] булырсыз,— диде.

Гобәйдулланың һич тә барасы килми иде, чөнки кичкә кадәр ул түгәрәк ясинны күчереп бетерергә тиеш. Башка бер сәбәп тә таба алмагач:

— Әле без чәй дә эчмәгән...— дип башлаган иде, хәзрәт аның сүзен кырт кисте:

— Тизрәк кузгал! Бер аягың монда, икенче аягың анда булсын!

[1] Фәргабә — циркуль.
[2] Савап — алла каршында яхшылыклы булу.

Чәй эчми эшләсәгез дә, үлмәссез! Савабыгыз артыр! Зур шәкертләрнең бөтенесен дә җыеп алып бар!..

Гобәйдулла чыгып киткәч, Заһидулла хәзрәт пишкадәм Галигә ябырылды:

— Оят түгелме сиңа? Тәнеңдә кяфер кебек йон үстереп йөрисең! Әллә дәһри[1] булдыңмы? Үзең бүген-иртәгә указлы мулла булырга йөрисең, ә үзең мөселман шәригатенә хилаф[2] булган эшләр эшлисең, ялангач утырасың...

— Тәкъсир! Мин кичә күлмәгемне юган идем. Кибеп өлгермәгәч, күлмәксез яткан идем...

Галинең ялварулы тавышы, аска карап кына әүлия[3] кыяфәте белән утыруы хәзрәтнең күңеленә хуш килде, ләкин сүзен бүлдергәнне яратмады:

— Зурлар сөйләгәндә ихлас күңел белән тыңларга кирәк! Әгәр пишкадәм булмасаң, бу итагатьсезлегең өчен камчы ашаган булыр идең. Синең бу гаепләреңне Вәли мулла җәнабларына әйтсәм, соңы ни белән бетәчәген уйлыйсыңмы?! Аллаһы тәгалә каршындагы гөнаһларыңны йолып алыр өчен өч көн эчендә корьән шәрифне бер тапкыр укып чык! Сиңа җәза шул!

Заһидулла хәзрәт тырпаеп торган озын кашлары астыннан төссез күзләре белән егетне тишәрдәй булып карап алды да чыгып китте. Гали исә, Шәһит куйган самавардан чәй эчкәннән соң, тәһарәт алып, корьәнне көйләп укырга кереште. Кем белә, бәлки Заһидулла хәзрәт тагын кереп тикшереп йөрер. Бик явыз кеше бит ул...

## 3

Быел ураза декабрь аена туры килде. Тышта чатнап торган коры суык. Урамга чыксаң, авыздан төтен төсле булып бу бөркелә, кашкерфекләргә бәс утыра. Каты кар аяк астында шыгыр-шыгыр килә. Шунысы яхшы: көннәр кыска. Дөнья яктырып өлгерми, инде кич тә җитә. Мондый кыска көннәрдә ураза тоту да җәйнең эссе көннәрендәге кебек авыр түгел!

Иртәгә рамазан ае дигән көнне ике хатын килеп, балалары чирләгән чакта әйткән нәзерләрен үтәү өчен, мәдрәсәнең тәрәзәләрен, идәннәрен юдылар, киезләрен кагып, тузаннарын сөртеп, хәзрәтнең хәерфатихасын алып киттеләр. Мәдрәсә яктырып, матурланып киткән кебек булды. Черек, сасы исләр бетеп, һавасы да сафлана төште.

Былтыргы тәҗрибә буенча Галимҗан яхшы белә: берәр бәхетсезлеккә очрап нәзер әйткән яки савап өмет иткән хатыннар, рамазан аенда атна кич саен килеп, мәдрәсәне юып, тазартып китәчәкләр. Шәкертләр исә мәдрәсәдә яшәгән Миңлебай суфи карамагында ишегалдындагы карларны көрәп юл ачалар. Укулар да җиңеләя төшә. Бөтен рамазан буена дәресләр булмый диярлек, тик биш вакыт намазга йөрү генә кала. Хәер, башка вакытларда да хәлфәләр дәресне күп булса атнага ике-өч тапкыр гына бирәләр. Калган чакларда шәкерт алган сабагын үз башына тәкърарлап, ятлап яки уйнап, үз эшләре белән шөгыльләнеп үткәрә.

Хатыннар мәдрәсәне тазартып киткәч, Заһидулла хәзрәт шәкертләрне җыеп, вәгазь-нәсихәтен әйтте:

— Рамазан ае — без мөселманнарның иң хөрмәтле ае, чөнки бу айда Мөхәммәде сәлаллаһе галәйһи сәламга Корьән иңгән. Бу айда, фаразан, бөтен мөселман галәме дөньяви эшләрдән ваз кичеп, тәнен пакьләп, ураза тотып, күңелен аллаһы тәгаләгә баглап, намаз-

[1] Дәһри — дин азгыны.
[2] Хилаф — каршы.
[3] Әүлия — алла каршында һич гөнаһсыз кеше.

гыйбадәттә үткәрергә тиеш. Иртәгәдән башлап бөтен шәкертләр таң атканчы, ак җеп кара җептән аерылмый торган мәлдә сәхәргә торып, ураза тотарга, биш вакыт намаздан калмаска тиешләр, фаразан... Бу айның кадер кичәсендә, ягъни рамазан мөбарәкнең егерме җиденче көнендә, күк капусы ачыла. Динендә могаять[1] булган кешеләрнең шул сәгатькә туры килгән догалары күккә ачылган юл белән аллаһы тәгалә хәзрәтләренә барып ирешәчәк. Кадер кичәсендә, фаразан, нәкъ сәхәр вакытында, җир астыннан мөлдерәп агып торган чишмәләрдә су кинәт корып китә, янә ага башлаганда чишмә суына оҗмахтагы кәүсәр елгасының суы кушыла һәм чишмә суы зәмзәмгә әверелә. Зәмзәм суы исә дин әһалисен шайтан вәсвәсәсеннән саклый, төрле авырулардан шифа була...

Галимҗан да, Шәһит тә Заһидулла хәзрәтнең бу вәгазен ихлас күңел белән тыңладылар. Хәзрәтнең һәр сүзенә чын-чыннан ышаналар иде алар.

Ник ышанмасыннар? Бу ышаныч баштанаяк наданлык, җаһиллек галәмәте икәнен каян белсен алар? Алар сүз аңлый башлаган көннәреннән үк «алла», «пәйгамбәр», «дин», «иман», «могҗиза» кебек сүзләрне ишетеп үскәннәр.

Чыннан да, баланың тирә-ягы акыл җитмәслек могҗизалар белән тулган бит. Менә, кечкенә генә орлык тамыр җәя, сабак җибәрә, яфрак яра, чәчәк ата, җимеш бирә. Менә иртән кояш чыгып, бөтен дөньяны нурга күмә, җылыта, кыздыра. Менә әллә каян өерелеп-өерелеп кара болытлар килеп чыга да суга сусаган җирне яшәртеп, коеп яңгыр ява. Болар могҗиза түгелмени?

— Аллаһы тәгаләнең рәхмәте! Ашлыклар уңар. Догабыз кабул булган икән,— ди әнкәсе мондый чакта.

Әнкәсе баланың иң ышанычлы кешесе түгелмени? Шулай булгач, аның сүзенә ник ышанмаска?..

Шулай да Галимҗанның күңелен ниндидер аңлашылып җитмәгән бер хис, тойгы тынычсызлый.

— Безнең Солтанморатта җир төбеннән бәреп чыга торган чишмә бар. Эчә торган суны без шуннан алабыз. Ләкин әткәйнең бервакытта да бу чишмә суы кадер кичәсендә оҗмахтагы кәүсәр суына кушылып зәмзәм була дип сөйләгәнен ишеткәнем юк...

Галимҗанның пышылдап кына әйткән бу сүзен ишеткәч, Шәһит кинәт аңа таба борылды. Чак кына аның өстеннән юрганын тартып алмады. Шәһитнең үз урын-җире булмагач, ул Галимҗан белән бер юрган астында ята иде. Шәһит ни әйтергә белмичә бераз эндәшмичә торды. Аннары:

— Син өйдә чакта ураза тота идеңме? — дип сорады.

Бу сорауга Галимҗан беркадәр гаҗәпләнде. Аның уйларына бәйләнеше юк шикелле тоелды. Шулай да җавап бирүне кирәк тапты:

— Юк. Әткәй миңа ураза тоттырмый иде. Син яшь бала әле, сиңа ураза тоту фарыз түгел, ди торган иде.

Шәһит куанып киткән кебек булды:

— Менә, күрәсең! Заһидулла хәзрәт чишмә суы сәхәр вакытында корый, диде ич. Ураза тотмагач, сәхәргә тормагансыңдыр. Кадер кичәсендә әткәңнең чишмәгә киткәнен белмәгәнсеңдер.

— Бәлки шулайдыр...— диде Галимҗан, тагын уйлана калды. Бераздан соң үзенең ачыкланып җитмәгән уйларына җавап биргәндәй, әйтә куйды: — Әти зәмзәм суын алып кайта торган булса, мин аны кайчан да булса бер күргән булыр идем. Без чирләгән чакларда әнкәй аны безгә эчерер иде. Беләсеңме нәрсә? Авылга кайткач, әткәйдән сорармын әле. Безнең әткәй үзе дә мулла.

[1] Динендә могаять булу — динендә бик нык булу, бик нык тору.

Шушы фикергә килгәч, Галимҗан беркадәр тынычланган кебек булды. Ләкин башына тагын бер уй килде.

Шәһит, аның уйларын бүлдереп:

— Бу Оренбург тирәсендә дә җирдән бәреп чыккан берәр чишмә юкмы икән? Кадер кичәсе көнне сәхәр вакытында торып зәмзәм суы алып килер идек, малай! — диде.

Галимҗан эндәшмәде.

— Әллә йоклыйсыңмы, Галимҗан? — дип сорады Шәһит.

— Юк, йокламыйм. Андый чишмә булса, Заһидулла хәзрәт үткән ел пишкадәмнәрне алып барган булыр иде. Мин башка нәрсә турында уйлыйм әле...

— Нәрсә турында?

— Заһидулла хәзрәт әйтә: кадер кичәсендә күк капусы ачыла, ди. Мөселманнарның теләге шул вакытка туры килсә, күкнең ачык капусы аркылы аллаһы тәгаләгә барып ирешә, ди. Әллә башка вакытларда мөселманнарның теләге аллаһы тәгаләгә барып ирешмиме икән? Күк капусы башка вакыт ябык, тик кадер кичәсендә генә ачыла, ди бит.

Галимҗанның бу сүзенә Шәһит тә аптырап калды. Чыннан да, шулай диде шул!.. Әллә башка вакытларда күкнең зур капусы ябык булса да, мөселманнар өчен ян капусы ачык торамы икән?

Шул турыда уйланып ята торгач, малайлар йоклап киттеләр.

## 4

Галимҗанның мәдрәсәгә килгәненә дүрт ел үтеп китте.

Ул, иртәнге намазга бармаска дип, кичтән үк уйлап яткан иде. Шулай да бик иртә уянды. Күзләрен ачмыйча гына уң ягына әйләнде. Әмма мәдрәсәдә купкан тавышлар аңа йокларга бирмәде. Ул торып утырды. Шәһит тә уянган иде.

— Әллә намазга барырга уйладыңмы? — дип сорады ул.

— Юк. Барам дисәң дә, тәһарәт алырга нәүбәт җитмәс. Ишетмисеңме, ничек комган өчен талашалар анда! — диде Галимҗан.

Шәһит, кара күзләрен елтыратып, хәйләле кыяфәт белән:

— Җылы юрган астыннан чыгып, бозлы су белән юыну бер дә кызык түгел шул! Кайберәүләр тәһарәт алмыйча да намазга баралар ич! Әллә күрмәдеңме? — диде.

Галимҗан нидер уйланып җавап бирми торды, аннары гына:

— Беләм, күргәнем бар,— диде.— Күрше бүлемгә күчкән Габдулла да күп вакыт тәһарәт алып өлгерми. Ашыгып-кабаланып киенә дә башкалар артыннан мәчеткә чаба. Тик бу язык эш бит!..

— Язык казык башында, ә савап алла каршында! Мәчеткә барып намаз укыгач, барыбер савапны була ул! — диде Шәһит көлеп һәм торып аягына басты. Иптәшенең җавап биргәнен дә көтмичә:— Халык намаздан кайтканчы, пишкадәмнәргә самавар кайнатып өлгертәсем бар,— дип, тәбәнәк өстәл өстеннән кәләпүшен алып киде дә чыгып китте.

Инде артык йоклап булмаячагын аңлагач, Галимҗан да торып урын-җирен җыештырды, ишегалдына чыгып, битен-кулын юды, уртак казаннан су алып килде. Шул арада тавышланып шәкертләр мәчеттән кайта башладылар. Бераздан соң, эшләрен бетергәч, кулына пешкән ике бәрәңге тотып, Шәһит тә әйләнеп кайтты.

Бүген хәлфәнең сабак бирми торган көне иде, шуңа күрә ике дус, көн буе намазга бармыйча, «Хөсәения» мәдрәсәсеннән алып кайткан «Әлфе ләйли вә ләйлә» [1] китабының тузып беткән битләрен иләп кенә ачып, укый башладылар.

---

[1] «Мең дә бер кичә» әкиятләре.

Бу әкиятләр шундый кызыклы икән, «Намазга! Намазга!» дигән тавышлар ишетелгәч кенә, Галимҗан белән Шәһит өйлә вакыты җиткәнен аңладылар.

Өйлә намазыннан соң һәркем үз ихтыярында: теләсә йоклый, теләсә саф һава сулап урамда йөреп кайта, акчасы булганнар, базарга барып, тегене-моны сатып ала. Олырак шәкертләр акча табар өчен бәти, шәмаил, түгәрәк ясиннар, тәлинкә читенә зәгъфран кара белән догалар язып маташалар. Кайберәүләр, берәр мәдрәсәгә моназара кылышырга барам, дигән булып чыгып китәләр дә таң алдыннан гына алҗып, хәлсезләнеп түшәкләренә кайтып авалар.

Галимҗан белән Шәһитнең боларда һич эшләре юк иде. Назир Заһидулла хәзрәтнең көн буе мәдрәсәдә булмавыннан файдаланып, бәлки ястү намазына чаклы да бу мавыктыргыч әкиятләрне укыган булырлар иде, ләкин түбән каттагы ашханәдән килгән тәмле аш исе аларның борыннарына керде. Бары тик шунда гына алар карыннары тәмам ачыккан булуын сизделәр.

— Синең дә ашыйсың киләме? — дип сорады Шәһит иптәшеннән.

— Ник килмәсен? Иртәнге ике бәрәңгедән башка авызыбызга бер кабым ризык тимәде бит! — диде Галимҗан.

— Ни эшлибез? Ашарга бер әйберебез дә юк ич!

Галимҗан алдындагы китапның битләрен теләр-теләмәс кенә җыештыра башлады.

— Шакирҗан абзый янына барып килик. Бәлки биш-ун тиен табып бирер,— диде. Шуннан соң:— Әйдә киттек,— дип, урыныннан кузгалды. Башка вакытны Галимҗан абыйсы белән очраша да йомышын йомышлап чыгып китә, бу мәдрәсә шәкертләре белән артык аралашмый иде. Бүген Шакирҗан мәдрәсәдә юк, каядыр чыгып киткән иде. Абыйсын көтәргә туры килде. Шакирҗанның якын дусты Салих Фәхретдинов иптәшенең энесен кунак итеп чәй куйды. Күңеллерәк булсын өчен тагын бер-ике шәкертне чәйгә чакырды. Галимҗан, соңгы вакытта үзләштергән гадәтенчә, түзә алмады: «Тукта әле, боларның кирәген бирим, арт сабакларын укытыйм әле, югыйсә, танауларын бик югары күтәрәләр!» — дип уйлап, Шәһитнең кабыргасына төртте. Янәсе: «Кызык күрсәтәм!» Аннары шәкертләргә карап:

— Гыйльме бәлфигыльме, әллә гыйльме бәлкуввәтен тугрымы? — дигән сорау ташлады.

Шәкертләрнең берсе сабыр гына тавыш белән:

— Бу — кирәк вакытта китаптан гына караумы, яки укып, тикшереп белү тугрымы? дигән сүз була. Минемчә, әлбәттә, кирәк фәнне укып, тикшереп белү, күңелеңә сеңдерү яхшырак,— дип җавап кайтарды.

Мәдрәсәгә килгәненә бишенче ел гына булуына карамастан, Галимҗан бу вакыт эчендә укылган китапларны гына түгел, алдагы биш ел дәвамында укылачак «аять» [1], «хәдисләр»нең [2] мәгънәсен аңлата торган тәфсир китапларын да өйрәнеп җиткән иде.

Хәзер ул, иптәше Шәһит белән бик тырышып, Заһидулла хәзрәттән мантыйк китаплары буенча сабак ала, моназара кагыйдәләрен өйрәнә иде.

Шундый тырышлыклары, зирәклекләренә сөенеп, хәзрәт бу ике шәкертне мәдрәсәнең баш мөдәррисе һәм хуҗасы Вәли муллага да мактап бетерә алмый иде. «Мактау әүлияны да раздыра», диләр бит. Бик мактала торгач, «җиңелмәс моназарачы» дигән шөһрәте дә арта баргач, Галимҗан үзен бик белдекле, артык акыллы итеп саный башлады. Хәзрәттән ишеткәнчә, ул: «Мантыйк кануннарын яхшы белгән

[1] Аять — корьәннең аерым бер җөмләсе.
[2] Хәдис — пәйгамбәр сүзе.

кеше теләсә нинди фәнне мөгаллимнән укымыйча да, үз көче, үз башы белән үзләштерә ала»,— дип уйлый иде.

Чыннан да, менә бит тәфсир хәдис, тәфсир аятьләр корьәннең һәм хәдисләрнең тулы тәрҗемәсе булмыйча, тик аларны шәрехләү генә икән. Шуны аңлагач, алар Шәһит белән икесе остазларына мөрәҗәгать итмәделәр, чөнки остазлары үзе дә гарәпчәнең тик кагыйдәләрен генә белә, ә гарәп теленең үзен рәтләп төшенми икән. Алар камус, әхтәриләр һәм башка китаплар табып, гарәп телен үзбаш өйрәнделәр. Димәк, башыңда акылың булса, мантыйк кануннары буенча уйлый белсәң, остаздан сабак алып утырмыйча да, теләгән фәнне үзләштерергә мөмкин, тик тиешле китабын табып, укып чыгарга гына кирәк!

«Хөсәения» шәкертенең җавабын ишеткәч, Галимҗан: «Менә хәзер миңа юл ачылды! Менә хәзер мин боларга күрсәтәм!» — дип, үзенең мәдрәсәсендә көн-төн ишетеп, күңеленә иман шарты кебек сеңгән фикерне уртага ташлады:

— Һәрбер гыйлемне, һәрбер фәнне тикшереп, остаздан укып утыру, аңа вакыт сарыф итү һич кирәк түгел! Сезнең төп хатагыз шунда! Әгәр сез мантыйкны тиешенчә үзләштерсәгез, аның бөтен кануннарын, бөтен кагыйдәләрен белсәгез, башка фәннәрне остаздан укымыйча, китаптан бер карап чыгу белән дә белергә мөмкин!

Теге шәкерт хәйләкәр кыяфәт белән маңгай астыннан гына Галимҗанның күзләренә текәлде дә:

— Сез мантыйкны тиешеннән дә артык беләсез икән. Афәрин! — диде.— Алай булгач, бәлки сез безгә мантыйк васитәсе белән шуны аңлатып бирерсез: туры почмак, кысынкы почмак, җәенке почмак дигәннәре нәрсә икән ул һәм бу почмакларның бер-береннән аермасы нидән гыйбарәт икән?

Галимҗан, әлбәттә, бу сорауга җавап бирә алмады. Шәкертнең мондый сорау бирүе хаксыз кебек тоелды аңа. Аның чын-чыннан ачуы килде. Һәм ул тавышын күтәрә төшеп, кычкырып җавап кайтарды.

— Мин бит сезгә мантыйкны белгән кеше һәммә фәннәрне дә зиһенендә тота дип әйтмәдем, билгеле бер фән буенча остаздан сабак алмаса да, тиешле китапка карап кына да кеше бу фәнне аңлый ала, дидем.

Тик хуҗа шәкертләр, моңа карап, сабырлыкларын җуймадылар. Галимҗан белән бәхәсләшеп утырган теге шәкерт:

— Мантыйк ярдәме белән мин моңарчы үземә мәгълүм булмаган, укымаган фәнне китабын карап чыгу белән үк аңлыйм, дидегез. Шулай түгелме? — дип сорау бирде.

— Әлбәттә, шулай! — диде Галимҗан. Шуннан соң бу шәкерт, Салихка карап:

— Салих, китер әле һәндәсә белән җәгърәфия китабын,— диде.

Салих бу китапларны китергәнче, Галимҗанга тагын бер сорау биреп өлгерделәр:

— Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам Мәккәдә туды, соңра Мәдинәгә һиҗрәт кылды, димез. Бәлки сез җәгърәфия китабындагы хәритәгә[1] карап, бу шәһәрләр дөньяның кайсы тарафында, кайсы мәмләкәттә, кайсы җирдә икәнен күрсәтеп бирерсез?

Галимҗан мантыйк кануннарын ничаклы исенә төшерергә тырышса да, Салих кулыннан алган китапларның битләрен нихәтле актарса да, шәкертләр биргән сорауларга җавап таба алмады. «Әллә чыннан да, һәрбер фәнне укып, тикшереп кенә белергә мөмкинме икән? Мантыйк кануннары гына җитмиме икән?» — дип уйлый башлады ул. Шулай да җиңелгәнен танымса, сүзен бирәсе килмәде:

---

[1] Хәритә — географик карта.

— Камус бирегез! Бу китаплардан түгел, камуска карап җавап бирермен! — дип кычкырды да кулындагы һәндәсә китабы белән җәгърәфияне өстәл өстенә ташлады.

Моңа каршы «Хөсәения» шәкерте:

— Кызык кеше сез, Галимҗан мәхдүм! — диде.— Әгәр нинди дә булса мәҗлестә сез белмәгән фәннән берәр сүз чыкса, шул чакта камуслар, әхтәриләр каян алырсыз икән? Югыйсә, һәркая үзегез белән калын-калын камуслар, әхтәриләр күтәреп йөрерсезме? — дип, җилкәсен сикертеп куйды.

Көтелмәгәндә шулай җиңелү Галимҗанны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Ул, хәтта абыйсы Шакирҗанның кайтканын да көтмичә, мәдрәсәдән чыгып китте. Шәһитнең аны юатып әйткән сүзләре колагына кермәде. Башын түбән иеп, уңга-сулга карамастан, үз уйларына баткан хәлдә атлавын белде.

«Дөресен әйткәндә, мин бит чыннан да аларның сорауларына җавап бирә алмадым. Моны үз-үзеңнән яшереп булмый шул! — дип үз алдына сөйләнде ул.— Хәтта биргән китапларын актарып, берничә битен укып чыксам да, бер нәрсә аңламадым. Ә харитә дигәнен әйтәсе дә юк! Авылда ике класс урысча укыганда да безгә җәгърәфия дигән фәнне укытмадылар, харитә күрсәтмәделәр. Аңлашыла: ул харитә дигән нәрсәгә карап кайда, нинди шәһәр барлыгын белергә мөмкин икән. Шулай ук мантыйк кануннарының ярдәме белән дөньядагы бөтен фәннәрне дә белеп булмыймы икәнни?.. Булса, ник җиңелдем соң мин? Әллә мин мантыйк кагыйдәләрен тиешенчә белмимме?..»

Шушы шөбһәләрне хәл итәр өчен, ул Шәһиттән:

— Әллә без мантыйк кануннарын яхшы өйрәнмәдекме икән? — дип сорады.

Юл буе сөйләшми барган Галимҗанның тавышын ишеткәч, Шәһит сискәнеп китте, иптәшенең ни сораганы аның зиһененә тиз генә барып җитмәде. Галимҗан соравын кабатларга мәҗбүр булды. Шуннан соң гына Шәһит:

— Син нәрсә сөйлисең, Галимҗан?! — диде.— Без бит «Исагуҗи»дән башлап, «Шәмсия», «Сәлам», «Тәһзиб»ләрне «Мулла Җәлил»ләргәчә укыдык. Бу китапларны яттан диярлек беләбез!

— Мантыйкны яхшы белсәк, ни өчен соң мин бүген шәкертләрнең сорауларына җавап бирә алмадым?

Шәһит ни дияргә дә белмәде. Галимҗан, үзе көткән җавапны ишетмәгәч, соравын тагын кабатлады:

— Әллә чыннан да мантыйк ярдәме белән генә дөньядагы бөтен фәннәрне дә белеп булмыймы икән?

Шулай сөйләшә-сөйләшә, алар ни өчендер шәһәрнең нәкъ уртасындагы Деев мәйданына килеп чыктылар. Шул вакытны Габделгани, Мәхмүт бай Хөсәеновларның мал складлары ягыннан казачилар пәйда булды. Атларга атланган, билләренә озын кылыч таккан, аркаларына мылтык аскан, кулларына камчы тоткан бу солдатларның кыяфәтләре яшь шәкертләргә бик дәһшәтле күренде. Галимҗан белән Шәһит, ихтыярсыз, баскан урыннарында туктап, катып калдылар. Хәер, алар гына түгел, бу вакытта урамдагы бөтен кеше гаҗәпләнеп туктап калган иде. Әнә, аякларына аю тиресе каплап, матур чанага утырган, каракүл якалы, каракүл бүрекле бай әфәндәнең кучеры да, дилбегәне тартып, атын туктатырга мәҗбүр булды. Бер-ике минут эчендә мәйданның тирә-ягында утыз-кырыклап кеше җыелды. Һәркем, тәшвишләнеп, бу казачиларга күзләрен төбәделәр.

Галимҗаннарның артына килеп туктаган берәү:

— Бу башкисәрләр кая баралар икән? — дип сорады.

Икенче бер тавыш:

— Кая булсын?! Тозтүбәгә җибәргәннәрдер бу җәлладларны. Анда шахтерлар тагын баш күтәргәннәр, көненә ундүрт сәгать эшләп, утыз-кырык тиен генә алып утырырга риза түгелбез! Эш көнебезне, һич югында, ун сәгатькә калдырыгыз, эш хакыбызны арттырыгыз дип эш ташлаганнар, имеш,— дип җавап бирде.

Беренчесе тагын сөйли башлады:

— Дөрес әйтәсең, Фәйзерахман, болар җәлладларның нәкъ үзе инде! Бу казачи дигәннәрнең арасында безнең татарлар да бар икән. Ничек итеп, алладан курыкмыйча, бу динсезләр белән бергә, үз мөселманнары өстенә кул күтәрәләр икән? Ул Тозтүбәдәге шахтерларның да яртысыннан күбе татар белән башкортлар ди бит...

Фәйзерахман исемлесе казачиларга карап бераз эндәшми торды да:

— Эш мөселманлык-урыслыкта, динле-динсезлектә түгел шул, Нурмөхәммәт дус! — диде.— Алар бит ата-бабаларыннан алып шушы көнгәчә вөҗданнарын сатып килгәннәр. Үзең уйлап кара: безнең татар авылларында җан башына ярты дисәтинә җир тисә, хуҗалыкта бер генә аты булса, безнең мужик: ничек тә көн күреп булыр, әле ачтан үлмәбез, алла бирсә,— ди. Ә бу сатлык җаннарга патша җан башына алтышар дисәтинә җир, әллә ничә төрле җиңеллекләр биргән. Ә алардан бер генә таләп: безнең кебекләр тормыш авырлыгына түзә алмыйча әзрәк баш күтәрә башласа, шуларны камчың белән яр, кылычың белән кис, мылтыгың белән ат, үтер! Быел март аенда Уфа губернасында булган хәлләрне ишетмәдеңме?

— Нинди хәл булган соң анда?

— Менә болар кебек башкисәр җандармнар егерме сигез кешене атып үтергән, унҗиде кешене авыр җәрәхәтләгәннәр. Алары больницага барып җитмичә үлгәннәр. Кырык ике кеше җәрәхәтләнеп больницага кергән. Инде шушы көннәрдә аларга суд булачак, имеш...

— Мондый хәбәрләрне син каян белеп бетерәсең?! Безнең заводның урысы-татары сине «безнең Шәмсетдинов адвокат ул!» дип зрәгә әйтмидер шул...

Нурмөхәммәтнең бу сүзенә каршы Фәйзерахман җавап кайтармады. Тик казачи отряды үтеп киткәч кенә, ул:

— Вакытны бушка үткәрмик, әйдә, киттек! — диде дә, шәкертләр яныннан узып, мәйдан аркылы каршы якка чыга башлады. Аның артыннан иптәше Нурмөхәммәт тә иярде.

Моңарчы шәкертләр, бу кешеләрнең сүзләрен тын да алмыйча тыңлап, хәтта артларына әйләнеп карарга да кыймыйча торганнар иде. Тик яннарыннан узып киткән чакта гына Галимҗан аларны күреп калды. Артларыннан караганда икесе дә киемнәре, башларындагы козыреклы фуражкалары белән гади урыс эшчесеннән бер дә аерылмыйлар иде. Әгәр Галимҗан бу ике кешенең үзара татарча сөйләшкәннәрен ишетмәгән булса, аларны урыс дип белгән булыр иде.

— Кара әле! Эш ташлаучылар урынына башка эш эзләүчеләр табылмыймы икән? Эшләми йөргәч, аларга теге утыз-кырык тиенне дә бирүче юктыр инде. Шулай булгач, алар ничек көн күрә икән? — диде Шәһит, әлеге шахтерлар өчен борчылып.

Галимҗан аның соравына ничек дип җавап бирергә дә белмәде. Чыннан да, тик торганда, эшләмичә йөргәндә хуҗа акча бирәме икән?! — дип уйланды ул. Әлеге Шәмсетдиновның «Тормыш авырлыгына түзә алмыйча баш күтәргәннәрне, эш ташлаганнарны бастырыр өчен менә шушы җәлладларны җибәрәләр!» — дигән сүзе аның исенә төште. Моннан ул үзенчә бер нәтиҗә чыгарды һәм иптәшенә:

— Ул Тозтүбәдә эш ташлаганнарның саны бик күп булырга тиеш. Аларны бастырыр өчен, күрмисеңме, күпме гаскәр җибәрәләр! Ул эшчеләр урынына шул ук санда яңа эшчеләр табып булмый торгандыр,— диде.

Бу җавап Шәһитне канәгатьләндермәде. Галимҗан үзе дә Шәһитнең канәгатьләндерерлек җавап бирмәгәнен аңлый иде. Шәһит соравын тагын кабатлады:

— Алар, көненә утыз-кырык тиен генә безгә аз, эш хакыбызны арттырыгыз, дип әйтәләр ди бит. Эшләмәгәч, аларга бу утыз-кырык тиенне дә бирми торганнардыр. Шулай булгач, алар ничек көн күрә икән?

— Менә бит, Шәһит дус, бу сорауга да мантыйк ярдәме белән генә җавап таба алмыйм,— дип, Галимҗан күңелсез генә көлемсерәп куйды.

Үзенә бик кирәкле нәрсәне югалтып, аны таба алмый йөргән кеше төсле, ул күңелендәге гаҗизлектән котыла алмый иде. Бу тойгы аны борчый, тынычлык бирми, эзләнергә мәҗбүр итә иде.

## Көрәш башланды!

### 1

«Хөсәения»дә җиңелеп кайтканнан соң, Галимҗан мәдрәсәдәге моназараларга катнашмый башлады. Читтән торып, тәнкыйть күзе белән карасаң, бу моназараларның нихәтле мәгънәсез булганы ачык күренә икән. Моңарчы мантыйк дәресләрен мавыгып укыган, һәрбер моназарага җилкенеп катнашкан Галимҗанның бу эшләргә дәрте көннән-көн сүнә барды. Кулларына акча эләккәч үк дуслар җәгъръфия һәм һәндәсә китаплары сатып алдылар. «Хөсәения» мәдрәсәсендәге моназарада үзенең хаксыз булганын аңлагач, ничаклы авыр булса да, Галимҗан анда яңадан барып үзенең хаксызлыгын танырга мәҗбүр булды. Моннан соң ул «Хөсәения» шәкертләре белән хәтта дуслашып та китте.

Бу сасы мәдрәсәдән киң дөньяга чыгып, кешеләр белән аралашып йөрсәң күп нәрсә күрәсең, ишетәсең, беләсең икән. Менә бүген дә Галимҗан белән Шәһит «Хөсәения» шәкертләреннән тагын бер яңа хәбәр ишеттеләр. Казан каласындагы кузгалышлар башында безнең татар егетләре дә бар, имеш. Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов дип исемнәрен дә әйттеләр. Бу кешеләр үзләре башта татар мәдрәсәсендә укыган булганнар, аннары мәдрәсәне ташлап, русча укыганнар, ди. Университетка керергә хәзерләнәләр икән...

Бу хәбәрне ишеткәч, Шәһит:

— Их, малай, егет булсаң әнә шундый бул икән! — дип куйды.

Галимҗан:

— Хак сүзгә җавап юк! — дип кенә әйтте.

«Хөсәения» мәдрәсәсеннән кайтышлый юл уңаенда китап кибетенә кергәннәр иде, анда тагын бер яңа хәбәр: Хәсән Рәхимов заводында да, Хөсәеновларның тегермәннәрендә дә ялчылары эш ташлаганнар! Бу хәл Казанда гына түгел. Оренбургта да башланган икән! Болар да:

— Без инде хайван дәрәҗәсенә барып җиттек! Якты көн күрмибез. Иртә таңнан кара төнгәчә эшлибез, ә үзебез дә, балаларыбыз да ач-ялангач. Артык түзәр хәлебез калмады! Сигез сәгатьтән артык эшләмибез. Безгә эш хакы арттырылсын! — дип әйтәләр икән.

Мондый хәлләр көн саен арта бара, ди. Инде көн саен диярлек урамнарда күк буяу белән язылган кәгазьләр ябыштырыла. Боларга прокламация дип әйтәләр икән. Кайвакыт татарча язылганнары да очрый, ди. Городовойлар ертып ташлаганчы укып өлгерсәң, монда да дөньядагы гаделсезлек, тигезсезлек, хезмәт ияләренең ни өчен шулай изелүләре, җәберләнүләренең сәбәпләре турында әйтелгән, якты киләчәк юлында патша хөкүмәтенә каршы көрәшкә өндәгән сүзләр язылган, ди...

Кибеттән чыгу белән, дуслар тагын яңа бер хәлгә тап булдылар: як-якка озын итеп салындырып бәйләгән билбаулы, бик җилле күренгән урыс егетләре:

Прощай, Нюра, Нюрочка,
С оборочкой юбочка...

— дип гармун уйнап, урам яңгыратып җырлап баралар иде. Бер-ике квартал үтәр-үтмәс, татар мәхәлләсенә керү белән, инде бер төркем татар яшьләре:

Мәскәү, Питербур янсайде,
Солдат алу калсайде!

— дип, бүрекләрен кыңгыр салып, күкрәкләрен киереп җырлап баралар!

Халык арасында бүген булмаса иртәгә япон безгә каршы сугыш ачачак икән, дигән хәбәр йөри. Шуның өчен быел солдатка каралачак егетләрнең күңеле бик тәшвишле иде.

Алар: «Шулай ук безне җәһәннәм утына — сугышка куарлармы икән, яшь башларыбыз шунда калырмы икән? Алай булса, хәзер диңгез тубыктан! Бер нәрсәдән курыкмыйбыз, кулыбыздан килсә Мәскәвен дә, Питербурын да яндырабыз!» — дигән хыялый дәрт белән җырлыйлар, ләкин бу эш кулларыннан килмәячәген үзләре дә яхшы беләләр иде.

Галимҗан иптәшенә карап сөйләп китте:

— Күрәсеңме? Кая карама, шунда көрәш, һәркем үзенең тормышын яхшыртырга, туры юлга куярга тырыша. Безгә дә берниндән дә курыкмыйча көрәш ачарга кирәк. Һәрнәрсә кечкенәдән башлап зурая бит! «Хөсәения» шәкертләреннән үрнәк алырга кирәк безгә! Аларның мәдрәсәләрендә тормышта кирәк була торган фәннәрне генә түгел, хәтта урыс телен укытсалар да, алар тагын да күбрәкне телиләр. Мәдрәсәдән чын мәгънәсе белән укымышлы, мәгърифәтле, халкыбызга файдалы кеше булып чыгарга омтылалар. Ә бездә нәрсә? Һаман шул «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд» [1], «Әнмүзәҗ», шул ук мантыйк. Һаман шул иске мунча, иске таш! Бер яңалык юк!..

Шәһит тә дустының сүзенә кушылып әйтеп куйды:

— Ә үзебез:

Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән һәм калыкты.
Уян, шәкерт, шәкерт, уян!
Уянырга вакыт җитте!

— дип җырлаган булабыз тагын!..

— Бөтен бәла да менә шунда. Балкыган кояшның кечкенә генә бер нуры да безнең мәдрәсәнең тәрәзәсен яктыртмый әле!

Шәһит кинәт көлеп җибәрде. Галимҗан, гаҗәпләнеп, аңа кырыс кына күз ташлады:

— Ни булды сиңа?

— Хәтерендәме? Теге көнне син Заһидулла хәзрәттән: «Нигә сез безгә корьәннең үзен аңларга өйрәтмисез, тик аерым аятьләрен тәрҗемә итмичә генә аңлатасыз?» — дип сорагач, ул сиңа: «Иҗтиһад мөнкариз! [2] Харам! Имам әгъзамның сүзләренә ышанмыйм, дисеңме? Дәһри!» — дип кычкырып, аз гына мендәрләре өстеннән тәгәрәп төшмәде! Шул хәтеремә килде.

---

[1] «Шәрхе Габдулла», «Кавагыйд» — гарәп теленең кагыйдәләрен өйрәтә торган китаплар.

[2] Иҗтиһад мөнкариз — кешегә киң мәгълүматлы булу ярамый, ягъни иҗтиһад заманы үткән, искеләр сүзеннән чыгу ярамый.

— Бу — көлке түгел, фаҗига! Имеш, адәм баласына белем хасил итү ярамасын! Моннан да зур торгынлык булырмы? Ни өчен Вәли мулла да, Заһидулла хәзрәт тә яңалыкка шулай каршы торалар дип уйлыйсың?

Галимҗан сүзен бүләргә мәҗбүр булды, чөнки бүлмәгә ике пишкадәм кайтып керделәр. Алар, үзара кычкырып сөйләшә-сөйләшә, чаршаулары артына керделәр дә актарына башладылар.

Боларның берсе Галимҗан бу мәдрәсәгә килгәннән бирле түгәрәк ясин, шәмаил, догалыклар язып, җеназаларда мәет күтәреп алган сәдакаларына яшәүче, ә соңгы вакытта укуын тәмамлап, пишкадәмлеккә чыккан Гобәйдулла иде. Икенчесе — киләсе елда гына мәдрәсәне бетерәчәк Габдулла дигән шәкерт иде.

Арада тик юка чаршау гына булганлыктан, Галимҗаннар, теләсә-теләмәсәләр дә, боларның сүзләрен тыңларга мәҗбүр булдылар.

— Кая гына куйдым икән? Әллә берәрсе чәлдеме?

Бусы Гобәйдулла тавышы иде.

— Яхшырак кара әле. Син аны сандыгыңның төбенә үк куйган идең бугай. Әйберләрең арасына кереп буталгандыр,— дип, Габдулла җавап кайтарды да:— Ишеттеңме? Гайса байның карт хатыны бик каты авырый икән,— дип өстәп куйды.

— Әй, сөйләмә әле! Ул хатын-кыз җеназасыннан алай бик күп төшми. Менә Рәхмәтулла бай бик каты чирләп ята. Менә шул бай үзе үлсә, апаңның туе кебек булыр иде! Исеңдәме, моннан ике ел элек Габделгани бай үлгәндә ничек булган иде? Безнең мәдрәсәдән генә Вәли мулла хәзрәтләре әткәсенең җеназасына кырык шәкерт алып барды. Сәдакасы кеше башына бер тәңкәдән туры килде. Каберстаннан кайткач та, күрше йортка алып кереп, туйганчы ашатканнар иде! Рәхмәтулла бай үлә калса, килере шул кадәр үк булмаса да, кеше башына илле тиеннән ким тимәс иде. Ә, менә таптым! Җилән кесәсенә салганмын икән!

— Тапсаң, әйдә, тизрәк киттек, югыйсә, соңга калабыз!— дип, Габдулла иптәшен ашыктыра башлады. Ләкин Гобәйдулланың Рәхмәтулла бай турында әйткән сүзләре аңа бик тәэсир иткән иде булса кирәк. Ишеккә барып җиткәч, Габдулла, туктап, Гобәйдуллага таба борылды да:

— Илле тиен аз акча түгел ул, урамда аунап ятмый! Тизрәк үлеп китсә, чыннан да бик әйбәт булыр иде,— диде.

Ишек шап итеп ябылганлыктан, Гобәйдулланың җавабы ишетелмәде.

Вәли мулла мәдрәсәсендә алты ел укып, Галимҗан мондый вөҗдансызлыкка өйрәнә алмады. Имеш, берничә тиен акча төшерү өчен кешеләргә үлем телә! Галимҗанны бу хәл рәнҗетә дә, нәфрәтләндерә дә иде. Бер тиен акчасыз калып, атналар буе каткан ипи кисәге кимереп яшәгән чаклары күп булды, ләкин кулын сәдакага сузмады, ифтарларга йөрмәде, чиратын башкаларга бирде. Гобәйдулла белән Габдулла чыгып киткәч, Галимҗан куе кашларын җыерып, Шәһиткә карады:

— Күрдеңме?! Менә ул безнең мәдрәсәнең житештергән җимешләре! Боларда инсаниятлек [1] калмаган. Болар соры кортлар! Берсе янтыгын кашыса: «Кесәсенә тыгылды, миңа сәдака бирергә тели бугай»,— дип, кулын сузып көткән теләнчеләр болар!..

— Минемчә, Габдулласы аның җасус та. Заһидулла хәзрәт аны Гобәйдулла янына бушка күчермәде, махсус безне күзәтер өчен күчерде. Кибеттән алган китапларыңны кая куйдың? Тагын бу җасусның күзенә эләкмәсен,— диде Шәһит.

Галимҗан күлмәген күтәреп, ыштан эченә кыстырган ике китапны күрсәтте. Боларның берсе Шакир Мөхәммәдовның «Җәһаләт яки

---

[1] Инсаниятлек — кешелек.

Галиәкбәр агай» дигән китабы, икенчесе шул ук кешенең «Яңа бәдәвам»ы иде. Китап кибетендә: «Бу китаплар җәһаләттән бик усал көләләр, мәгърифәткә өндиләр»,— дигәч, Галимҗан аларны бик куанып алган иде.

— Заһидулла хәзрәт «Хисаметдин менла»ны сандыгымнан табып, ертып ташлагач, мин мондый китапларны әйберләрем арасында тотмыйм, тышта берәр төшкә яшереп куям,— диде Галимҗан.

Бу китапларны укып чыккач, алар үзләренә фикердәш кебек булып күренгән шәрикләренә дә биреп укыталар иде. Тирә-юньдә шикләнерлек кешеләр күренмәгәч, караңгы төшкәнче укып алыйк дип, китапның берсен мантыйк эченә тыгып, икенчесен тагын бер дәрес китабы эченә куеп укый башладылар.

## 2

Икенче көнне Галимҗан белән Шәһит һәм аларның шәрикләре Заһидулла хәзрәткә, мантыйк дәресенә керергә тиешләр иде. Соңгы вакытларда мантыйк укымаган шәкертләр дә: «Тагын нинди кызык булыр икән?» дип, хәзрәтнең бүлмәсеннән ерак китмәскә тырышалар иде.

Шәкертләр дәрескә кергәндә, хәзрәт инде өч кат мендәр өстенә менеп, аякларын бөкләп утырган иде. Кулында мәшһүр камчысы булмаса да, тез өстенә аркылы куйган озын чыбыгы бар иде.

Шәкертләр хәзрәт алдына тезләнеп утырышу белән, Галимҗан мөгаллимнәренең сүз башлавын да көтмәде.

— Сез һәр вакыт: мантыйк белгән кеше башка фәннәрне укымыйча да белә,— дип әйтәсез. Бүген мин үзем белән гарәпчә язылган «Мәкамәт Хәрири»[1] китабын алып кердем. Мондагы газидәләрнең[2] берсен генә булса да мантыйк ярдәме белән безгә укып аңлатсагыз икән,— дип, китапны хәзрәткә сузды.

Галимҗан белән Шәһит төрле сүзлек, камус һәм башка китаплар ярдәмендә гарәп әдәби телен яхшы ук өйрәнгәннәр иде инде. Шунлыктан «Хөсәения» мәдрәсәсеннән алып килгән бу китапны укып аңлау аларга авыр булмады. Әмма хәзрәтнең газидәне укып шәкертләргә аңлатырлык белеме юклыгына Галимҗанның ышанычы камил иде.

Заһидулла хәзрәт, киресенчә: «Мантыйк белгәч, моны гына белермен әле. Кирәген бирим әле бу азгынның»,— дигән кыяфәт белән китапны Галимҗан кулыннан алды.

Шәкертләр: «Мантыйкны белсәң, чыннан да башка нәрсәләрне укымыйча да беләсеңме икән?» — дип тынып калдылар.

Заһидулла хәзрәт китапны кычкырып укырга керешкән иде,— ике-өч сүздән соң ук туктап калды, чөнки бу китапта, корьәндәге кебек, тартык авазлы хәрефләрне сузыкка әйләндерү өчен куела торган билгеләр — хәрәкәләр юк иде.

Шәкертләр бер-берсенә төрткәләп, авызларын җиңнәре белән каплап, хихылдаша башладылар. Моны сизеп алган хәзрәтнең җен ачулары чыкты:

— Сез ахмаклар! Әгәр кулымда «Әхтәри», «Камус» булса, монда язылганнарның барысын да мин сезгә укып, аңлатып бирер идем!..

— Димәк, сез үзегез укыта торган гарәп телендәге газидәне төшенер өчен сезгә мантыйк кына җитми, тагын «Әхтәри»ләр, «Камус»лар да кирәк икән. Китапның бер газидәсен укыр өчен үзең белән бергә

[1] Мәкамәт Хәрири — Хәрири шигырьләре.
[2] Газидә — маҗара, берәүнең башыннан кичкән вакыйгалар.

калын-калын «Әхтәри»ләр, «Камус»лар сөйрәп йөрмәссең бит! — диде Галимҗан, аның сүзен бүлеп.

Шәкертләр инде ачыктан-ачык көлешә башладылар. Галимҗанның әлеге сүзләрен, шәкертләрнең мыскыллы көлүләрен ишеткәч, хәзрәт бөтенләй котырып китте:

— Итагатьсез! Шәкертләрне аздырырга уйлыйсыңмы?! Үзең кебек дәһри итмәкче буласыңмы?! Мин сиңа кирәгеңне бирермен!! — дип, чыбыгын күтәреп, Галимҗан өстенә ташланды. Галимҗан чыбыкны тартып алды да, тез өстенә куеп, сындырып ташлады. Мәдрәсәдә моңарчы күрелмәгән бер хәл иде бу.

Хәзрәт ахыргы чиккә җитте. Куллары, тезләре бушап, калтырана башлады, хәтта мендәрләре янына барырлык та хәле калмады. Басып торган урынында лып итеп шәкертләр арасына, киез өстенә утырды. Яшь этәч тавышлары чыгарып, тотлыга-тотлыга:

— Бәд... дога сиңа! Бәд... дога!! — дип, кулларын күтәреп, кәҗә сакалын селкетеп, ниләрдер пышылдады да кул аркасы белән дога кылды.

Бәддога! Шәкертләр тынып калдылар. Аларның күңелләрен әйтеп бетергесез хафа, курку басты. Менә хәзер күк күкрәп, дәһшәтле яшен яшьнәп, аяк өстендә басып торган Галимҗанны орачак та көлен күккә очырачак! Алар бер Галимҗанга, бер мөдәррисләренә карап, шул фаҗигане көтәләр иде. Ләкин вакыт уза, ә Галимҗанга һаман бер нәрсә дә булмый. Ул әүвәлгечә аяк өстендә басып тора иде.

Ниһаять, Галимҗан шәкертләргә карап, кырыс тавыш белән:

— Нәрсәдән курыктыгыз? Хәзрәтнең бәддогасыннанмы? Күрәсез, бер нәрсә дә булмады һәм булмаячак та. Бу — бер ат кәмите генә! — диде.

Бу сүзне ишеткәч, Заһидулла хәзрәт утырган урыныннан сикереп торды, зәһәрле караш белән Галимҗанны баштанаяк сөзеп чыкты да, таягын алып, ишеккә юнәлде.

Хәзрәт чыгып китү белән, шәкертләр арасында шау-шу күтәрелде. Алар шундук Галимҗанны урап алдылар. Кайберләре борчулы тавыш белән:

— Инде ни булыр икән? Вәли муллага шикаять итәргә киттеме икән? — диделәр.

Икенчеләре:

— Әмма да авызын каппадың, ә! Ни әйтергә белми калды. Егет син, Галимҗан! — дип Галимҗанны якладылар.

— Алла сакласын, бәддогасы кабул була күрмәсен! Безнең башка да төшмәсен! — диючеләр дә булды.

Бу сүзләргә Галимҗанның ачуы килде:

— Җаһил хәзрәтләрнең һәрбер дога-бәддогаларын, аларның ахмак теләкләрен тыңлап, башкарып утырудан гайре алланың мөһимрәк эше юк микәнни? Сез бүтән нәрсә турында уйлагыз! — дип сөйли башлады да соңгы вакыттагы гадәтенчә кызып ук китте:— Ничә еллар укып, без бу мәдрәсәдә нинди белем алдык? Бар белгәнебез: намаз, җеназа уку, никах, талак, истинҗа... Без, шәкертләр генә түгел, безне укыткан мөдәррисләребез дә шуннан артыкны белмәгәннәрен һәр көн күреп торабыз! Мәдрәсәне хәтме кетеп иткәч [1], без кем булып чыгачакбыз. Теләнче кебек, сәдакага яшәүче җаһил мулла булыпмы? Сезне шул канәгатьләндерәме? Халкыбызга юл күрсәтүче, ярдәмче булабыз дисәк, безгә тормышта хаҗәте булган фәннәрне дә укырга кирәк. Безнең мәдрәсәләр торгынлык, кадимчелек учагы түгел, мәгърифәт, мәдәният учагы булырга тиеш! Димәк, безгә ислах кирәк! Ислах булмаса, без

[1] Хәтме кетеп иткәч — мәдрәсәне тәмамлагач.

һаман да шул халкыбыз җилкәсен кимерә торган соры кортларның берсе булып калачакбыз, әмма халкыбызны җаһиллек, торгынлыктан якты дөньяга алып чыгучылар була алмабыз! Ислах кирәк дигән ышанычыгыз нык булса, һичбер нәрсәдән курыкмыйча, бөтен көчегезне куеп көрәшергә кирәк!

Ул күп сөйләде. Аның бөтен теләге — шәкертләр арасында ислах фикерен тарату, аларны шул юлда көрәшкә өндәү, кадимчелекне бәреп егу иде.

Мондый хәлләрдән соң Заһидулла хәзрәт Галимҗанны үз көче белән генә җиңә алмаячагын аңлады. Вәли мулла алдында үзенең көчсезлеген күрсәтергә теләмәсә дә, көннәрнең берендә аның белән бу турыда киңәшергә булды.



## 3

Түрдә тап-такыр итеп кырган башына Бохара дуппысы, өстенә кар кебек ак күлмәк, кыска җиңле, биш билле кара камзул кигән, бик пөхтәләп кискән кара сакаллы Вәли мулла утыра. Аның каршысына, мескенләнеп, Заһидулла хәзрәт урнашкан. Идәнгә, келәм өстенә җәелгән ашъяулык читендәге самавар янына тезләнгән кызыл фәсле унике-унөч яшьлек малай боларга чынаяклары бушаган саен чәй ясап бирә. Ашъяулык өстендә Казандагы Килдишевлардан махсус заказ белән алдырылган казылык, өйдә пешкән күмәч, кәрәзле бал, атланмай...

Читтән караганда, бу ике кеше арасында тыныч кына әңгәмә барадыр кебек. Сүзләре ашыкмыйча, салмак кына агыла шикелле. Ләкин Вәли мулланың да, Заһидулла хәзрәтнең дә күңелләре тыныч түгел.

— Заманалар бозыла бара. Дөнья фетнә белән тулды. Бу азгынлык безнең мәдрәсәгә килеп кагылмас дип уйлаган идем...

Вәли мулла кара эш күрмәгән симез, йомшак бармаклары белән хаҗелектән[1] алып кайткан тәсбихенең төймәләрен берәм-берәм тарта башлады. Заһидулла хәзрәткә бу сүзләр: «Мәдрәсәнең бөтен эчке низам-интизамнарын синә ышанып тапшырган идем, әмма ышанычымны аклый алмадың!» — дигән төсле тоелды. Вәли мулланың тел төбендә чыннан да шул мәгънә бар иде. Заһидулла хәзрәт, үзенең гаебен таныган төс белән, башын түбән иеп, бераз эндәшмичә утырды. Аннары, күзләрен күтәрмичә генә:

— Шулай азып китәр дип кем уйлаган аны! — диде.— Ул бит иң инсафлы, иң итагатьле, тырыш, зирәк шәкертләрдән иде. Башта мантыйк дәресләрендә, моназараларда аңа җитешкән кеше юк иде. Хәзер исә ни остазын тыңлау, ни итагать күрсәтү! Үзенә фарыз итеп алган сыман, кичәсе-көндезе ачкан авызын япмый. «Җитәр, күп йокладык, уянырга күптән вакыт! Безгә ислах кирәк!» — дип, үзеннән олы шәкертләргә генә түгел, остазларына да сүз бирмичә кычкырып утыра...

Вәли мулла, сүзләрен тәсбихенең төймәләре белән беррәттән санаган шикелле, сабыр гына тавыш белән:

— Мәдрәсәдән читкә чыгып йөрүләргә юл куймаска, сак булырга кирәк иде. Мондый саксызлыкның нәтиҗәсе хәзер күз алдымызда,— диде.

Аның бу сүзләре Заһидулла хәзрәт йөрәген тагын да ныграк әрнетте, чөнки болай дию аны турыдан-туры ваемсызлыкта, гамьсезлектә гаепләү иде. Ул үзен акларга тырышты:

— Я, аны ничек чыгармыйсың? «Акчам бетте, бер телем икмәгем калмады. «Хөсәения» мәдрәсәсенә, абыем янына барам, бәлки аңардан биш-ун тиен алып кайтырмын», дип чыгып китә. Кайчак сорамыйча да

---

[1] Хаҗелек — Мәккәгә барып Мөхәммәт пәйгамбәрнең каберендә гыйбадәт кылу.

кача. Аннан җиләне астыннан култыгына кыстырып әллә нинди китаплар алып кайта икән. Аларны үзе генә түгел, башка шәкертләргә дә биреп укыта. Ничә мәртәбә мин аны үзем дә тоттым. Китапларын ертып утка яктым. Әтисе Гыйрфан муллага хат яздым. Кыш уртасында мәдрәсәгә килеп, улын үгетләп китте. Кулымның аркасы белән ул азгынга бәддога кылдым. Бер нәрсә дә тәэсир итми үзенә! Я, тагын ни эшләмәк кирәк?!.

Хәзрәт гадәтенчә кызып китте. Әмма, Вәли мулланың кызу, кабалануларны бик үк яратмаганлыгы исенә төшеп, туктап калды.

Чыннан да, ни эшләргә мөмкин? Бу ахыр заман фетнәсе могтәбәр мөселман әһалисе арасына да җәелеп бара бит!..

Башына шундый уй килгәч, хәзрәт җанланып китте. Хәтта казылыкка сузылырга да җөрьәт итте, чөнки дөньядагы бу фетнәләр бары тик аның ваемсызлыгыннан гына түгел икәнен исбат итәргә юл тапты ул. Казылык кисәген авыз эчендә тәмләп әвәләгәннән соң, сабырлык белән сөйләргә кереште:

— Бая бик дөрес әйттегез, мөхтәрәм Вәли әфәнде: дөнья көннән-көн бозыла бара. Акылы утырып җитмәгән яшь-җилкенчәкләрне бер читкә куеп торыйк. Безнең мөселман дөньясында дан казанган, милләтебезнең нык терәкләре дип хисапланган Рәмиевләр, Акчуриннар, Әхтәмовларны мисал өчен алыйк. Ишетмешем буенча, бу адәмнәр: «Милләтемезне инкишаф иттермәк истәр исәк [1], үз арамыздан урыс телен, исәп-хисапны белгән, дөньяви фәннәрдән хәбәрдар булган кешеләр үстермәк лазымдыр»,— дип, үз балаларын урыс мәктәпләренә бирәләр икән. Мөселман мәдрәсәләрендә дә шундый фәннәр укытмак лазым дип әйтәләр икән...

Бу сүзләрне ишеткәч, Вәли мулла ясалма сабырлыгын югалта төште. Заһидулла хәзрәт мулланың әтисе мәрхүм Габделгани байга һәм аның абыйсы Әхмәт байга ишарә иткән шикелле тоелды. «Әнә, синең үзеңнең атаң һәм атаңның агасы да мәдрәсәләрдә фәнуне җәдиди укытырга кирәк дип, бөтен гомерләре буе шул юлда тырыштылар, акча түктеләр бит»,— дип әйткән кебек булды аңа Заһидулла хәзрәт. Бу сүз аның йөрәгенә тиде. Әткәсе Габделгани бай үлгәч, Ризаэтдин бин Фәхретдин, Фатих Кәрими кебек әфәнделәр Вәли муллага күп тапкыр:

— Әткәгез Габделгани бай үзе исән чакта безгә берничә тапкыр: «Ысуле саутия буенча укыта торган мәктәп-мәдрәсәләрем, мөгаллимнәр хәзерли торган дарелмөгаллиминем үзем үлгәч тә шул юлдагы эшләрен дәвам итсен һәм башка шуның кебек әмәлләрем өчен йөз егерме мең тәнкә васыять итәм», дигән иде. Мәрхүмнең теләген үтәргә кирәк! — дип тартышып карадылар. Ләкин Вәли мулла бирешмәде: «Васыятьнамәсе юк!» — дигән сәбәп табып, бу эшләргә бер тиен дә бирдертмәде! «Шулай булгач, ни дип бу канатсыз карга ишарәләр ясап утыра әле!» — дип уйлап, ул тәсбихен тезенә ташлады, аңгәмәдәшенең йөзенә төбәлеп карады:

— Бик яхшы беләм. Безнең үз арамызда да моның кебек дәһрилеккә ауганнар бар,— диде. Ачуын басарга тырышып, янә кулына тәсбихен алды да төймәләрен тарта башлады. Аннары болай дип дәвам итте: — Бу — диннән дүнмәк димәктер, мөселман галәменнән баш тартып, урыска орылмак димәктер! Мәгыйшәтемезне [2] диннән аермак улмаз! Дин вә мәгыйшәт берлектә бармак лазымдыр. Бу — мәгыйшәтемез динемезнең бөтен кагыйдәләренә буйсынмак кирәк димәктер. Шәкертләремезне менә шул иманда тәрбияләмәк лазым. Әгәр без шул юлымызда сабит булмасак [3], дөньямыз тар-мар улачак!..

[1] «Милләтебезне алга атлатырга, үстереп җибәрергә теләсәк».
[2] Мәгыйшәт — тормыш, көнкүреш.
[3] Сабит булу — тотрыклы булу.

Сүзләремнең мәгънәсе Заһидулла хәзрәтнең миенә ныграк урнашсын дигәндәй, Вәли мулла туктала торды. Хәзрәт исә, аның әйткән һәр сүзенә «ләббәйкә!» дигән сыман, сирәк кәҗә сакалын селкетеп, башын каккалап утырды. Әйтерсең Вәли мулла аның күңелендә сакланган, ләкин ачыкланып җитмәгән томанлы фикерләрен ачыклый, сүзләр калыбына сугып, төгәлли, аныклый иде. Ләкин бу тыштан гына шулай күренә, хәзрәтнең башында бөтенләй бүтән уйлар кайный иде: «Шәкертләр, ислах диеп, исемнәре гомеремдә ишетелмәгән фәннәрне генә түгел, болардан башка фәлсәфәи диния, тарихеләнбия[1] кеби фәннәрне дә сорыйлар. Коръәннең тулы тәрҗемәсен укытыгыз, диләр. Бер ай буена тырышып, камуслар актарып башым катып бетте, әмма коръәннең бер-ике битен дә тәрҗемә итә алмадым. Әгәр фәлсәфәи диния кебек фәннәргә килсәк, мин үзем дә, мәдрәсәдәге башка мөгаллимнәр дә моны булдыра алмаячакбыз. Бу хәл ачыктан-ачык мәйданга чыгачак. Нәтиҗәдә, мәдрәсәдән үкчәне күтәрергә туры киләчәк. Мәдрәсәдән китеп кая барачаксың? Яшең иллегә җиткәндә, Вәли мулла җәнаблары әйткәндәй, бөтен тормышың тар-мар киләчәк!..»

Вәли мулланың сүзе бетте дип уйлап, ул үзе сүзгә башлады:

— Димәк, бердәнбер юл...

Ләкин мулла, кулын күтәреп, аны сүзеннән туктатты.

— Әлхасиле вәл кәлям[2],— диде ул,— без үз мәдрәсәбездә төрле дәһрилеккә, дин азгыннарына юл куймаска тиешбез. Шуны һәм искә алырга кирәк ки: дөньяви фәннәр, замана таләпләре дип, көферлеккә дүнә башлаган, тар чалбар киеп, чәч үстереп маташкан, ислах дип кычкырып йөргән таләбәләр[3] башка төрле гөнаһларга да дучар булмаклары ихтимал. Бәлфараз[4]: хәмер[5] эчеп, зина кылып йөрүләре дә мөмкин... Моңа бу тарафтан да бик сак улмак лазым, чөнки аларның башка шәкертне дә аздырулары бар. Мондый абруйсызлыклар мөселман диненә хилаф улганын шәкертләргә аңлатмак лазым!

Вәли мулла бу сүзләренә аеруча басым ясап әйтте һәм бик мәгънәле итеп хәзрәтнең күзләренә текәлеп карады. Ул һичкемнең исемен атамады, «син шул азгын шәкертне таяк белән кыйна!» — дип тә әйтмәде. Ләкин Заһидулла хәзрәткә шул кадәресе дә җитә калды.

Мәдрәсәгә кайтышлый, ул юл буе уйланып, хуҗасыннан ишеткән кинаяле сүзләр нигезендә төрле планнар корып кайтты һәм билгеле бер карарга килде.

## 4

Заһидулла хәзрәт мәдрәсәгә әйләнеп кайтканда, Галимҗан кунаклары белән чәй эчеп утыра иде. Тәбәнәк өстәл тирәсенә Галимҗан үзе, бергә уйнап үскән балалык дусты, туганнан-туганы Мохтар һәм Мохтарның шәриге Гомәр Нигъмәтуллин белән Шәһит Әхмәдиев утырышканнар иде.

Мохтарның «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга килүенә Галимҗан чиктән тыш шат иде. Аны күргәч, ул үзен дә гамьсез бер бала кебек хис итте. Әти-әниләре, авыл хәлләре турында сорашканнан соң, бала чактагы уеннарын да хәтерләп алды:

— Син, Мохтар, киләсе җәйгә авылга кайтмыйм, дисең. Алай булгач, Вәлиулла бабайның шалканнарын кем белән урлармын икән соң? Аның шалканнары бик уңа торган иде бит!— диде.

---

[1] Тарихеләнбия — пәйгамбәрләр тарихы.
[2] Әлхасиле вәл кәлям — бөтенесен бергә җыеп әйткәндә, кыскасы.
[3] Таләбә — шәкерт.
[4] Бәлфараз — мисал өчен.
[5] Хәмер — исерткеч эчемлек, аракы.

Аның бу сүзеннән Мохтар ихтыярсыз көлеп җибәрде. Шәһит белән Гомәр бу шаяртуның мәгънәсен аңламадылар. Шуның өчен:

— Күңелле бер вакыйга булса кирәк, безгә дә сөйләгез әле,— дип үтенделәр.

Мохтар тагын көлеп җибәрде. Галимҗан исә гадәтенчә елмаеп кына куйды. Ул кычкырып көләргә яратмый, моны әдәпсезлек дип саный иде.

Иптәшләренең үтенеченә каршы Мохтар җавап бирде:

— Без бала чакта, ашау-эчүне онытып, тырышып-тырышып, дүрт көпчәге дүрт эздән тәгәрәп бара торган бер арба ясаган идек,— дип сөйләп китте ул.— Арбабызга ат булып җигелдек тә басу капкасы аркылы авылдан чыгып киттек. Вәлиулла бабайлар җире турысына барып җиткәч, күзебез шалкан өеменә төште. Тирә-юньдә кеше-кара юк иде. Шалкан җиренә атылып кергәнебезне сизми дә калдык. Арбабызга шалкан төядек тә тиз генә кире авылга борылдык. Өйгә кайтып җиткәндә генә бик яман эш эшләгәнебезне аңлап алдык. Караклыгыбыз өчен әткәйләр безгә чыбык ашатачак инде, дибез. Кеше күрмәгәндә дип, тиз генә ындыр ягына сыздык. Шалканнарны шунда печән кибәне астына яшереп куйдык. Соңыннан алып та ашамадык, барып та карамадык. Күрәсез, бик күптәнге, бик борынгы шалкан караклары инде без!..

Мохтар, менә хәзер шалкан урлаган кебек, үзләренең шул вакытта ничек кыланышканнарын күрсәтә-күрсәтә тасвирлап сөйләде. Тыңлап торучыларга бусы бигрәк тә кызык тоелды. Алар кычкырып көлештеләр. Бу тавышны ишетеп, Заһидулла хәзрәт үз бүлмәсеннән чыкты, егетләр янына килде. «Болар бик күңелләнеп көлешеп утыралар. Тукта әле, карарга кирәк: чәй эчәм дигән булып, хәмер эчмиләрме икән?» дигән шик килде аның башына. Дорфа гына итеп Галимҗанның алдындагы чынаягын күтәреп алды да борынына китереп иснәп карады. Юк, кызганычка каршы, аракы исе килми иде. Чынаякны тык иттереп кире өстәл өстенә куйды.

Кунаклар гаҗәпсенеп бер Заһидулла хәзрәткә, бер Галимҗанга карадылар. Галимҗан авыз кырые белән генә көлемсерәп куйды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Шул вакыт ябыклыктан һәр тамыры беленеп торган нечкә муенлы, сулган яңаклы бер шәкерт Заһидулла хәзрәт янына килеп басты. Хәзрәтне үзенә терәк санап, ул Галимҗанны иптәшләре алдында хур итмәкче, тетеп ташламакчы булды. Озын муенын тагын да суза төшеп, карлыккан тавыш белән:

— Галимҗан, вә ма ля фәла? [1] — дип кычкырды.

Галимҗан аңа күтәрелеп тә карамады, башын гына чайкап куйды. Җавап алмагач, шәкерт, төпкә баткан күзләрен акайтып, өстәл янынарак килде.

— Галимҗан, синнән сорыйм, вә ма ля фәла? — дип тагын кычкырды.

Галимҗан, шәкертнең кычкырганын ишетмәгән кыяфәт белән, иптәшләренә:

— Әйдәгез, ашап-эчегез! Аннары азрак шәһәргә чыгып йөрербез дә, соңыннан мин сезне мәдрәсәгезгә озатып куярмын. Монда күрергә, танышырга тиешле нәрсәләр юк түгел,— диде.

Галимҗанның шулай моназарага чакыруны санга сукмыйча игътибарсыз калдыруы хәзрәтнең ачуын бик кабарткан иде, ләкин соңгы сүзләре бераз тынычландырды аны: «Әйдә, чыгып китсен. Бу бик уңай булды әле!» — дип уйлады ул.

---

[1] Вә ма ля фәла — юк нәрсә юк булгач, нәрсә ул?

Төссезләнеп калган керфексез күзләре белән Галимҗанга кырын карады да борылып чыгып китте. Аның планы өлгереп җиткән иде инде.

## 5

Иптәшләрен озаткач, Галимҗан белән Шәһит, китап кибетенә кереп, рус теле грамматикасы алып чыктылар. Үзлекләреннән рус телен өйрәнергә карар кылганнар иде алар.

Мәдрәсәгә кайтып, үз чаршаулары артына керү белән, беренче кайгылары китапны яшерү булды, чөнки хәзрәтнең күзенә элэгә калса, тагын гауга чыгачак, тагын китап ертылып ташланачак. Тышка да яшереп булмый, чөнки китап һәр көн кирәк булачак.

— Көн саен сандыкны актарып тормас инде. Мәмнуг ителгән китапларын бүтән урынга яшерә башладылар дип уйлый торгандыр. Әйдә, бу юлы китапны сандыкка куеп карыйк,— дип, Галимҗан кышлык нәрсәләрен саклый торган кечкенә агач сандыгын ачты. Сандыктагы нәрсәләр үзе куйганча түгел кебек тоелды. Шәһиткә карап: «Сандыкны кемдер актарганга охшый,— диде ул.

— Хәзрәттән башка кем булсын? Кыйраәтханәдән тагын нинди дә булса фетнәле китап алып кайтмаганмы дип тикшергәндер. Карак кермәгәндер әле, керсә дә урларлык нәрсә тапмагандыр! — диде Шәһит.

— Шулай да карап карыйк әле,— дип, Галимҗан сандыгындагы әйберләрен бушата башлады. Шәһит тә аның янына килеп чүгәләп утырды.

Галимҗан иң элек өстә яткан колакчын бүреген читкә алып куйды. Аннары сырган бишмәтен күтәргән генә иде, аның арасыннан бер шешә аракы шуып төште. Яшьләр исләре китеп бер-берсенә карадылар. Ниһаять, Галимҗан телгә килде:

— Моның каян килгәнен аңладыңмы? — диде, кулындагы бишмәтен әйбәтләбрәк төрим дип күтәргән иде, аннан тагын бер хикмәт килеп төште. Карасалар: ялангач марҗа рәсеме! Галимҗанның йөрәге кайнап китте.

— Бар әле, Шәһит, Мөхәммәтҗанны чакырып китер әле, ул дөресен әйтер,— диде.

Мөхәммәтҗан былтыр гына укырга килгән һәм мәдрәсәдәге начар гадәтләрне үзләштереп өлгермәгән ун-унбер яшьлек бер малай иде.

Каушаган Мөхәммәтҗанны Шәһит җитәкләп алып килү белән, Галимҗан аңардан:

— Син бүген кая да булса чыкмадыңмы? — дип сорады.

Малай ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

— Юк, мин беркая да чыкмадым,— диде, үзе һаман Шәһит артына посарга тырышты.

Галимҗан, аның каушаганын күреп:

— Егет кеше батыр булырга тиеш! Син курыкма! Без сине кыерсытмабыз, тик син дөресен сөйлә: без киткәч, монда кемнәр килде? — диде.

— Сез киткәч, монда беркем дә килмәде. Заһидулла хәзрәт белән Миңлебай суфи да каядыр чыгып киттеләр.

— Шулай ук без кайтканчы һичкем булмадымы?

— Янәшә бүлмәдә берничә шәкерт бар иде, аларның бу якка чыкканнарын күрмәдем. Малайлар тышта уйнап йөрделәр.

«Ничек инде бу болай? Имеш, бүлмәдә беркем булмаган... Аракы белән марҗа рәсеме минем сандыгыма үзләре килеп кергәнме икән?! Юк! Малайдан башкача сорарга кирәк»,— дип уйлады Галимҗан һәм Мөхәммәтҗанга карап:

— Шулай ук без кайтканчы беркем дә чаршаулар артына кереп йөрмәдемени? — дип сорады.

Мөхәммәтҗан күзләрен тагы да зуррак итеп ачты:

— Керделәр,— диде ул.— Башта Заһидулла хәзрәт кайткан иде. Соңрак Миңлебай суфи бер төргәк күтәреп кайтты. Алар икәүләп сезнең чаршау артына кереп нидер эшләделәр. Ни эшләгәннәрен мин күрмәдем.

— Аңлашылды! — диде Галимҗан. Мохтар аркылы әнисе җибәргән итле сумсаларның берсен алып, малайга тоттырды да:— Син бар инде, сабагыңны кара,— дип, аны чыгарып җибәрде.

Малай чыгып киткәч, Шәһиткә:

— Әйткәнең дөрес булып чыкты. Хәзрәтнең этлеге икән шул бу,— диде.— Хәер, мин үзем дә шулай уйлаган идем, тик, чыннан да, шулаймы икән дип беләсем килде. Күрерсең әле, берәр сәбәп табып, мәдрәсәдә тентү ясатыр. Минем сандыгымнан бу аракы белән марҗа рәсемен чыгарып, мине шәкертләр алдында мәсхәрә итәргә, абруйсыз итеп күрсәтергә маташа ул! — диде. Шуннан соң:— Инде боларны ни эшләтәбез? — дип сорады.

Шәһит дәртләнеп:

— Давай, малай, без аның үзен мәсхәрә итик! — диде.

— Кычкырма әле! Монда озын колаклар барлыгын онытма! — диде Галимҗан, аны кисәтеп, аннары шыпырт кына:— Дөрес әйтәсең. Икенче тапкыр мондый этлекне эшләмәс! Без боларны аның үз мендәрләре арасына тыгып куйыйк,— дип өстәде.

Уңайлы вакыт табып, кеше күрмәгәндә, Галимҗан белән Шәһит аракы белән рәсемне хәзрәтнең дәрес биргәндә менеп утыра торган мендәрләре арасына яшереп куйдылар.

Төрле йомышлары белән чыгып киткән шәкертләр мәдрәсәгә кайтып беткәч, кинәт тавыш купты. Кемдер әче аваз белән кычкыра, елый башлады. Шәкертләр, ни булды икән? дип куркышып, урыннарыннан сикереп тордылар. Карасалар, коридор буйлап арлы-бирле, ботларына суккалап, Миңлебай суфи йөри икән. Ул:

— Минем берәр тиенләп сәдакадан җыйган дүрт таңкә дә алтмыш тиен акчамны урлаганнар! Йа, ходай, мине шулай рәнҗеткән каракның йөзе кара булсын, кулы корсын! — дип такмаклый, бәддогалар укый иде.

— Бу тагын нинди шау-шу?! Бу нинди ыгы-зыгы?! — дип кычкырынып, бүлмәсеннән Заһидулла хәзрәт тә килеп чыкты.

Миңлебай суфи, күз яшьләрен түгеп, хәзрәт алдына килеп басты:

— Акчамны урлаганнар! Дүрт таңкә дә алтмыш тиен иде! Елдан артык тиенләп җыйган акчам иде!..— дип, тагын бәддогалар тезеп китте.

Чәй кайнату, аш пешерү өчен алып куйган күмерләрне, утын кисәкләрен, ашамлыкларны урлашу шәкертләр арасында бер гадәт булса да, биш таңкәгә якын акча урлау гадәттән тыш җинаять иде. Әлбәттә, бу каракны табарга кирәк, җәзасын бирергә кирәк, югыйсә, «карак», «угры» дигән кара тап гаепсез шәкертләр өстенә дә төшәчәк. Шуның өчен Заһидулла хәзрәт:

— Миңлебай, ишекне биклә! Бер шәкерт тә мәдрәсәдән чыкмасын! Тентү ясарга кирәк! — дип кычкыруга, укучылар бу боерыкны хуплап каршы алдылар.

— Дөрес!

— Тентү кирәк!

— Безнең өстебезгә яла якмасын йөзе кара!

— Намуссыз! — диештеләр.

Галимҗан Шәһитнең кабыргасына төртте:

— Әйтмәдемме мин сиңа?!

Шәкертләрнең барысын да Галимҗаннар бүлмәсенә җыйдылар. Кесәләрен, куеннарын тикшерделәр. Тентүне Зәһидулла хәзрәт белән Миңлебай суфи башкарды. Шәкертләрнең үз яннарыннан бер нәрсә дә чыкмаячагы билгеле булганлыктан, өс-башларын игътибарсыз гына тикшерделәр. Инде аларның ята торган урыннарын, әйберләрен тентү башланды.

Галимҗан әйберләре арасыннан теге куелган нәрсәләр килеп чыкмагач, хәзрәт ни эшләргә белмичә исәнкерәп калды. Сандыктан чыгарып ташланган әйберләрне тагын бер тапкыр күтәреп-күтәреп селеккәләде. Бәлки башка урынга күчереп куйгандыр дип, киезне күтәреп карады, түшәк-юрганны таратып ташлады. Юк! Ниһаять, буен турайта алмыйча, авырткан билен сул кулы белән угалап, уң кулы белән таягына таянды. «Кая гына яшергәннәр икән бу имансызлар?!» — дип уйлап, Миңлебай белән икесе бер-берсенә карашып хәйран калдылар. Чыннан да, алар өчен көтелмәгән хәл иде бу.

Хәзрәт артыннан калмыйча, «Ни булыр икән? Кемнән табылыр икән?» дип кызыксынып йөргән шәкертләр төркеменнән:

— Шөкер ходайга, безнең бүлмәдән чыкмады!

— Башка бүлмәләрдән дә карарга кирәк! Ник тукталып калдыгыз? — дигән тавышлар ишетелде.

Шәһитнең теге мендәрләргә тизрәк җитәсе килә иде. Шуңа күрә ул:

— Әйдәгез, башка бүлмәләргә киттек! — дип, шәкертләрне ыра-ера, каршыдагы Зәһидулла хәзрәт бүлмәсенә омтылды. Тентүне кайсы бүлмәдә дәвам иттерсәләр дә, шәкертләргә барыбер иде. Шуның өчен алар, дөбер-шатыр килеп, сабырсыз Шәһит артыннан атылдылар.

Зәһидулла хәзрәт аракы белән рәсемне үз кулы белән Галимҗан сандыгына куйганга, башка бүлмәләрдән һичбер нәрсә чыкмас, аракыны да, рәсемне дә Галимҗан кая да булса чыгарып ташлагандыр, яки үзенең мехзанына бикләп куйгандыр дип уйлый иде. Шулай булгач, мехзаннарны тикшерү урынына бүлмәләрне тентүдән ни файда? Ләкин бүлмәләрне тентүдән туктасаң, «акча урланды» дигән сүзнең бөтенләй ялган икәне ачылачак. Димәк, тентүне дәвам иттерергә кирәк. Соңыннан, чормага менеп, шәкертләрнең мехзаннарын тентергә кирәк булыр. Шул карарга килгәч, Зәһидулла хәзрәт шәкертләр артыннан китте. Миңлебай суфи да, чепи күзләрен челт-челт йомгалап, бичара кыяфәтендә хәзрәт артыннан иярде.

Һәрхәлдә, житәкчелекне кулдан ычкындырмау кирәклеген хәзрәт яхшы аңлый иде. Ул тирә-ягына каранды да:

— Габдерәхим, Габдулла! Без арыдык инде. Тентүне сез дәвам иттерегез. Мин сезгә ышанам,— диде.

Бу ике олы шәкерт:

— Киез өстеннән төшегез! — дип, хәзрәтнең тентү башлавын көтеп торган укучыларны читкә кудылар. Үзләре идән уртасындагы зур киезнең ике почмагыннан тотып күтәрделәр. Монда да бер нәрсә күренмәде. Ләкин киезне күтәргән чакта, Зәһидулла хәзрәтнең өч кат итеп өелгән мендәрләре авып төште дә, шулар арасыннан аракы шешәсе тәгәрәп чыкты. Шәкертләрнең берсе шешәне шундук эләктереп алды. Үз күзенә үзе ышанмыйча ул:

— Бәлеш! Аракы түгелме бу?! — дип кычкырып ук җибәрде. Шәкертнең кыяфәтендә дә, тавышында да чиксез гаҗәпләнү чагыла иде.

Гаҗәпләнерлек тә шул! Имеш, мәдрәсәдә иң мөтәгассыйб саналган хәзрәтнең мендәрләре арасыннан аракы чыксын әле! Шешә кулдан-кулга күчеп йөри башлады. Кемдер:

— Яхшырак карагыз, бәлки мөхтәрәм хәзрәтнең мендәрләре арасыннан безнең өчен гыйбрәтле тагын берәр нәрсә килеп чыкмасмы? — дип кычкырды.

Карасалар, аннан тагын бер хикмәт: ялангач марҗа рәсеме килеп чыкты. Моны күргәч, Заһидулла хәзрәтне аз гына зыяндаш авыруы тотмады. Йөзләре күгәреп, күзләре акаеп китте, аяк-кулы калтыранып, ул идәнгә ава башлады. Шәкертләр шаркылдашып көлешергә керештеләр.

Шау-шу, кычкырып көлгән тавышлар арасыннан:

— Безнең хәзрәт дөньяның тәмен белә икән!

— Марҗасын ни дип әйтәсең! Карап туймаслык бит!..— дигән сүзләр яңгырады.

Шул вакыт берсе, бер кулына рәсемне, икенче кулына шешәне тотып, җырлый-җырлый биеп тә җибәрде:

Замана ахыры булса ниләр булгай?
Дөньяга төрле-төрле фетнә тулгай,
Муллалар хәмер эчеп зина кылгай...

Кул чабып, сикерешеп, җырга башкалар да кушылды. Бусы инде соңгы чик иде. Заһидулла хәзрәт җан ачуы белән теге шәкертнең өстенә ташланды. Кулыннан шешәне тартып алып, бар көче белән идәнгә ыргытты. Шешә чәлпәрәмә килде. Бөтен мәдрәсә эченә аракы исе таралды. Рәсемне вак-вак кисәкләргә ертып ташлады. «Моны кемнәр эшләгәнен мин яхшы беләм! Бу мәлгуньнәр миннән үз кирәкләрен алырлар әле!» — дип кычкырмакчы булды, ләкин сулышы буылып, тавышы өзек-өзек булып яшь этәчнеке кебек нечкәреп чыкты.

## 6

Бу хәйләнең Галимҗан белән Шәһит тарафыннан оештырылганын хәзрәт бик яхшы белә иде. Ләкин ул: «Бу мәкерне болардан башка һичкем эшләмәгән»,— дип әйтсә, ни өчен шулай уйлаганын исбат итәргә тиеш булачак. Исбатсыз сүзгә кем ышансын? Әмма исбат итәргә мөмкин түгел, чөнки ул вакытта үзенең Миңлебай белән бергә эшләгән хыянәте фаш булачак. Шуның өчен ул, ачуы кайнап ташыса да, әлеге хәлне йомып калырга мәҗбүр булды, хәтта Вәли муллага да җиткермәде. Ниһаять, ярсуын ничек тә басарга юл тапмагач, Галимҗанның әтисенә тагын бер хат язарга булды. Егет өстенә бөтен пычракны түккәннән соң, хатны: «Әгәр улыгыз акылга утырмаса, без аны мәдрәсәдән куарга мәҗбүр булачакбыз. Хәзергә исә сезгә ихтирам йөзеннән генә аны мәдрәсәдә тотабыз», дигән сүзләр белән бетерде.

Гыйрфан мулланың бөтен теләге балаларын халыкка аң-белем таратучы мөгаллимнәр итеп тәрбияләү иде. Уллары мулла булырлар дип уйламый иде ул, чөнки үзе аллага ышанса да, муллалык вазифасыннан авырсына, бу эшеннән тәм тапмый иде. Менә бит, кем уйлар: балалары арасында иң тотнаклы, иң сабыр булган Шакирҗанны күптән түгел «Хөсәения» мәдрәсәсеннән нindидер буталышларга катнашканы өчен куганнар. Оренбургтан алган хәбәрләргә, хатларга карагандa, инде Галимҗан да соңгы елларда укуында бик ихлас түгел, итагатьсезләнеп бозыла бара икән. Ничек боларны акылга утыртырга?! Куелган бөтен көч, бөтен өмет шулай бушка чыгармы икән?!

Мондый уйлар Гыйрфан мулланы никадәр ачындырса да, Оренбургка ул үзе бара алмады. Галимҗанны бик каты орышып озын хат язды: «Авылга кайткан чагында: «Мәдрәсәдә безгә чын мәгънәсендә мәдәниятле, белемле кеше булып чыгарлык фәннәр укытсыннар өчен көрәшәбез», дигән булып, күз буяп, бушбугазланып йөргәнсең икән. Инде билгеле булды! Аракы эчеп, тәмәке тартып, аллага каршы, дингә хилаф булган сүзләр сөйләп, шәкертләрне юлдан яздырып йөрисең

икән! Әгәр аллаһы тәгаләдән курыкмыйча, мөдәррисләреңә итагать итмәсәң, дәресләреңне ихлас күңел белән укымасаң, мин сине, мәдрәсәдән алып, сукага җигәчәкмен, яки сине дә, Шакирҗан абыең төсле, улым итеп танымаячакмын!»

Һәр вакыттагы гадәтенчә, Заһидулла хәзрәт бу хатны да башта үзе укыды. Әчтәлеге үзе теләгәнчә булгач, шатланып Галимҗанга тапшыртты. Галимҗанга исә бу хат бик авыр тәэсир итте. Димәк, әтисе аның изге теләкләрен, яхшылыкка омтылуларын аңламаган, карагруһ Заһидулла хәзрәтнең бөһтаннарына[1] ышанган! Ул бит абыйсы Шакирҗанның да, үзенең дә ни өчен көрәшкәннәре турында авылга кайткан чакларында әтисе белән берничә тапкыр сөйләшкән иде инде!

Әтисенең хатын укыгач, «Хөсәения» мәдрәсәсендә булган вакыйгалар тагын бер мәртәбә аның күз алдыннан кичте.

Күңелләрне боектырып, көн-төн көзге вак яңгыр яуган вакытлар иде бу. Соры күк йөзе, юешлегеннән авыраеп, җиргә шуышып төшкән сыман түбәнәйгән. Аяк асты пычрак. Бик үк суык булмаса да, дымлы һава үзәккә үтеп калтырата...

— Бу һавадан күңелем болгана башлады. Шакирҗан абзый янына барып килим әле. Алар мәдрәсәләренең идарәсенә таләпнамә язып тапшырганнар иде. Ни булды икән? Шуны белеп кайтыйм,— дип сөйләнде Галимҗан.

Ямьсез көн тудырган күңел төшенкелегеннән ничек котылырга белми утырган Шәһит, бу сүзне ишеткәч:

— Мин дә барам! — дип сикереп торды. Галимҗан каршы килмәде.

Мантыйк, моназаралар белән мавыгудан суынгач, аларның мәгънәсез бер нәрсә икәнлеген аңлагач, Галимҗанның күңелендә Шакирҗанга карата кардәшлек җылылыгы, кардәшлек мәхәббәте артты, фикердәшлек хисе дә туды. Алар хәзер ешрак очрашырга тырышалар, очрашкан чакларында үзләренең теләкләре, омтылышлары белән уртаклашалар. «Хөсәения» шәкертләре арасында да Галимҗанның дуслары арта бара иде.

Вәли мулла белән Әхмәт бай арасында якын туганлык булса да, Әхмәт байның «Хөсәения» мәдрәсәсе белән Вәли мулла мәдрәсәсен тиңләштерерлек түгел иде. Монда гаҗәпләнерлек бер нәрсә дә юк: Вәли мулла кадимчелекнең дә кадиме Кышкар мәдрәсәсенең җимеше булса, Әхмәт бай, унтугызынчы йөзнең азагыннан башлап Россия капитализмының үсә баруы нәтиҗәсендә, патша хөкүмәтенең төрле киртәләренә карамастан, капиталын миллионнарга җиткергән татар бае иде. Әнә шул хәл аны «Хөсәения» мәдрәсәсен ачарга мәҗбүр иткән иде. Бу мәдрәсәдә хисап, җәгърәфия кебек фәннәрне укыту гына түгел, рус теле укыта торган махсус өч класс та бар иде. Ләкин, бу яңалыклар белән бергә, татар шәкерте динле, шәригать кануннарына сукырларча буйсынган, олыларның, хуҗаларының сүзеннән чыкмый торган кеше булып тәрбияләнсен өчен, мәдрәсәдә дин дәресләре дә артыгы белән киң куелган иде: монда тәфсире аять, тәфсире хәдисләрдән башка, тарихеләнбия, ислам тарихы кебек нәрсәләр дә укытыла иде. Башта алдынгылык булып күренгән бу программа дөньяда искән яңа җилләр тәэсире белән ашкынган яшь йөрәкләрне инде канәгатьләндерми башлаган иде. Шәкертләр мәдрәсәнең укыту программасы реальное училище яки гимназия программасына якын булуын, мәдрәсәдә институт, университетларга керерлек мәгълүмат бирелсен дип таләп итәләр иде.

Мондый таләпләрне мәдрәсә идарәсе дә, Әхмәт бай тарафыннан билгеләнгән мөтәвәллиләр[2] дә кабул итә алмыйлар һәм кабул итәргә

[1] Бөһтан — яла, ялган.

[2] Мөтәвәлли — бу урында үлгән кешенең васыяте буенча мәдрәсәдәге тәрбия, укыту эшләрен күзәтеп торучы.

теләмиләр дә иде. «Хөсәения» мәдрәсәсе кебек мәдрәсәләрне тудырган төп иҗтимагый-икътисади сәбәпләрне Галимҗан аңламаса да, шәкертләрнең таләпләре нигезендә мәдрәсәдә зур гауга чыгачагын яхшы сизенә һәм шәкертләрнең бу кузгалышына абыйсы Шакирҗан да катнашкач, абыйсы өчен борчыла иде. «Әгәр аларның таләпләрен кабул итмәсәләр, нинди дә булса җәза бируләре, хәтта «гыйсъянчы» дип мәдрәсәдән куулары ихтимал. Шакирҗан абзыйны мәдрәсәдән куылу, әлбәттә, куркытмый, ләкин әткәй абзыйны бик каты орышыр. Аннан да бигрәк: «Бу — синең тәрбияң! Аларны башларыннан сыйпап кына үстерүеңнең нәтиҗәсе! — дип, әнкәйне кыерсытыр», дип уйлады ул.

Галимҗан белән Шәһит «Хөсәения» тирәсенә җыелган халыкны һәм «тәртип саклауны» күзәтеп йөргән унлап полицейскийны күргәч: «Эшләр бик зурдан киткән икән!» — дип уйладылар һәм, беразга тукталып, халык арасында нинди сүзләр йөргәнен тыңларга булдылар. Ләкин аларга берни дә ишетергә туры килмәде, чөнки аларның да, башкаларның да дикъкатен яңа бер нәрсә җәлеп итте: мәдрәсә ишегеннән зурзур төенчекләрен күтәреп утыздан артык шәкерт килеп чыкты; алар әйберләрен ишегалдында өелгән утыннар өстенә китереп куя башладылар. Бу шәкертләр арасында Шакирҗан да бар иде. Абыйсын күргәч, Галимҗан Шәһиткә баш какты да Шакирҗанга таба атлады. Абыйсыннан:

— Ни булды? Ни өчен әйберләрегезне күтәреп чыктыгыз? — дип сорады.

— Мин сиңа әйткән идем бит,— дип аңлатырга кереште Шакирҗан,— без дүрт шәкерт, кырык шәкерт исеменнән язылган таләпнамәгә кул куеп, идарәгә тапшырган идек. Идарә безнең таләпләрне кабул итмәде. Бездән: «Бу кырык шәкерт кемнәр? Югыйсә, кырык шәкерт дигән булып үзегез генә бу сафсатаны уйлап чыгардыгызмы?» — дип кысып сорадылар. Без сүзебездән кайтмадык: «Юк, чыннан да, бу таләпләр кырык шәкерт исеменнән»,— дидек, ләкин беркемнең дә исемен атамадык. «Әйтмәсәгез, сезнең дүртегезне дә мәдрәсәдән куабыз. Барыгыз, уйлап карагыз»,— диделәр...

Шәкертләрнең нинди карарга килүләрен Галимҗан инде сизеп алган булса да, сабырсызланып тагын баштагы соравын кабатлады:

— Я, нинди карарга килдегез? Ни өчен әйберләрегезне күтәреп чыктыгыз?

— Безне мәдрәсәдән кууны рәсмиләштерер өченме, әллә ни эшлик дип киңәшер өченме, мөтәвәллиләрне, аннары тагын берничә алдынгы җәмәгать хадимен чакырганнар. Идарәдәге җыелышка безне кертмәделәр. Анда ни сөйли торганнардыр, без белмибез. Безнең файдага түгелдер дип уйлыйбыз. Иптәшләр: «Сезне кусалар, без дә мәдрәсәне ташлап чыгабыз»,— дип, әйберләрен җыештырдылар да чыктылар. Инде идарәдә нинди карарга килүләрен көтәбез,— диде Шакирҗан.

Галимҗан, «аңлашылды» дигән сыман, башын селекте.

— Карарлары ни булсын? Шул ук булыр, әлбәттә! Кырык шәкертнең исем-фамилияләрен белергә тырышырлар. Сезне сатлык җан булырга өндәрләр,— диде Шәһит.

— Өндәргә калмаган инде. Күрәсең бит, гыйсъянчылар үзләре урынҗирләрен күтәреп чykканнар. Тагын нинди күрсәтү дә әйтү кирәк? — дип көлемсерәде Галимҗан.

Шул вакыт мәдрәсәнең ишеге ачылып, бусагада «алдынгы җәмәгать хадимнәре» саналган Борһан Шәрәф, Фатих Кәрими, мәдрәсәдә рус теле укытучысы Байтирәков һәм тагын бер-ике кеше күренде.

Борһан Шәрәф башкалардан алгарак чыгып басты. Аның беркадәр аптыраганрак, каушаганрак кыяфәте шәкертләрне байлар исеменнән үгетләргә чыгуыннан бераз уңайсызлануын күрсәтә иде.

Ишегалдында бераз таптанып торгач, Борһан Шәрәф сүз башлады:

— Безнең милләтне, гомумән, мөселман дөньясын Европа милләтләре, рус милләте белән тиңләштереп булмый. Алар белән безнең ара житәрлек дәрәҗәдә ерак! Хәзерге вакытта безнең бу мәктәп-мәдрәсәләребез дә байларыбызның һиммәте белән генә яши. Әгәр Әхмәт бай яки аның кебек милләтнең тәрәкъкыйсе өчен янган башка байларыбыз булмаса, «Хөсәения», «Мөхәммәдия» кебек мәдрәсәләребез дә булмас иде. Сез шуңа шөкер итеп, укуларыгызны дәвам иттерергә тиешсез! Байларыбызның шул һиммәтләрен тәкъдир итә алмаган, кадерен белмәгән өч-дүрт шәкерт артыннан иярмәскә тиешсез!.. Без сезнең теләкләрегезне хаксыз дип әйтмибез,— диде Борһан Шәрәф, бераз тын алып торганнан соң.— Алар төп-нигезендә хаклы, ләкин аларны башкачарак куярга кирәк. Һәрбер эшнең, һәрбер хәлнең үз уңайлы вакыты, үзенең урыны, үзенең билгеле бер тәртибе була. Мондый мәсьәләләр әйтелгән минутында ук яки забастовка тәртибендә хәл кылынмый!..

Борһан Шәрәф шактый озак сөйләде. Шәкертләр башта сабыр гына тыңлап торсалар да, ахырда бу бушбугазлык аларны туйдырды. Яңа бер нәрсә дә ишетмәячәкләрен аңлагач, берсе бик тыныч тавыш белән:

— Җитәр! Рәхмәт! Күп сөйләдегез, күп сайрадыгыз, туктасагыз да ярый. Тавышыгыз карлыкмасын, хуҗаларыгыз алдында сайрарга кирәк булыр! — диде.

Мондый мәсхәрәле сүз ишеткәч, Борһан Шәрәф телсез калды. Кулларын җәеп, иңбашларын җыерып, тирә-ягына каранды. Әлеге шәкерт аның яңадан телгә килгәнен көтеп тормады, иптәшләренә карап:

— Мәсьәлә аңлашылды. Яңгыр астында чыланып торудан артык файда юк. Киттек! — дип, үз төенчегенә ябышты.

Шәкертнең шул сүзен генә көткән төсле, соры болытлар тарала башлап, көн яктырып китте, яңгыр да туктады. Полицейскийга сылтау булдырмас өчен, шәкертләр, тавыш-талаш чыгармыйча, төенчекләрен иңбашларына күтәреп кузгалып киттеләр. Галимҗан белән Шәһит тә аларга иярделәр.

«Шулай булырга тиеш тә иде!» — диде Галимҗан, үзенең уйларын йомгаклап. Кулындагы хатка күзе төште. Уйлана-уйлана, әтисенең хатын онытып та җибәргән икән ул. «Әткәй никадәр ачуланса да, рәнҗесә дә, соңыннан безнең хаклы булганлыгыбызны аңлар! Ул бит алай торгынлыкта катып калган адәм түгел!» — дип, үзен тынычландырырга, юатырга тырышты.

Иптәшләре алдында әтисен иске фикерле кеше итеп күрсәтәсе килми иде аның. Шуның өчен ул хатны аларга укытыргамы-юкмы дип икеләнеп торды. Аннары: «Аларга да укытырга кирәк! Заһидулла хәзрәтнең никадәр түбән, пычрак бәндә икәнен тагын бер тапкыр күреп нәфрәтләнсеннәр!» — дигән карарга килде.

Бу вакытта инде Галимҗан белән Шәһит тә тирәләренә егермегә якын фикердәшләрен — кадимчелек баткаклыгыннан котылырга кирәклеген аңлаган шәкертләрне туплап өлгергәннәр һәм бу берләшмәләренә «Иттифак» дигән исем дә биргәннәр иде.

Хатны, күпчелек кеше ахшам намазына киткән арада, буш калган бер бүлмәгә кереп укыдылар. «Иттифакчы»ларның Хәмит исемлесе, йодрыгы белән тезенә сугып:

— Шундый карт башы белән ялганлап кеше өстенә пычрак түгәргә оялмадымы икән бу хәзрәт?! — дип кычкырды.

Илле тирәсендәге Заһидулла хәзрәт унҗиде-унсигез яшьләрендәге бу егетләргә бик карт булып күренә иде.

Госман атлысы да Хәмиткә кушылды:

— Кара син аны! Бу хынзыр [1] хыялындагы ни бар пычракны синең

[1] Хынзыр — дуңгыз.

башка аударган икән! Әллә караңгы жирдә тотып, кеше күрмәгәндә яхшы гына ишәбезме үзен?..

Госманның ачудан ычкынган бу сүзенә каршы Галимҗан кулын гына селекте һәм Госманның әйткәнен, рәхәтләнеп көлеп, шаяру дип кабул иткән иптәшләренә:

— Ислахны урам малайлары кебек кыйнашып түгел, көрәшеп алырга кирәк,— диде; бераз уйланып торды да:— Хәзер без генә түгел, бөтен Русия көрәшә,— дип өстәде.— Инде хәзрәтнең шундый бөһтаннар язуына килсәк, минем аңа исем китми. Бу аның кулыннан бик килә торган эш икәнен үзегез дә беләсез. Мине әткәйнең бу бөһтаннарга ышануы бик өркетә. Ул бит акны карадан аера алмаслык кеше түгел. Вакыты белән, һичшиксез, ул бөтенесен дә аңлар, ләкин, ләкин...— дип көрсенеп куйды Галимҗан.

— Нәрсә «ләкин?» Заһидулла хәзрәтнең бәддогасыннан курыкмадың, әткәңнең бәддогасыннан куркасыңмы әллә? — дип ачулана башлады аны Госман.

Галимҗан аңа кырыс кына карап куйды:

— Синнән мондый сүз ишетермен дип уйламаган идем. Бәддогалардан курыксам, «иттифак»лар оештырып, иптәшләрне ислах юлында көрәшкә чакырып йөрмәс идем,— диде ул.

Госман әйткән сүзләреннән кайта башлады:

— Син, дус, ачуланма, тик, «ләкин, ләкин» дип көрсенеп куйгач, ничектер уйламыйча, ихтыярсыз ычкынып китте бу сүзләрем. Мин бит синең сүзеңдә нык тора торган егет икәнеңне яхшы беләм!

— Әйе син уйлап сөйлә! — дип кисте Галимҗан. Шулай да аның ачуы басыла төшкән иде инде.

Шәһит тә сүздән читтә калырга теләмәде:

— Мондый бөһтаннарга юл куймас өчен безгә үз таләпләребезне мәдрәсә алдына куярга вакыт түгелме? Безнең «иттифакчылар»ның саны хәзер егермегә якын. Әгәр эшне ачыктан-ачык алып барсак, бәлки безнең якка кушылучылар тагын табылыр?

— Менә бу дөрес сүз! Шуннан башларга да кирәк иде, «куркасыңкурыкмыйсың»нан түгел! Куяннар курыксын, мин куян түгел! Бәддогаларыннан да, мәдрәсәдән куууларыннан да курыкмыйм. Бөтен дөньяда тик Вәли мулла мәдрәсәсе генә түгелдер әле! — диде Галимҗан.

Шәһит, шикләнебрәк:

— Моннан кусалар, «абыйсы гыйсъянчы иде, бусы да шул», дип, сине «Хөсәения» мәдрәсәсенә алмаслар бит,— дип сүз кыстырды.

— Мәдрәсәләр бер Оренбургта гынамы? Башка шәһәрләрдә дә бар ич. Әнә, Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ысул җәдит, хәтта рус телен дә укыталар икән.

— Әткәң ярдәм итмәсә, ничек көн күрерсең соң? — дип әйтеп куйды Хәмит.

— Менә, Шәһитнең ярдәм итә торган әтисе дә, әнисе дә юк, ә моңарчы ачтан үлмәде ич. Җәй көне казакъ арасына китеп балалар укытырмын, я башка берәр эшкә ялланырмын. Мәдрәсәгә кайткач, шул алган хезмәт хакыма яшәрмен, юрганыма карап аягымны сузармын,— дип җавап бирде аңа Галимҗан.

— Сине моннан кусалар, мин дә бу мәдрәсәдә калмыйм! — диде Шәһит.

— Юк, Шәһит дус, алай булмый! — диде Галимҗан.— Шуны бел: карагруһларны җиңмичә, мәдрәсәдә фәнүне җәдидә укытыла башламыйча, мин үз ихтыярым белән бу мәдрәсәдән чыгып китмәм! Әгәр инде куып чыгарсалар, икенче мәсьәлә. Ул вакытта безнең «иттифакчылар»ның берсе дә үз ихтыяры белән мәдрәсәне ташлап чыкмаска, ислах юлында ахырга кадәр көрәшергә тиеш. Югыйсә, монда һаман шул инсанның рухын үтерә торган, яшьләрнең гомерен заегъ итә торган

козгыннар оясы булып калачак. Бу турыда баштан ук сүз килешеп куярга кирәк!

— Син китсәң бик күңелсез булыр шул миңа... Ләкин ни чара? Ә таләпләребезне кайчан язабыз?

— Калган эшкә кар ява,— диде Галимҗан шундук.— Без дә эшне соңга калдырмыйк. Авылга кайтыр вакыт җитеп килә. Алдагы уку елына кадәр сузмыйк. Иртәгә ахшам намазына бармыйча, бөтенебез бергә җыелыйк. Аңа кадәр мин таләпләребезне бер тәртипкә тезеп язып куярмын...

Икенче көнне, ахшам намазына китәсе кешеләр китеп беткәч, «иттифакчылар» тентү вакыйгасыннан соң «маржалы бүлмә» дип йөртелә торган бүлмәгә җыелдылар. Күпчелек бүген сүз ни турында булачагын белә иде, чөнки мәҗлес хакында хәбәр таратканда:

— Вәли муллага үзебезнең таләпләребезне тапшырачакбыз,— дип аңлатканнар иде.

Галимҗан, санаган төсле, иптәшләрен берәм-берәм күздән кичерде дә:

— Һади белән Исхак күренми, әллә аларга әйтелмәдеме? — дип сорады.

Арадан кемдер:

— Алар шүрләделәр, ахры. Тәһарәтсез булсалар да, мәчеткә киттеләр,— дип җавап кайтарды.

— Ни өчен шулай эшләгәннәрен үзләреннән сорашып белербез.— диде Галимҗан, кашларын җыерып.— Хәзергә мәҗлесебезнең төп максатына күчик. Үзебезнең таләпләребезне язып Вәли муллага тапшыру турында ни дисез?

Шәкертләр арасында тавыш күтәрелде:

— Язабыз!

— Тапшырабыз!

— Җитәр, күп түздек!

Шау-шуны басар өчен Галимҗан кулын күтәрде:

— Аңлашылды. Каршы кеше юк икән. Шулай булгач, вакытны бушка уткәрмик. Халык намаздан кайтып җиткәнче эшне бетерергә кирәк. Шуның өчен үзебезнең таләпләребезне мин алдан язып, әзерләп килдем. Әгәр кушасы фикерләрегез булса, яки минем язганнарым сезгә ошамаса, әйтерсез,— дип, кулындагы кәгазьне Хәмиткә сузды:— Син укып бир әле шуны, мин үзем дә читтән торып тыңлап карыйм.

Хәмит кәгазьне алды да иплә кенә Заһидулла хәзрәтнең өч мендәре өстенә менеп утырды. Шәкертләр көлештеләр, ләкин таләпнамәне укый башлау белән тынып калдылар. Гаризада болай дип язылган иде: «Яшь гомеребезнең иң матур, иң кадерле ун-унбиш елын без мәдрәсәдә уткәрәбез. Мәдрәсәгә килгәндә без укымышлы, белемле, милләтебезгә файдалы кеше булып чыгарбыз дигән өмет белән килдек, ләкин кирәк белемнәрне ала алмадык, чөнки монда уткәргән гомеребезнең күп өлеше тормышта һич кирәкмәгән, мәгънәсез талашларга өйрәтә торган, «Исагуҗи», «Шәмсия»ләр кебек китаплар укып уздырдык. Мәдрәсәгә бездән соң килгәннәрнең дә күрәчәге шундый, гомерләре шулай заегъ булачак. Шуның өчен безнең иң беренче таләбебез: болар урынына гомуми тарих, дин тарихы, җәгърафия, хисап кебек фәннәр укытылсын. Шулай ук рус теле белән гарәп теле укытуыгызны таләп итәбез. Гарәп теленең кагыйдәләрен, кануннарын укысак та, телнең үзен белмибез, корьәннең аерым сүзләрен генә төшенәбез.

Әгәр дә сез үз ихтыярыгыз белән безгә бу сораган фәннәрне укытмасагыз, мөфассал[1] иттереп, моңарчы укыткан дәресләрегезнең фай-

[1] Мөфассал — тулы рәвештә.

дасыз икәнен дәлилләр белән исбат итеп, мәхәллә байларына вә әһле мәгарифкә [1] гариза бирәчәкбез».

Хәмит укып бетергәч, Галимҗан иптәшләреннән:

— Ничек? Монда әйтелгән фикерләргә кушыласызмы, кул куясызмы? — дип сорады.

Төрле яктан тәкъдимнәр ява башлады:

— Язганнарың барысы да дөрес! Тик тагын бер нәрсә кушарга кирәк иде: гарәп теле белән чикләнмичә, безгә тәфсир [2] дә укытсыннар,— дип кычкырды Госман.

Бу сүзгә каршы арадан берсе:

— Син үзең бервакыт «безгә укыткан мөхтәсәрләр куян шулпасының шулпасы гына!» дип әйткән идең бит,— дип башлаган иде, икенчесе эләктереп алды:

— Чыннан да, дин гыйлеме мөхтәсәр, «Һидая» [3] белән генә чикләнми торгандыр. Гарәп телен укытсыннар! Коръән безнең кебек гади бәндәләр аңламаслык түгелдер. Телен белсәк, аңларбыз!

— Кыйраәтханәдән китаплар алып укырга рөхсәт ителсен!..

Шуннан артык өстәмә, төзәтмәләр булмагач, таләпнамәне акка күчереп, кул куеп, икенче көнне иртүк Вәли муллага тапшырырга булдылар.

Инде икенче мәсьәлә туды: таләпнамәне кем тапшырыр? Бөтен «иттифакчылар» бергә тупланып, шәкертләр садасын әйтеп, Вәли мулланың өенә барыргамы, әллә бу эшне бер кешегә генә тапшырыргамы? Бу мәсьәләдә Галимҗан тәкъдиме җиңде:

— Әгәр мәдрәсә идарәсе безнең таләпләргә риза булмаса, чукмарның иң зурысы гаризаны тапшырган кешеләрнең башына төшәчәк. Чукмар күп кеше башында уйнаганчы, бер кеше башында уйнасын. Үзегез күреп торасыз: Заһидулла хәзрәт мине ничек кенә итеп мәдрәсәдән кудырырга юл тапмый аптырый. Иртәме, соңмы, барыбер мине моннан куачаклар. Шуның өчен гаризаны мин үзем тапшырыйм,— диде ул.

Икенче көнне иртүк Галимҗан акка күчерелгән гаризаны Вәли мулланың өенә алып китте.

## 7

Урамга чыгу белән, ул биттән сыйпап искән җылымса йомшак җилне тойды. Юл читендәге биек көртләр инде салкын кыш вакытындагы пакьлеген югалтканнар, керләнеп ямьсезләнә башлаганнар, шуңа да карамастан, көн матурланып, ачылып киткән төсле иде. Кар астыннан челтерәп аккан гөрләвекләрнең ягымлы тавышына, иртәнге кояшның рәхәт яктысына бөтен күңеле белән бирелеп, Галимҗан бераз туктап торды. Ләкин озакламый аның дикъкатен башка бер нәрсә җәлеп итте. Каршы яктагы коймага нииндидер кәгазь ябыштырылган иде.

— Бу прокламация түгелме икән? — дип, Галимҗан ашыгып урам аркылы чыкты.

Чыннан да, прокламация булып чыкты бу. Монда былтыр 9 гыйнварда канечкеч Николай патшаның Петербург эшчеләрен аттырып үтертүе, шулай ук Оренбургның үзендә генерал Архангельскийның 22 гыйнварда форштаттан казачилар китертеп, Петербург фаҗигасенә протест йөзеннән баш күтәргән эшчеләрне аттыруы, кистерүе, төрмәгә утыртуы искә алынган. Төрмәгә утыртылган фидакарь иптәшләрен

[1] Әһле мәгариф — мәгариф кайгыртучылар.
[2] Тәфсир — коръәнне шәрехләп аңлата торган фән.
[3] Һидая — таһарәт, никах, талак кебек шәригать кануннарын өйрәтә торган китап.

гаделсез хөкемнән коткарыр өчен, прокламация эшче халкын көрәшергә чакырган иде.

Галимҗан кәгазьне ахырына кадәр укып кына өлгергән иде, урам башында городовой күренде.

«Кара син боларны: патшасыннан да, губернаторыннан да курыкмаганнар! Әбез аждаһа хәзрәттән котыбыз очып яшибез. Безне бит атмаячаклар да, кисмәячәкләр дә. Күп булса, мәдрәсәдән генә куарлар!» — дип уйланып, ул Вәли мулланың өенә юнәлде.

Галимҗанны эчкә кертмәделәр. Кызыл фәсле бер малай, ишекне ачып, Галимҗанның нинди йомыш белән килгәнен сорады да мулла янына кереп:

— Анда бер шәкерт сезгә таләбәләр исеменнән ниндидер гариза тапшырырга килгән,— дип белдерде.

— Нинди гариза ул тагын? — дип сорады Вәли мулла, гаҗәпсенә һәм шикләнә төшеп, «Гаризаны кабул итәргәме, юкмы?» — дип бераз уйланып торды. Шуннан соң гына: — Бар, кәгазен алып кер, үзе кайтып китсен, җавабы соңыннан булыр,— дип боерды да тәрәзә катына килде. Үзалдына:

— Ә, теге гыйсъянчы икән бу! Тыштан караганда бозык дип уйламассың да үзен,— дип, пәрдә артыннан Галимҗанны күзәтте.

Март кояшы яктысында, кар өстендә басып торган унсигез яшьлек Галимҗан төскә-башка чибәр күренә иде. Һава салкынча булуына карамастан, аның башында кара кәләпүш кенә. Кәләпүш кырыйларыннан кара-коңгырт җиту чәче күренеп тора. Ачык карашлы уйчан күзләр. Балалык чалымнарын югалтмаган ирене өстендә пәке тимәгән мыек әсәре...

Фәсле малай чыгып, Галимҗанның кулыннан таләпнамәне алды.

— Вәли мулла җәнаблары: «Гаризасын карап чыгармын. Җавабы соңыннан булыр», дип әйтте,— дигәнне ишеткәч, Галимҗан кайтып китте.

Вәли мулланың шикләнүе бушка булмаган икән. Гаризаны укып чыгу белән, бөтен күңеле зәһәрле ачу катыш пошыну белән тулды, үзалдына: «Имеш, таләпләрен кабул итмәсәм, әһле мәгарифкә язачаклар! Бу Заһидулла хәзрәт ни караган бу көнгәчә мәдрәсәдә?! Ничә тапкыр үзенә, шул бозык Галимҗанны берәр хәйлә табып мәдрәсәдән ку, дип әйттем бит!» — дип сөйләнде. Зур бүлмәдә арлы-бирле йөренә торгач, тизрәк Заһидулла картны чакыртырга булды.

Фәсле малай тыны кысылып мәдрәсәгә йөгереп килгәндә, Заһидулла хәзрәт комганын күтәреп тышка чыгып бара иде.

— Бушка гына болай вакытлы-вакытсыз чакыртмагандыр! — дип, хәзрәт комганын куйды да кабаланып кире керде. Кадакта эленеп торган җиләнен эләктереп алды да, барган шәпкә бер җиңен киеп, бер җиңе һәм итәге белән идәнне себереп, уңга-сулга карамастан, тиз-тиз мәдрәсәдән чыгып китте.

Заһидулла хәзрәт килеп кергәндә, Вәли мулла әле һаман да, кулларын артка куеп, борчулы кыяфәт белән арлы-бирле йөренә иде. Хәзрәтнең сәламен алыр-алмас, аңа шәкертләрнең таләпнамәсен тоттырды:

— Дикъкать белән укып чык шуны! — дип, келәм өстенә матурлап тезеп куелган кызыл атлас тышлы мендәрләргә ишарә итте. Үзе дә мендәргә утырды. Ләкин хәзрәтнең таләпнамәне соңына кадәр укып чыгуын көтәргә мулланың сабыры җитмәде. Утырган урыныннан торып, ул тагын бүлмә буйлап йөренә башлады. Бүлмәне берничә әйләнгәч, хәзрәтнең алдына ук килеп басты.

— Ни эшлиләр, ә? Җитмәсә тагын, риза булмасагыз, таләпнамәбезне байларга гына түгел, әһле мәгарифкә дә бирәбез диләр бит! Ни

эшлибез? Уйлашырга кирәк. Моны болай гына калдырып булмый! — дип, хәзрәттән акыллы киңәш көткәндәй, аңа карап торды.

Шәкертләрнең таләпләре Вәли мулла өчен дә, хәзрәт өчен дә көтелмәгән бер яңалык түгел иде. Ләкин алар эш бу дәрәҗәгә үк җитәр дип уйламыйлар иде әле.

Заһидулла хәзрәт, таләпнамәне укып чыккач, аны тез өстенә куйган килеш башын иеп, бераз уйланып утырды. Ахры, бер фикергә килде, башын күтәреп, Вәли муллага:

— Бәлки хәзергә һичбер төрле чара күрмәстән, гаризаларын байларга тапшырганнарын көтеп тормак лазымдыр?! Шул вакытта сез байларга мәсьәләне үзегез кирәк тапканча аңлатыр идегез. Мәхәлләнең Гыйсмәт бай, Рәхмәтулла бай, Фәхрелислам бай кебек нөфүзле вә дәүләтле адәмнәре сезнең сүздән бервакытта да чыкмаячаклар. Шул вакытта гыйсъянчыларны мәдрәсәдән кусак та, без куган булып күренмәбез, ә иганәләре белән мәдрәсәне тотып торган байлар куган булып күренер,— диде.

Вәли мулланың түгәрәк йөзе ачудан кызарынып китте:

— Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?! — диде ул, тавышын күтәрә төшеп.— Күрәсең бит, шәкертләр динемезгә хилаф булмаган тәфсир, фәлсәфәи диния, тарихеләнбия кебек гыйлемнәр укытылсын дип сорыйлар. Әгәр шәкертләр таләпләрен байларга үзләре аңлатсалар, байлар алар тарафына аумас дип уйлыйсыңмы?! Сиңа күптән инде дөньяны буташтырып йөргән шул Галимҗанның абруен төшереп, мәдрәсәдән куарга бирәр хәйлә табарга кирәк иде.

Заһидулла хәзрәтнең йөрәге чәнчешеп куйды: нинди генә хәйләләр кормады ул, нинди генә хыянәтләр эшләмәде, ә нәтиҗәдә ни килеп чыкты?

Хәзрәтнең исенә теге тентү вакыйгасы килеп төшкәч, хәтта иреннәре калтырый башлады. Вәли мулла белән бергә Кышкар мәдрәсәсендә бер табактан ашап, шәрик булып укыган булсалар да, бу вакыйганы аңа ачыктан-ачык сөйләп бирмәссең бит инде? «Кулыңнан бернәрсә дә килми икән. Гыйсъянчыны мәсхәрә итү урынына, үз абруеңны гына төшергәнсең!» — дип, Галимҗан урынына аның үзен куып чыгаруы да ихтимал. Кайчандыр шәриге булса да, хәзер ул мәдрәсәнең дамелласы, хуҗасы, мәхәлләнең могтәбәр имамы бит!

Шуларны уйлагач, ул мескенләнеп:

— Уф, алла! — дип көрсенеп куярга мәҗбүр булды.

Чыннан да! Әгәр байлар шәкертләрнең тәфсире хәдис, фәлсәфәи диния, гарәп теле кебек фәннәрне укырга теләүләрен белсәләр, «бу фәннәр мөселман диненә хилаф түгел, киресенчә, шәкертләр динемезне этрафлы сурәттә укып, тирән мәгълүмат алырга телиләр икән, сораган фәннәрен укытырга кирәк»,— дип әйтәчәкләр. Әмма Кышкар мәдрәсәсендә Вәли мулла үзе дә, Заһидулла хәзрәт тә мондый фәннәрне уку түгел, исемнәрен дә ишеткәннәре юк иде. Бу фәннәр турында аларга шул азгын Галимҗанның үзеннән ишетергә туры килде. Хәзрәт тагын уфтанып куйды да:

— Дөрес әйтәсез, мөхтәрәм Вәли әфәнде, байларга бу гаризаны күрсәтергә ярамый икән шул. Чыннан да, алар шәкертләр теләгән фәннәрне укытыгыз дисәләр, ни эшләрбез? Без бу фәннәрне укыта алырбызмы? — диде.

Бу эш кулларыннан килмәячәген Вәли мулла бик яхшы белә иде. Димәк, ислахны кабул итсәң, гомуми тарих, җәгърафия кебек фәннәрне белә торган мөдәррисләрне чакырырга, үзеңнең наданлыгыңны фаш итәргә мәҗбүрсең.

Заһидулла хәзрәт белән Вәли мулла озак киңәштеләр. Ниһаять, шундый карарга килделәр: Вәли мулланың сүзеннән чыкмый торган ике-өч байны чакырып, аларга шәкертләрнең таләпнамәсен күрсәтмичә,

мәдрәсәдән Галимҗанны куу турында алардан ризалык алырга. Әшне озакка сузмыйча, бүлмә тирәсендә тыңланып йөргән фәсле малайны шунда ук әлеге байларны чакыртырга җибәрделәр.

Байлар килеп кергәндә, әйтеләчәк сүзләр дә, кайнар пәрәмәчләр дә хәзер иде инде. Кышкар мәдрәсәсендә оста моназирлеге белән дан казанган Вәли муллага диндар, надан байларны үз сүзләренә ышандыру, үз теләгенә күндерү авыр булмады. Алар Галимҗанны һәм аның тарафдарларын мәдрәсәдән куарга кирәк дигән карарын хуплап каршы алдылар һәм, кайнар пәрәмәчләр ашап чәй эчкәннән соң, Вәли мулла белән хәзрәткә ияреп, мәдрәсәгә юнәлделәр. Үзләре «изге» дип таныган эшкә аларның турыдан-туры иштирак[1] итәселәре килде.

Фәсле малай Заһидулла хәзрәтне чакырырга килгәндә үк әле «иттифакчылар» аны урап алып:

— Таләпнамәбезне укыдымы?

— Ни дип әйтте?

— Заһидулла хәзрәтне ни өчен чакыртты? — дип, сораулар яудыра башладылар.

Ләкин малай «иттифакчылар»ны канәгатьләндерерлек бертөрле дә хәбәр әйтә алмады. Нибары:

— Галимҗан китергән кәгазьне укыды, тик бер сүз дә әйтмәде. Заһидулла хәзрәтне чакырырга гына кушты. Мин башка бернәрсә дә белмим,— дип котылырга тырышты. Шәкертләр аны һаман урталарыннан чыгармадылар.

— Белмәсәң белми торгансыңдыр, анысына ышанабыз. Хәзер инде Вәли мулла белән Заһидулла хәзрәтнең ни турында сөйләшкәннәрен ишетерлек колакларың бар ич! — диде Госман.

Хәмит дигәне Госманның сүзләренә өстәп:

— Әгәр син Вәли мулла белән Заһидулла хәзрәтнең ни сөйләшкәннәрен безгә төкми-чәчми килеп әйтсәң, без сиңа биш тиен бирербез! — диде.

Менә шул биш тиенне югалтмас өчен, фәсле малай байларны чакырырга барганда, юл уңаеннан мәдрәсәгә кереп, шәкертләргә остазлары арасындагы әңгәмәне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Аның сүзләренә караганда, Галимҗанны мәдрәсәдән куачаклары шиксез иде.

Бу хәбәрне ишеткәч, мәдрәсә эче кырмыска оясы кебек кайный башлады. Җыелыш кирәк дигән сүз әйтелмәсә дә, шәкертләр Заһидулла хәзрәтнең бүлмәсенә агылдылар. Аларның каннары кызышкан, күңелләре дулкынланган иде. Төрле яктан төрле сүз, төрле тәкъдимнәр ишетелде:

— Байларны монда мәдрәсәгә алып килсәләр, форсаттан истифадә итеп[2], аларга үз таләпләребезне сөйләп бирергә кирәк. Яхшы итеп аңлатсак, бәлки алар безнең таләпләребезне кабул итәрләр...

— Таптың аңлый торган кешеләрне! Кайсы байлар чакырылганын ишетмәдеңмени? Алар бит икесе дә карагруһ, икесе дә мөтәгассыйбләр! Алар гомердә Вәли мулланың сүзеннән чыгачак түгелләр!

— Аңлатачак, имеш! Алар инде алдан ук Галимҗанны мәдрәсәдән куарга дип сүз куешканнар. Ишетмәдеңме әллә?

— Галимҗанны гына түгел, бөтен «иттифакчылар»ны куарга кирәк дип әйтәләр ди!

Моңарчы бер читтәрәк эндәшми басып торган Галимҗан кулын күтәрде:

---

[1] Иштирак итү — катнашу.
[2] Форсаттан истифадә итеп — очрактан файдаланып.

— Дуслар!— дип кычкырды ул. Шау-шу кинәт тукталды. Барысы да Галимҗанга таба борылдылар.— Гаризабызны Вәли муллага алып китәр алдыннан, мин, аны яңадан күчереп, егерме биш «иттифакчы» шәкерт исеменнән дип үзем генә имза иттем. Ни өчен шулай эшләгәнемне аңлыйсыздыр. Гаризаның асыл нөсхәсе монда! — дип, Галимҗан кесәсеннән шәкертләр кул куйган гаризаны чыгарып күрсәтте. Иптәшләре шундук аны сырып алдылар. Чыннан да, асыл нөсхәсе микән? дигәндәй, гаризаны алып кулдан-кулга йөртә башладылар.

— Минем сезгә әйтәсе сүзем бар! — диде Галимҗан, яңадан кузгалган шау-шуны туктатырга тырышып.— Мине мәдрәсәдән куачаклары ачыктан-ачык мәгълүм булды. Мин моңа һич тә борчылмыйм. Киресенчә, моны мин үземә шан-шәрәф саныйм. Димәк, мин карагруһларны куркытырлык дәрәҗәдә яхшы көрәшкәнмен икән. Тик мине куулары белән мәдрәсәдә ислах юлындагы көрәш тукталмаска тиеш. Шуның өчен, мине мәдрәсәдән куу турындагы карарны игълан иткәндә, берегез дә мине яклап сөйләмәгез. Шул сылтау белән сезне дә кумасыннар! Мәдрәсәдә калып, көрәшне дәвам иттерергә тиешсез! Шуны онытмагыз: инсаният микроблары нихәтле тырышсалар да, ислахның җиңеп чыгуында һич шик-шөбһә юк!..

Артларыннан ике байны ияртеп, Вәли мулла белән хәзрәт мәдрәсәгә килеп кергәндә, шәкертләр таралмаган иде әле.

Иң алдан, симез, йомшак бармаклары белән тәсбих төймәләрен саный-саный, Вәли мулла атлап керде. Тәбәнәк буйлы Фәхрелислам бай белән Гыйсмәт бай, юан корсакларын көчкә күтәреп, аның артыннан ияргәннәр. Заһидулла хәзрәт исә, аларга тагылган койрык сыман, иң ахырда күренде.

Шәкертләр тавышыннан шау-гөр килеп торган бүлмәгә керү белән, Вәли мулла ачуланып:

— Бу нинди рөхсәтсез җәмгыять тагын?! — дип кычкырды.

Яшьләр бердән тынып калдылар. Муллага җавап кайтаручы булмагач, Галимҗан алгарак чыгып басты:

— Безнең таләпнамәбезгә җавап алып киләчәгегезне ишетеп җыелдык без,— диде ул.

— Ә, син үзең дә монда икән! Бик яхшы! Беркая да китмә, шунда тор! — дип әмер бирде Вәли мулла һәм тәбәнәк өстәл өстенә утырды.

Аракы шешәсе кебек тагын берәр бәла чыга күрмәсен дигәндәй, Заһидулла хәзрәт саклык белән генә мендәрләрен берәм-берәм күтәреп карады. Шуннан соң гына берсен алып Вәли муллага тәкъдим итте:

— Тәкъсир, астыгызга мендәр куярга рөхсәт итегез! — диде. Вәли мулла утырган өстәл өстенә мендәрне куйгач, калган икесен ике байга тәкъдим итте. Үзе исә, таягына таянып, аяк өстендә басып калды.

Вәли мулла, хәзрәткә таба борылып:

— Син тикшереп кил әле, шәкертләрнең барысы да мондамы икән? — диде. Шәкертләргә карап, кырыс тавыш белән:— Ә сез тыгызланыбрак утырыгыз, башкаларга да урын калсын,— дип боерды.

Шәкертләр, дәрес вакытындагы кебек, тезләнешеп киез өстенә утырдылар. Алар, авызларына су капкандай, бер сүз әйтмәделәр, тавыштын чыгармадылар. Яңадан унлап шәкерт килеп урнашканнан соң, алар артыннан Заһидулла хәзрәт тә күренде. Ул, Вәли муллага карап:

— Мәдрәсәдәге һәммә шәкерт җыелып бетте, мәҗлесне башласагыз да була,— диде.

— Алайса, җәмгыятьне башлыйбыз,— дип, Вәли мулла кесәсеннән бер кәгазь чыгарды. Тагын шәкертләргә карап:— Тавышланмагыз! Мин хәзер сезгә ошбу кәгазьне укыячакмын, яхшы тыңлагыз һәм гыйбрәт алыгыз! — диде.

Шәкертләр, кәгазьдә ни язылганын алдан ук белсәләр дә, дүрт колак белән тыңларга хәзерләнделәр.

«Итагатьсезлек җәзасы» дип аталган бу әмернамәне Вәли мулла үзе укыды. Байлар да, Заһидулла хәзрәт тә мулланың көчле, янгыравыклы тавыш белән укыган һәрбер сүзенә «ләббәйкә», «бик дөрес», «шулай» дигәндәй, канәгатьлек күрсәтеп, башларын кагып-кагып куялар иде. Бу кәгазьгә караганда, әүвәлге елларда ин итагатьле, «афәрин», тәхсин»[1] гә генә укып килгән Галимҗан мәхдүм[2], соңгы бер-ике ел эчендә бик бозылып, монафыйкланып киткән икән. Берничә тапкыр аның әйберләре арасыннан тәмәке, аракы кебек нәрсәләр табылган. Кыйраәтханәдән ул әллә нинди, шәригатькә сыймаган оят нәрсәләр язылган китаплар алып кайткан, аларны үзе генә укып калмаган, башка шәкертләргә дә биреп укыткан. Шуның белән аларның да инсафларын бозуга сәбәпче булган. Мәдрәсәдә укытыла торган дини китапларны укытмагыз, ул китаплар безгә бертөрле дә белем бирми,— дип, дәһрилеккә баш орган. Менә шундый кабахәтлекләре, әхлаксызлыклары өчен Галимҗан мәхдүм мәдрәсәдән куылырга хөкем ителгән...

Бу карарда әйтелгән тәмәке, аракы шикелле нәрсәләрнең Галимҗан әйберләре арасыннан чыкканын шәкертләрнең моңарчы күргәне юк иде. Шулай булса да алар бу ялганга үз мөнәсәбәтләрен күрсәтмәделәр, алдан сүз куешканча, тынлык сакладылар. Шәкертләрнең эндәшми утыруларын Вәли мулла, аларның моңа ышануы дип санап, рухланып китте.

«Бу дәһрине яклаучы табылмады. Димәк, куркыныч ул кадәр зур түгел икән. Бәлки бу хәл гыйсъянчының үзенә дә тәэсир иткәндер. Шулай булса, ул шәкертләр өчен үзе бер гыйбрәт булыр», дип уйлады, шуннан соң Галимҗанга мөрәҗәгать итте:

— Я, Галимҗан мәхдүм, уйлап кара! Күрәсең бит, шәкертләрнең барысы да итагать саклап, безнең карарга каршы чыкмадылар. Димәк, алар моны дөрес, хаклы дип таныйлар. Әгәр син бүген мөдәррисләрең вә мәдрәсәгә зур химая кылып торган Фәхрелислам вә Гыйсмәт байлар алдында тәүбә итсәң һәм киләчәктә бөтен бозыклыкларыңны, фетнәләреңне ташлап, итагатьле шәкерт булырга сүз бирсәң, бәлки гафу итәрбез...

Галимҗан Вәли мулланың сүзен бетергәнен дә көтмәде — утырган урыныннан сикереп торды. Үзенең муллага ни дип җавап бирәсен киеренке хәлдә көтеп торган иптәшләренә күз йөртеп чыкты да бөтен гәүдәсе белән Вәли муллага таба борылды. Башын горур гына артка ташлап:

— Юк, мин тәүбә итмәм! — диде.— Юк! Чөнки сезнең әмернамәгездә язылганнар барысы да бөһтан, барысы да ялган! Мин мәдрәсәдә хакыйкый белем алып, мәгърифәтле кеше булып чыгу юлында көрәштем һәм киләчәктә дә шул юлда бөтен көчемне куеп көрәшәчәкмен. Мине мәдрәсәдән куу белән сез ислах хәрәкәтен туктата алмассыз! Ул барыбер җиңеп чыгачак! Күпме генә ислахка каршы көрәшергә, кадимчелекне сакларга тырышсагыз да, буш хыял ул!..

Байлардан да, аның үзеннән дә тартынмыйча, Галимҗанның шундый коточкыч сүз сөйләвенә аптырап калган Вәли мулла, ниһаять, акылын җыйды, ләкин ясалма сабырлыгын саклап кала алмады.

— Тукта! Яп авызыңны, монафыйк! Мөртәт! Дәһри! Хәзер үк мәдрәсәдән чыгып кит! Бер минут та монда торасы булма! Эзең булмасын бу изге урында! — дип җикерде.

Шәкертләр арасыннан:

— Кешене куасыз икән, ул сезнең ихтыярыгызда, куыгыз. Ләкин ни өчен аңар сөйләргә бирмисез?

---

[1] Афәрин, тәхсин — хәзерге замандагы «яхшы», «бик яхшы» билгеләре мәгънәсендә.

[2] Мәхдүм — мулла баласы, мулла улы.

— Бөтен гомерен фәхешханәләрдә, сыраханәләрдә үткәргән шәкертләрне кумыйсыз, кирәк фәннәрне укытуны сораган кешене куасыз. Җитмәсә тагын, сөйләргә дә бирмисез! — дигән тавышлар ишетелде. Галимҗан аларга кулын гына селекте. Моның белән иптәшләренә: «Бушка сүз әрәм итеп утырмагыз! Миңа биргән вәгъдәгезне онытмагыз!» — дип әйтәсе килде.

Ишек янына җиткәч, Галимҗан, туктап, тагын Вәли муллага борылып карады:

— Сезнең бу вәхшәт вә җәһаләт зинданыгыздан котылуыма мин бик шатмын! Ләкин кабат әйтәм: теләсәгез нинди золым вә вәхшәтлек күрсәтеп көрәшсәгез дә, ислахның җиңеп чыгуын туктата алмассыз! — диде дә бүлмәдән чыгып китте.

Мәдрәсәдән куылачагын белгәч, ул әйберләрен алдан ук җыйнап, юлга хәзерләп куйган иде. Үз бүлеменә кергәч, ул, Шәһитне көтеп, түгәрәкләп төргән урын-җире өстенә утырды. Тирә-ягына каранды. Мәдрәсәдә яшәгән чакта әйбер артык булу түгел, кирәк әйберләр дә житешми төсле күренә иде, ә менә китә башлагач, әллә никадәр йөк җыелган: урын-җире, кечкенә булса да агач сандык, бер капчык китап, аннары тәлинкә, чынаяк, чәйнек кебек вак-төяк бәйләнгән төенчек... Һәрхәлдә, бер кеше генә күтәрерлек түгел. Ләкин Галимҗанга озак уйланып утырырга туры килмәде. Җыелыш үткәрелгән бүлмә ягыннан дөбер-шатыр килгән аяк тавышлары, кычкырулар ишетелде. Галимҗан: «Инде җыелыш таралды бугай»,— дип уйлап өлгермәде, әллә никадәрле шәкерт шаулашып-көлешеп аның бүлеменә килеп тулды.

Хәмит, килеп керү белән, Галимҗанның астыннан урын-җир төргәген тартып алып, иңбашына күтәрде. Госман агач сандыкка тотынды. Шәһит, китап тулы капчыкны берүзе генә күтәрә алмагач, китапларны иптәшләренә өләшә башлады.

Галимҗанның иптәшләре ничек булса да аңа булышырга, үзләренең теләктәшлекләрен күрсәтергә тырышалар иде.

Шәһит, бушаган капчыкны култыгына кыстырып, ыгы-зыгы эчендә аптырап калган Галимҗанның янына килде, аның кулыннан тотты да:

— Әйдә, башладык, дуслар! — дип кычкырды.

Шәкертләр, бөтен мәдрәсә эчен яңгыратып, беравыздан:

Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән һәм калыкты!
Уян, шәкерт, шәкерт, уян!
Уянырга вакыт җитте!

— дип җырлап җибәрделәр һәм аннары, аякларын солдатча каты-каты басып, мәдрәсәдән чыгып киттеләр.

## Мәдрәсәи галия диния

### 1

Бәйрут, Стамбул югары мәдрәсәләрендә дүрт ел укыганнан соң, Зыя Камали бер мең тугыз йөз дүртенче елда Уфага кайтып төште.

Егерменче йөзнең башларында французлар тәэсире көчле булган Төркиядә, берникадәр Европа мәдәниятен үзләштереп, төрек теленә тәрҗемә ителгән Вольтер, Руссоларның тәрбия турындагы әсәрләре белән танышып, гарәп әдәбияты һәм тарихы аркылы хәтта космогония турында да билгеле бер микъдарда мәгълүмат алып, дөнья күреп кайткан Зыя Камали — укытачак шәкертләрен татар халкын агартучы, аңбелем бирүче мәгърифәтле кешеләр итү дәрте белән яна иде. Шул

теләк белән ул чит илгә киткәнче үзе укыткан «Госмания» мәдрәсәсенә укытырга керде.

Жан Жак Руссоның феодализм җәмгыятендәге тәрбия, уку-укыту эшләренең куелышына каршы әйтелгән фикерләрен уртаклашса да, Зыя Камали аның «табигый тәрбия» турындагы карашларын кабул итә алмый иде. Шулай ук Вольтерның схоластикага, искелеккә, торгынлыкка каршы әйткән фикерләрен дөрес дип тапса да, аның «дин ул — халыкны йөгәнләү, тыю коралы» дигән фикеренә кушыла алмый, чөнки Зыя Камали өчен дин адәм баласын хайваннардан аера торган бөек, саф рухи бер көч иде. Ул шулай дип уйлый һәм аллага чын күңеле белән ышана, алла — бөтен галәмне, бөтен барлыкны яратучы, тудыручы дип таный иде.

Иске карашлы татар галәме өчен яңа булган фикерләр белән коралланып, дәртләнеп кайткан Зыя Камали беренче көннән үк үз идеяләрен «Госмания» мәдрәсәсендә тормышка ашырырга кереште.

Моңарчы шәкертләр баш мөдәррис Хәйрулла ахунның яки башка мөгаллимнең алдына атнага бер, күп булса ике тапкыр керәләр, аларның:

— Моннан монда тикле укыгыз! — дип, китап битен тырнак белән сызып күрсәткән сабакларын тыңлатып кына чыгалар иде. Сабакны шәкерткә аңлатып бирү дигән нәрсә юк. Зыя Камали исә дәрескә көненә берничә тапкыр керә. Бер сәгать дәвамында дин тарихыннан яки «Һидая»дән лекция укыса, икенче сәгатьне хифзыссыйхәткә, ягъни гигиенага багышлый, өченче сәгатьтә космогониядән, җәгъррафиядән дәрес бирә... Кирәк тапкан дәресләрен көндез укытып өлгермәсә, кичләрен дә килеп аңлата.

— Төшенми калганнарыгызны сорагыз, тартынмагыз! Бәйрут, Стамбул гали мәдрәсәләрендә шул ысул белән укыталар. Безгә дә Европаның яхшы үрнәкләреннән гыйбрәт алырга кирәк! — ди ул.

Бу — татар мәдрәсәләрендә күренмәгән бер хәл булганга, шәкертләр Зыя Камалиның бер дәресен дә калдырмаска тырышалар иде.

Урта буйлы, чандыр гәүдәле, уйчан күзле, авызының ике ягына салынып төшкән нечкә мыеклы, ияк очында гына бөдрәләнеп торган сирәк сакаллы Зыя Камалины шәкертләр: «Бүген тагын нинди кызыклы нәрсәләр турында сөйләр икән?» — дип, сабырсызланып көтеп алалар иде.

Дөрес, мөгаллимнәренең өр-яңа булып күренгән фикерләре шәкертләрнең башына беренче ишетүдә үк сыеп бетми. Шулай да бу фикерләр аларны уйланырга мәҗбүр итә. Иске мәдрәсә рухы белән сугарылган шәкертләр өчен бу үзе дә бер уңыш иде.

Шәкертләргә аның табигать кануннары турында сөйләгәннәре бигрәк кызыклы да, ничектер хәвефле дә кебек тоела. Имеш, Җир Кояш тирәсендә бушлыкта әйләнә, Ай исә Җир тирәсендә әйләнеп йөри! Шәкертләр ышанырга да, ышанмаска да белмиләр. Тирә-яктан сораулар ява башлый:

— Ничек инде ул алай? «Сөбателгаҗизин» китабында:

Җирнең бардыр үгезе,
Үгезнең бар мөгезе.
Кодрәт белән күтәрәдер
Бөтен җирне бер үзе,

— дип әйтелә ләбаса!? Шулай булгач?..

— Кояш үзе Җир тирәсендә әйләнә! Аны һәркем үз күзе белән көн саен күреп тора бит!..

— Җир бушлыкта әйләнеп торса, ничек итеп без җир өстеннән егылып төшмибез?..

Мондый сорауларга каршы Зыя Камали борынгы гарәп галимнәренең, Галилей, Коперникларның исемнәрен атап, шәкертләргә аңлата, иске хорафатлар белән каткан башларын тазартырга тырыша. Ләкин «тазартулар»ның нигезе шул дингә, аллага кайтып кала:

— Аллаһы тәгаләнең хикмәтен вә кодрәтен сез үгез мөгезенә бәйләмәгез. Мөгезенә җирне күтәреп торган үгезнең үзенә дә басып торырга җир кирәк түгелмени? Аллаһы тәгаләнең хикмәте вә кодрәте — табигатьне, менә мин сезгә сөйләп биргән какшамас, җимерелмәс канунnarны төзүендә, шул кануннарга бөтен галәмне буйсындыруында!..

Зыя Камали «Госмания»дә укыту белән генә чикләнмәде. Руслар белән аралашып, рус гореф-гадәтләренә авыша төшкән, шәригатьнең бөтен кануннарын үтәүне авырсынган яшь татар байлары, мирзалары да аңардан «мөселманча» укырга теләк белдерделәр. Зыя Камали аларга да атнасына ике тапкыр дәрес бирә иде. Бу кешеләр аны:

— Ачык фикерле, мәдәниятле кеше, философ, дин белгече, халыкка аң-белем таратучы,— дип санап, бай гаиләләр каршында аның дәрәҗәсен күтәрәләр иде.

Икенче яктан, «Госмания» мәдрәсәсенең баш остазы Хәйрулла ахун Усманов кебек карагруһлар аны «дин азгыны», «дәһри» дип дошман күрәләр иде.

Хәйрулла ахун башта: «Чит илләрдә тирән мәгълүмат алып кайткан галим булгач, мәдрәсәнең абруен арттырыр»,— дип, үз мәдрәсәсенә алган иде, әмма соңга таба: «Үзен Зыя Камали дип йөрткән бу пәрвәз хәлфәнең абруе бай гаиләләр арасында көннән-көн арта бара. Эшләр болайга китсә, мәдрәсәне кулдан ычкындыруым да ихтимал. Мине куып, үзе хуҗа булып калуы мөмкин. Ничек тә булса мәдрәсәне кулдан ычкындырмаска кирәк»,— дип уйлый башлады.

Шул сәбәптән Хәйрулла ахун, Зыя Камалины кан дошманы кебек күреп, аның абруен төшерергә бөтен көчен куя, үзе кебек карагруһ мулла-мәзиннәр, карт байлар, итче-кибетче, талчукчылар арасында яшь укытучы турында төрле гайбәтләр тарата иде. Моның белән генә канәгатьләнмичә, Зыя Камалиның дәресләренә кереп, шәкертләр алдында аның сүзен бүлеп, мөгаллимнәренең әйткәннәренә капма-каршы иске, надан фикерләр әйтеп, аны үзенчә «хур итәргә» тырыша иде.

Менә бүген дә, ахшам намазыннан соң Зыя Камалиның бер төркем зур шәкертләр белән мәдрәсәгә юнәлгәнлеген күреп, Хәйрулла ахун аның артыннан китте. Юлда туктап, бер-ике кеше белән сөйләшергә туры килгәнлектән, ул мәдрәсәгә килеп кергәндә, Зыя Камали дәресне башлаган иде инде.

Кичләрен дәрес бирү гадәт булмаса да, бүлмәгә зур шәкертләр генә түгел, унике-унөч яшьлек шәкертләр дә тыгызланып тулганнар иде.

Хәйрулла ахун күренүгә, шәкертләр арасыннан, җиңелчә җил искән сыман, шыпырт кына, сизелер-сизелмәс кенә тавыш үтеп китте.

Зыя Камали Хәйрулла ахунның керүен дә, үзенең янына килеп кабарынып утыруын да күрмәгән төсле, сүзен дәвам иттерде:

— Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам ни өчен мөселманнарга ураза тотарга, биш вакыт намаз укырга кушкан?..

«Ярый әле, болары шәригатькә сыя торган сүзләр. Карап карыйк, ничек аңлатырсың», дип уйлап куйды Хәйрулла ахун.

Камали, соравына җавап көткән төсле, бераз тукталып торды да авызына керердәй булып, дикъкать белән тынып калган шәкертләргә күз йөртеп чыкты. Аннары аңлата башлады:

— Пәйгамбәребез мөселманнарның саглам, нык халык булуын теләгән. Ураза ашказанын тазарта. Бу исә хифзыссыйхәт тарафыннан бик кирәк нәрсә. Бигрәк тә ел буена майлы аш, симез ит ашап, ашказаннарына авырлык китергән кешеләр өчен бу бик зарур...

Зыя Камалиның бу сүзе Хәйрулла ахунның нәкъ үзенә төбәп әйтелгән кебек тоелды. Хәзрәтнең ачуы кабарды, Зыяның сүзен бүлеп, ул:

— Хифзыссыйхәт, имеш!.. Ул тагын нинди нәрсә? Имеш, ураза майлы аш, симез ит ашаган кешеләргә генә фарыз икән! Башкаларга фарыз түгелмени? Ураза тоту бөтен әһле мөслимингә фарыз! Үзеңнең дәһри фикерләреңне Мөхәммәт галәйһиссәламнең өстенә йөкләмә! — дип кычкырды.

Зыя Камали ахунның сүзләрен түбән карап тыныч кына тыңлап торды да, аның тавышы тыну белән, тукталган урыныннан сүзен ялгап китте:

— Намаз дисәң, ул үзе бер гимнастика. Кешенең бәдәнен ныгыта, кан тамырларына көч бирә. Минә сезнең кебек көн буе мәдрәсәдә хәрәкәтсез яшәгән кешеләр өчен ул бигрәк тә кирәк...

Хәйрулла ахун утырган урынында сикереп үк куйды.

— Намаз аллаһы тәгаләгә гыйбадәт түгел, тик ат кәмите гимнас дип әйтмәкче буласыңмы?! Син ни, шәкертләрне диннән яздырырга булдыңмы? Үзең кебек дәһри итмәкче булдыңмы?! Мәдрәсәне бөтен әһле мөслимин каршында рисвай итәргә ниятләндеңме?! — дип, куллары бутап кычкырына башлады.

Хәйрулла ахунның шулай кылануы шәкертләр өчен бер дә яңалык түгел иде. Күңелләреннән алар хәлфәләре Зыя Камали җиңеп чыгуын телиләр. Бер ахунга, бер Камалига карап: «Мөгаллим нинди җавап бирер икән»,— дип, бер-беренә төртешеп, кызыксынып көтәләр иде.

Ахунның сулышы бетеп, тынып калуга, Зыя Камали:

— Хәйрулла әфәнде хәзрәтләре, бу дәрес — пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламнең хифзыссыйхәт турында безгә калдырган кануннарын аңлатуга багышланган. Шуның өчен бүген намазның тик хифзыссыйхәт назарыннан файдалылыгын тикшерәбез. Намазның аллаһы тәгаләгә гыйбадәт булуы шәригать кануннарын укыган дәресләрдә аңлатыла,— диде, шуннан соң тагы дәресен дәвам иттереп сөйләп китте: — Дуңгыз ите ашау хәрам дип әйтүнең сәбәбе дә хифзыссыйхәт назарыннандыр, чөнки дуңгыз ите бик майлы, симез була. Гарәбстанда исә һавалар бик эссе. Шул сәбәптән симез дуңгыз ите ашаган кешеләр эч авыруына дучар булып үләләр икән. Икенче тарафтан, ул якларда дуңгыз итендә трихина дигән корт була. Шул кортлар дуңгыз ите ашаган кешеләрнең ашказаннарын, эчәкләрен тишеп, бөтен бәдәненә тарала, түзә алмаслык авыруга сабыштыра икән...

Бу юлы инде Хәйрулла ахун бөтенләй кабынып китте. Әйтерсең ут өстенә май китереп сиптеләр! Ул янә урыныннан сикереп торды:

— Таралыгыз, шәкертләр! Мин үз мәдрәсәмдә мондый фетнәләргә юл куя алмыйм! — дип кычкырды да, шәкертләрнең чыгып киткәнен дә көтмичә, Зыя Камалига таба борылды:— Син инде шәкертләрне урыс булырга, дуңгыз ите ашарга димли башладыңмы? Инде сиңа урыслардан бер ящик тәре китертеп, шәкертләргә өләшергә генә калган икән! — дип котырына башлады.

Зыя Камали, башын түбән иеп, эндәшмичә басып торды. Хәйрулла ахун яшь хәлфәнең шулай торуын: «Җиңдем бит үзен! Ни дип җавап бирергә сүз тапмый. Каппадым авызын!» — дип аңлады. Зыя Камалиның исә башында бөтенләй башка уйлар иде. Ул: «Бу кеше белән бергә эшләп булмаячагы күптән инде мәгълүм булды. Аның белән бәхәсләшеп утыру сүз әрәм итү генә! Татар халкын агартучы мәгърифәтле яшьләр тәрбия итәм дисәм, бу кара козгын белән бәхилләшеп, үземә мәдрәсә ачарга кирәк булачак! Шәһәрнең могтәбәр зыялылары белән тагын сөйләшергә, киңәшергә дә, бу юлда гамәли эшкә керешергә кирәк!» — дигән фикергә килде. Башын күтәреп, Хәйрулла ахунның зәһәр чәчеп торган күзләренә карады. Сабырлык сакларга тырышып, сүзләрен санап әйткәндәй итеп салмак кына:

— Төркиядән кайтканнан бирле, сезнең мәдрәсәдә укытуыма икенче ел инде. Бу вакыт эчендә шул мәгълүм булды: мин сезнең белән бергә эшли алмаячакмын. Яз башында, шәкертләр таралып беткәч үк, мин сезнең мәдрәсәдән китәчәкмен. Минем урыныма башка мөгаллим эзләгез,— диде дә ишеккә таба юнәлде.

Хәйрулла ахун аның артыннан:

— Дүрт ягың кыйбла! Бүген үк китсәң дә кайгырмыйм! — дип кычкырып калды.

Егерменче йөзнең башларында татар байлары арасында «милли мәдәниятне үстерергә кирәк» дигән фикерләр тарала башлаган иде. «Милли мәдәният» дигән пәрдә артына яшеренеп, алар икътисади көчкә генә түгел, сәяси көчкә дә ия булырга, халыкның милли азатлык юлындагы көрәшендә юлбашчылыкны үз кулларына алырга, бу көрәшне үз файдаларына юнәлтергә тырышалар иде. Шуның өчен дә Зыя Камалиның «Мәдәни халыкларда кабул ителгән ысул буенча, дини генә түгел, дөньяви фәннәр дә укытылачак, мәдәниятле, мәгърифәтле кешеләр тәрбияләп чыгарачак» мәдрәсә ачарга теләве татар байлары, мирзалары тарафыннан хуплап каршыланды, төрле яктан иганәләр ява башлады.

1906 елның башларында Зыя Камалиның кулында байтак акча җыелган, яңа мәдрәсә ачу хыялы инде гамәлгә ашырылачагына ышанычы туып җиткән иде.

## 2

Улы Галимҗанның мәдрәсәдән куылуына Гыйрфан мулла бик борчылды.

— Мин сезне адәм булсыннар, белем алсыннар, халкыбызны наданлык баткагыннан чыгарырлык мөгаллим булсыннар дип, өстемә төшкән авырлыкларга карамастан, мәдрәсәләргә биреп укыттым. Абыеңны «Хөсәения»дән, сине Вәли мулла мәдрәсәсеннән куганнар. Башыгызда җил уйнамаса, тугры юл белән йөргән булсагыз, кумаган булырлар иде...— дип, кабат-кабат шелтәләде ул аны.

Әтисе белән килешә, аңлаша алмыйча Галимҗан Троицк якларына чыгып китте. «Күңелемә ошаган бирәр мәдрәсә булмасмы, яки кыш буе үз башыма укып чыгарлык акчалы бирәр эш тапмаммы», дип уйлаган иде ул. Күңеленә ошаган мәдрәсә тапмагач, бәлки рус телендә яхшы сөйләшергә өйрәнермен дигән өмет белән, бер бай рус казагына хезмәтче булып ялланды.

Сентябрь ахырларында аңа таныш бер шәкертеннән хат килде. Иптәше Уфада яңа гали мәдрәсә ачылачагын хәбәр иткән, дәресләр, рус һәм Европа мәктәпләрендәге кебек, гадәттәгедән иртәрәк, сентябрь аеннан ук башланачагын әйткән иде. Хат кичегеп килгәнлектән, Галимҗан шул көнне үк хуҗасы белән исәп-хисапны өздө дә Уфага китте.

Белем дәрәҗәсе беренче югары сыйныфка керерлек булса да, ул икенче тәгъзирия сыйныфка имтихан тотты, чөнки, иске мәдрәсәдә укытылмаган җәгърафия, математика кебек дәресләр икенче тәгъзириядән башлана икән. Аннары, беренче югары сыйныфта барлыгы дүрт кенә шәкерт, ә икенче тәгъзириядә егермегә якын икән. «Монда иптәшләр, фикердәшләр дә күбрәк булыр», дип уйлады Галимҗан.

Инде октябрь аеның урталары да җитте. Көннәр гадәттә булмаганча җылы иде әле. Агачлар алтын-сары һәм бурлаттай кызыл төсләргә кергән яфраклары белән бизәнеп утыралар. Һавада салмак кына агылып пәрәвез җепләре оча. Бөтен табигатьтә ниндидер бер моңсу тынлык. Тик аяк астындагы корыган юкә яфраклары гына, адым саен кыштырдап, үзләренең зарларын сөйли кебек... Ни әйтергә телиләр икән алар?..

«Инде аяк астында тапталырга калдык микәнни?» — дип зарланалармы? Әллә: «Нигә безне кызганмыйча таптыйсың?» — дип рәнжиләрме?..

Галимҗан бер мизгелгә генә күңеленнән шундый тойгы кичерде һәм Воскресенская урамы уртасындагы юкә, сәрби агачлары утыртылган аллея буйлап, Случевский бакчасына таба ашыгып атлап китте.

Соңгы вакытларда аның күңеле күтәренке иде. Ничә еллар буе ашкынган теләк-хыялларына, ниһаять, ирешкән төсле тоя иде ул үзен. Менә хәзер дә ул укуга, мәдрәсәгә мөнәсәбәте булмаган бер очрашуга бара. Аңардан: «Кая барасың? Кем рөхсәт итте сиңа?» — дип сораган, янсә: «Барма! Аягыңны атлыйсы булма!» — дип тыйган кеше юк. Вәли мулла мәдрәсәсендә мондый иркенлек мөмкин идеме соң? Шуңа күрә күзгә табигатьнең моңсулыгы да аның күңелендәге куанычлы тойгыларны басып китә алмый иде. Дөрес, Фәйзерахман Урманов очрашасы кешенең кем икәнен атап әйтмәде, тик:

— Шуны бел: кая барачагыбызны һичкемгә дә әйтмә! — дип кисәтеп куйды.

Агыйделнең текә яры буенда зур гына кызыл таш өстендә сөйләшеп утырган ике кешене Галимҗан ерактан ук күрде. Берсе, әлбәттә, Урманов булырга тиеш, ә икенчесе — кечерәк гәүдәлесе — мөгаен, шул кешедер. Ләкин якынрак килгәч, шул кешедер дигәне Вәсим Солтанов булып чыкты.

— Әле килмәгән икән,— дип, Галимҗан шәрикләре янына утырды. Тирә-ягына каранды. Искиткеч матур бер күренеш аның дикъкатен җәлеп итте.

Сокланырлык шул! Атластай шома кәүсәле ак каеннар текә яр итәгеннән йөгереп төшкәннәр дә, Агыйдел суына көзгегә карагандай карап, үзләренең зифа буйларына сокланып торалар сыман... Каршы якта — әле яшеллеген югалтмаган киң болыннар. Еракта — юка гына күгелҗем пәрдә бөркәнгән таулар... Юмарт, йомшак кояш нурлары су өстенә көмеш тәңкәләр сибеп уйный...

— Инде кузгалсак та була,— дигән сүзгә Галимҗан хыялыннан айнып киткәндәй булды.

Димәк, очрашу монда булмаячак. Көлешә-шаяра, текә сукмактан су буена төшеп киттеләр. Агач сал-паром аркылы Агыйделнең аргы ягына чыктылар.

Агыйдел белән Дим кушылган төштә кармак салып утырган аксылсары чәчле бер яшь балыкчыны күргәч, Фәйзерахман аның янына туктады. Рус телен ватыбрак:

— Здравствуй, рибак! Мнуга налавил риба? — дип сорады.

Егет иңбашына салган вак шакмаклы иске тужурканы киң җилкәсен сикертеп кенә җиргә ташлады. Күзләре өстенә төшеп торган чәчен бармаклары белән артка тарап җибәрде.

— Ваша дорога ведет вон к тем кустам,— дип, сул якка таба кулын сузды ул.

Балыкчы егеттән ераклаша төшкәч, Галимҗан Фәйзерахманга:

— Бу урыс егетен мин синең торган фатирыңда күргән кебек булам. Ул вакытта аның өстендә студент тужуркасы иде бугай,— диде.

— Әйе. Ул янәшә бүлмәдә тора. Миңа рус теленнән дәрес бирә.

Галимҗанны бу җавап канәгатьләндермәде. Уфада университет юк. Студент тужуркасы кигәч, әлеге егет үзе дә студент булырга тиеш. Университетта дәресләр сентябрьдә башлана диләр. Шулай булгач, ни өчен бу октябрь аенда монда, Уфада балык каптырып утыра икән? Ләкин Фәйзерахманнан ул:

— Студентмы? — дип кенә сорады.

Фәйзерахманның җавабы бик кыска булды:

— Куганнар.

«Куганнар... Университеттан куганнар... Үзе монда ят кешеләр күзеннән качып йөргән адәмне каян табарга дип юл күрсәтеп утыра. Ни өчен куылганы да, ни өчен монда утырганы да аңлашыла»,— дип уйлады Галимҗан һәм бу турыда бүтән сорау бирмәде. Сорашырга вакыт та калмаган, чөнки шәкертләр әлеге балыкчы егет күрсәткән куаклыкка килеп җиткәннәр иде.

Куаклар арасындагы кечкенә бер аланда, астына пинжәген җәеп, терсәгенә таянган, егерме дүрт-егерме биш яшьләрендәге киң маңгайлы, сызылып торган кара кашлы, нечкә кара мыеклы бер кеше ята иде. Килүчеләрне күргәч, ул урыныннан торып, аякка басты. Мыек астыннан ап-ак булып тезелеп торган тешләрен күрсәтеп елмайды да:

— Хуш килдегез, егетләр! — диде.

Урманов белән ул таныш икән инде. Башта аңа мөрәҗәгать итте:

— Я, Фәйзерахман, таныштыр иптәшләрең белән.

— Менә бусы — Галимҗан Ибраһимов,— диде Фәйзерахман, Галимҗанга таба кулы белән ишарәләп.— Ислах юлында ялкынлы көрәшче. Шуның өчен кадимнең кадиме булган Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган. Хәзер «Галия»гә укырга килде. Килеп өлгермәде, бөтен шәкертләрне үзенә гашыйк итте, үз «диненә» күндерә башлады дип әйтер идем, соңыннан мактанып, борыгын югары чөя башлавы бар. Ә менә бусы — Вәсим Солтанов. Кечкенә, ябык булуына карамастан, бик булдыклы, тырыш егет. Мәгърифәт өчен көрәшкә җанын бирер!..

Ярым шаяртулы, ярым җитди тонда иптәшләре белән таныштырганнан соң, Фәйзерахман ни өчендер бу кешенең исемен әйтмәде.

«Бәлки Фәйзерахман үзе дә аның исемен белми торгандыр», дип уйлады Галимҗан.

— Димәк, монда барысы да ялкынлы көрәшчеләр икән! — дип, яңа таныш тагын бер тапкыр мөлаем гына елмайды да егетләрнең кулларын кысып чыкты, шуннан соң Фәйзерахманга карады:— Фәйзерахман туган, безне нәрсә белән сыйларга уйлыйсың?

Фәйзерахман култык астына кыстырган төргәген җиргә куеп ача башлады. Аннан ике шешә ниндидер эчемлек, бер кисәк казылык, икмәк, ике чынаяк чыкты. Кәгазьне ашъяулык сыман җәеп, ризыкларны шунда тезештерде. Эшен бетергәч, тезләнеп торган хәлдә:

— Рәхим итегез! Сый аз булса да, күп итеп кабул итегез! — дип, кулларын җәеп, түбәнчелекле кыяфәт белән баш иде. Фәйзерахман моңарчы гомерендә бер театр, артист күрмәгән булса да, шулай артистларча кыланырга ярата иде. Аның зифа буена, мәдрәсә шәкерте дип әйтмәслек көязлегенә, кара кашлы, озын керфекле, кара күзле сөйкемле йөзенә, үткен теленә болай кылану бик килешә иде.

Егетләрне көтеп алган кеше:

— Егетләр, әйдәгез утырышыйк. Телләрне чишеп җибәрер өчен, иптәшегез китергән сыйдан авыз итик,— диде дә беренче булып үзе ашъяулык янына утырды. Бераз уйланып торгач, әйтә куйды: — Уңайсызлык булмасын өчен шуны әйтәм: миңа Хөсәен абый дип тә, Хөсәен иптәш дип тә эндәшергә мөмкин. Анысы үз ихтыярыгызда. Тик Хөсәен әфәнде дип атый күрмәгез. Яратмыйм шул сүзне,— диде һәм, бер шешәне ачып, чынаякларга ширбәт сала башлады.

Бер чынаякны Галимҗанга, икенчесен Вәсимгә сузды. Егетләр уңайсызланган сыман күренделәр. Вәсимнең ап-ак йөзенә кызыллык чыкты. Кулына алган тулы чынаякны ул ашъяулык өстенә кире куйды.

— Без бит хәмер эчеп өйрәнмәгәнбез... Кичерәсез инде,— дип, Вәсим тагын колакларына кадәр кызарды.

Хөсәен көлемсерәп куйды:

— Анысы бик яхшы! Ләкин сезне, әйткәнегезчә, «хәмер» эчәргә өйрәтүче мин булмам. Шуның өчен курыкмыйча эчеп җибәрегез, исермәссез! — дип, шәкертләрне тынычландырырга тырышты.

Үзе, җитди сүз башларга да вакыт дип уйлап, Галимҗанга карады:

— Вәли мулла мәдрәсәсеннән ислах өчен көрәшкәнлегегез сәбәпле куылгансыз икән. Сезне ул мәдрәсәдә нәрсә канәгатьләндермәде? Мәдрәсәнең укыту ысулларында нинди үзгәрешләр булуын тели идегез? Минем шуны беләсем килә,— дип сорады.

Хөсәен бу сорауны Галимҗанның күңелендә ни бар, ни югын капшап карау нияте белән бирде. Галимҗан исә күп уйланып тормады, чөнки бу сорау аның күптәнге әрнүле ярасына килеп кагылды. Бу турыда инде ул Вәли мулла мәдрәсәсендә чагында күп уйланган, күп сөйләнгән һәм шуның өчен куылган да иде.

— Мәсьәлә Вәли мулла мәдрәсәсендәге укыту ысулында гына түгел бит. Җәдитчәрәк укытырга тырышкан мәдрәсәләрдә дә шул ук хәл: шәкерт, балалыгыннан башлап, сакал-мыек чыкканчы, ун-унбиш ел ачлы-туклы яшәп, йөзе саргаеп, бөтен бәдәне корып кипкәнче мәдрәсәдә утыра. Әмма нинди белем алып чыга? Бар белгәне биш вакыт намаз... Гарәп теленең сарыфын, нәхуын ятласа да, аерым сүзләреннән башка телнең үзен белми. Мәдрәсәне бетереп чыкканда, шәкертнең башында белем, кулында һөнәр булмый... Я, мондый укуның кемгә кирәге бар? Әгәр мин мулла булырга, теләнче кебек сәдакага яшәргә теләсәм, яки авылга кайтып, сабый балаларның миен черетергә уйласам, миңа шул мәдрәсәнең биргәне җитәр иде. Балаларның яшь гомерләрен заягъ итәсем килми минем. Кем тизрәк үләр икән дә, кайчан күпме җеназа сәдакасы килер икән дип көткән козгын да буласым килми!..— Шушы җирдә Галимҗан кинәт сүзеннән туктады. Чыраенда уңайсызлану галәмәте күренде. Хөсәенгә карап, аптыраганрак тавыш белән:— «Мин», «мин» дип сөйләгәч, бу үзен генә уйлый икән дип аңлый күрмәгез,— диде.— Ширбәтегез исерткеч булмаса да, мин азрак кызышып киттем, ахрысы. Фикеремне ачыграк аңлатыр өчен «мин»гә күчтем. Әйткәннәрем, әлбәттә, тик минем фикерләр генә түгел. Мәдрәсәләрнең торгынлыгы, тәгассыплыгы белән мие тәмам томаланып бетмәгән һәрбер шәкерт шулай уйлый...

— Үз исемегездән генә сөйләнмәгәнегезне яхшы аңлыйм, борчылмагыз. Вәсим туган белән Фәйзерахман да сезнең һәрбер сүзегезгә кул куяр, әлбәттә! — дип, Хөсәен Вәсимгә карады. Бу егетне дә сүзгә катнаштырасы килә иде аның.

Вәсимнең җавабы кыска булды:

— Галимҗанның мәдрәсәләр турында әйткән һәр сүзе дөрес. Хәзер «Галия»гә җыелган шәкертләрнең барысы да шулай уйлый дип әйтергә мөмкин, чөнки «Галия» шәкертләренең барысы да диярлек я шул иске кадим мәдрәсәләрдән куылган, я кадим мәдрәсәләрне ташлап килгән шәкертләр. Ләкин мин Галимҗан кебек тезештереп сөйли алмыйм. Ул сөйләсен!

Урманов һәр вакыттагы кебек эләктереп алды:

— Шәкертләр бушка гына Галимҗанның авызына шайтан төкергән дип әйтмиләр! Ул сөйли башласа, әүлияны да юлдан яздырыр!..

Хөсәен Фәйзерахманның мәзәген кабул итмәде, аңа:

— Син шаяртуларыңны куеп тор әле,— дип, тагын Галимҗанга карады:— Мәдрәсәләрдә сезне нәрсә канәгатьләндермәгәне аңлашылды. Сез мәдрәсәләрнең нинди булуын телисез соң?

— Без дини фәннәр генә укытылмасын, күбрәк тормышта кирәк булган белемнәр бирелсен дибез. Без рус теле укытылуын телибез. Мәдрәсәләр бирә торган белем русларның гимназияләре, реальное училищелары биргән белем белән тиң булсын, яки шуңа якын булсын. Шул вакытта гына без Русиянең гали мәктәпләренә якын бара алачакбыз. Без мәдрәсәләрдән халкыбыз өчен кирәкле һәм файдалы кешеләр булып чыгарга тиешбез дигән хыял белән яшибез...

Галимҗан ашыкмыйча, тавышын күтәрмичә, башын артка ташлап, ерактагы күгелҗем пәрдә артына яшеренгән таулардан күзен алмыйча сөйли. Хөсәен дә аны дикъкать белән тыңлый һәм әле башын кагып, әле көлемсерәп куя иде.

Галимҗанның туктап, уйланып калганын күргәч, ул тагын сорау бирде:

— «Галия» мәдрәсәсе сезгә теләгән белемнәрегезне бирер дип ышанасызмы?

— Әлегә мәдрәсәнең үз бинасы юк, ә вакытлыча шәкертләр урнашкан Зариф мулла мәчете бик кечкенә. Шунлыктан тиешле дәресләрнең барысы да укытылмый. Яңа фәннәрне укытырлык мөгаллимнәр дә тиз генә табылмый, ахрысы. Киләсе уку елына «Галия»нең үз бинасы салынып бетәр бәлки. Сабир мулла мәхәлләсенә таш, ком кебек төзелеш кирәкләрен ташыйлар инде...

Фәйзерахман сүзне Галимҗанның авызыннан өзеп алды:

— Имеш, төзелеш кирәкләрен ташыйлар! Сабир мулла: «Минем мәхәлләмә салмасыннар», дип дулый икән, хәтта губернаторга жалоба биргән, диләр!

— Анда салмасалар, әллә Уфада башка урын беткәнме? Һәрхәлдә, мәдрәсәнең үзенең зур бинасы булачак. Бер елга куян тиресе дә чыдаган, диләр. Без дә бер елга Зариф мулла мәчетендә түзәрбез әле. Шунысы мөһим: монда, Вәли мулла мәдрәсәсендәге кебек, кешенең инсаният сыйфатын таптамыйлар. Теләсәң нинди китап укы, теләсәң нинди кием ки, теләсәң кыйраәтханәгә, теләсәң театрга бар. Теләсәң җырла, теләсәң көл, тик әхлакка хилаф булган эш кенә эшләмә! — диде Галимҗан иптәшенең сүзенә каршы.

Хөсәен әүвәлге мәсьәләгә кайтты:

— Татар мәдрәсәләре гимназияләр биргән белемне бирергә тиеш, дидегез. Хәзерге көндә дә менә шул гимназияләрдә, реальное училищеларда, хәтта университетларда укып йөрүче татар егетләре бар бит. Ислах таләп иткән шәкертләр дә мәдрәсәләрне ташлап, үзлекләреннән хәзерләнеп, турыдан-туры гимназиягә укырга керсәләр булмыймы?

Әллә бу миннән көләме икән дип шикләнеп, Галимҗан Хөсәенгә күз ташлады. Вәсим белән Фәйзерахман: «Бу ничек дип җавап бирер икән?» дигән сыман Галимҗанга карадылар.

— Безнең мәдрәсәләр биргән белем белән гимназияләрнең ишегенә дә якын барырга мөмкин түгел. Ансын сез мин әйтмәсәм дә бик яхшы беләсез,— диде Галимҗан.— Үзлегеңнән хәзерләнер өчен матди нигез кирәк. Аны каян аласың?

Хөсәен Галимҗанның иңбашына җиңелчә генә кагылып алды да:

— Мәсьәләнең асыл төбе дә менә шунда шул! — диде.— Сез әйтмешли, гади татар баласы нинди генә мәдрәсә бетермәсен, аның өчен университет ишеге түгел, гимназиянеке дә ябык. Гади татар баласына гына түгел, гади еврей, чуваш, мордва һәм башка шундый милләт балаларына да шулай. Тагы шуны да кушарга мөмкин: «кухаркин сын» дип йөртелә торган ярлы рус малайлары өчен дә бу уку йортларының ишеге ябык...— Хөсәен сүзен әйтеп бетерде дә егетләргә күз йөртеп чыкты. Галимҗанның «Хөсәения» шәкертләреннән ишеткәннәре исенә төште: Казандагы революцион хәрәкәтләргә җитәкчелек итүче кешеләр арасында Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов исемле татар егетләре дә бар икән дип сөйләгәннәр иде. Үзен «Хөсәен» дип таныткан бу кешенең менә шул татар революционеры Хөсәен Ямашев икәненә Галимҗан хәзер тәмам ышанды. Шуның өчен ул, мондый сирәк очрактан файдаланып, күңелендәге бөтен төеннәрен чишеп калырга, мөмкин булса, киңәшләр дә алырга уйлады. Башкаларның сүз башлавын көтеп тормастан:

— Дөньядагы вакыйгалар без шәкертләргә дә шуны бик яхшы аңлатты, — дип сүзгә кереште. — Без халкыбызның изелеп яшәвен күрәбез, ыңгырашуын ишетәбез, ләкин аңа ничек ярдәм итәргә кирәклеген белмибез. Гаделсезлекне күрсен дисәң, халыкны наданлык дөньясыннан алып чыгарга кирәк. Ләкин кем алып чыгачак? Безме? Без бит үзебез дә шул кара сөрем эчендә яшибез. Димәк, беренче нәүбәттә без үзебез якты дөньяга нинди юл алып барачагын ачык күрү дәрәҗәсенә килергә тиешбез...

Галимҗанның чырае кырысланган, ул Хөсәенгә караган, һәр сүзен ничектер йөрәгеннән тартып алып әйтә кебек иде.

Хөсәен шәкертләрне сөйләтергә тели иде. Шуның өчен ул тагын бер сорау бирде:

— Халыкны якты юлга чыгарырлык мәгърифәтле кешеләр булырга теләвегез, һичшиксез, изге теләк. Ләкин дөньяда юл бер генә түгел бит. Төрле юллар бар. Сезнең хыялыгыздагы юл халыкны кай якка алып чыгарга тиеш соң?

Галимҗан: «Чыннан да, юл бер генә түгелдер шул. Күп юлларның берсен сайларга кирәк булачак...» — дип уйлады.

Урманов та, Солтанов та эндәшми утырдылар. Аларның да башларында шул уй иде. «Син башладың, син дәвам ит», дигән сыман, алар икесе дә Галимҗанга карадылар. Галимҗан да моны сизде.

— Мәсьәлә дә шунда шул,— дип, ул сүзгә кереште дә бераз уйланып торды. Аннары үкенечле кыяфәттә кулын селтәп: — Без бу юлны үзебез дә ачык күрмибез бит әле,— диде.— Якты юлны эзләп табар өчен хакыйкый белем белән коралланырга кирәктер! Бу — безнең беренче нәүбәттәге вазифабыз дип уйлыйм. Бәлки бу коралны безгә «Галия» бирә алыр. Бүгенге көндә дә ул кадим мәдрәсәләр белән тиңләштерелмәслек дәрәҗәдә алда. Шәригатькә сыймый дигән булып, төрле мәдәни күңел ачулардан тыймыйлар. Мәдрәсәгә татар, гарәп телендә генә түгел, рус телендә чыга торган газетларны да алдыралар...

— «Галия» мәдрәсәсе сезгә хыялыгызда яшәгән мәгърифәтне бирерме-юкмы, анысын киләчәк күрсәтер,— диде Хөсәен, Галимҗанның бу сүзенә җавап итеп.— Әмма җиде инеш суы бергә кушылса, тегермәнне дә җимерә, диләр. Сез дә фикердәшләрегез белән кушылып, бер булып керешсәгез, хәзерге көндә өстегезгә алган бурычны үтәү юлында уңышка ирешерсез...— Хөсәен нәрсәгәдер икеләнгән сыман аз гына тукталып торды. Аннары билгеле бер карарга килгән кебек:— Менә Казанда «Әльислах» дигән бер комитет эшли,— диде.— Аның башында Фатих Әмирхан кебек алдынгы фикерле, сәләтле яшьләр тора. Әнә шул комитет белән элемтәгә керсәгез, ничек булыр? — Хөсәен, сүзеннән туктап, егетләргә күз йөртеп чыкты.— Сезнең кебек аңлы-белемле булырга теләгән яшьләр тик Уфада гына түгелдер. Алар Оренбургта да, Астраханьда да, гомумән, мәдрәсәле һәрбер шәһәрдә булырга тиеш. Сез ул шәкертләр белән дә элемтәгә керергә тиешсез дип уйлыйм...

Яшьләр арасындагы элемтә, бәйләнешләр турында әнә шулай шактый гына гәпләшкәннән соң, Хөсәен аларга кызыклы гына бер киңәш тә әйтеп куйды:

— Бәлки сезгә шәкерт газетасы кебек берәр нәрсә турында уйланырга кирәктер...— диде ул.

Урманов бу юлы да сабырсызлык күрсәтте:

— Газета дисез! Ул бит машинада басыла. Ул чаклы зур-зур кәгазьләрне без каян алырбыз! Безгә машина каян килсен!..

Вәсим, сирәк кашларын җыерып, Урмановка карады:

— Тукта әле, Фәйзерахман, кешегә сүзен сөйләп бетерергә бир! Дуамалланма!..

Галимҗан исә бер сүз дә дәшмәде, тик ничектер чырае яктырыбрак киткән кебек булды.

Фәйзерахманга җавап биргән сыман, Хөсәен сөйләп китте:

— Сезгә бит типографияләрдәге кебек зур машиналар кирәк түгел. Урам коймаларына ябыштырылган прокламацияләрне күргәнсездер. Менә шулар күләмендә булса җитә бит сезгә. Андый зурлыктагы газетаны җилем басма белән дә чыгарып була. Сез әнә теге, су буенда утырган балыкчы егеткә мөрәҗәгать итегез. Ул сезгә кирәк әсбапларны табып бирер. Кызганычка каршы, мин сезнең белән якын арада очраша алмам. Миңа моннан мөмкин кадәр тизрәк китәргә кирәк. Сез балыкчы егет белән элемтәне өзмәгез. Аның файдасы тияр...

Большевик Саммер аркылы РСДРП Үзәк Комитетыннан һәм Уфаның большевиклар оешмасыннан Хөсәен инде кирәк булган матди ярдәм алган һәм якын көннәрдә Оренбургка китеп татар телендә большевистик идеяләрне пропагандалаучы газета чыгару эшенә керешергә тиеш иде.

Ул, чалбарының кечкенә кесәсеннән чыгарып, сәгатенә карады:

— Миңа кузгалырга вакыт икән. Бигайбә, егетләр.— Аннары тирәякка карап кулы белән ишарә итте:— Әгәр сезне бу матур манзара үзенә җәлеп итмәсә, ун-унбиш минуттан сез дә кайту юлын карарсыз,— дип өстәде. Аягына торып басты.— Сезнең кебек егетләр белән танышуыма бик шатмын. Иртәме-соңмы, чын юлыгызны табачагыгызга ышанам,— дип, шәкертләр белән саубуллаша башлады.

Галимҗанның кулын кысканда, аның күзләренә карап, бераз уйланып торды да:

— Ә сезнең, Галимҗан туган, телегез бик бай, шома. Вәли мулла мәдрәсәсендә күргәннәрегез, аннан ни өчен куылганыгыз турында, кыскасы, ислах өчен көрәшегез, омтылган максатларыгыз турында язып карасагыз ничек булыр икән? Бу сезнең кулыгыздан килерлек эш дип уйлыйм. Хәзер андый нәрсәләрне бастырырлык татар газеталары да юк түгел. Ислах юлында үзе бер агитация булыр иде,— дип, Галимҗанның күңеленә коткы салды һәм, шәкертләр белән тагын бер тапкыр саубуллашып, шәһәр ягына таба китеп барды.

## 3

Егетләр бераз вакыт эндәшмичә, уйланып утырдылар. Ниһаять, Вәсим иптәшләренә күтәрелеп карады:

— Мин дөрес аңлаган булсам, теге балык каптырып утырган егет аркылы Хөсәен абый безгә шәкерт газетасы бастырыр өчен ниндидер җилемле тартма бирергә вәгъдә итте бугай...

— Шулай булса, бу бит әйтеп бетергесез зур ярдәм булыр иде безгә! — дип, сүзгә Галимҗан да кушылды.— Югыйсә, бу җилем басма дигән нәрсәне без каян табар идек? Аны безгә кем бирер иде?! Әгәр, чыннан да, безгә ул нәрсәне бирсәләр, газета чыгару кебек эшне башкарырга көчебез җитәрдер, ә?

Әгәр мөмкин булса, егетләрнең газетаны шушы җирдә үк баса башларлык дәртләре бар иде. Ашкынып торуын башта Урманов белдерде:

— Алай булгач, дуслар, бу унбиш минутны да бушка үткәрмик. Эшне хәзер үк башлыйк!

«Галия» мәдрәсәсенә килә торган һәрбер газетаның «Вакыт», «Йолдыз» дигән кебек исемнәре булуын хәтерләп:

— Башласак башлыйк,— диде Галимҗан.— Исемсез газета булмый. Башта исем кушарга кирәк. Я, нинди тәкъдимнәрегез бар? — дип сорады.

Тегеләр уйга калдылар. Ниһаять, Фәйзерахман кычкырып әйтеп салды:

— Мин таптым: газетаны «Шәкерт тавышы» дип атыйбыз!

— Син бик кычкырма әле, монда чукрак кешеләр юк! — диде аңа Галимҗан. Аннары Вәсимнән сорады:— Ә син нинди исем куяр идең?

Вәсим гадәтенчә сабыр тавыш белән:

— «Шәкерт тавышы» дигән исем дә яхшы, ләкин «Безнең юл» дисәк, яхшырак булмасмы икән? Син үзең ничек уйлыйсың?— диде.

Галимҗан, ерактагы тауларга карап, бераз җавапсыз утырды. Шуннан соң иптәшләренә таба борылып:

— «Шәкерт тавышы» да, «Безнең юл» да бик яхшы исемнәр,— диде. Җанлана төшеп, үз фикерен әйтергә кереште:— Ләкин бит газетаны зур итеп чыгара алмабыз, Хөсәен абый җилем басмада прокламация зурлыгында гына итеп басарга мөмкин дигән кебек булды. Исеме озын булса, күп урын алыр. «Аң» яки «Ирек» дип атасак, ничек булыр? Без бит иптәшләребезне иректә, аңлы булырга өндибез...

Бу тәкъдимгә каршы килмәделәр, газетаны «Аң» дип атарга булдылар.

Кәгазь, буяу алыр өчен дип, шунда ук утыз бишәр тиен салышып, бер сум да биш тиен акча җыйдылар. Аны Фәйзерахман кулына тапшырдылар. Галимҗанга — газетаның максатын аңлаткан баш мәкалә язу, Урмановка — чит шәһәрләрдә укучы шәкертләргә хитап язу бурычы йөкләнде. Вәсимнең язуы бик ачык һәм матур булганлыктан, аңа бу мәкаләләрне акка күчерү эшен тапшырдылар.

Эшне шулай үзара бүлешкәннән соң, егетләр кузгалырга булдылар. Су буенда теге балыкчы егет күренми иде инде. Ул Хөсәен белән бергә киткәнме, әллә аны саклап артыннан атлаганмы? — анысы шәкертләр өчен билгесез иде. Ихтыярсыз, алар шул җирдә беразга тукталдылар. Вак дулкыннар белән каплана башлаган Агыйдел суы өстенә карап тордылар. Куанычлары эчләренә сыймаган төсле, өчесе дә бердән киерелеп тирән итеп сулап куйдылар. Моны үзләре дә сизде: бер-беренә карап көлешеп алдылар. Ниһаять, Галимҗан:

— Кайтыйк, туганнар. Җилемле тартма килгәнче уйланасы уйлар күп әле! — дип, шәһәр ягына таба борылды.

4

Газетаның беренче санын Урманов белән Солтанов шәкертләр күрмәгән арада аларның урын-җирләре арасына тыгып куйдылар. Оренбург, Троицк, Казан, Астрахань мәдрәсәләренә икешәр-өчәр нөсхә җибәрделәр.

Кичен урын-җирләрен таратып, ятарга хәзерләнә башлагач, шәкертләр арасында шау-шу кузгалды.

— Кара әле, бу нәрсә?

— Минем дә әйберләрем арасыннан килеп чыкты!

— «Аң» — «Галия» шәкертләренең газетасы дип язылган!..

Барысы да тәбәнәк өстәл өстендәге җиделе лампа тирәсенә килеп тыгызландылар. Фәтхел Корбангалиев газетаны тиз генә укып чыкты да, кемнедер эзләгән төсле, шәрикләрен күздән кичерде. Йокларга хәзерләнеп сузылып яткан Солтановны күргәч, аның янына барды:

— Бу синең кул язуың! Әйт, моны кемнәр белән чыгардыгыз? — дип, газетаны Вәсимгә сузды.

Вәсимнең болай да аксыл чырае тагы да агарына төште. Ул яткан урыныннан торып утырды. Бераз вакыт ни әйтергә белмичә, кулындагы газетага карап торды. Вакытны күпме генә сузма, кайчан да булса барыбер җавап бирергә кирәк бит. Ниһаять, ул:

— Чыннан да, минем язуга охшый икән шул, — диде дә тагын туктап калды. Башын түбән иеп, Фәтхелгә карамаска тырышты.— Ләкин моны мин язмадым, — дигән булды.

— Син мине алдый алмассың, мин ул хәтле ахмак түгел! Бу — синең язуың. Шик-шөбһә юк! Дөресен әйт! Бу эшкә минем дә катнашасым килә!..

Фәтхелнең бу сүзеннән Вәсим уйга калды. Ул бит Фәтхелне «Госмания» мәдрәсәсеннән үк яхшы белә. Фәтхел — чын күңеленнән ислах теләүче шәкерт. Аңа тулысынча ышанырга мөмкин. Газета эшендә дә файдасыннан башка зарары тимәс иде. Менә бит, газетаның беренче саны алай ук күп басылмады. Шулай да баскан бер кәгазь бөгәрләнеп-бөгәрләнеп чыга. Алар белән бөтен бүлмә тула. Шуларны тигезләп, авыр нәрсә белән бастырып барыр өчен дә бер кеше кирәк... Ләкин Галимҗан белән киңәшмичә үзе генә ни әйтсен?!.

Вәсимнең эндәшми калуын Фәтхел үзенчә: «Җиңдем бугай» — дип аңлады һәм җиңүен ныгытыр өчен, Вәсимнең җавабын да көтмичә:

— «Госмания» мәдрәсәсендә биш йөздән артык шәкерт изелеп ятуы турында язган бер нәрсәм бар минем, — диде. — Бу нәрсә «Аң»га бик килешеп китәр иде. Мәкаләгә рәсем дә ясап куйдым: зур бер арбага бик күп шәкерт башы салып, Хәйрулла ахун Госманов аларны авыр калак белән изеп маташа. Әгәр шундый рәсемне куеп чыгарсаң, газета тагын да кызыграк булыр иде дим...

Ниһаять, Вәсим билгеле бер карарга килде, ахры, Фәтхелгә күтәрелеп карады:

— Син сабырсызланма әле. Барыбер хәзер мин сиңа бер нәрсә дә әйтә алмыйм. Белешеп карыйм. Әгәр берәр нәрсә ачыкланса, сиңа хәбәр итәрмен.

Бу җавап канәгатьләндермәсә дә, Фәтхел артык бәйләнеп утырмады, чөнки бу мәсьәләне чишү Вәсимнең генә кулында түгеллеген белә иде ул.

«Башкалар белән дә сөйләшсен. Ни дип әйтерләр. Аннан соң ни эшләячәгебезне күрербез»,— дип уйлады Фәтхел. Шулай да Вәсимне кисәтеп куйды:

— Бу газетаны чыгаручылар кемнәр икәнен белми бу дип уйлама! Бик яхшы чамалап алдым мин аны. Әгәр син миңа иртәгә җавап бирмәсәң, мин үзем ул кешеләр белән сөйләшәм!

Ләкин Галимҗан да, Фәйзерахман да Фәтхелнең теләгенә каршы килмәделәр.

— Газетабызны «Галия» шәкертләренең газетасы» дип атадык. Шулай булгач, ни дип Фәтхел кебек аңлы, дәртле шәкертләрдән яшеренеп маташырга?! Аның кебекләр газетада язышырга теләсәләр — язсыннар, эшләргә теләсәләр — эшләсеннәр. Аның кебекләрнең язганнары газетабызның рухына хилаф булмас! — диде Галимҗан.

## 5

Галимҗан мәдрәсәгә бик ашыгып килеп керде.

Суыктан аның яңаклары алсуланып кызарган, керфек-кашларының һәр төгенә кадәр ак бәс утырган иде. Ул ике кулы белән, юынган төсле, битен сөртеп алды. Куллары юешләнгәч, кесәсенә тыгылып, кульяулык эзләде. Таба алмагач, ике кулын ике чабуына сөртте. Күзенә очраган шәрикләрен кулы белән ымлап янына чакырды, тик аларның якын килгәнен көтмичә, үзе каршы атлады. Галимҗанның бөтен хәрәкәтләре гадәтендә булмаганча ашыгыч кебек иде. Аның нидәндер бик дулкынланган булуын иптәшләре шунда ук сизеп алдылар.

Галимҗан мәдрәсәдән читтә, фатирда торгач, үзенең шәрикләреннән башка кешеләр белән дә күп аралаша. Шуның өчен дөнья хәбәрләрен

алардан алдарак белеп тора иде. Аның тәнәфес вакытында, яки дәресләрдән соң калып, шәһәрдәге, хәтта илдәге яңа хәбәрләрне сөйләвенә иптәшләре күнеккән иде. Бу юлы да алар: «Нинди дер бик кызыклы хәбәр алып килгән бугай, югыйсә, болай дулкынланмас иде»,— дип, Галимҗан тирәсенә җыелдылар. Галимҗан бүреген, пальтосын салып, аларны янында басып торган Вәсим кулына тоттырды. Аннары иптәшләрен көттермичә сөйли башлады:

— Дәрес башланырга вакыт аз калды. Сүзне озынга сузмыйча хәзергә шуны гына әйтәм: иртәгә төнге поезд белән Уфа губернасыннан Думага сайланган вәкилләр Петербурга китәчәк икән. Вокзалга приказчиклар, гимназистлар аларны озатырга төшәчәк, Дума әгъзаларына үзләренең теләкләрен, таләпләрен әйтәчәкләр. Минемчә, безгә дә җыелышып вокзалга төшәргә кирәк. Без дә үзебезнең теләкләребезне белдерик. Дума мәҗлесләрендә алар безнең таләпләрне дә тормышка ашыру юлында көрәшсеннәр. Мин үзебезнең берничә таләбебезне язып өлгердем, ләкин хәзер аларны укып торырга вакыт юк. Шуның өчен безгә дәресләрдән таралмыйча Дума әгъзаларына тапшырачак йомышларыбыз турында уйлашырга кирәк. Җыелышка уйлашып, хәзерләнеп килегез.

Шәкертләр арасыннан кемдер:

— Мөселманар исеменнән Думага сайланган әгъзалар кемнәр алар? — дип сорады.

Сорауга җавап бирүче булмагач, Галимҗан:

— Берсе — Сабир мулла Хәсәнов, икенчесе — Стәрлебаштан зур бай сәүдәгәр Шакир Тукалев, өченчесе — алпавытлардан мирза Кугушев. Мин белгәннәр менә шулар,— диде.— Әлбәттә, бу вәкилләр бөтенләй ук ышанырлык кешеләр түгел,— дип өстәп китте Галимҗан.— Ләкин татарның бер сүзе бар бит: ятып калганчы, атып кал, диләр. Әх, юкка атмадык, бәлки тидергән булыр идек, дип, соңыннан үкенерлек булмасын...

Галимҗанга сүзен бетерергә туры килмәде, коридорда мөгаллимнәре күренде.

Дәрестән соң дәвам иткән җыелышта шәкертләр Галимҗанның Дума әгъзаларына мөрәҗәгать итеп язган таләпләрен тыңладылар. Бу таләпләр шәкертләр арасында күп сөйләнгән, җилем басма газеталарында да күп басылган, күп язылган мәсьәләләр турында иде. Шуның өчен татар мәдрәсәләрендә ислах кирәклеген исбат итә торган бүлекне шәкертләр хуплап каршы алдылар.

— Шушы таләпләргә кушыласызмы? Тагын нинди теләкләрегез бар? — дип сорады Галимҗан, таләпләрне укып чыккач,

Шәкерт хокуклары турында бер-ике өстәмә ясалгач, таләпнамәне кабул иттеләр һәм аны вокзалда Дума әгъзаларына кычкырып укуны Галимҗанга тапшырдылар.

Икенче көнне, шәкертләр җыелышып вокзалга төшкәндә, Дума әгъзалары әле килмәгәннәр иде. Бераз көткәннән соң алар да, үзләренең озатучылары белән килеп, вокзалның беренче классына кереп утырдылар. Шәкертләр Дума әгъзаларының каршыларына барып бастылар һәм тирән ихтирам күрсәтеп сәлам бирделәр. Фәтхел Корбангалиев, башкалардан алгарак чыгып, Дума әгъзаларына мөрәҗәгать итте:

— Без, «Мәдрәсәи галия Диния» шәкертләре, үзара киңәшкәннән соң, сезгә, ягъни Думага халык хадимнәре булып сайланган вәкилләргә, үзебезнең мәгариф, мәгърифәт юлындагы теләкләребезне вә таләпләребезне белдереп, безнең бу таләпләребезне Дума мәҗлесендә киңәшеп, тикшертеп, тормышка ашыруыгызны үтенәбез...

Вәкилләрнең йөзләрендә беркадәр аптырау, каушау галәмәтләре сизелсә дә, алар, алыш-биреш турындагы әңгәмәләрен туктатып:

— Рәхим итегез! Рәхим итегез!..

— Сөйләгез, тыңлыйк! — диештеләр.

Яхшы кәгазьгә бик пөхтәләп, матур итеп язган таләпнамәне Галимҗан кесәсеннән чыгарып укый башлады. Ләкин ул икенче пунктны да укып өлгермәде, кинәт каяндыр ике жандарм килеп чыкты. Берсе таләпнамәне тартып алмакчы булып, Галимҗанның уң беләгеннән тотты. Галимҗан кәгазьне тиз генә сул кулына күчереп, кесәсенә яшерде. Таләпнамәне ала алмагач, жандарм Галимҗанның күкрәгенә төрткәләп, залдан куа башлады. Икенче жандарм, сыбызгысын сызгырта-сызгырта:

— Уходите добром, а то плохо будет! В кутузку хотите угодить! — дип, шәкертләрне ишеккә таба тибәрә иде. Шәкертләр шауларга, кычкырышырга тотындылар. Залдагы тәртипсезлектән файдаланып, Кырмыскалы егете Мөхәммәдетдин эскәмиягә сикереп менде дә матур, көчле тавыш белән:

— Әй, сез! Думага сайланган әфәнделәр! Уфаның ике жандармыннан курыккан куян йөрәгегез Петербург жандармнарын күргәч ярыла күрмәсен! — дип кычкырды.

Залдагы ыгы-зыгы, шау-шу арасында колакны ертырлык итеп чөрелдәгән хатын-кыз тавышы ишетелде. Болай да куркынган әфәнделәрнең йөрәгенә бу ачы тавыш тагын да көчлерәк дәһшәт салды. Алар утырган урыннарыннан сикереп тордылар, төсләре китеп, ыгы-зыгының иң кызу җиреннән читкәрәк шуарга ашыктылар.

Жандармның сызгыртуына, залга городовойлар килеп керде. Болар ярдәме белән, ниһаять, шәкертләрне залдан куып чыгара алдылар. Ләкин яшьләр җиңел генә бирешергә теләмәделәр. Урамга чыккач, мәдрәсәгә кайтып китмичә, барысы бергә җыелып перронга чыктылар. Перронга аяк басу белән Мөхәммәдетдин «Марсельеза»ны җырлый башлады. Башка шәкертләр җырны күтәреп алдылар. Галимҗан, һәр вакыттагы кебек, үзе җырламыйча, җырчыларның алдына чыгып, дирижерлык итә башлады. Перронга төрле яктан халык агылды. Ләкин аларга «Марсельеза»ны ахырына кадәр җырларга туры килмәде. «Почта, телеграф» дип язылган ишектән ниндидер бер кеше ашыгып чыкты да җырчылар янына йөгереп килеп:

— Тизрәк таралыгыз! Шәһәрдән казачиларны чакырттылар! — дип кычкырды.

Күз ачып йомганчы перрон бушап калды.

Бу вакыйгадан соң Галимҗан байтак вакыт күңелсезләнеп, чырае караңгыланып йөрде. Аны һаман бер уй борчый иде:

«Дума әгъзалары булгач, без халкыбызның теләкләренә колак салырга бурычлыбыз! Шәкертләргә тимәгез! Алар хаклы булса, Дума мәҗлесләрендә без бу турыда фикер алышырбыз!» — дип, бу кешеләр жандармнарны да туктатырга тиешләр иде. Ә алар ни эшләделәр? Үзләре тизрәк городовойлар артына яшеренделәр. Болар да халык вәкилләре, имеш! Юан корсак байларның, карагруһ муллаларның, ничә мең дисәтинә җирләре булган мирза-алпавытларның халык ихтыяҗларында ни эшләре бар?! Авыру хәлен сау белмәс, ач кадерен тук белмәс, дип тикмәгә әйтми шул халык! Ләкин ни өчен халык мондый кешеләрне Думага сайлаган икән?» — дип уйланды ул.

«Патша манифест игълан итте, халыкка ирек бирде. Хәзер халык үзенең вәкилләрен сайлап, шул вәкилләре аркылы Думада үзенең ихтыяҗларын канәгатьләндерүне таләп итәчәк. Думага сайланган вәкилләр — халык ихтыяҗларын үтәүче хадимнәр!» дип газеталарның көн саен тәкърарлаган сүзләренә шулай балаларча ышануына Галимҗан бик гарьләнә иде.

Ләкин тормыш бер җирдә генә тормый шул. Кеше алдына ул яңадан-яңа өмет, шатлыклар, уңышлар белән бергә, яңадан-яңа мәшәкать, бурычлар, эшләр тудыра тора. Элекке кайгы, мәшәкатьләр, гарьләнү, алданулар әкрен-әкрен артка кала бара, акылның «тәҗрибә» дигән почмагында сакланырга тапшырыла, яки кара кан булып укмашып, йөрәк төбендә ятып кала.

Бара-тора Галимҗанның да бу ачулары басылды. Аның алдына яңа бурычлар, яңа мәшәкатьләр, яңа эшләр килеп басты. Тиздән мәдрәсәдә имтиханнар башланырга тиеш. Имтиханнарны тыңларга читтән бик күп кунаклар киләчәк, имеш. Димәк, Зыя Камалиның йөзенә кызыллык китермәс өчен, мәдрәсәнең абруен төшермәс өчен, шәкертләр имтиханга бик тырышып хәзерләнергә тиешләр. Киләсе ел укыту программасына нинди фәннәр, нинди үзгәрешләр кертү турында үзара уйлашырга, бу турыдагы таләпләрне мәдрәсә идарәсенә тапшырырга кирәк. Кыскасы, алда эшләр күп. Төшенкелеккә бирелергә вакыт юк!

### 6

«Галия» мәдрәсәсендәге беренче уку елы үзенең ыгы-зыгылы тормышы белән үтеп тә китте. Көз, кыш буе укыган сабакларын ничек үзләштергәнлекләрен сынау вакыты — язгы имтиханнар килеп житте.

Татар дөньясында беренче югары мәдрәсә булган «Галия»гә имтихан вакытында төрле яктан татар зыялылары, иганә биргән байлар, мирзалар килде. Бу кунаклар арасында «Галия»нең дуслары белән бергә дошманнары да бар иде. Соңгылары арасында иң усалы, Зыя Камалиның күптәнге көндәше Һинди Минһаҗ иде. Зыя Камали «Галия» мәдрәсәсен ачам дип хәбәр таратып, халыктан ярдәм сораган чакта, хвалынскилы Һинди Минһаҗ да, гали мәдрәсәсе ачам дип, халыктан акча җыйган иде. Ләкин Хвалынскида гали мәдрәсә ачылмый калды, чөнки җыелган бөтен акчаны Минһаҗ өйләнеп, зур туй ясап сарыф итеп бетергән иде.

«Галия»дә имтиханнарны моңарчы татар дөньясында күрелмәгән алым белән кабул итәләр: өчәр-дүртәр шәкертне чакырып, мөгаллимнәр каршына утырталар. Аларга билетлар тәкъдим ителә. Бу билетлар арасыннан шәкертләр, җирәбә тарткан кебек, сайламыйча, кайсы туры килсә, шуны алырга тиешләр. Билетларга ел буена укытылган һәр фәннән икешәр-өчәр сорау язылган һәм шәкертләр шул сорауларга җавап бирергә тиешләр.

Хәтта ялкаурак саналган шәкертләрнең дә җаваплары имтихан алучыларны канәгатьләндерерлек иде.

Имтихан алучыларның уртасында утырган Зыя Камалиның йөзендә хозурлык чаткылары уйный. «Куйган көчебез бушка китмәгән, чәчкән орлыкларыбыз әрәм булмаган икән. Сусаган җир яңгыр суын ничек йотып алса, болар да биргән белемне шулай йотып алганнар!» — дип уйлап куанып утыра иде ул.

Ләкин кунакларның иң алгы рәтендә утырган Һинди Минһаҗның элек-электән күңелендә Зыя Камалига каршы урын алган көнчелек хисе торган саен көчәя бара иде. «Мәдрәсәне дә сала башлады. Таләбәләр дә җыйды. Инде имтиханнары да уңышлы үтеп бара. Кара син, шәкертләренең теле телгә йокмый! Бөтен сорауларга шартлатып җавап биреп торалар. Бу хәл Камалиның абруен тагын да арттыра бит...» — дигән уй Һиндигә тынгылык бирми иде. Үзенә кирәк чакта төрле хәйлә, хәтта хыянәтләрне дә чит күрмәгән Минһаҗның башына кинәт: «Тукта әле, монда берәр хәйлә юкмы икән? Мөгаен, бу җирәбә кәгазьләре шәкертләргә алдан күрсәтелгәндер! Шуның өчен аларның җаваплары да шомадыр!» — дигән уй килде. Имтихан биреп торган шәкертнең сүзен

бүлеп, Минһаж урынынnан торды, Зыя Камалига карап бик төче итеп елмайды да:

— Мөхтәрәм Зыя әфәнде! — диде.— Сезнең сәләтле мөдәррис икәнегезне без барчабыз да бик яхшы беләбез. Укыткан сабакларыгызны таләбәләрегез яхшы үзләштергәнлегенә дә шик-шөбһәбез юк! Шулай булгач, алдан җаваплары хәзерләнгән сорауларны кәгазьгә язып, имтихан вакытында шәкертләрдән жирәбә тарттырмасагыз да булыр иде,— дип, күкрәгенә кулын куйды, башын иеп алды да урынына утырды.

Шәкертләр арасында гына түгел, кунаклар арасында да ниндидер бер хәрәкәт булып алды: берәүләр йөткергән сыман иттеләр. Икенчеләре тамак кыргалап куйды, бүтәннәр утырган урыннарыннан кузгалып, нидер әйтергә теләгән төсле күренделәр. Галимҗан белән янәшә утырган түземсезрәк Фәйзерахман, шул минутта ук аякка басып, Минһажның тетмәсен тетәргә дип кузгалган да иде инде, Галимҗан аны иңбашына басып кире утыртты.

— Без аңар тәнәфес вакытында арт сабагын укытырбыз. Хәзер исә аның кирәген бирергә синнән олырак кешеләр дә табылыр! — дип, күзе белән Зыя хәлфәне күрсәтте.

Чыннан да, бу бит Зыя Камалины күз буяуда гаепләү иде. Көтелмәгәндә шундый тупас яла ишеткәч, Зыя Камалиның гарьләнүдән тыны кысылды, йөзе агарып китте. Шулай да ул, бөтен көчен туплап, тынычланырга тырышты. Алдындагы стаканга графиннан су салып эчте, аннары аягүрә басты да Минһажга карап, һәрбер сүзен аерып-аерып:

— Мөхтәрәм Минһаж әфәнде! — дип сөйли башлады. — Башымда «Мәдрәсәи галия» ачу фикере тугач та галиҗәнаб мирзаларымыз һәм зыялы байларымыз биргән иганәләре аркасында максадымызга ирешкән соңында, ягъни хыялымызда яшәгән мәдрәсәне ачып, таләбәләрне укыта башлагач та, бөтен теләгебез яшь буынга хакыйкый белем бирү, яшьләрне чын мәгънәсендә мәгърифәтле кешеләр итеп тәрбияләү иде. Мәдрәсәдәге барча мөдәррисләр дә таләбәләргә мөмкин кадәр тирән һәм этрафлы белем бирергә тырыштылар. Таләбәләремез күңел куеп укыганнар икән, без мөдәррисләрнең сарыф иткән көчләре бушка китмәгән икән, бүгенге имтихан шуны һәркемгә күрсәтмәктә дип уйлап, куанып утырмакта идем. Ләкин, тәәссефкә каршы [1], хөрмәтле мөсафирләремез [2] арасында бу турыда шикләнүчеләр бар икән. Хөрмәтле мөсафирләремезнең күңелендә бу турыда һичбер төрле шик-шөбһә калмасын өчен, имтихан кабул итү тәртибен бераз үзгәртүне тиеш табам. Шикләнүен беренче булып изһар иткән [3] мөхтәрәм Минһаж әфәндегә үтенечем шул: имтихан ителәчәк шәкертләр арасыннан ул теләсә кемне күрсәтсен. Шул шәкерттән без билетсыз, кыш буе укыган фәннәре буенча башымызга нинди сорау килсә, шуны сорап, аның белем дәрәҗәсенә бәя бирермез. Әгәр мөсафирләремез дә шәкерткә сорау бирергә теләсәләр — рәхим итсеннәр!..

Кунаклар арасыннан кемдер:

— Кирәкми! Имтихан шул башланган тәртибе белән бара бирсен! — дисә дә, һинди Минһаж бу сүзгә әһәмият итмәде, алга атлап, шәкертләр арасына керде. «Менә хәзер кызык күрерсез!» — дигәндәй, авызының бер кырые белән генә мыскыллы елмаеп, ул уртадарак утырган Мөдәррис исемле шәкертнең җилкәсенә тотынды. Мөдәррис аңа сәерсенгән бер төс белән күтәрелеп карады. Билетсыз имтихан тотарга Минһаж аны сайлап алганлыгы Мөдәрриснең башына әле барып җитмәгән иде. Янәшә утырган Мөхәммәдетдин аның кабыргасына төртте:

---

[1] Тәәссефкә каршы — кызганычка каршы.
[2] Мөсафир — кунак.
[3] Изһар итү — күрсәтү, сиздертү, ачык итеп әйтү.

— Тор, алга чык! Хәзер син имтихан тотарга тиеш. Элэктең, малай, кармакка! — дип пышылдады.

Мөдәррис алга чыгып утыруга, аңа бер-бер артлы сораулар ява башлады. Бер мөгаллимгә җавап биреп өлгерми, икенчесе тагын бишалты сорау хәзерләп куя. Кунаклар да, шәкертләр дә аның өчен чын күңелдән борчылып, тын да алмыйча, җавабын көтеп торалар иде. Ләкин шәкерт хәлфәләренең дә, шәрикләренең дә йөзенә кызыллык китермәде. Һәр сорауга җавап бирә торды. Мөдәрристән имтихан ала башлауга инде бер сәгать чамасы вакыт үтте. Кунаклар ялыга башладылар, әмма сораулар һаман тукталмый иде.

— Бу кәгазьне үзең укы да Мөхәммәдетдингә тапшыр,— дип, Галимҗан Фәйзерахманга кәгазь сузды.

Кәгазьгә мондый сүзләр язылган иде: «Мөхәммәдетдин! Тәнәфес башлану белән бу оятсыз Минһаҗны уратып алыйк. Янындагыларга шуны әйт: гафил булып, төрле якка олакмасыннар. Син үзең дә алга чыгып, бөтен кеше ишетерлек итеп көр тавыш белән Тукайның Минһаҗ турында язган шигырен әйт. Бу шигырьне белмәсәң, менә ул, ятла:

Таш ташыйлар, анда Минһаҗ «Галия» нигезен сала.
Туй ясыйлар, монда Минһаҗ гаилә нигезен сала.

Салыныр да, төпләнер дә, бик уңайдыр соңгысы;
Шикләнәм мин әллә ник, булмас кебек әүвәлгесе[1].

Калган ягын без үзебез башкарырбыз».

Фәйзерахман кәгазьне укып чыкты да, Галимҗанга борылып:

— Бу шигырь кая басылган иде? Минем аны бер җирдә дә укыганым юк, — дип пышылдады.

— Ул бер җирдә дә басылмаган әле. Миңа аны, шигырьнең кулъязмасыннан күчереп, Казаннан җибәрделәр,— дип Галимҗан да пышылдап җавап кайтарды. Урманов кәгазьне яңадан иплэп дүрткә бөкләде дә алдагы рәттә утырган шәкерткә тапшырды. Кулдан-кулга күчеп, кәгазь Мөхәммәдетдингә барып җитте. Ул чыннан да бу шигырьне белми икән. Ара-тирә кәгазьгә карый-карый, шигырьне ятлый башлады.

Вакыт үтә бирә. Мөдәрристән имтихан ала башлаганга инде ике сәгать тулды.

— Бу нинди эш тагын?! Болай барса, көн буена ике-өч шәкерттән генә имтихан алачаклар. Димәк, безнең сыйныфка гына иң кимендә алты-җиде көн кирәк булачак! — дип, Галимҗан Фәйзерахманга пышылдады.

Кунаклар арасыннан да:

— Җитәр инде! Бичара шәкерт кенә түгел, без дә арыдык!

— Шәкерткә «тәхсин» куегыз да тәнәфес игълан итегез, — дигән ризасыз тавышлар ишетелә башлады.

Зыя Камали да, башка мөгаллимнәр дә җитәрлек йончыганнар иде. Шәкертне инде әйтәсе юк. Маңгаена бәреп чыккан эре тир тамчыларын ул күптән җиң очы белән сөрткәли башлаган иде.

— Алай булгач, кунакларның үтенече буенча ярты сәгатькә тәнәфес игълан итеlә,— дип, Зыя Камали, аркасын турайтып, аякка басты.

---

[1] Тукайның бу эпиграммасы 1909 елда «Әдәбият» исемле җыентыкта гына (10нчы дәфтәр) басылып чыга. «Галия»дә беренче имтихан 1907 елда була. Матбугатта чыкканчы бу эпиграмма кулъязма рәвешендә аерым кешеләр кулында булган икән дип уйларга туры килә, чөнки Галимҗан шәрикләреннән берсе әйтүенчә, эпиграмманы Мөхәммәдетдин имтихан вакытында кунаклар алдына чыгып, кычкырып укыган.— Г. М.

Тәнәфес башлангач, халык сөннәт бүлмәсенә чыгу белән, шәкертләр Минһажны күздән югалтмаска тырышып, кунаклар артыннан агылдылар. Сөннәт бүлмәсенә чыккач, иплəп-иплəп кенә, кунакларга кагылмаска тырышып, Минһажны уратып алдылар.

Зыя Камали кунаклар, шәкертләр артыннан сөннәт бүлмәсенә чыкканда, Мөхәммәдетдин Минһажның алдына ук килеп баскан да көр, матур тавыш белән бөтен бүлмәне яңгыратып Тукайның эпиграммасын әйтеп тора иде. Зыя Камалиның беренче омтылышы шәкертләр арасына кереп, Мөхәммәдетдинне читкә алып чыгу һәм аңа: «Оят түгелме синә кунакны шулай мыскылларга? Ул тотнаксызлык күрсәткән икән, ояты үзенә булсын. Сезнең «Галия»дә алган белемнәрегез ни дәрәҗәдә нигезле, әтрафлы икәнен Минһаж әфәндегә генә түгел, бөтен кунакларга Мөдәррис бик яхшы күрсәтте бит!» — дип, үгет-нәсихәт бирү иде. Ләкин хисаптан, тарихтан дәрес бирүче мөгаллим Гариф Байчурин моны сизеп алды да Зыя Камалиның кулыннан тотты:

— Тимәгез! Шулай кирәк ул Минһажга! — диде.

Мәчет эченнән тышка саф һавага чыгарга хәзерләнгән кунаклар, Мөхәммәдетдиннең Тукай шигырен шулай матур итеп, Минһажның алдына басып әйтүен ишеткәч, атлауларыннан туктадылар, кызыксынып тыңлап тора башладылар. Күбесенең йөзендә мыскыллы елмаю уйный иде.

Минһаж мондый һөҗүм булыр дип көтмәгән, билгеле. Шәкертләр арасыннан ычкынырга тырышты ул. Ләкин бер яктан Фәйзерахман, икенче яктан Галимҗан, арттан Фәтхел, алдан Мөхәммәдетдин һәм башка шәкертләр аны шундый тыгыз итеп уратып алганнар иде, ычкыну түгел, кузгалырга да мөмкинлек юк иде. Бик нык эләккәнен сизеп, ул калтырана ук башлады.

Мөхәммәдетдин шигырьне әйтеп бетерүгә, Минһажның алдына Фәйзерахман килеп басты һәм чак якасыннан тотмыйча:

— Без ике-өч көннән таралырга тиеш. Эшләр болай барса, имтихан ай буена да сузылыр. Безнең монда артык торырлык акчабыз юк! Әгәр имтиханны шулай суздыртам дисәң, безнең белемебезгә ышанмасаң, «Галия» салам дип, халыкны алдап җыйган акчаңны безгә бир! Без ул акчага имтиханнар беткәнче монда яшәрбез! — дип, бөтен халыкка ишетелерлек итеп кычкырды.

Минһажның тезләре, буыннары бушап калды.

— Бәбкәйләрем! Мин бит сезнең белемнәрегезгә ышанмыйм дип әйтмәдем, тик әнә теге җирәбә кәгазьләрегез турында гына әйттем. Бик яхшы укыган икәнсез, машалла! — дип мыгырдана башлады ул, ә үзе эченнән: «Нигә кирәк иде миңа телемне тыя алмыйча сөйләнергә?! Хәзер инде менә халык алдына чыгып мәсхәрә булырга калды!» — дип, үз-үзен тиргәде, тәнәфестән соң кунаклар һәм шәкертләр алдында акланырга тиеш тапты.

Халык имтихан бүлмәсенә кереп урнашкач, Минһаж аякка басты да:

— «Галия»гә башка мәдрәсәләрнең иң зирәк, иң акыллы, алдынгы фикерле шәкертләре килеп тупланганын мин күз алдымда тотмаганмын икән, — диде. — Минем төп ялгышым менә шул игътибарсызлык аркасында. Бу — гафу итәрлек хәл дип уйлыйм. Шуның өчен баштарак шәкертләрнең яхшы җавап бирүләренә шикләнеп каравымны кичерерсез дип үтенәм. «Галия» мәдрәсәсендә шәкертләр чын-чыннан белем алганлыкларына мин генә түгел, башка кунаклар да тулысынча ышандылар һәм моңа чын күңелдән шатландылар дип беләм. Шуның өчен, вакытны бушка үткәрмичә, имтиханны әүвәлгечә билетлар васитасы белән кабул итүегезне үтенәм,— диде ул. Теле бу дөрес сүзләрне татлы тавыш белән әйтсә дә, эчен зәһәрле ут көйдерә иде аның...

Галимҗан, зур базарга чыгып эзләнә торгач, Солтанморатка кайтып китәргә хәзерләнгән бер арба хуҗасын тапты. Бу — шәһәр базарына бәрәңге сатарга килгән урта байлыклы Заһит абзый икән. Үзе авылдаш, үзе муллабызның улы дип, Заһит Галимҗаннан акча алмаска булды. Кечкенә төенчектәге юк-бар акчасына юнәткән шәһәр күчтәнәчләрен, биш-алты китаптан гыйбарәт бер бәйләмне Галимҗан арбага китереп куйды. Үзе дә менеп утырды.

Мәдрәсәдәге соңгы көннәр бик арыткан икән аны. Юлда ул күбесенчә йоклап кайтты. Уянган вакытларында уйлары һаман әтисе белән очрашу, сөйләшү, аңлашу турында булды: «Мин бит хәзер татарның иң гали мәдрәсәсенең шәкерте! Әткәй моны, әлбәттә, бик яхшы аңларга тиеш. Хәзер инде ике арабызда әшәке яла ягучы Заһидулла хәзрәт юк. Инде әнкәйнең дә күңеле тынычлангандыр. Әткәй дә, былтыргы кебек, Заһидулла хәзрәтнең пычрак ялаларына ышанып: «Менә бит нинди синең сөекле улларың! Иркәли-иркәли бозып бетердең үзләрен!» дип борчымый торгандыр инде әнкәйне...»

Әнисе исенә төшкәч, Галимҗанның авылга тизрәк кайтып җитәсе килә башлады. Әгәр мөмкин булса, арба хуҗасы Заһит абзый кулыннан чыбыркыны алып, атны үзе куалар иде.

Галимҗан ничаклы ашкынса да, Солтанморатка шул көнне үк кайтып җитмәделәр. Ике ара, артык булмаса, йөз чакрымнан ким түгелдер. Уфадан чыкканның икенче көнендә генә ат Гыйрфан мулланың капкасы төбенә килеп туктады.

Галимҗанның, арбадан төшеп, Заһит абзыйсына рәхмәт әйтеп кулын кысуын беренче булып Габделхәким күрде. Ул, өй артындагы бәрәңге утыртылачак җирне карап, иңбашына көрәк күтәреп кайтып килә иде.

Соңгы ел эчендә малай матураеп, үсеп киткән. Күреп алуга, ул, шатлыгыннан кара күзләрен елтыратып, авызын колагына чаклы ерып, абыйсына таба атылды. Килеп җитү белән:

— Исән-саумы, абый?! — дип кулын сузды. Бу хәрәкәте дә мин хәзер кечкенә малай түгел инде! дигән мәгънәне аңлата иде.

Галимҗан, сөенеп, энесен баштанаяк күздән кичерде. Кочаклап аркасыннан какты:

— Инде син дә егет булып киләсең! — диде, ләкин эченнән: «Авыл мәктәпләреннән ерак китә алмас, укымыйча калуы әйбәт түгел», — дип көенеп уйлап куйды.

Габделхәким ян капканы ачып җибәрде дә:

— Әнкәй, Галимҗан абый кайтты! — дип кычкырып, кулындагы көрәкне ишегалдына ташлады, Заһит абзыйлары кулыннан тергәк белән китап бәйләмен килеп алды. «Болар синекеме?» дип тә сорамады. Китаплар булгач, әлбәттә, абыйсыныкы!

Заһит абзыйларына тагын бер кат рәхмәт әйтеп, ян капкадан ишегалдына кергәннәр генә иде, каршыларына ашыгып әнкәләре килеп чыкты. Ул Габделхәкимнең кычкырганын ишеткән икән. Галимҗан да анасына каршы омтылды.

Хәсәнә остабикә инде кырык биш-кырык алты тирәләрендәге олыгаеп барган хатын булса да, матурлыгы әле сулмаган иде. Киресенчә, шушы минутта шатлык нуры чәчеп торган озын керфекле кара күзләре, елмайган иреннәре арасыннан күренгән энҗедәй ак тешләре аны тагын да матуррак итә иде.

— Шөкер ходайга! Син дә сау-сәламәт кайттың! — дип, улын кочаклап, аның маңгаеннан, ике күзеннән үпте. Аннары ике кулын Галимҗанның иңбашларына куеп, үзе арткарак чикте, улының ябыга төшкән йөзенә карады.

— Бик ябыккансың, йончыгансың. Былтыр бер дә ял итмәдең шул, балам! — дип, башындагы яулыгының очы белән күзләрен сөртте.

Галимҗан әнисенең әле бер кулын, әле икенчесен алып үбә башлады.

— Чү, балам! Ниткәнең? Кирәкми! — дип, Хәсәнә остабикә кулларын ычкындырырга ашыкты.

Галимҗанның әнисе белән күрешүен читтән карап торган Габделхәкимнең сабыры бетте.

— Я, җитәр инде, абый! Әйдәгез, өйгә керик! Әнә Шакирҗан абзый да чыкты, өйгә чакыра, — диде.

— Чыннан да, нәрсә дип мин сезне монда, ишегалдында тотам! Әйдәгез өйгә,— дип, әнисе Галимҗанны яшь бала кебек кулыннан җитәкләп өйгә таба алып китте.

Өйгә керә торган өч басмалы баскыч өстендә аларны Шакирҗан каршы алды. Абый белән эне бер-беренә елмаеп, сүзсез генә кул биреп күрештеләр. Әнкәләре аларның икесенең дә аркаларыннан кагып, ишектән кертеп җибәрде. Алар артыннан Габделхәким белән үзе дә керде.

Зал дип йөртелә торган зур бүлмәдә беркем дә юк иде. Бүлмәдәге бөтен нәрсә әүвәлгечә үз урынында икән. Әнә, кергәч үк уң кулдагы почмакка зур көзге эленгән. Урамга караган ике тәрәзәгә мәк чәчәкләре чигелгән ак пәрдәләр корылган. Тәрәзә төпләрендә — яран гөлләре. Каршы стенага киң агач караватт терәп куелган. Аның өстендә — матурлап, кабартып куелган ястык-мендәрләр...

Залны үтеп, сәкеле бүлмәгә чыктылар. Сәке өстендә аякларын бөкләп Гыйрфан мулла утыра иде. Галимҗанга әтисе шактый картайган, ябыккан кебек күренде. «Әллә әткәй авырыймы икән? Алай чәче-сакалы яртылаш агарырлык бик карт та түгел бит әле!» — дип уйлады ул, ләкин бу күңелсез уйларын тыштан сиздермәскә тырышты. Күтәренке рух күрсәтеп, елмайды. Кулын күкрәгенә куеп:

— Әссәләмәгаләйкем, әткәй! — дип сәлам бирде.

Гыйрфан мулла да улының сәламен кабул итеп:

— Вәгаләйкемсәлам! Әйдә, утыр, угылым, сөйлә, ниләр алып кайттың? — диде.

Әтисенең соңгы соравында нинди борчылу барлыгын Галимҗан бик яхшы аңлады. Юкка борчылмасын өчен, ул сандык өстендәге китап бәйләмен сузылып алды. Бәйләмне чишеп, китаплар арасыннан ялтырап торган кызыл кәгазьгә бик пөхтәләп төргән бер нәрсә чыгарып бирде. Әткәсе гаҗәпләнгән кыяфәт белән бу нәрсәне улының кулыннан алды. Матур кызыл кәгазьне сүтә башлады. Шакирҗан белән Габделхәким дә кызыксынып, әтиләре янына килделәр. Ялтыравыклы кызыл кәгазь эченнән аннан да матур, ак атласка охшаган, өстенә алтын белән язган калын кәгазь килеп чыкты. Бу — Галимҗанның шәһадәтнамәсе икән. Укытылган бөтен фәннәр буенча алган билгеләре тик тәхсин генә, ягъни гел бишле генә икән. Моны күргәч, Гыйрфан мулланың чырае ачылып китте.

— Машалла! Башка ни дип әйтерсең?!—диде дә тагын:—Машалла!— дип кабатлады. Шәһадәтнамәне Галимҗанга кайтармады, тезе өстенә куйды. Ашханә ягына карап: — Анасы, кил әле! — дип кычкырды. Кулын алъяпкычына сөртә-сөртә, ашханә ишегендә күренгән остабикәсенә карап, Гыйрфан мулла чакыру ишарәсе рәвешендә кулын болгады:

— Якынрак кил әле!

Остабикә баскан урыныннан кузгалмыйча гына:

— Ни булды, тизрәк әйт инде! Ашханәдә әшем башымнан ашкан! — диде.

— Син барып Хәтимә җиңгәнне чакыр әле. Килеп энкәңә булышсын. «Абыйлар кайтты. Табын хәстәрләшергә килсен!» диген, — дип, Гыйрфан мулла сандык өстендә аякларын салындырып утырган Габделхәкимгә боерды, аннары хатынына карап: — Бераз вакытка гына сәке читенә утырсаң, балаларың ачтан үлмәс әле. Якынрак килеп, менә бу кәгазьне яхшылап карасаң, үзең дә үкенмәссең, — диде. Шәһадәтнамәне тез өстеннән алып, Хәсәнә остабикәгә сузды.

Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары Гыйрфан мулла кулындагы кәгазьнең алтын язулары белән уйнап, чаткылар кабызып алды.

— Монда чыннан да бер мәгънә бардыр, — дип, остабикә кызыксынып, сәке янына килде, иренең кулыннан шәһадәтнамәне алды.

Хәсәнә остабикә үз заманасы өчен яхшы белем алган хатын иде, ягъни укый гына түгел, яза да белә иде. Гыйрфан муллага иргә чыккач, яшь Хәсәнә остабикә булып кызлар укытырга хыяллана иде. Ләкин ул яшьлек хыялларын тормышка ашыра алмады. Троицкидан авылга, Солтанморатка, күчеп килү белән, шәһәрдә туып үскән назлы Хәсәнәне йорт-җир эше бөтен авырлыгы белән басты. Яңа урында, бигрәк тә авыл җирендә, тормыш корып җибәрү җиңел булмый шул! Караңгылы-яктылы вакытта ук җылы түшәгеңнән торып, сыер саварга, угын кертеп мичләрне ягарга, камыр басарга кирәк... Кыскасы, шундый эшләр бер-бер артлы тезелеп кенә тора. Кара төнгә кадәр шулай. Инде күнегә башладым дигәндә, балалар дөньяга килде. Аларны карарга, тәрбияләргә, үскәннәрен үстерергә, үлгәннәрен, канлы күз яшьләрен түгеп, соңгы сәфәрләренә озатырга кирәк булды... Әнә шулай Фәрдәнәне, Нәфисәне, иң соңыннан Гобәйдулланы озатты ул.

Шулай да авыл мәктәбенә биргәнче, балаларына беренче хәреф танытучы, укырга-язарга өйрәтүче, акны карадан аерттыручы ул үзе булды.

Шәһадәтнамәне кулына алып, андагы билгеләрне күргәч, ул дулкынланып бер улының, бер иренең күзенә карады. Балалары алдында беркайчан да иренә каршы сүз яки берәр кеше турында начар сүз әйтмәгән Хәсәнә остабикә бу юлы тирән үпкә хисенә бирелеп:

— Мин сиңа ничә тапкыр әйттем, эткәсе, — диде. — «Ул синең кәҗә сакал Заһидуллаң бала өстенә яла яга», — дидем. «Мондый кабахәтлекләрне эшли торган бала түгел безнең Галимҗан, булмас!» — дидем, ә син миңа ышанмадың. Имеш, олы башы белән, хәзрәт намын күтәргән кеше ялганламас, ди идең. Менә сиңа аның бөтен сүзләре ялган булуына шаһит! — дип, шәһадәтнамәне иренең алдына салды.

Гыйрфан мулла ни әйтергә белмичә, уңайсызланып, башын иде, ләкин бу уңайсыз хәлдән аны ишектән килеп кергән Хәтимә җиңги коткарды. Аны күрү белән Гыйрфан мулла:

— Я, энкәсе! Әнә, ярдәмчең дә килде. Табыныңны тизрәк хәстәрлә, карыныбыз бик ачты, — дип, хатынын ашханәгә җибәрде, аның туры сүзенә җавап бирүдән котылырга ашыкты. Хәсәнә остабикә дә, улы Галимҗанның ерак юлдан кайтканын хәтерләп, Хәтимә җиңги белән ашханәгә чыгып китте.

Ашап-эчеп алгач, Шакирҗан:

— Әзрәк йөреп килмибезме? — дип, Галимҗанны урамга чакырды. Галимҗан, ризалык күрсәтеп, утырган урыныннан кузгалган иде, әнисе Шакирҗанны шелтәләп алды:

— Урамда нинди ашыгыч эшең бар? Кешенең, рәтләп төн йокламыйча, ерак юлдан кайтканын онытма! Ичмасам, җылы өйдә безнең белән сөйләшеп утырсын азрак!..

Галимҗан кире урынына утырды. Энкәсенең бу сүзеннән соң чыгып китәргә омтылса, эткәсен дә, энкәсен дә санга сукмау булыр кебек тоелды аңа. Шакирҗан исә, урынсыз сүз әйткәнен сизеп, Габделхәким

янына, сандык өстенә барып утырды. Бертөрле дә уңайсызлык булмаган кебек, Галимҗан Габделхәкимнән:

— Син нинди эшләр бетереп, көрәк күтәреп йөри идең? — дип сорады.

Габделхәким инде табын яныннан торгач, зурларның сөйләшкәннәрен тыңлап, яраткан урыны — сандык өстенә күчеп утырган иде. Көтмәгәндә абыйсы үзенә сүз кушканын ишеткәч ул:

— Миңа әйтәсеңме, абый? — дип сорады.

— Әлбәттә, сиңа! Көрәк күтәреп килүче мин түгел, син идең бугай. Әллә мин ялгышаммы?

Габделхәким көлеп җибәрде:

— Әйе, әйе, мин идем. Бәрәңге җирен казырга дип чыккан идем. Җир әле бик юеш икән. Кайбер чокыр урыннарда кар да эреп бетмәгән. Казымадым, кире кайттым.

Бераздан Гыйрфан мулла намазга китте, Шакирҗан белән Галимҗан да урамга чыктылар. Аларның барырга дип ниятләнгән билгеле бер урыннары юк, шулай да абый белән эне икәүдән-икәү генә калырга телиләр иде.

Капка алдында бер мәл эндәшмичә торгач, алар ничектер үзлегеннән үк, күпер янына борылдылар. Күпергә барып җиткәнче сөйләшмәделәр. Аларга менә шулай берсүзсез янәшә бару да рәхәт иде. Күпер өстендә туктап, Аургазы белән Түрсегеленең апа белән сеңел кебек кочаклашып, иркенләп акканын карап тордылар. Ниһаять, Шакирҗан телгә килде:

— Халык сезнең «Галия»не бик мактый. Анда исәп-хисап кына түгел, һәндәсә, җәбер, җәгъърафия, тарих, рус теле кебек әллә ничаклы яңа фәннәр укыталар, имеш. Мәдрәсәгезнең мактаулы даны Төркстанга чаклы барып җитте. Синең шәһадәтнамәңне эткәйләр кулыннан алып карарга уңайсызландым, шуның өчен нинди фәннәрдән имтихан тотканыңны белә алмадым.

— Быел укыту программасына кергән бөтен фәннәрне укыта алмадылар, чөнки мәдрәсәнең үз бинасы салынып бетмәде, ә Зариф мулланың кечкенә мәчетендә программа буенча укытырга тиешле шартлар юк, — дип, үзенең мәдрәсә хәлләрен сөйләргә кереште Галимҗан.

Шакирҗан аны бик игътибар белән тыңлап торды һәм ахырдан үзен кызыксындырган тагын бер мәсьәлә турында сорады:

— Син кыш буе Уфада фатирда тордым дип язган идең. Быел мәдрәсәнең үз бинасы салынып бетсә, мәдрәсәдә торачаксыңмы, әллә тагын да фатирга чыгачаксыңмы? — дип сорады ул.

— Фатирга чыгармын дип уйлыйм. Шуның өчен быел язгы кыр эшләре бетү белән кая да булса китеп, имтиханнарга хәтле җитәрлек акча табу юлын карарга кирәк. Аннары бер таныш студенттан русча укырмын дигән ниятем дә бар. Кыскасы, байтак акча кирәк булачак...

— Быел мин дә сиңа ярдәм итә алмам. Менә нәрсә, Галимҗан: монда кыр эшләрен мин Әхми белән икәүләп тә башкарырмын. Ярдәмгә Габделхәким дә бар. Мин бит быел көзгә чаклы авылда булам, чөнки көз көне мин солдатка каралырга тиеш. Шулай булгач, сиңа монда артык эш тә табылмас. Син бер атна-ун көн ял ит, иртәрәк юлыңны кара. Кай якка барырга уйлыйсың?

— Яз, җәй булдымы, шәкертләрнең барысы диярлек казакъ арасына тарала. Ул якларда эш тапканчы байтак эзләнеп йөреп, вакыт әрәмгә китмәсме икән, Кавказ ягына китсәм ничек булыр икән, дип тә уйлыйм. Анда татарлар да, нугайлар да күп диләр. Күнегелмәгән, ерак юл димәсәң...

Апрель урталарында Галимҗан Кавказ ягына юлга чыкты.

Солтанмораттан чыгып киткәндә, уйсу җирләрдә, тау башларында әле карлар эреп бетмәгән, аяк асты тездән былчырак иде. Нугай даласының нәкъ уртасына урнашкан Тирәкле мәктәп дигән җиргә килеп төшкәндә әле апрель азаклары гына булса да, җәймә шикелле тип-тигез далада ямь-яшел үлән үскән, кыр үләннәре чәчәкләр аткан иде. Бер якка карасаң — бөтен дөньяга күк чәчәк сибелгән төсле, очсыз-кырыйсыз киңлек! Икенче якка карасаң — алтын төсле сары чәчәкләр киң кырны каплап алган! Нинди генә үләннәр юк монда! Менә башаклары бәләкәй генә селеркәгә охшаган зөбәрҗәт төсле яшел йонча, сарут. Әнә анда — хуш исле чабыр, әрем, бөтнек. Саф һавасын сулаган саен күкрәк киңәя, иркенәя бара кебек. Нәфис зәңгәр ефәк төсле күк йөзендә йөзеп йөргән ак болытлар әллә ничек күңелне канатландыра, үзләре белән сине дә очыртып алып китәрләр сыман...

Нугай даласы Галимҗанны әнә шулай шагыйранә каршылады.

Тирәкле мәктәп — авыл дисәң авыл түгел, шәһәр дисәң шәһәр түгел, шундый бер җир икән. Монда чыннан да ике бүлмәле мәктәп бинасы бар. Мәктәпнең ишегалдына дүрт сәрби агачы утыртылган. Шушы дүрт сәрбидән башка бөтен авылда бер агач та юк диярлек. Ләкин төньякта Кума, көньякта Терек елгалары буенда, мул тормышлы нугайларның чыгыр белән сугарыла торган алмагач, чия, йөземнәр утыртылган бакчалары — кавын, карбыз, кыяр, кабак үстерә торган яшелчә бакчалары — бустаннары бар диләр, ә бу киң далада исә алар терлек асрау белән шөгыльләнәләр икән.

Мәктәпнең бинасы булса да, мөгаллим булмау сәбәпле авылның карты-яше диярлек укый-яза белми. Шуның өчен Галимҗанны Тирәкле мәктәптә бик шатланып каршы алдылар, мәктәпне ачып, аның бер бүлмәсенә яшь мөгаллимне урнаштырдылар.

Укырга теләүче балалар күп иде. Хәтта зурлар арасында да:

— Мага сан билгеләрен өйрәтсәнә. Алыш-биреш иткәндә кирәк буладыгу! Һәммәсен исеңдә тотып булмайды. Сан билгеләрен белеп бер ергә язып куйсаң, каккан казыктай булып тора бирәдә. Кызларга[1] барып малны кибетчегә сатканда, ул чутның төймәләрен ул як-бу якка сугады да, сага фәләнчә манит дип, акча санап бирәде. Дөрес әйтәдеме, алдатадымы — алла беләде. Чут сукмага өйрәтсәң, мулла Галимҗан, синең кулыңны буш итмәс идем гу! — дип килүчеләр аз булмады.

Галимҗан үзе белән берничә әлифба китабы, егермеләп дәфтәр, карандаш алып килсә дә, чут алып килмәгән иде. Китергән дәфтәрләре, карандашлары да җитмәячәге аңлашылды. Шунлыктан, берсенең киңәше буенча, быел кысыр калган биш-алты сарыкны аякларын бәйләп арбага салдылар да, бер кешене утыртып, Кизлерга җибәрделәр, грифель такталар, дәфтәр, язу карасы, каләм, булса берничә әлифба, бигрәк тә биш-алты чут алып кайтырга куштылар.

Әллә Галимҗанның мөгаллимлек сәләте көчле идеме, әллә шәкертләрнең белемгә омтылышлары бик зур идеме — апрель аенда хәреф танымаганнар июнь аенда инде иҗекләп укый башладылар, ә исәп-хисап, чут сугарга өйрәнүчеләр хисапның дүрт гамәлен авырлык белән үзләштерсәләр дә, чут сугарга бик тиз остарып киттеләр.

«Мин моннан киткәнче балалар әлифба китабын укып чыгачаклар, укырга-язарга өйрәнәчәкләр. Киләсе елда тагын монда шул ук әлифбаны күтәреп килсәм, бу балалар өчен файдалы булмас. Укытуны дәвам иттерү өчен әлифбадан башка китаплар кирәк булачак. Ләкин нинди китаплар? Безнең үзебезнең татар телендә кулга алырлык бер кыйраәт

[1] «Кызлар» — Кизлер шәһәре.

тә юк бит! Иске мунча, иске таш дигәндәй, тагын шул «Шәрхе Габдулла», «Сөбателгаҗизин», гарәп теле сарыфы, нәхуымы?! Ә нигә соң беренче адымыбыздан башлап, соңгы сулышыбызга кадәр безгә ярдәмче булган, тормышыбызга ямь, мәгънә биргән үзебезнең ана телебез кануннарын өйрәнү урынына, көндәлек тормышыбызда кирәк булмаган гарәп теле канууннарын өйрәнәбез?!» — дип уйланды Галимҗан.

«Ләкин ана телебезнең кануннарын өйрәтә торган китапларны каян табарга соң? Алар бармы икән? Булса, ни өчен аларны мәдрәсәләребездә укытмыйлар?» — дигән сорау туды аның башында. Ләкин монда, Тирәкле мәктәптә, торып кына бу сорауларга җавап таба алмаячагын Галимҗан яхшы белә иде. Шуның өчен ул Уфага кайткач бу турыда сорашырга, эзләнергә карар итте.

Июнь ае кергәч, һава көннән-көн эсселәнә башлады. Мондый кызуга күнекмәгән Галимҗан, әүвәлге көннәрдәге кебек, балалар мәктәптән чыгып китү белән, үзе дә далага чыгарга ашыкмый башлады. Эссе кояш астында корып саргайган, күңел кузгаткыч сафлыгын югалткан дала хәзер инде аны үзенә тартмый иде. Өйлә вакытларында ишегалдына чыгарга туры килсә, үзеңне янып торган кызу мич эченә кергән кебек хис итәсең. Шуның өчен ул ахшам намазына чаклы бүлмәсеннән чыкмаска булды. Ләкин вакытын бушка үткәрергә гадәтләнмәгәнлектән, тик ятып уза торган бу сәгатьләр Галимҗанны изә, газаплый иде.

Нугай даласына килгәннән бирле, Хөсәен белән очрашу, аның белән сөйләшү әледән-әле Галимҗанның исенә төшкәләде.

«Вәли мулла мәдрәсәсендә күргәннәреңне, башыңнан үткәннәреңне язып, берәр газетага бастырырга бирсәң, бу үзе фикердәшләрегезне берләштерүгә, ислах өчен көрәшне киңәйтүгә ярдәм булыр иде»,— дигән иде Хөсәен. Аның бу киңәше Галимҗанның күңелен торган саен ешрак кытыклый башлады.

«Халыкның карты-яше яктылыкка омтыла. Әллә нихәтле Кавказ кабиләләре арасында кысылып калган бу нугайларның балалары гына түгел, олылары да белем алырга тырыша, дөньяда ачык күз белән яшәргә телиләр. Ә безнең мәдрәсәләребез мәгърифәтнең якты йөзен ачып бирү урынына, халыкны наданлык баткаклыгыннан ычкындырмас өчен бөтен көчләрен куялар! Дөрес әйтә Хөсәен абый: бу карагруһларга каршы нинди корал тапсаң, шуның белән көрәшергә кирәк! Әгәр Вәли мулла мәдрәсәсендә минем башымнан үткән хәлләр бу юлда көрәш коралы була алса, язарга кирәк!..»

Әнә шундый уйлар Галимҗанның күңеленә тынычлык бирми иде. Бер көнне дәфтәр уртасыннан алынган шакмаклы озынча кәгазьгә соңгы елларда аның йөрәген гел яндырып торган:

Ачылмасмы татарның ике күзе?
Җәһаләттән һәлак була милләт үзе!
Мондан соң күренмәсме икән безгә
Мәгъшукамез мәгарифнең якты йөзе?

— дигән юллар төште.

Кадим мәдрәсәнең бусагасын атлап кергән беренче адымыннан башлап, монда үткәрелгән соңгы көнгә чаклы шәкертнең башыннан кичкән бөтен авырлыкларны тасвир итәргә уйлады Галимҗан. Хикәянең: «Октябрьның соңгы көннәре якынлашты»,— дигән беренче сүзләре язылды.

«Галия»дә кыш буе җилем басма газетага мәкаләләр яза-яза Галимҗанның каләме шомарган иде. Әйтергә теләгән фикерен укучыларга аңлатырлык сәләт сизә иде ул үзендә. Бер яктан, язу теләге көчәя барганга, икенче яктан, тасвир итәргә теләгән вакыйгаларның һәрберсе диярлек үз башыннан кичкәнгә яки күз алдында булып үткәнгә, бу беренче әсәр тиз һәм җиңел язылды. Күңелендә кадим мәдрәсәгә каршы

сакланган бөтен нәфрәтен әйтеп бетергәч, ул еллар дәвамында йөрәк төбенә кара кан булып җыелып килгән чиксез авыр хатирәләрдән арынган төсле булып, җиңеләеп китте.

Тирәкле мәктәптән китәр вакыт җиткәндә, хикәя инде язылып беткән һәм исеме «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дип куелган иде.

Шәһиттән алган соңгы хатта, Казанда «Әльислах» исемле яшьләр газетасы чыгачак, дигән хәбәр бар иде. Аның язуына караганда, бу газета үзенең төп максаты итеп мәктәп-мәдрәсәләрдә ислах өчен көрәшне куячак икән. Шуның өчен Галимҗан үзенең беренче әсәрен бу газетага җибәрергә булды.

## 9

1907 елның октябрь башларында шәкертләр «Галия»гә җыелганда аларны төшләренә дә кермәгән бер күренеш — таштан салынган өч катлы бина каршылады. Мәдрәсә искиткеч иде: аның иң өске өченче катында — сыйныф бүлмәләре. Бүлмәләрдә — ялт итеп торган өр-яңа кара парталар, язар өчен зур кара такта элеп куелган, тәрәзәләре зур, яп-якты... дәрескә керү-чыгу кыңгырау белән.

Урта катта ятак бүлмәләре. Монда ике катлы караватлар. Караватларда матрас, мендәр, юрган. Иске мәдрәсәләрдә башка баш, аякка аяк куеп идәндә тезелешеп ятарга күнеккән шәкертләргә караватларның ике катлы булуы да сәер күренмәде, киресенчә, мәдәни бер комфорт булып тоелды.

Аскы катта ашханә, кухня һәм башка хуҗалык бүлмәләре. Бу катта шулай ук аш пешерүче, аның ярдәмчеләре һәм башка эшчеләрнең фатирлары.

Тик быел ашау бушлай түгел икән. Шулай да шәкертләрнең күпчелеге мәдрәсә ашханәсендә ашарга булды, чөнки ашларны монда бик яхшы, тәмле итеп пешерәләр, хаклары да укучыларның хәле җитәрлек арзан иде.

Шәкертләрнең саны да быел былтыргы белән бөтенләй чагыштыра торган түгел: өч йөздән артык! Кай яклардан гына килмәгәннәр! Монда җилем басма «Аң» газетасының тәэсире яхшы булган, күрәсең. Һәрхәлдә, безнең яшь газетачыларыбызның күңелләрендә шундый горурлык хисе юк түгел иде.

Укытучыларның да саны былтыргыдан артык. Инде җәбер-алгебра, һәндәсә-геометрия, физика кебек фәннәр дә укытыла башлаячак, имеш.

Галимҗан хикәя язып, «Әльислах» редакциясенә җибәрүе турында иң якын дусларына да бер сүз әйтмәде, ләкин үзе мәдрәсәгә килеп керү белән китапханәгә ашыга. «Вакыт», «Таң йолдызы», «Казан мөхбире» кебек дикъкать белән карап чыга торган газеталарын читкә алып куя да «Әльислах»ны эзли башлый иде. Менә ул бүген дә газетаны кулына алу белән соңгы битендәге «җаваплар»га күз ташлады. Гадәттә, газеталарның бу битендә төрле кимчелекләре булу сәбәпле кабул ителмәгән әсәрләрнең авторларына киңәшләр басыла иде. Галимҗан монда үзенең яки әсәрнең исемен тапмагач, башка битләрне дикъкать белән карап чыкты. Ләкин аңа күп көтәргә туры килмәде. Тик шунысы гаҗәп булды: мәдрәсәгә килеп керү белән китапханәгә чапкан Галимҗан беренче хикәясе басыла башлаган санны иң элек үзе күрә алмады. Газетаның ул саны җомга көн кичкырын килгән икән. Җомга көннәрдә татар мәдрәсәләрендә дәресләр булмаганлыктан, читтә квартирда яшәгән Галимҗан ул көнне мәдрәсәгә бармыйча, якын иптәшләрен үз фатирына чакырган һәм шәкертләрнең белем дәрәҗәләрен арттыру өчен «Белем җәмгыяте» дигән бер түгәрәк төзү турында киңәшләшеп утырганнар иде.

Шимбә көнне мәдрәсә ишеген ачып, коридорга аяк басу белән, аны иптәшләренең сәер күз карашлары гаҗәпләндерде.

«Әллә өс-башымда берәр кимчелек бармы икән?» — дип уйлады Галимҗан. Ләкин бу фикереннән шундук кире кайтты. Әгәр шулай булса, шәкерт дигән адәм күрү белән генә чикләнмәс, шаркылдап көләр, мәзәк сүз әйтеп, артыннан кычкырып калыр иде. Димәк, башка сәбәп бар...

Галимҗанның бу шиген мәдрәсәнең үзендә яшәгән Шәһит белән Вәсим тараттылар. Алар кичә Галимҗанның фатирыннан кайткач, «Әльислах» газетасын укып өлгергәннәр икән.

— Күрдеңме, Галимҗан, «Әльислах» газетасында синең әсәреңне бастыра башлаганнар, — дип, шат чырай белән кычкырды Шәһит.

— Кадим мәдрәсәсенең нәкъ үзен тасвир иткәнсең! Укыганда җылыйсың да, көләсең дә килә! Инде дәвамы кайчан чыгар икән? — дип сорады Вәсим.

— Егет икәнсең, Галимҗан! — дип кычкырып, шул арада каяндыр Салих та атылып килеп чыкты.

Галимҗан тирәсенә шәкертләр җыела башлады. Язучы булып, әсәр язып, газеталарда бастыргач, аның тышкы кыяфәтендә дә әдиплеген белдереп торган берәр галәмәт бардыр, тик без моңарчы илтифат кына итмәгәнбездер,— дигән сыман, алар Галимҗанга текәлеп-текәлеп карыйлар иде.

— Бөтен шәкертләрнең исе китте! Кичә «Әльислах»ны чак кына өзгәләп бетермәделәр! Берсенең кулыннан икенчесе тартып алып укыды!..— дип, Шәһит, үз әсәре турында сөйләгән кебек, җанланып сөйли башлаган иде, аның сүзен Галимҗан тирәсенә җыелган иптәшләрен ерып кергән Фәтхел бүлде:

— Нинди әчле кеше икәнсең, Галимҗан! Һичбер кемгә әйтмәстән, шыпырт кына йөрисең, ә үзең язучы булып, әсәр язып Казан газеталарында бастыра башлагансың! — дип, Фәтхел Галимҗанның аркасыннан какты һәм: — Нигә моңарчы әсәр язганыңны бездән яшереп йөрдең? — дип сорады.

— Алдан кычкырган күкенең башы таз була, диләр бит. Әгәр басмаган булсалар, нишләр идем? — диде Галимҗан, иптәшләре арасыннан чыгып, китапханәгә таба атлады.

Анда Галимҗанның үз исеменә җибәрелгән газета шактый таушалган булса да, сакланган икән. Галимҗан газетаны бик җентекләп карап чыкты, шуннан соң пөхтәләп бөкләде дә куен кесәсенә тыкты.

## 10

Үткән җомга көнне Галимҗанның фатирында «Белем җәмгыяте»н төзүгә каршы чыккан кеше булмады. Тик Фәйзерахман гына нәрсәдәндер риза булмаган шикелле:

— Әле кайчан гына үзең «Вәли мулла мәдрәсәсеннән соң «Галия»гә килеп кергәч, зинданнан якты дөньяга чыккан кебек булдым», дип сөйли идең, хәзер «Галия»дән дә мең төрле кимчелек табасың,— диде.

Моны ул, әлбәттә, «Белем җәмгыяте»нә каршы булганлыктан әйгмәде. Киресенчә, бу фикернең иң ялкынлы тарафдары иде ул. Аны гаҗәпләндергәне дә шул иде: бер ел үтәр-үтмәс үк Галимҗанның «Галия»гә карашы үзгәрде, аннан да бигрәк, мәдрәсәдәге кимчелекләрне башкалардан алда күреп өлгерде.

Фәтхел Корбангалиев Фәйзерахманның бу сүзен туры мәгънәсендә аңлады:

— Идарә алдына без тиешсез таләпләр куябыз дип уйлыйсың бугай син! Алай булса, ни өчен син моңарчы риза түгеллегеңне әйтми

йөрдең? Бу бит инде бүген генә туган мәсьәлә түгел! Газетабызда гына мең дә бер тапкыр язылды бу хакта! — дип кыза башлады ул.

Фәйзерахман сикереп торып җавап бирергә дип авызын ачкан иде, Салих аны сөйләтмәде:

— Әллә без үтәлмәслек таләпләр куябызмы? — диде ул.— Рус теле вә әдәбияты укытылсын дип былтыр мәдрәсәдән таралыр алдыннан ук әйтелгән иде бит. Идарә, ризалык күрсәтеп, быел укулар башлануга мөгаллим алырга вәгъдә иткән иде. Укулар күптән башланды, ә вәгъдә ителгән мөгаллим кайда соң?!

Ниһаять, Фәйзерахманга да сүз тиде:

— Кем сезгә, «Урманов таләпләргә каршы», дип әйтте?! Галимҗанның шундый өлгер булуына гына исем китеп әйткән идем мин ул сүзне, ә сез шунда ук мине чукый башладыгыз. Былтыр таләпләребезне рәткә салып идарәгә тапшыру фикере иң элек Галимҗанның башына килгән иде. Быел да «Белем җәмгыяте» төзү мәсьәләсен беренче булып ул уйлап чыгарды. Шулай түгелме?..

Галимҗан кулын селтәде дә:

— Юк-бар сүзләреңне куеп тор әле! — диде.— Бу фикерне бүген мин әйтмәгән булсам, иртәгә син әйткән булыр идең. Адәм баласы чынчыннан инсан булса, аның ихтыяҗлары, тормышка таләпләре артканнан-арта бара. Бу — аны хайваннан аерган хосусият дип уйлыйм мин. Әгәр сез дә шул хосусияткә ия булмасагыз, хәзерге сәгатьтә монда килеп үз ихтыяҗларыгыз турында сөйләшеп утырмас идегез, — диде ул. Иптәшләре ихтыярсыз көлеп җибәрделәр. Моңарчы эндәшми генә утырган Вәсим сүзгә кушылды:

— Мәсьәлә бит кем беренче, кем икенче булып әйтүдә түгел. «Галия» күп мәдрәсәләрдән алда торса да, безнең теләкләребезне тулаем үти алмый. Менә бит, вәгъдә ителгән белемле мөгаллимнәр чакырылмаган, ә хакы базар көнендә сукыр бер тиенгә тормаслык надан назир мәдрәсәдән куылмаган. Имеш, ул Закир байныңмы, яки башка берәүнеңме туганнарыннан икән. Шуның өчен аны мәдрәсәдән куып булмый икән!..

— Әгәр эчке идарәдә үзебезнең вәкилебез булса, мәдрәсәдәге кимчелекләрнең күбесе инде төзәтелер иде, чөнки ул идарәнең биргән вәгъдәләрен оныттырмас, хәтерләренә төшерә торыр иде! — диде Булат.

Менә шулай сөйләшүдән соң, «Идарә бу көнгәчә биргән вәгъдәләрен үти алмаган икән, без үз көчебез белән белемебезне арттырырга тырышыйк, үзебезне әтрафлырак уйларга, киңрәк фикер йөртергә күнектерик», дигән карарга килделәр. Идарә белән сөйләшеп, «Белем җәмгыяте»нә рөхсәт алу эше Галимҗанга тапшырылды.

Зур тәнәфес вакытында Галимҗан Зыя Камалиның кабинетына керде. Остазы һәр вакыттагыча аны ачык йөз белән каршы алды һәм, урындык күрсәтеп, утырырга тәкъдим итте. Шуннан соң гына:

— Ихтыяҗыгыз нидән гыйбарәт, Галимҗан мәхдүм? — дип сорады.

Зыя Камалиның мәдрәсәдән ачык фикерле, җитлеккән кешеләр тәрбияләп чыгарырга тырышканлыгын Галимҗан бик яхшы аңлый иде. Шул сәбәпле, остазының шәкертләр теләгенә каршы килмәячәгенә ышанып, сүзне бик тыныч башлады:

— Безне нинди теләкләр, нинди ихтыяҗлар дулкынландырганын сөйләп тору хаҗәт түгел, чөнки бу турыда идарәгә тапшырган таләпнамәбездә әйтелгән иде,— диде ул.— Белемебезне арттыру, фикеребезне әтрафлы, тирән йөртергә өйрәнү юлында һичшиксез без үзебез дә бөтен көчебезне куеп тырышырга тиешбез! Шул теләк белән «Белем җәмгыяте» дигән фикри вә гыйльми җәмгыять төзүне лазым күрдек. Бу турыда сезнең белән сөйләшеп, фикерегезне белүне иптәшләрем миңа тапшырдылар...

Зыя Камали Галимҗанның сүзләрен дикъкать белән тыңлап торды. Бераз уйланып утыргач:

— Сезнең үз көчегез белән белем алу юлында тырышуыгызга каршы килә алмыйм. Ләкин җәмгыятегезнең низам-интизамы ничек корылачак, җыелышларыгызда нинди мәсьәләләр тикшереләчәк — боларның һәммәсен мин белергә тиеш. Сезгә идарә исеменә җәмгыятегезнең уставын язып бирергә кирәк булыр, — диде ул.

Идарә башлыгы тарафыннан шундый шартлар куелачагын Галимҗан алдан ук белгән иде, шуңа күрә аның җавабы да әзер иде.

— Безнең фикеребезчә, бу җәмгыятьнең утырышларында теләгән һәрбер шәкерт катнаша ала. Утырышлар ике атнага бер тапкыр үткәрелеп, нинди дә булса бер мәсьәләгә багышланачак. Һәрбер мәсьәлә буенча берәр шәкерт хәзерләнеп реферат укыячак. Оештыру комиссиясе утырыштан бер атна элгәре шәкертләргә: «Киләсе утырышта шул мәсьәлә мөзакәрә кылыначак. Бу турыда сөйләргә теләүчеләр булса, хәзерләнеп килсеннәр», — дип игълан итәчәк. Рефератны тыңлаганнан соң, мөзакәрәгә катнашырга теләп хәзерләнеп килгән шәкертләр сүз алып, үз фикерләрен әйтәчәкләр...

Галимҗан, сүзеннән туктап, кесәсеннән бер дәфтәр чыгарды да остазына сузды:

— Бу — җәмгыятьнең уставы.

Дәфтәрне алгач, Зыя Камали тагын бер сорау бирде:

— Әлбәттә, алдан хәзерләнеп куйган берничә мәсьәләгез бардыр. Мисал өчен бер-икесен күрсәтә алмассызмы?

— Ни өчен күрсәтмәскә? Беренче мәсьәлә: «Татар халкының артта калуының сәбәпләре нәрсәдә?» Икенчесе: «Үзебезне һәм халкыбызны үстерү, житлектерү өчен безгә нинди белемнәр кирәк вә без кайсы халыктан гыйбрәт алырга тиешбез?» Өченчесе: «Хатын-кызларга уку кирәкме-юкмы?..» Хәзергә менә шул өч мәсьәлә билгеләнде.

Зыя Камали кыска, сирәк сакалын ике бармагы арасына алып сыйпады, уйчан күзләрен югарыга текәде. Уйланды, Галимҗан булган, Галимҗан җитәкчелек иткән җәмгыятьнең утырышларында тышкы идарә әгъзалары, ягъни мәдрәсәгә акчалата ярдәм бирүче байлар арасында ризасызлык тудыра торган күп сүзләр, күп фикерләр әйтеләчәген ул бик яхшы белә иде. «Минем ике ут арасында янганымны белми яки белергә теләми бит бу егет. Бер яктан, шәкертләрнең хаклы теләкләрен үтәргә теләсәң, икенче яктан, байлар тавыш күтәрәләр, иганәбезне туктатабыз дип куркыталар!» — дип борчылды Зыя әфәнде. Ниһаять, ул:

— Бу, әлбәттә, бик яхшы план,— диде.— Мондый эш башлавыгызга минем тарафтан һичбер төрле каршылык юк дип әйтер идем, ләкин бер-ике шарт куярга мәҗбүр булачакмын, — дип, тагын бераз уйланып торды. Шуннан соң шартын әйтте. — Һәрбер җыелыш алдыннан тикшереләчәк маузуг[1] буенча кыскача тезисларыгызны идарәгә белдерүегез кирәк булыр. Икенчедән, җыелышларыгызга мөгаллимнәрегезгә дә катнашырга рөхсәт ителсен...

Җәмгыятьне төзүгә каршылык юклыгын сизеп, Галимҗан аякка басты.

— Димәк, җәмгыятьне оештыру мәҗлесен бүген үткәрергә рөхсәт? Мин шулай аңладым, — диде. — Беренче җыелышта укылачак рефератның маузугын да бүген игълан итәрбез. Беренче рефератны Фәйзерахман Урмановка тапшырабыз. Сез үзегез дә, башка мөгаллимнәр дә мәҗлесләрдә кадерле кунак булырсыз. Рәхим итегез! — дип башын иде.

— Хәерле сәгатьтә! — дип, Зыя Камали да башын какты. Шул минутта ук коридорда, тәнәфес беткәнен белдереп, кыңгырау шалтырый башлады.

---

[1] Маузуг — тема.

— Долой!..
— Бойкот!..
— Мөртәт!..
— Сөйләмәсен!..
— Тыңламыйбыз!..
— Сөйләсен!..
— Монда һәркем үз фикерен әйтергә хаклы!
— Ник кычкырасың? Әллә син үзең бик динлеме? Тәһарәтсез намазга йөрисең!..

Җыелыш булмасендә әнә шундый колак тондыргыч шау-шу купты. Берәүләр өстәлгә йодрык сугып кычкыра, икенче берләре йодрыгын селкеп акыра, аяк тибеп тавышлана иде...

Җыелышны алып барган Галимҗан урыныннан торды да кулындагы карандаш белән өстәлгә шакыды. Шәкертләр бераз тынган кебек булдылар.

— Кычкырмагыз әле! Бу бит сезгә базар түгел! Бу — белем җәмгыяте! — дигәнне ишеткәч, шәкертләр бөтенләй тын булдылар. Галимҗан сүзен дәвам иттерде: — Салих дус татар халкының хәзерге рәвештә артта калуының төп сәбәбе ислам дине ди икән, бу — аның фикере. Кешенең ышанычын кычкыру, көчләп авызын ябу белән генә җиңеп булмый. Аллага ышану-ышанмау — һәркемнең вөҗдан эше. Сезнең вөҗданыгыз аның карашын кабул итми, тугры түгел дип таный икән, шул фикерләрегезне исбат итәрлек дәлилләр күрсәтеп, уртага чыгып сөйләгез...

Үзе тупасрак булса да, һәр нәрсәдән кимчелек табып, ризасызлык күрсәтеп йөргән Мәндиев:

— Әллә син үзең дә Салих кебек мөртәтләрнең берсеме? — дип кычкырды.

Мәндиев ише тагын берничә шәкерт шау күтәрде:

— Салихка бойкот! Сөйләмәсен! Без аны тыңларга теләмибез!

Аларга каршы:

— Бу сезгә кадим мәдрәсәсенең моназарасы түгел! Оялмыйсызмы? — дип кычкырдылар.

Галимҗан тагын торып басты. Кулындагы карандаш белән каты итеп өстәлгә шакыды. Ниһаять, шау-шу тына башлады.

— Мондый әдәпсезлек күрсәтеп кычкырышканчы, сүз алып фикерегезне әйтегез! Кем сөйләргә тели? — диде ул.

Сөйләргә теләүче табылмады. Шәкертләр эндәшми калдылар. Бераз көтеп торганнан соң, Галимҗан:

— Димәк, сүз сораучылар юк, — диде. Тагын беравык көтеп торды. Берәү дә эндәшмәгәч, дәвам итте: — Сөйләргә теләүче булмаса, рөхсәт итегез, мин бер-ике фикеремне әйтәм. Башта, бүгенге утырышыбызның тәртибе, дөресрәк әйткәндә, тәртипсезлеге турында. Безнең «Мәдрәсәи галия»нең мактанырлык хосусиятләренең берсе — шәкертнең рухын измәскә тырышу, аңа мөмкин кадәр ирек бирүдер. Әмма безнең бүгенге кычкырышуларыбыз нине күрсәтте? Кадим мәдрәсәсенең тунлыгыннан безнең үз рухыбыз котылып җитмәгәнен күрсәтте түгелме? Башкаларның игътикадын күкле-яшелле тавыш чыгарып кычкыру, сүгенү белән җиңеп була дигән иске моназара кагыйдәләрен без миебездән кырып-себереп ташлый алмаганбыз икән...

Шәкертләрнең күпчелеге уңайсызланып, башларын түбән иделәр.

Мәндиев тагын түзмәде:

— Татарны артта калдырган нәрсә — ислам дине, ди бит ул! Бу — бөтен ислам галәме ислам диненнән кайтып, урыс булсын димәк түгелме? — дип кычкырды.

— Галимҗан дөрес әйтте: дингә, аллага ышану-ышанмау һәркемнең вөҗдан эше. Аллага ышанмаган кешене көчләп ышандырып булмый,— дип башлаган иде Салих, Фәтхел аның сүзен бүлде:

— Безнең татар халкы, киресенчә, бигрәк, артыгы белән, дингә бирелгән. Дөнья өчен кайгыру кирәкми, ахирәтне, оҗмахны гына уйлап яшәргә кирәк, ди ул. Тиздән ахыр заман килер. Дәҗҗал, Яәҗүҗ-Мәәҗүҗ чыгар, мин исә чалган корбаннарыма атланып, сыйрат күперен кичәрмен дә, оҗмах түрендә утырып, хур кызлары кочып, җирне күтәреп торган үгезне суеп, аның итен ашап кәефләнермен дип уйлый ул. Башкада эше юк...

Урманов шаяртмыйча булдыра алмады:

— Кем үз ихтыяры белән оҗмахның шундый кәеф-сафасыннан баш тартыр?!

— Син шаяртуларыңны куеп тор әле, Фәйзерахман. Фәтхел бик дөрес әйтә, — дип, Галимҗан иптәшенә кырыс караш ташлады да башкаларга карап: — Иске тормышны җимереп, яңа тормыш кору юлындагы һәрбер хәрәкәткә дин исеменнән сугыш ачулар күз алдыбызда бит. Безнең мондагы күпчелегебез яңа тормыш юлындагы көрәшкә катнашканыбыз өчен дин нигезенә корылган кадим мәдрәсәләрдән куылган шәкертләр түгелме? — диде.

«Безнең үз әдибебез» дип горурланып йөргән шәкертләр Галимҗанны бик хөрмәт итәләр иде, аның сөйләгән фикерләре Салихның шау күтәргән фикереннән әллә ни ерак булмаса да, аны тавыш-тын чыгармыйча тыңладылар. Тик әлеге дә баягы Мәндиев кенә тагын үзенекен тәкърарлый башлады:

— Син дә татар халкын тәрәкъкый иттерер өчен аны динсез ясарга, алладан биздерергә кирәк, дип әйтмәкче буласыңмы?

— Сине берәү дә көчләп динсез итәргә тормый. Тик син үзең генә тәһарәт алмыйча, бәдрәфтән туры мәчеткә китеп, башкаларга гыйбрәт булып йөрисең! — дип, Вәсим аның авызын каплады. Шәкертләр шаркылдап көлештеләр, кызып бәхәсләштеләр. Галимҗанның соңгы сүзләре аларны тагын уйга калдырды:

— Татарның артта калып, наданлык сазлыгында яшәвенең сәбәбе тик ислам диненең тәэсире генә түгелдер, моның тагын бер-ике бик әһәмиятле сәбәпләре бардыр. Соңгы елларда безгә тормыш биргән сабакларны онытмаска кирәк... Ләкин хәзер, вакыт бик соң булганлыктан, бу турыдагы чыгышларны киләсе утырышка калдырсак та ярый. Киләсе атна кичкә иптәшләр тирәнрәк уйланып, хәзерләнеп килсәләр, бик яхшы булыр иде. Шуның белән бүгенге утырышны ябык дип игълан итәм...

## 12

Бу утырышта сөйләнгән сүзләрне Закир байга кем җиткергәндер, анысы билгесез калды. Дөрес, Мәндиевтән һәм аның ише бер-ике шәкерттән шикләнделәр шикләнүен, ләкин аларның якаларыннан тотарлык дәлилләр булмагач, бер нәрсә дә эшли алмадылар.

Утырыш булганның икенче көнендә үк Закир бай, өйлә намазыннан чыгу белән, Зыя Камалины, «ашка» дигән булып, үз өенә алып китте. Байның җыерылган кашлары, чал керә башлаган кыска мыегы астыннан турсаеп торган иреннәре мәсьәлә ашта гына түгеллеген, көтелмәгәндә «ашка» чакыруның башка сәбәбе булырга тиешлеген аңлата иде. Зыя Камалидан башка тагы «Галия» мәдрәсәсенә акчалата ярдәм биреп торучылардан ике бай да чакырылган икән.

Бүлмә европача җиһазланган. Уртада — ак ашъяулык җәелгән зур өстәл. Аның тирәсендә — йомшак урындыклар. Өстәлнең нәкъ уртасы-

на туры китереп түшәмгә асылган алсу абажурлы, түгәрәк филтәле зур лампа. Тәрәзәләрдә тюль һәм бәрхет пәрдәләр. Идәндә калын, йомшак келәм. Стеналарда алтын төсенә буялган рам эчендәге шамаилләр белән янәшә табигать күренешләре ясалган рәсемнәр. Йорт эче европача җиһазланган булса да, өй хуҗасының хатыны кунаклар янына чыкмады, алар белән бергә ашка утырмады. Тавык шулпасын да, тутырган тавыкны да, каз бәлешен дә — берсе артыннан икенчесен байның яшь приказчигы ташый торды. Өстәлгә татлы бәлешләр белән самавар килеп утырганчы, сүз тик кунакларны сыйлау, ашларны мактау тирәсеннән үтмәде. Өстәл өстенә самавар килеп утыргач, Закир бай: «Чыгып кит!» — дигән мәгънәдә приказчикка ишарә итте. Кунакларны күздән кичерде. Аның йөзе һаман да болытлы көн төсле караңгы иде. Сүзне мәҗлеснең асыл максатына күчерергә вакыт җитте дип уйлап, ул:

— Мөхтәрәм Низаметдин вә Галәветдин әфәнделәр! — дип кереште. Зыя Камалиның исемен әйтмәде.

Камали тәшвишкә төште: «Бу — бушка булмас... Тагын берәр җасусы мәдрәсә турында нинди дә булса гайбәт сөйләгәндер», — дип борчыла башлады.

Закир бай исә сүзендә дәвам итте:

— Без, «Мәдрәсәи галия диния»не динемезне ныгытучы ышанычлы бер терәк булыр дип, кулыбыздан килгәнчә, хәтта кулыбыздан килгәненнән артыграк та, акчалата ярдәм күрсәтеп торабыз. Безнең кебекләрнең һиммәте белән татар дөньясында моңарчы булмаган, күрелмәгән өч катлы таш бина салынып, мәдрәсә ачылды. Төрле-төрле фәннәрдән мөгаллимнәр чакыртылып, аларга һичбер мәдрәсәдә булмаган, күрелмәгән зур жалованьелар биреп торабыз!

«Менә, һәр вакыт шулай, мәдрәсәне без кордык, без төзедек, мәдрәсә безнең акчага яши диләр дә, сүзне шул өч катлы бинадан башлап, мөгаллимнәргә түләнә торган эш хакы белән бетерәләр. Әмма мәдрәсәнең эчке мөндәриҗәсендә, шул мөгаллимнәрнең шәкертләрне мөстәкыйль фикер йөртә алырлык белемле, мәгърифәтле кешеләр итеп тәрбияләргә тырышуларында байларның эше юк!» — дип ачынды Зыя Камали, ләкин бу уйларын тыштан һичбер хәрәкәт яки сүз белән сиздермәде.

Закир бай чыннан да укыту, тәрбия мәсьәләләренә тукталып тормады:

— Ләкин мәдрәсәдәге вакыйгалар безнең биргән акчаларыбызның әрәмгә киткәнен күрсәтәләр! — дип тавышын күтәргәннән-күтәрә барып, ниһаять, ул Зыя Камалига усал күз карашы белән кадалып алды. Әмма Камали гадәттәге сабырлыгын җуймады. Байның сүзләрен ул ахырга кадәр тынычлык саклап тыңларга булды. Һөҗүменә каршы Зыяның бер сүз дә әйтмичә утыруын күреп, бай тагын да гайрәтләнеп китте:

— Тар балаклы ычкырсыз чалбарлар киеп, чәч үстереп попка охшап йөрүләрен, муллаларны, байларны рисвай кылып күрсәткән театрларга йөрүләрен монда сөйләп утырасы юк. Бу турыда үз вакытында сүз булган иде дә, «Ни эшлисең, замана яшьләре. Мәсьәлә тышкы кыяфәттә түгел бит. Аларның күңелләре саф. Алар җаннары-тәннәре белән укуга, белем алуга, мәдрәсәдән чын мәгънәсендә зыялы кеше булып чыгуга бирелгәннәр», дигән сүзләр белән күз буяп, мәдрәсәнең эчке идарәсе безнең бик хаклы булган таләпләребезне кире кайтарган иде. Менә бу замана яшьләре кичә үзләренең тышкы кыяфәтләрен генә түгел, эчке кыяфәтләрен дә күрсәткәннәр!..

Әйткән сүзләренең тәэсире тагын да көчлерәк булсын өчен, Закир бай бармагын янады да, кунакларына мәгънәле итеп карап, тукталып торды.

ГӨЛСЕМ МӨХӘММӘДОВА ◆ ЯШЬЛЕК КӨННӘРЕ

Аның «муллаларны, байларны рисвай кылган театрларга шәкертләрнең йөрүен» искә алуы тикмәгә генә түгел иде. Моннан берникадәр вакыт элегрәк приказчиклар клубында һәвәскәрләр тарафыннан спектакль-комедия куелган икән. Бу комедиядә Закир бай белән «Госмания» мәдрәсәсенең баш мөдәррисе Хәйрулла ахун бик көлке рәвештә күрсәтелеп, мәсхәрә ителә дигән хәбәр алдан ук таралган булган. Шул хәбәрне ишеткәч, Хәйрулла ахун белән Закир бай берләшеп, «Галия» һәм «Госмания» шәкертләре бу спектакльгә бармаска тиешләр дип әмер биргәннәр. Бу аз булса: «Безнең сүзне тыңламыйча кәмит карарга барган шәкертләрнең исем-фамилияләрен язып бирерсең!» дип, Хәйрулла ахун мәчетенең мәзинен яллап театрга җибәргәннәр.

Комедия куелган көнне, әлбәттә, клуб бинасы «Галия» шәкертләре белән тулы булган. Икенче көнне үк Закир бай дулап, театрга барган шәкертләрнең исемлеген тотып, мәдрәсәгә үзе килеп чыга. Эчке идарә белән тышкы идарәнең берләшкән утырышын җыеп, исемлектә күрсәтелгән шәкертләрне «итагатьсезлекләре, бозыклыклары» өчен мәдрәсәдән куыгыз, дип таләп итә. Ләкин тышкы идарәдә әгъза булган байлар, үзләре турында комедиядә сүз булмагач, Закир байның таләпләренә кушылмыйлар, хәтта мыек астыннан көлеп:

— Бу турыда гайбәтләрне, Закир әфәнде, сез үзегез кабартып, таратып йөрмәсәгез дә булыр иде. Бер-ике атна да үтмәс, бу кәмиттә әйтелгәннәрнең барысы да онытылыр, — дип үгетлиләр.

Инде җәмгыять мәсьәләсе килеп чыккач, Закир бай шәкертләрдән ул вакыттагы үчен алырга ниятләде.

Моңарчы Закир байның сүзләрен дикъкать белән тыңлап утырган Галәветдин бай:

— Тагын ни эшләгәннәр бу тынгысыз шәкертләр? — дип сорады.

— Аларның ни эшләгәннәрен миннән түгел, менә каршыгызда утырган Зыя әфәнде Камалидан сорагыз. Мәдрәсәнең мөдире ул. Ни булганын ул сезгә миннән тәфсиллерәк сөйләп бирер,— дип җавап кайтарды Закир бай.

Зыя Камали кичә, «Белем җәмгыяте»нең утырышы башлангач, шәкертләр янына кергән иде, ләкин аларның тартынганын күреп: «Яшьләргә комачауламыйм, иркенләп сөйләсеннәр!» — дип, утырыштан чыгып киткән иде. Шәкертләрнең һәр адымын тикшереп, тәфтишләп утыра торган гадәте юк иде аның. Шуның өчен үзе чыгып киткәч, мәҗлестә кемнәр, нәрсә сөйләгәннәрен ул белми иде. «Мәдрәсәнең башлыгы булып, мәдрәсәдә ни сөйләнгәнен, ни эшләнгәнен белмисең икән!» дигән шелтәне ишетәсе килми иде аның. «Бәлки ул кадәр кабартырлык нәрсә дә юктыр, тыңлап карыйм»,— дип уйлап, Камали бик сабыр тавыш белән:

— Мөхтәрәм Закир әфәнде, сүзне сез башлагач, тәмамларга да сез тиеш дип уйлыйм мин,— диде.

Закир бай исә, куе кара кашларын югары күтәреп, болай да зур кара күзләрен тагын да зуррак ачып, хәттән тыш гаҗәпләнгән кыяфәт белән Зыя әфәндегә карады:

— Имеш, мин башладым, мин тәмамларга тиеш икәнмен! Ә сез читкә кагылып калырга тиешме? Мәдрәсәнең эчке идарә башлыгы кем? Минме, сезме? Мәдрәсәнең эчке низам-интизамы, уку-укыту, тәрбия эшләре кемгә тапшырылган? Миңамы, сезгәме, мөхтәрәм Зыя әфәнде?!

Бу сүзләрне әйткәндә Закир бай бармагын өстәл читенә сугып-сугып әйтте. Аның шулай кылануы Зыя Камалига һич тә ошамады. Байның аны кимсетергә, түбәнәйтергә тырышуы ачык күренеп тора иде. Кабара барган ачуын басарга тырышып, ул сабыр тавыш белән:

— Закир әфәнде, мин сезнең приказчигыгыз да, кибет малаегыз да түгел. Шуның өчен минем белән сөйләшкәндә бармак янамыйча, кычкырынмыйча, тыныч кына сөйләшүегезне үтенәм, — диде.

Галәветдин бай Закир байның сүзләреннән мәдрәсәдә ниндидер ямьсез бер вакыйга булган дип белә, ләкин мәсьәләнең асылына төшенеп җитә алмый утыра иде. Шуның өчен ул Закир байга:

— Мөхтәрәм Закир әфәнде, мәдрәсәдә ни булганын безгә дә сөйләп бирсәгез, яхшы булыр иде, — дип мөрәҗәгать итте.

Низаметдин бай да аның сүзен куәтләде:

— Чыннан да, чыннан да! Ярамаган бер эш булганын төшендек төшенүен, әмма ләкин асылда ни булганын, шәкертләрнең нинди җинаять эшләгәннәрен әле һаман анлый алмый утырабыз..

Зыя Камалиның үз дәрәҗәсен белеп әйткән сүзләренә каршы мондый «тәкәбберлек»не күреп өйрәнмәгән Закир бай җавап кайтарырга сүз таба алмыйча калган иде. Байларның үтенечләрен ишеткәч, ниһаять, телгә килде. Зыя Камалига кадалып караган күзләрен байларга күчерде:

— Остазлары Зыя Камалиның рөхсәте белән, шәкертләр «Белем җәмгыяте» дигән бер нәрсә тәшкил иткәннәр икән. Кичә шул җәмгыятьнең мәҗлесе булган, бу мәҗлестә шәкертләрниләр сөйләгән дисез? Беләсегез килсә, Зыя Камалиның тәрбия итмәктә булган шәкертләренең фикере буенча, татар халкының артта калуының сәбәбе — дин, ислам дине, Корьән шәрифтә язылган һәм барча әһле мөслимингә фарыз булган кануннар икән! Бу ни димәктер?! Әгәр татар халкы аллаһы тәгаләгә ышанмаса, ислам диненең кагыйдәләрен үтәмәсә, динсез, мөртәт булса гына тәрәккъый итәчәк икән! Хәйрулла ахун дөрес әйткән икән. Хәтерегездә булса, Зыя әфәнде «Госмания» мәдрәсәсендә укыткан чакта, Хәйрулла хәзрәт әйткән иде: «Зыя Камалига урыслардан бер ящик тәре алдырып, шәкертләрнең муеннарына тактырырга гына калды. Ул ислам диненә чалма урынына урыс эшләпәсен кидерергә маташа», — дигән иде. Ул вакытта без бу сүзләргә ышанмаган идек. Менә инде хәзер күз алдымызда: тәрәккъый итмәк өчен, мәгърифәтле кеше исемен алмак өчен динсез булмак кирәк икән. «Мәдрәсәи галия диния»нең шәкертләргә биргән белеме шул икән! Безнең бу мәдрәсәгә биргән иганәләребез менә нәрсәгә сарыф ителә икән! — Закир бай тавышын тагын да күтәрә төшеп, каш астыннан Зыя Камалига карады. — Әллә сез мондый имансызлык, динсезлек таратуга безнең урамнан, юл өстеннән тапкан акчабыз бар дип беләсезме? Болар барысы да дилбегәне кулыгызда нык тота белмәвегездән, шәкертләрне үз ихтыярларына куюыгыздан түгелме, Зыя әфәнде?!

Зыя Камали кыерсытылганын сиздермәскә тырышты, Закир байның күзләренә туры карады:

— Хәтта мин белмәгән мәдрәсә хәбәрләрен сезгә кем җитештерә торгандыр — мин ул кешене белмим, — диде ул. — Аңлашылганча, сезнең дә аны миңа танытырга исәбегез юкка охшый. Хәер, «кеше» дигән исем әрәм булган андый түбән мәхлукларны таныйсым да, алар белән эш йөртәсем дә килми. Бу урында тик шуны гына әйтергә телим: тикшерелмәгән, анықланмаган доносларга ышанып, кешене пычратудан да җиңел эш юк. Минемчә, кеше өстенә әллә никадәр гаеп йөкләгәнче, ялалар якканчы, иганәләребезне туктатабыз дип куркытканчы, башта үзара тыныч кына киңәшеп, бу вакыйганы тикшерергә, ялганны хакыйкатьтән аерырга кирәк иде. Бәлки ул хәтле тавыш күтәрерлек нәрсә дә юктыр!

Зыя Камалиның болай диюе кунак байларга төпле, дөрес кебек күренде. Закир бай да эшне ашыгыбрак, уйламыйчарак башлаганын аңлады. Чыннан да, бер шәкертнең генә сүзенә ышанмастан, тагын берничәсен чакыртып сораштырырга кирәк иде. Шул ук шәкертнең сүзенә караганда, динсезләргә каршы берничә кеше чыгып сөйләгән икән бит. Менә шул шәкертләр белән дә сөйләшергә кирәк булган. Шунда инде Зыя Камалиның авызын бик шәп итеп капларга мөм-

кин иде. «Ашыкканмын! Ашыкканмын!» — дип үкенсә дә, Закир байның әйткәннәреннән тиз генә кире чигенәсе килми иде. Низаметдин байның:

— Сезгә җитешкән хәбәр, Закир әфәнде, шулай ук дөресме икән? Ягъни мәсәлән, дошманлык, көнчелек, яки башка шундый берәр сәбәп белән әйтелгән бөһтан түгелме икән дим? Бергә бишне кушып сөйләүчеләр дөньяда аз түгел. Иганәләр турында билгеле бер карарга килгәнче, ягъни мәсәлән, тикшерергә кирәк иде... — диюе Закир байга чигенү өчен бер сылтау булды. Икенче байга карап, ул:

— Ә сез ни дисез, мөхтәрәм Галәветдин әфәнде? — дип сорады.

— Мин дә, Низаметдин әфәнде әйткәндәй, сезгә җитешкән бу хәбәрнең төбендә үч алу кебек берәр нәрсә юкмы икән, дим. Әмма ликин бик тә була торган хәл бу, — диде анысы.

Бу сүздән соң Закир бай җиңелгән кеше кыяфәтендә кулын селекте:

— Ярар, алайса! Барыгыз да миңа каршы булгач, ни эшлим? Тикшерү мәсьәләсенә килсәк, бу эшне, әлбәттә, Зыя әфәнденең үзе белән Габдулла әфәнде Шонасигә тапшырырга кирәк булыр дип уйлыйм. Җәмгыятьнең җитәкчеләрен, кирәк булса, җәмгыятьнең мәҗлесендә иштирак иткән шәкертләрнең дә берничәсен чакырып, бик ныклап, җентекләп тикшергәннән соң, тикшерүнең нәтиҗәсен тышкы идарәгә белдерергә тиешләр. Минем фикерем шул! — дип, ул сүзен бетерде.

Кунак байлар икесе дә бер авыздан Закир байның тәкъдименә кушылдылар.

Зыя Камали: «Бу юлы да котылдым бугай үзләреннән!» — дип, вакытын әрәм итәргә теләмичә, байлар белән саубуллашып чыгып китте.

## 14

Икенче көнне дәресләрдән соң, Галимҗан, Салих, Булат Сәлиев, Фәйзерахман һәм Шәһит мөдәррисләренең кабинетына керделәр. Зыя Камали боларны ни өчен чакыруын әйтмәсә дә, сүзнең нәрсә турында булачагын егетләр сизенәләр иде. Сүз җирдә ятмый диләр бит. Кичә Закир байларда «Белем җәмгыяте»нең утырышы турында сүз булган, Зыя Камалига бик каты эләккән дигән хәбәр «озын колак»тан шәкертләргә дә килеп җиткән иде. Шуңа күрә мөдәррисләренең:

— Мин җыелыштан чыгып киткәч, ислам дине турынданиләр сөйләнелде? Шул хакта миңа тәфсиллерәк итеп әйтсәгез иде, — диюе бер дә гаҗәп тоелмады.

Бу сорауны Зыя Камали Галимҗанга карап әйтсә дә, җавапны Салих башлады:

— Татар халкының башка халыкларга караганда артта калуының төп сәбәбе — дин, шәригать кануннары, дип беренче булып мин әйттем... — диде ул.

Зыя Камали: «Дөресен сөйлиме бу, әллә гаепне Галимҗаннан үз өстенә алырга телиме?» — дип уйлап өлгермәде, сүзне Фәйзерахман ялгап китте:

— Дин, шәригать исеменнән безнең тормышыбызга бик нык кереп урнашкан хорафатлар дөрес булганын сез үзегез дә безгә аңлата киләсез бит. Әмма безнең татар халкы: «Динебез, шәригатебез шулай кушкан дип, бу хорафатлардан бер адым да тайпылырга теләми. «Коръән шәрифтә шулай язылган!» ди дә — тәмам! Ләкин коръән шуны дөрестән дә кушканмы, юкмы, анда аның эше юк, тикшереп утырырга белеме дә юк, чукымыйча — карга, укымыйча мулла булган «хәзрәте» аңа шулай дип әйткән, ата-бабасыннан да шулай килгән. Аңа шул җитеп тора! Без, гали сыйныфта укучылар, коръәннең телен аңларлык дә-

рәҗәдә өйрәндек дип әйтә алабыз. Халыкка корьән ни кушкан, ни кушмаганны аңлатыр өчен безнең үзебезгә корьәнне шул ноктаи назардан дикъкать белән укып чыгарга кирәк дигән сүз булды. Моңа каршы чыгучылар да булды...

Моңарчы эндәшмичә, Зыя Камалиның уң ягыннан өстәл кырыена таянып утырган Габдулла Шонаси:

— Корьән шәрифкә каршы нинди сүзләр әйтелде? — дип сорады.

Бу сорауны Шонаси шәкертләрне батыру нияте белән бирмәде. Үзенә тапшырылган һәрбер эшне, яратса-яратмаса да, инәсеннән җебенә кадәр төгәл итеп башкарырга өйрәнгән иде ул. Хәзер дә аның түгәрәк тулы йөзендә, коңгырт күзләрендә кызыксынудан башка бернәрсә дә күренми иде.

Остазы Шонаси әфәнде: «Корьән шәрифкә каршы нинди сүзләр әйтелде?» — дип сорагач, Галимҗан уйлана калды. Корьәнне инде ул яхшы ук аңлый иде. Аллага ышануы бөтенләй тамырыннан какшап җитмәгән булса да, корьәннең кайбер сүрәләре, аятьләре аны бик нык шикләндерә башлаган иде. Үз фикеренчә, һичбер тәртәгә сыймый торган аятьләрне ул аерым дәфтәргә күчереп, шунда ук татарчага тәрҗемәләрен язып бара иде.

Галимҗанның уйга калганын күреп, Шонасигә Шәһит җавап бирде:

— Юк нәрсәне сөйләп йөрергә кемгә кирәк булгандыр! — диде ул, ачу белән. — Җәмгыять утырышында сүз ни турыда булганын әйттеләр ич инде! Корьәнгә каршы сүзләр булса, аны да әйтер идек!

— Ә сез бу турыда ни әйтерсез? — дип, Зыя Камали Галимҗанга карады. Галимҗаның ялганламыйча, туры сөйләвен ул яхшы белә иде. Әгәр турысын әйтергә теләмәсә, авызына су капкан кебек, кабарына төшеп, эндәшмичә утыруын да шулай ук яхшы белә иде.

Галимҗан остазына күтәрелеп карады:

— Дин, корьән турында минем шәхси фикеремне сез яхшы беләсез, — дип башлады ул. — Бу хакта сездән шелтәләр дә аз ишетмәдем. Ләкин «Белем җәмгыяте»нең утырышында корьән турында һичбер төрле сүз булмады. Дин турында минем ни сөйләгәнемне белергә телисез икән, «Эльислах» газетасына язган ике мәкаләмне укысагыз, шул җитә. Җыелышта да мин шуны сөйләдем...

Галимҗан кинәт сүзеннән туктап калды. Аның башына: «Чыннан да бит, дин турында сүз киткәч, корьән турында да әйтеләсе фикерләр юк түгел иде. Ләкин ни өчендер бу турыда һич сөйләнмәде. Ни өчен шулай булды икән?» — дигән уй килде.

Шәкертенең уйга калганын күреп, Зыя Камали аны ашыктырмады. Галимҗан исә озак көттермәде:

— Җыелышның алдагы утырышы киләсе атна кич булачак. Үткән утырышта бу маузугта сүз бетмәде. Бәлки фикер алышу дәвам итәр. Ихтимал, шул вакытта корьән турында да сүз чыгар. Алдан бернәрсә дә әйтеп, вәгъдә итеп булмый мондый мәсьәләдә. Һәрхәлдә, төрле гайбәтләргә юл куймас өчен, Зыя әфәнде, сез үзегез җыелышның ахырына хәтле утырсагыз яхшы булыр иде. Корьән турында булсын, яки дин турында булсын, безнең сөйләгән сүзләр күңелегезгә ошаса-ошамаса да, аларны үз колагыгыз белән ишетерсез, шуңа карап безне хөкем итәрсез,— диде ул.

«Белем җәмгыяте»нең беренче утырышында шәкертләрнең кылган «гөнаһларын» тикшерү хәзергә шулай тыныч кына бетте. Ләкин киләсе утырышта да шулай дин, шәригать мәсьәләләре кискен рәвештә тәнкыйть ителсә, корьән турында да бер-ике кырынрак сүз әйтелсә — әмондый сүзләр, шиксез, булачак, — идарә белән җәмгыять арасында сугыш башланачагын Галимҗан да, башкалар да яхшы сизәләр иде. Остазлары нихәтле хөр күңелле булса да, шәкертләрнең бу мәсьәләләргә яшьләрчә бик ирекле карашларын кабул итә алмаячак. Җитмәсә

тагын, Зыя әфәнде өстенә җәмгыятьнең утырышында шәкертләрнең ни сөйләгәннәрен тикшерү йөкләнгән бит! Шулай булгач, җыелышта дингә, корьәнгә каршы сөйләнгән сүзләрне тышкы идарәгә җиткермичә, яшереп калуга аның вөҗданы ирек бирмәс. Яшереп калам дисә дә, бергә бишне кушып, Закир бай кебекләргә җиткерүчеләр табылачак. Тышкы идарә исә җәмгыятьнең җитәкчеләре булган шәкертләрнең берсен дә калдырмыйча мәдрәсәдән кууны таләп итәчәк. Бу «Белем җәмгыяте» дигән нәрсә алда бик күп күңелсезлекләр тудырыр кебек күренә.

Ни эшләргә? Әллә эшли башлар-башламас ук җәмгыятьне тышкы идарә тарафыннан тар-мар иттерергәме, әллә аны саклап калыр өчен вакытлыча нинди дә булса юл эзләргәме? Җәмгыять җитәкчеләрен әнә шундый уйлар борчый башлады.

## 15

Закир байларда булып үткән шау-шулы мәҗлес турындагы хәбәр шәкертләр арасында кызу бәхәс, төрле шикләр тудырды.

— Кем икән бу гайбәт ташып йөрүче? Дәрес вакытында мин сыйныфтагы бөтен шәкертләрне берәм-берәм карап чыктым. Безнең сыйныфта шикләнерлек ике генә кеше таптым... — диде Шәһит. Галимҗан ни әйтер икән дип, бераз туктап торды. Галимҗан ишек тоткасына үрелгән хәлдә, Шәһиткә борылып карады:

— Я, синеңчә кемнәр шикле? — дип сорады. Үзе җавап та көтмичә, ишекне ачып, урам баскычына атлады. Шәһит тә аның артыннан чыкты.

— Минемчә, безнең сыйныфта Мәндиев белән Фәтхуллиннан башка ике арада сүз ташып йөрерлек кеше юк. Я Мәндиев, я Фәтхуллин! Икесенең берсе!

Галимҗанның да фикере шуңа якын иде. Җәмгыять утырышында иң үтә динче булып кычкырынучы Мәндиев иде. Аннан соң ул һәр вакыт һәр нәрсәдән риза түгел. Бернәрсә дә аны канәгатьләндерми, әмма бер тәлинкә тәмле аш өчен җанын сатар.

Ләкин ризасызлыгын теле белән ачык әйтсә дә, үз фикерен, үз теләген ахырга кадәр яклап көрәшә алмый, ялкаулыгы да зур, көрәшер өчен гайрәте дә җитми аның. Әгәр инде берәр төрле җиңел, әйләнчек юл тапса, бу юл яхшымы-яманмы дип тормый, тик аның теләгенә генә туры килсен! Фәтхуллин күп сөйләргә яратса да, алай ук усал гайбәтчегә охшамый. Сүз ташуының сәбәбе яманлык уйлаудан, кешеләргә зарар китерергә теләүдән булмаска тиеш. Галимҗан фикеренчә, берәр кешедән ишеткән хәбәргә Фәтхуллин үз хыялыннан яңа детальләр өсти. Аннары инде ул, үз хыялына үзе ышанып, аны эченә сыйдыра алмый, кабартып, башкаларга сөйләп йөри. Галимҗан, шулай уйласа да, бу турыда катгый бер фикергә килергә ашыкмады.

— Җәмгыять утырышында икенче тәгъзирия шәкертләре дә бар иде ич. Бәлки алар арасыннан берәрсенең Закир байга якынлыгы булып, шул хәбәр йөртәдер?

Галимҗанның бу сүзе Шәһиткә ошамады. Иптәше аның әйткәннәренә тиешенчә бәя бирмәде кебек тоелды. Үпкәләгән тавыш белән ул:

— Менә син һәр вакыт шулай! Башкаларның яманлыгына һич ышанырга теләмисең!..— диде.

Галимҗан аның сүзен бүлде:

— Мәсьәлә ышану-ышанмауда түгел. Фараз итү нигезендә генә кешене гаепләү бик җиңел эш ул. Син фараз белән генә берьюлы ике кешене гаепләргә маташасың. Турысын әйтсәң, эш Закир байга кем, нәрсә дип сүз җиткерүендә түгел. Закир бай кебек әләк сүз җыеп йөрү-

челәр булмаса, доносчылар да булмас иде. Безнең мәдрәсәнең матди зәмине менә шундый карагруһ байлар кулында булуы бик кызганыч!..

Галимҗан сүзен бүлеп: «Әйдә, киттек!» — дигәндәй, кулы белән Шәһитнең терсәгенә кагылды да үзе баскыч басмаларыннан егетләрчә житез-житез атлап төшеп китте.

Урамда бик куе булып ябалак-ябалак кар ява иде, әйтерсең бөтен дөньяны тоташ, калын ак пәрдә каплап алган! Бу пәрдә аша урамның икенче ягы да күренми. Агачларның әле иртә белән генә ялангач булган ботаклары хәзер, бизәнеп, җылы йомшак мамыкка төренгәннәр сыман. Аягыңны атлап өлгермисең, эре-эре кар бөртекләре эзләреңне тигезләп китә.

Егетләр, шушы матурлыкны тоеп, бераз вакыт эндәшми атладылар. Ниһаять, Галимҗан Шәһиткә борылып карады:

— Минемчә, җәмгыятьнең алдагы җыелышында Закир байларга чәйнәрлек ризык бирмәскә кирәк булыр. Әйтеләсе сүзләр үткән җыелышта әйтелде инде.

— Шау-шу купкач, бу мәсьәлә җәмгыятьнең алдагы утырышына калдырыла дип әйткән идек бит! — диде Шәһит.

— Аны бик шома гына йомгакларга мөмкин. Шул турыда киңәшер өчен бүген Фәйзерахманның фатирына җыелышырга булдык.

— Ә дәресләрдән соң мәдрәсәдә үк җыелышсак?

— Гаҗәп кеше син, Шәһит! Үзең гайбәт капчыгын эзләп тапсаң, яхшы гына итеп арт сабагын укытырга янап йөрисең, ә үзең шул гайбәтчегә тагын бер сылтау булырга телисең!

Башта Шәһит аңламады:

— Тагын нинди сылтау булам икән мин аңар?

— Мәдрәсәгә җыелсак, шул ук гайбәтче ишек артына яшеренеп безнең сүзләрне тыңлап тормас та, тагын бергә бишне кушып, идарәгә җиткермәс дисеңмени?

— Ә-ә! Ул ягын әйтәсең икән. Дөрес, алай булуы бик ихтимал шул!

Сөйләшә-сөйләшә, Фәйзерахман фатирына килеп тә җиткәннәр икән. Капкадан кереп, ишегалдының уң ягына салынган бер катлы агач өйнең өч басмалы баскычына менделәр. Бусаганы атлап коридорга керүгә, гөр килеп сөйләшкән, көлешкән тавышлар ишетелде. Шәһит тә көлеп җибәрде. Галимҗанга карап:

— Әйтерсең лә туй ясыйлар! Ярый әле, тәрәзәләрнең кышлык рамнары куелган, югыйсә, тавышлары бөтен урамга яңгырар иде, — диде.

Галимҗан җавап бирмәде. Өс-башындагы, аягындагы карны кагып төшерде дә ишекне ачып бүлмәгә керде.

Бүлмә уртача зурлыкта булса да, җиһазлары аз булганга зур күренә иде. Түрдә, урамга караган тәрәзәгә терәп, нарат агачыннан ясалган өстәл куелган. Өстәл өстенә, пөхтәләп, атлас төсле ялтырап торган калын яшел кәгазь ябылган. Китап-дәфтәрләр дә җыйнак итеп өстәл өстенә урнаштырылган. Уртада тагын бер өстәл. Аның өстенә кызыллы-яшелле шакмаклы ашъяулык җәелгән. Кыскасы, бүлмәдәге бөтен әйбер Фәйзерахманның үзе кебек җыйнак, пөхтә күренә иде.

Шәһиткә тавышлар бик күп булып ишетелсә дә, бүлмәдә биш кенә шәкерт иде. Фәйзерахманның үзеннән башка монда Фәтхел Корбангалиев, Вәсим Солтанов, Булат Сәлиев, Салих Әхмәтҗанов дигән шәкертләр бар иде.

Көлешүләренең сәбәбе шунда икән: Фәйзерахман, янәшә бүлмәдә тора торган рус студентыннан күреп, тәмәке тарту мәдәнилек, егетлек билгесе дип, тәмәке тартырга өйрәнәчәк икән. Шул ният белән «Шурымуры» дигән бер пачка папирос сатып алган. Салих белән икесе берәр папирос кабызып, бер суырулары булган, буылып-буылып йөткерә башлаганнар. Моны күреп, барысы да:

— Менә сиңа кирәк булса зыялы господин Фәйзерахман белән господин Салих!

— Господинлык ул бушлай килми шул, бераз җәфа чикмичә булмый!

— Алар господин булыр өчен түгел, җәмгыятьтә дингә каршы сөйләгән сүзләрен раслау өчен полный культурный мөртәт булырга тырышалар. Мөселман дине тәмәке тарту, аракы эчүне гөнаһ саный бит, — дип көлешәләр икән.

Галимҗан белән Шәһит килеп керүгә, Фәйзерахман ишеккә таба атлады.

Аларның кулларыннан пальто һәм бүрекләрен алды.

Салих, Шәһит, Фәтхел, Фәйзерахман үзе караватка тезелешеп утырдылар. Вәсим белән Булат, Галимҗанны уртага алып, өстәлгә якынрак елыштылар.

— Тегеннән кәгазь белән кара ал, катип син булырсың, — дип, Салих Вәсимгә тәрәзә янындагы өстәлгә бармагы белән күрсәтте. Моңа каршы Галимҗан:

— Минемчә, катип-сәркатиплар кирәкмәстер, — диде. — Без монда рәсми киңәшмәгә җыелмадык. Үзара сөйләшеп, җәмгыятебезнең алдагы утырышын ничек алып бару турында гомуми бер фикергә килсәк, безгә шул җитә. Бу турыда кемнең нинди фикере бар?—әйтсен, — диде.

Кызу канлы Фәйзерахман: «Башкалар ни әйтер, тыңлап карыйк», — дип уйламады, шундук урыныннан торды:

— Монда ике төрле фикер булу ихтималы юк! — диде ул. — Әллә без, Закир бай кебекләрдән куркып, үз фикеребездән кире чигенергә тиешме?! Ул вакытта «Белем җәмгыяте»нең кемгә кирәге бар?! Минемчә, алдагы утырышны шулай әүвәлгечә дәвам иттерергә кирәк!

— Берәү дә Закир байдан куркып тәүбә итәргә җыенмый. Син алай уйлар-уйламас кешеләрне хурлама әле? — дип каршы төште аңа Шәһит.

— Шулай булмаса, бу кешеләр монда ни өчен җыелганнар?! — Фәйзерахман кулларын җәеп күрсәтте. — Әллә болар җәмгыятьнең утырышын ни рәвешле Закир байның кәефен кырмаслык итеп үткәрергә икән дип килмәгәннәрме?!

Фәйзерахманның шулай сөйләнүе Галимҗанның да ачуына тиде:

— Бераз сабыр ит әле, Фәйзерахман! Синең фикерең аңлашылды. Башкаларны да тыңлап карыйк әле,— диде ул һәм башын иеп утырган Вәсимнән: — Арабызда иң сабыр, иң тотнаклы кеше син булсаң кирәк. Бу мәсьәләгә карата синең фикерең ничек? — дип сорады.

Вәсим монголчарак кысык күзләрен күтәреп башта Галимҗанга, аннары калган иптәшләренә карады. Әйтәсе сүзе Фәйзерахман фикеренә капма-каршы булганлыктан бераз уңайсызлана иде ул. Шулай да үз фикереннән кайтырга исәбе юк иде.

— Мин башкачарак уйлыйм, — диде ул, сабыр гына тавыш белән. Бераз башын иеп, аяк очына карап торды да күтәрелеп карамыйча гына дәвам итте: — Без бу мәдрәсәнең ачылганын дүрт күз белән көтеп алдык. Безнең татар галәмендә, хәтта татарның мәркәзе саналган Казанның үзендә дә мондый ирекле мәдрәсә юктыр дип уйлыйм. Без монда укырга теләгән фәннәрне идарәдән таләп итә алабыз. «Безгә хисап укытыгыз!» — дидек, Гариф әфәнде Байчуринны чакырып, хисап кына түгел, тарих та укыта башладылар. «Җәгърафия укытыгыз!» — дидек, Хәтмулла әфәнде Фазыловны чакырып җәгърафия укыта башладылар. Бара-тора рус телен дә укыта башларлар. Теләсә кая барабыз, китапханәләрдән теләсә нинди китап алып укыйбыз, теләсәк җырлыйбыз, теләсәк биибез! Менә шул казанышларыбызны Закир бай кебекләрнең көйсезлекләре сәбәпле юкка чыгарабызмы?! Әле хәзергә Закир байлар белән исәпләшмичә дә булмый. Ни эшлисең, мәдрәсә шул бай-

ларның, Суфия бикә, Гөлсем бикә кебек алпавытларның биргән иганәләренә яши бит! Моны, без ничек тә үзгәртә алмыйбыз. Әгәр байлар чыннан да иганәләрен туктатсалар, үз канатыбызны үзебез каерган булмабызмы? Үзе утырган ботакны чапкан ахмакка охшамабызмы?!

Вәсимнең бераз тукталып торуыннан файдаланып, Фәйзерахман тагын үзенекен сайрарга кереште:

— Димәк, тәүбә, тәүбә, әстәгъфирулла! Әйттек тә кайттык! Куркуыннан койрыгын бот арасына кыстырып, артка чигенгән эт шикелле безгә дә кире чигенергә кушасыңмы?

Бу сүзгә каршы да Вәсим әүвәлгечә сабыр тавыш белән ашыкмый гына җавап кайтарды:

— Җәмгыятьнең алдагы утырышында, гауга чыгарган мәсьәләне кузгатмыйча, башка бер мәсьәләне тикшерсәк, монда бернинди дә безне түбәнсетерлек, кимсетерлек нәрсә булмас. Моннан: «Без фикеребездән кайттык, тәүбә иттек» дигән мәгънә чыгару бөтенләй урынсыз! Без тик саклык күрсәткән булабыз! Арабыздан сүз ташучыларны чыгарып ташлагач, бу мәсьәләгә без яңадан кайта алачакбыз...

Вәсимнең соңгы сүзен ишеткәч, Фәтхел:

— Кулыннан тотмагач, каракны да карак дип әйтә алмыйсың! — диде. — Бердәнбер юл: гайбәтченең исемен атап әйтмәсәк тә, һәркем аңларлык итеп мыскыллап газетабызга язарга, байлар кулындагы сөяккә кызыгып, койрыгын болгап торган эт рәвешендә сурәтен ясап чыгарырга кирәк! Озын сүзнең кыскасы шул: киләсе утырышуда беренче маузугны кыска тотып йомгакларга да икенче маузугка күчәргә кирәк.

Салих белән Вәсим дә Фәтхел фикеренә кушылдылар. Һәр вакыттагы кебек соңгы сүз Галимҗанга бирелде:

— Димәк, тиешсез урында нигез фикеребездән кайтмыйбыз дип үҗәтләнмәскә булдык. Минемчә, алдагы утырышта Салих дуска тапшырылган маузуг тикшерелер. Моңа каршы кеше юктыр?

Каршы кеше булмады.

Дәресләрдән соң җилем басма газета чыгару, «Белем җәмгыяте»нең утырышларын үткәрү, рефератлар язу кебек эшләр белән вакыт тиз үтеп китте. Инде имтиханнар вакыты да килеп җитте. Бу юлы читтән килгән кунаклар күп булмады, шуның өчен имтиханнар да шау-шусыз тыныч кына узды.

Тулы хокуклы әгъза сыйфатында мәдрәсәнең эчке идарәсенә шәкертләр вәкиле дә сайлансын, дин дәресләрен киметү исәбенә, укыту программасына гомуми тарих, рус теле һәм әдәбияты, физика, химия фәннәре, математикадан җәбер, һәндәсә бүлекләре дә кертелсен дигән таләпләрен эчке идарәгә тапшыргач, шәкертләр авылларына тарадылар.

Галимҗан да Солтанморатка кайтып китте. Ләкин анда ул озак тормады. Ялчылары Әхми, әнесе Габделхәким белән өчәүләп иген эшләрен бетергәннән соң, ул казакъ арасына балалар укытырга дип чыгып китте.

## Яңа тәфсир[1]

### 1

1908 елның сентябрь азакларында Галимҗан Уфага әйләнеп кайтты. Фатир табу белән үзенә ике ел буе рус теленнән дәрес биргән Андрей янына китте. Соңгы елда аларның аралары тагын да якыная төшкән иде. Галимҗан аңа мәдрәсәләрне яңарту, халыкны агарту турындагы

[1] Тәфсир — корьән аятьләренә аңлатма.

хыялларын сөйли, Андрей исә аны бик ихлас күңел белән тыңлый, тиешле дип тапкан урыннарда киңәш тә биргәли иде.

Галимҗан килеп кергәндә, Андрей әйберләрен җыештырып йөри иде. Кием-салымнарын камыштан үргән чемоданга салып бикләгән, урын-җир әйберләрен портпледка бәйләп куйган. Инде китапларын бәйләм-бәйләм итеп калын кәгазьгә төреп маташа иде.

Галимҗан, бу күренешкә хәйран калып, сәлам бирергә дә онытты. Ишеккә арты белән торган Андрей, Галимҗанга таба борылып:

— Нигә туктап калдың? Әйдә уз! — диде.

Ниһаять, Галимҗан сәлам бирде һәм:

— Бу ни хәл? Кая җыенасың? — дип сорады.

Андрей соңгы бәйләм китапларын өстәл читенә этәрде де, үзе бик арыган кыяфәт белән ике кулын салындырып, лап итеп урындыкка утырды. Бары тик шуннан соң гына:

— Әйе, җыенам, — диде. Хәлне аңлатып сөйләп китте: — Киев губернаторы Александр Федорович заманында минем әткәй белән бергә кадетский корпусны бетереп чыккан икән. «Казан университетыннан куылгач, фамилиясе кара исемлеккә кергәндер, кая гына гариза тапшырмасын, үзен бер университетка да кабул итмиләр», — дип, әткәй аңа минем турыда хат язган булган. Кичә әткәйдән хат килде. Александр Федорович сине Киев университетына урнаштырырга вәгъдә итте, дип язган. Шундый уңайлы очрактан файдаланып, берьюлы ике куян атып булмасмы, дим.

Галимҗан тиз генә төшенмәде:

— Ул нинди ике куян? — дип сорады.

— Соңгы вакытларда Киевта студентлар хәрәкәте көчәя бара дигән хәбәр бар. Шул хәрәкәтнең үзәгенә кереп эшләп булмасмы, дим. Куянның беренчесе шул. Икенчесе — укуымны тәмамлый алмаммы дигән өмет, — дип аңлатты Андрей.

— Бәхетең бар икән, егет! Университетка керәчәксең, тирән, этрафлы белем алып, киң колачлы белгеч, халык хадиме булачаксың! Безгә андый бәхет тими инде. Ни дисәң дә син алпавыт баласы шул! Карга карганың күзен чукымый диләр бит... — дип, Галимҗан көнләшеп тә куйды.

Әтисеннән хат килгәч үк, Андрей бу хатны үзе белән яшерен элемтә тота торган бер кешегә күрсәткән иде. Берничә көннән соң бу кеше аңа:

— Иптәшләр сиңа Киевка барырга куштылар. Анда кемнәр белән очрашырга кирәклеге, ул кешеләрнең адреслары, парольләр сиңа поездга утырачак көнне әйтелер, — диде.

Галимҗанның соңгы сүзләре Андрейның беркадәр хәтерен калдырса да, элемтәчедән алган күрсәтмә турында ул авыз ачып бер сүз дә әйтмәде. Тик үпкәсен басу өчен генә:

— Мине университетка кертте дип әллә губернатор алдында тез чүгеп, аягын үбәрмен дип уйлыйсыңмы? Яисә кияү алдында кыланчыкланган кыз кебек чытлыкланып: «Абау, бу сасы дуңгызның кылыннан җирәнәм!» — дип, университет тәмамлау мөмкинлегеннән баш тартыймы? — диде.

— Син бик кабарынма әле, Андрей! — диде Галимҗан. — Үзең уйлап кара: әгәр сүз минем университетка керүем турында булса, ул губернатор минем өчен бармагын да селкетмәс иде. Шулай түгелме? Ә менә синең алпавыт әтиең хөрмәтенә ул бармагын селкетү генә түгел, берьюлы ике кулы белән күтәреп, сине туп-туры студентлар арасына кертеп утыртачак. Мин шул турыда гына әйтәм.

Андрей тынычланган төсле булды:

— Ярар, алайса! Аңлашылды! Аерылышу алдыннан талашмыйк. Син хаклы, — диде.

Аерылуны искә төшергәч, Галимҗан:

— Син киткәч бик күңелсез булыр инде миңа! Ялгыш әйтәм бугай дип тартынмыйча, кем белән русча сөйләшеп утырырмын икән? — дип, үзенең кайгысын белдермичә кала алмады.

— Син инде рус теле грамматикасын бик яхшы беләсең. Хәзер син әдәби телдә иркенләп сөйләшергә өйрән. Аның өчен рус әдәбиятын күбрәк укы. Шул вакытта тел байлыгың да артыр, матур һәм дөрес итеп сөйләргә дә өйрәнерсең.— Шулай дигәч, Андрей кинәт исенә бер нәрсә төшкән кебек, кашларын күтәреп, күзләрен зур ачып, Галимҗанга карады, аның аркасыннан кагып: — Минем ике сәгатьтән артык вакытым бар. Сүз боткасы пешереп утырганчы, мин сине бер китапханәгә алып барыйм. Янында илле тиен акчаң бармы? — диде. Галимҗанның «бар» дип әйткәнен дә көтмичә, сүзендә дәвам итте: — Хәер, синдә булмаса, миндә табылыр. Бу илле тиен — залог хисабына. Аннары, китаптан файдаланган өчен ай саен утыз тиен түләргә кирәк. Аның каравы, теләгән китабыңны алып укырсың. Әйдә, киттек. Мин сине китапханәнең мөдире белән таныштырырмын,— дип, Андрей Галимҗанны ияртеп чыгып китте.

2

Шәкерт газетасы «Аң»ны да, «Белем җәмгыяте»н дә төрле юллар белән кыш буе саклап кала алдылар. Җәмгыятьнең утырышларын күбесенчә мәдрәсәдән читтә, берәрсенең фатирында үткәрәләр иде. Әлбәттә, бу мәҗлесләргә әләкчелектә шикле шәкертләр чакырылмый иде. Тик «Халык әдәбияты ни димәктер вә аның мисаллары», яки «Пушкинның «Капитан кызы» дигән әсәре» кебек темаларга багышланган утырышларны гына мәдрәсәдә уздыралар иде. Ләкин җәнҗал көтелмәгәндә башка бер сәбәптән килеп чыкты.

Бу вакытта Галимҗанның «Коръән алладанмы, түгелме?» дигән әсәре язылган, акка да күчерелгән һәм шәкертләр арасында кулданкулга күчеп укыла башлаган иде.

Бер көнне иртән, шәкертләр әле йоклап яткан чакта, Габделхак исемле шәкерт түбәнге кат караватта яткан Фәтхелне төртеп уятты. Фәтхел, сискәнеп, торып утырды да:

— Ни бар? Ни булды? — дип сорады.

Габделхак калтыранган тавыш белән:

— Кемдер китапны урлаган... — дип җавап бирде.

Фәтхел башта аңламады:

— Нинди китапны? Кем урлаган? Каян урлаган?

— Яткан чагымда мин аны мендәрем астына кыстырып куйган идем. Хәзер уянып карасам, китап юк!

Фәтхел йокысы тәмам качып, инде аңлый башлады:

— Әллә Галимҗанның «Коръәнен» әйтәсеңме? — дип пышылдады.

Габделхакның «шул» дип әйтергә теле бармады, эндәшми калды.

Боларның үзара пышылдашуларыннан янәшә караватлардагы шәкертләр дә уяна башлады. Фәтхел Габделхакка:

— Хаккый, киен дә коридорга чык! — диде. Үзе дә тиз генә киенеп, аяк очларына гына баса-баса, бүлмәдән чыгып китте.

Коридор тын, караңгы... Көн буе шаулап торган коридорның шундый күнегелмәгән тынлыгы аяк очларына гына басып, акрын гына атларга мәҗбүр итә. Егетләр өченче катка менделәр һәм сыйныф бүлмәләренең берсенә кереп утырдылар.

— Я, сөйлә! Әллә берәрсенә: «Мин шундый китап укыйм», дип мактанган идеңме? — диде Фәтхел.

Габделхак аның алдында үзен бик зур гаепле санаса да, үпкәсен баса алмады:

— Мине шул хәтле ахмак дип беләсеңме әллә? Һичкемгә дә мактанганым юк, — диде. — Тик, үзеңә билгеле, бер бүлмәдә яшәгәч, бер сыйныфта укыгач, нәрсәдер яшереп укыганыңны сизәләр, әлбәттә.

— Укыганыңны күргәннәр арасыннан кемнән булса да шикләнәсеңме?

Габделхак уйлана калды. Китапны укырга сораган иптәшләре бербер артлы аның күңел күзе алдыннан үтте. Юк! Аларның берсе турында да: «Менә бу — хаин, менә бу — угры, бу — карак!» — дип әйтә алмый ул. Ләкин бит китапны сорамыйча, читтән кырын күз белән генә сынаулы караш ташлап йөрүчеләр дә булды. Бәлки шуларның берәрсе алгандыр? Ниһаять, ул Фәтхелгә күтәрелеп карады:

— Юк, китапны укырга сораучыларның берсеннән дә шикләнмим. Берсе дә алай хыянәт итәрлек кешегә охшамый. — Аннары беркадәр икеләнеп торды да болай диде: — Тик менә мин кичә, дәрестән соң сыйныфта калып, китапта күрсәтелгән сүрә вә аятьләрне корьәннең үзе белән чагыштырып утырдым. Бик мавыгып, бирелеп киткәнмен дә беренче тәгъзирия шәкерте Нәсих Мәүлудовның сыйныфка кергәнен сизми калганмын. Тик колак төбемдә аның мышнап сулу алганын ишеткәч, сискәнеп киттем...

Фәтхел кулы белән өстәлгә сугып куйды:

— Менә, күрдеңме? Эзләнә торгач, йомгакның очы табылды! Ул малайны уртага алып, яхшы гына кысып сорарга кирәк үзен! — дип, Фәтхел урыныннан кузгалды. Габделхак та, башын иеп, аның артыннан иярде...

Юынып, өс-башына киенгәч, Фәтхел китапханәгә керде. Галимҗанның мәдрәсәгә һәр вакыт иртәрәк килеп, дәресләр башланганчы газеталар укып чыкканын белә иде ул. Чыннан да, Галимҗан «Вакыт» газетасын карап утыра икән. Фәтхел урындыгын Галимҗанның янына ук китереп куйды. Галимҗан, аңа әйләнеп тә карамыйча, үз урындыгын читкәрәк этеп, укуында дәвам итте. Фәтхел иптәшенең кулындагы газетаны тартты. Шунда гына Галимҗан, гаҗәпсенеп, дорфаланган күршесенә карады. Фәтхелне күргәч, газетаны өстәлгә куйды да:

— Сиңа ни булды? — дип сорады.

Фәтхелнең китапханәдәге шәкертләр алдында әлеге хәлне сөйлисе килмәде. Кесәсеннән карандаш чыгарып, газетаның читен ертып алыйм дигән иде, Галимҗан сөзеп карап, аның кулын читкә этәрде. Үз кесәсеннән кечкенә дәфтәр чыгарып, Фәтхел алдына куйды. Фәтхел: «Корьән турындагы китабың Хаккыйда иде. Бүген төнлә аны Хаккыйның мендәр астыннан урлаганнар», — дип язды да Галимҗан алдына куйды. Галимҗан бу сүзләрне Фәтхел язган чакта ук укып өлгергән иде инде. Дәфтәрне алып, кире кесәсенә тыкты. Газетасын әйбәтләп бөкләде дә алган урынына куйды. Тик шуннан соң гына, башы белән Фәтхелгә ишарә итеп, ишеккә юнәлде.

## 4

Нәсих Мәүлудовны сыйныф бүлмәсенә чакырып сорау алганнан соң шул нәрсә мәгълүм булды: алдагы көнне ашханәдән чыгу белән аны дүрт-биш шәкерт уратып алганнар да Габделхакның нинди китап укыганын белергә кушканнар. «Ул дүрт-биш шәкерт дигәнең кемнәр?» — дип сорагач, шәкерт:

— Исемнәрен белмим. Алар безнең сыйныфтан түгел. Икесе — беренче гали сыйныфтан, өчесе — икенче тәгъзириядән бугай,— дип җавап кайтарды. Үзләрен күрсә, тануын әйтте...

Нәсих Мәүлудовка Габделхакны күзәтергә кушкан кешеләрнең кемнәр икәне икенче көнне үк мәгълүм булды. Нәсихнең: беренче гали сыйныфтан ике шәкерт бар иде дигәннәренең берсе — Габдулла Рифгатов, икенчесе — Хәбибулла Ишморатов икән. Җәмгыятьнең беренче утырышында Салих белән Галимҗанның дини хорафатларны тәнкыйть итеп сөйләүләренә каршы, авызларыннан күбекләр чәчрәтеп: «Долой!», «Бойкот!» дип кычкырып утыручылар да шулар булгач, Закир байга барып әләкләүчеләр дә алар икәнлегенә хәзер беркем дә шикләнми иде. Шул көнне үк дәресләрдән соң сыйныфтан чыкмыйча җыелыш ясадылар. Рифгатов белән Ишморатовны җыелышка китереп, үзләренең хаинлекләрен танырга мәҗбүр иттеләр, Галимҗанның китабын алар урлап, Габдулла әфәнде Шонасигә тапшырганнар икән. Ишморатов хәтта «Белем җәмгыяте»ндә сөйләнгән сүзләрне Закир байга җиткереп торуын да яшермәде. «Мин сездән курыкмыйм!..» — дип, бик тәкәббер кыяфәт белән җыелыштан чыгып китте.



## 5

Әлеге китап югалу хәбәрен ишеткәч, Зыя Камали Габдулла Шонасине кабинетына чакырып алды. Гадәттәгечә дәресләрнең ничек баруы, шәкертләрнең дәресләрне үзләштерү дәрәҗәләре һәм шуның кебек башка мәсьәләләр турында сораштырганнан соң, ниһаять, төп максатына күчте:

— Миңа ирешкән хәбәр дөрес булса, Габдулла әфәнде, сезнең кулыгызга ниндидер аллага, дингә каршы язылган китап төшкән икән. Бу китапны безнең мәдрәсә шәкерте язган, диләр...

Сүзнең нәкъ шул хакта буласын Габдулла әфәнде башта ук сизенгән булса да, хәзер ни әйтергә дә белми торды. Бәлки бу мәсьәлә Зыя Камалига да башка идарә әгъзаларына да барып җитмәгәндер, шулай тынып калыр дип өметләнгән иде ул. «Я китапның икенче нөсхәсен Зыя әфәндегә дә биргәннәр, я бу китап миндә икәнен аңа хәбәр иткәннәр», — дип уйлап, Шонаси:

— Әллә сезгә дә бу китапның бер нөсхәсен бирделәрме? — дип сорады.

— Өстәлемә имзасыз бер язу ташлап киткәннәр. Менә ул кәгазь, — дип, Зыя Камали язманы Габдулла әфәндегә сузды.

Анда: «Икенче гали сыйныфның шәкерте дәһри Галимҗанның аллаһ тәгаләгә каршы язган китабы остазыбыз Габдулла әфәнде Шонасигә тапшырылды. Бу китапны укып чыккач та, мәлгунь дәһрине мәдрәсәдән кумыйча, шәкертләрне диннән яздырырга юл куюыгызны дәвам иттерәчәксезме?» дип язылган иде.

Язуны укыгач, Шонаси моңарчы аңлый алмаган нәрсәсен яңа аңлаган кыяфәт белән:

— Ә! Менә ни өчен китапны сезгә бирмичә, минем китапларым арасына тыгып киткәннәр икән! — диде. — Моны язган кеше, Галимҗан Ибраһимовны сез башка шәкертләргә караганда артыграк яратасыз, артыграк химая кыласыз, дигән фикердә икән. Әгәр корьәнгә каршы язган китабын сезгә тапшырса, сез бу турыда тавыш-тын чыгармыйча, Ибраһимовны мәдрәсәдән кудырмаска тырышырсыз дип уйлыйдыр ул!

Шонасинең бу фикере нигезсез түгел икәнен Зыя Камали бик яхшы белә иде. Моны инкарь итәсе килмәде аның:

— Хакыйкатән [1], Галимҗан Ибраһимов мәдрәсәнең күп шәкертләреннән акыллырак та, сәләтлерәк тә, белемлерәк тә. Ләкин яшьлек чире, яшьлек кызулыгы аны туры юлдан читкә алып киткән чакларыда була.

[1] Хакыйкатән — чыннан да.

Шул вакытта аңа ярдәм кулы сузып, туры юлга төшерәсе килә... — дигәч, сүзен кинәт китап мәсьәләсенә кайтарды: — Аның бу нәрсәсе дөрестән дә аллага, дингә каршы язылганмы? Ни өчен сез аны миңа бирмәдегез?

— Әлбәттә, мин аны укып чыккач сезгә тапшырган булыр идем. Ләкин мин азагына кадәр укып чыга алмадым. Китап кӧтелмәгәндә юкка чыкты. Кемдер аны минем китап-дәфтәрләрем арасыннан алган.

— Гаҗәп хәл! Бәлки укыган кадәресе белән генә булса да мине таныштырырсыз, Габдулла әфәнде?

Шонаси китап югалганнан бирле үзенә тынычлык бирмәгән уйларын әйтергә булды:

— Бер яктан, Зыя әфәнде, яртысыннан да кимен уку белән генә китап турында катгый бер фикер әйтеп булмый бит! Икенче яктан, китапның берничә битен генә укып өлгердем, шуның өчен аның турында ачык фикер әйтә алмыйм дип тә калырга мөмкин булмас... Мин тышкы идарә тарафыннан безнең өскә йөкләнгән вазифа турында әйтәм...

Зыя Камали, йокыдан уянып киткән кеше төсле, кинәт башын күтәрде, күзләрен угалады да:

— Анысы шула-а-ай, — дип сузып куйды. Аннары тагын: — Китапны күрмәгәч, укымагач, сез дә аның мөндәриҗәсе белән ахырга кадәр таныш булмагач, тышкы идарә әгъзаларына бу турыда ни дип әйтә алабыз соң? — диде.

Габдулла әфәндегә Зыя Камали бу сүзләре белән аны шелтәләгән төсле тоелды. Ләкин ул үпкәләмәде. «Чыннан да, мин бик гафиллек күрсәттем шул, югыйсә, кулымдагы китапны урлатмас идем»,— дип уйлады. Үз гафиллегенең нәтиҗәсен ничек төзәтергә белмичә аптырап:

— Китапны яңадан кулга төшереп укып чыкканчы, бу турыда тышкы идарәгә белдерми торсак булмасмы икән, Зыя әфәнде? — диде.

Зыя Камали бик кәефсезләнгән кыяфәттә кинәт кулы белән өстәлгә сугып куйды:

— Аны бит әхлаксыз, азгын, акылсыз димәссең! Ниятләре дә начар түгел, изге. Әмма үзе, мәдрәсәнең тынычлыгын бозып, бертуктаусыз әллә ниләр уйлап чыгара! Кара инде: хәзер «Корьән алладанмы, түгелме?» дип кычкырып, чукмар күтәреп, динебезнең терәге булган корьән шәрифкә каршы чыккан! Я, ни эшләтәсе моны?!

— Бәлки бу китап турындагы хәбәр тышкы идарәгә барып җитмәгәндер?

— Була торган эш түгел! — дип, Зыя әфәнде кулын селекте. — Китап сезнең кулыгызга төшкән көнне үк хәбәр Закир байга барып ирешкәндер. Бу турыда һич шик-шөбһә булу мөмкин түгел! Хәзер Закир бай бу хәбәрне тышкы идарә әгъзалары арасында таратып, безне ни эшләрләр икән дә ни әйтерләр икән, дип көтеп утыра торгандыр.

Шонаси дә шулай уйлый иде, ләкин ничек итеп бу күңелсезлекләрнең алдан чарасын күрергә белми аптырый иде. Шуның өчен ул:

— Инде ни эшләргә кирәк? — дигән сүз белән генә чикләнде.

Ни дә булса эшләргә кирәклеген Зыя Камали үзе дә белми иде.

— Әлбәттә, берәр чара күрмичә булмас, чөнки аның мондый зарарлы фикерләре башка шәкертләргә дә тәэсир итә, әлбәттә. Икенче яктан, имтиханнар вакыты да якынлашып килә. Бу вакытта мәдрәсәнең абруен төшереп, артык зур шау-шу күтәрү дә ярап бетмәс дип уйлыйм...

Зыя Камали тагы башын иеп, уйга калды. Бераздан, билгеле бер карарга килде, ахры, Шонасигә күтәрелеп карады:

— Менә ни эшлик, Габдулла әфәнде! — диде ул.— Тышкы идарә бу турыда гауга күтәреп өлгергәнче, ничек тә ул китапны кулга төшереп, башыннан азагына кадәр укып чыгарга кирәк. Ансыз китап турында бертөрле дә фикер йөртә алмаячакбыз. Минемчә, Галимҗанны чакырып, аңардан китабын сорап алырга кирәк. Китапны ул үз кулы белән

китереп бирер дип ышанам. Ул шәкертнең дин мәсьәләсендә шулай бозылып китүе бигрәк тә кызганыч. Китабы, чыннан да, корьән алладан түгел дигән фикерне алга сөрсә, ул вакытта Галимҗан Ибраһимов дигән шәкертне мәдрәсәдә тота алмаячакбыз. Ләкин бу эшне ничек тә шау-шусыз, җәнҗалсыз башкарырга кирәк булачак...



## 6

Иртәгә тышкы идарә белән эчке идарәнең берләшкән утырышы булачак, бу утырышта аеруча Галимҗанның китабы һәм аның үзе турында сүз булачак дигән хәбәр шәкертләр арасында шул көнне үк таралып өлгерде.

Иптәшләре күпме әйтсәләр дә, Галимҗан тыңламады: «Шонаси әфәнде китапны, һичшиксез, укып чыккандыр. Хәзер инде аны бирмәүдән, яшерүдән бертөрле дә файда юк»,— дип, китапның икенче нөсхәсен шул көнне үк Зыя әфәндегә тапшырды.

Закир бай, без — тышкы идарә әгъзалары — өйлә намазыннан соң килербез, дигәч, икенче көнне дәресләрне иртәрәк бетерделәр. Хәлфәләр сыйныфлардан чыгып китү белән, шәкертләр түбәнге кат коридорына агылдылар. Монда Галимҗанның шәрикләре генә түгел, тәгъзирия сыйныфларыннан да шәкертләр байтак иде. Дөрес, соңгыларның күбесе башкалар артыннан кызык эзләп кенә төшкәннәр иде.

Галимҗанның якын дуслары: Шәһит, Фәйзерахман, Салих, Булат, Фәтхел, Вәсим, Габделхак һәм башкалар урамга чыга торган ишекнең нәкъ каршындагы икенче кат баскычына тыгызланып утырганнар. Шәкертләрнең үзара сөйләшүләре гөр иткән тоташ бер тавыш булып ишетелеп тора. Назирның чыгып үгетләвенә каршы югары сыйныф шәкертләре:

— Идарә утырышында безнең сыйныфлардан да вәкил булсын!

— Шәригебезне нахакка кыерсыттырырга теләмибез!

— Кеше акылына ияреп йөрергә без инде сабый балалар түгел! Үз акылыбыз уянган өчен безгә җәза бирмәкче буласызмы? — дип кычкырып, тагын да зуррак тавыш куптардылар.

Кинәт тышкы ишек ачылды. Бередүче булып озын буйлы, түгәрәк кара сакаллы Закир бай килеп керде. Башындагы каракүл бүреге аны тагын да озынрак, каракүл якалы төлке туны киң җилкәсен тагын да киңрәк итеп күрсәтә иде. Аның артыннан кайсы чапан-чалма кигән, кайсы европача киенеп, мыекларын божра шикелле итеп бөтереп куйган дүрт-биш кеше күренде. Умартадагы бал кортлары кебек гөҗләп торган шәкертләрне күргәч, Закир бай тукталып калды һәм назирга карап:

— Бу ни эш тагын?! Болар монда ни өчен җыелганнар? — дип сорады.

Назир җавап биреп өлгермәде, Фәйзерахман күкрәген киереп алга чыкты:

— Әгәр Галимҗан Ибраһимовны мәдрәсәдән кусагыз, аның белән бергә без дә бөтен сыйныфыбыз белән мәдрәсәне ташлап чыгабыз! — дип кычкырды.

Закир бай күзләрен Фәйзерахманнан аның янында басып торган назирга күчерде:

— Бусы тагын кем? Исем-фамилиясен язып алыгыз да идарәгә тапшырыгыз! — дип боерды.

Моны ишеткәч, шәкертләр шундый тавыш, шундый шау күтәрделәр, хәтта Закир бай да аптырап калды. Ул арада Фәйзерахман янына Шәһит, Салих һәм тагын унлап шәкерт атылып чыктылар. Тышкы идарә әгъзаларын сарып алып, алар:

— Анықын гына түгел, минем исем-фамилияне дә языгыз!
— Мине дә языгыз!
— Мине дә! Әллә куркабызмы?! — дип кычкырдылар.
Закир бай:
— Болар бөтенләй юлдан язганнар! Боларны акылга утыртыр өчен полицие чакырырга кирәк! — дип җикеренде, ә эченнән: «Утырышуны мәдрәсәдән тышта ясарга кирәк булган икән. Бу башы бозыкларның өстебезгә һөҗүм итү ихтималы да бар!» — дип, шәкертләр арасыннан узып, тизрәк идарә бүлмәсенә керергә ашыкты. Башка әгъзалар да аның артыннан иярделәр.

Тышкы идарә әгъзалары өсләрендәге туннарын салып бүлмәгә кергәндә, эчке идарә әгъзалары бөтенесе дә җыелган һәм имтихан алу тәртибе, сорау билетлары язып хәзерләү кебек эшләр турында киңәшә башлаганнар иде. Бүлмәгә яңа кешеләр килеп кергәч, гадәт буенча, кул биреп исәнләштеләр, дога кылдылар, догадан соң исәнлек-саулык сораштылар. Тик шуннан соң гына рәис вазифасын үтәүче Зыя Камали, көн тәртибендәге мәсьәләләргә күчәргә инде мөмкиндер дип уйлап:

— Мөхтәрәм әфәнделәр! Бер ай-ай ярымнан мәдрәсәбездә имтиханнар башланачак. Сез килгәнче без монда имтиханнар турында киңәшеп, шул карарга килдек... — дип сөйли башлады. Ләкин Закир бай, аны тупас кына бүлдереп:
— Имтиханнар мәсьәләсен эчке идарә әгъзалары үзләре дә хәл кыла алырлар,— диде.— Иң әүвәл без, корьән шәрифкә каршы китап язган... Кем соң анда... ә, Галимҗан исемле дәһри шәкерт турында киңәшеп карар чыгарыйк,— диде.
Зыя Камали, эчке идарә әгъзаларына мөрәҗәгать итеп:
— Ни дип әйтәсез, хөрмәтле әфәнделәр? — дип сорады. Алар моңа каршы баш кагып:
— Әлбәттә, әлбәттә! — диештеләр.
Коридордагы шау-шу ара-тирә шул кадәр көчәеп китә, хәтта идарә әгъзалары бер-берсен ишетми башлыйлар иде. Зыя Камали, янында утырган Байчурин фамилияле мөгаллимгә карап:
— Гариф әфәнде, рәхим итеп шәкертләрне тынычландырып керегезче, — диде.
Шул арада Закир бай тагын чәпчергә керешә:
— Шәкертләрегез бөтенләй юлдан язган. Биргән тәрбиягез шул булса, әстәгъфирулла тәүбә, алла сакласын! Беләсезме, анда ни дип кычкырыналар? Алар анда: «Әгәр Галимҗанны кусагыз, без дә мәдрәсәдә калмыйбыз, барыбыз да ташлап чыгабыз»,— дип кычкырыналар! Бу ни димәк, ә? Забастовка кыламыз дигән сүзме? Мондый сүзләрне, мондый хәлләрне тиешле урынга җиткерсәң ни булачагын беләсезме?
Закир бай сөйләгәндә, Гариф әфәнде ишек тоткасына үрелгән хәлдә туктап торды. Бай, сүзен бетерү өчен, «Бу хакта шәкертләргә ни дип әйтергә кушасыз?» дигән сыман, Зыя әфәндегә борылып карады. Камали аңа:

— Әйтегез, шаулашмасыннар. Үз эшләре белән шөгыльләнсеннәр. Галимҗан Ибраһимов турында идарә нинди карар чыгарса да, ул карар аларга мәгълүм булыр,— диде.

Байчурин коридорга чыгу белән, шаулашу тагын да көчәя төште. Кайбер сүзләре хәтта идарә әгъзаларына аермачык булып ишетелде.

— Тышкы идарә әгъзаларының бүген монда ни өчен килгәннәрен без бик беләбез! Әгәр Галимҗанны мәдрәсәдән кусалар, без мәдрәсәне ташлап чыгу белән генә калмабыз, бигрәк тә тышкы идарә әгъзаларының байлыкларына, акчаларына масаеп, безнең рухыбызны изәргә, кысарга теләүләре турында газеталарга язып, бөтен әһле мөслимингә фаш итәрбез! — диде бер батыррагы.

— Шулай!

— Дөрес әйтәләр! — дип кычкыргалап, арттарак басып торган шәкертләр алдагыларны тыгызлый башладылар.

Бу шау-шу, буталыш арасында нәрсәдер «гөрс!» итеп җиргә төште дә чәлпәрәмә килеп ватылды. Шуннан соң тавыш кинәт тынды. Шәкертләр:

— Ни булды? Нәрсә ватылды? — дип, аптырашып бер-берсенә караштылар.

Кемдер:

— Дуслар! Низамнамә ватылган! — дип кычкырды.

Низамнамәнең стенадан төшеп ватылуы идарә әгъзаларына да ишетелде. Закир бай тыелып кала алмады:

— Бертөрле тәртәгә дә сыймаган бу тәртипсезлеккә хәтта дивардагы низамнамә дә түзмәде! — дип, бик мәгънәле итеп Зыя Камалига карады.

— Кичерегез, әфәнделәр, миңа чыгарга кирәк, үзем чыгып шәкертләрне низам-интизамга өндәмәсәм булмас, ахрысы! — дип, Камали ишеккә таба юнәлде. Аның артыннан Закир бай һәм аның иярченнәре: «Менә бит нинди чамадан тыш тәртипсезлек, әхлаксызлык!» дигән сыман, башларын чайкап калдылар.

Зыя Камалиның шәкертләргә ни әйткәне идарә бүлмәсендә утыручыларга билгесез булып калды, ләкин ул бүлмәгә кергәннән соң, тавышлар ишетелмәде. Зыя Камали, урынына килеп утырып, бүлмәдәгеләрне күздән кичерде дә:

— Галимҗан Ибраһимов исемле шәкертнең корьән шәрифкә каршы язган китабы турындагы сүзне Габдулла әфәнде Шонасигә тапшырам,— диде.— Ул тулаем укып чыкты. Мин исә, вакыт азлыктан, өстән-өстән генә карап чыга алдым. Китап белән танышырга теләүчеләр булса, китап үзе менә, алдыгызда,— дип, унлап дәфтәрне бер-берсенә кушып теккән калын гына кулъязманы өстәлнең уртасына куйды.

Закир бай:

— Моны ничек кулга төшерә алдыгыз?! — дип, ышанырга да, ышанмаска да белмичә, сузылып китапны үзенә таба тартты һәм битләрен актара башлады.

— Кичә сезнең белән сөйләшкәннән соң, мин Галимҗан шәкертне чакырттым. «Китапны китереп миңа тапшыр. Аның мөндәриҗәсе белән без, синең остазларың, танышырга тиеш һәм шул танышу нәтиҗәсендә генә синең хакта тугры фикер йөртә алачакбыз», — дидем. Берсүзсез китереп тапшырды... Кыскасы, китап алдыгызда. Габдулла әфәнде Шонаси сезне аның мөндәриҗәсе белән таныштырыр, — дип, Камали Шонасигә борылды: — Рәхим итегез, Габдулла әфәнде, сүз — сезгә!

Шонаси сүзне озакка сузмады:

— Мин бу китапны бик җентекләп укып чыктым, ләкин анда турыдан-туры аллаһы тәгаләгә каршы әйтелгән сүз тапмадым. Ләкин шәкертнең корьән шәриф алладан түгел дигән фикере, әлбәттә, мөртәтлекнең гафу ителмәслек бер күренеше. Шуның өчен мондый китапларны шәкертләр арасында тарату — аларның күңелендә дингә каршы шөбһә тудыру димәктер. Мондый хәлгә күз йомып калу ярамас. Һичшиксез, тиешле чараларны күрергә кирәк!..

Шонасинең бу сүзләре тышкы идарә әгъзаларына бик ошады.

— Дөрес әйтәсез, Габдулла әфәнде, күз йомып калырга ярамый!

— Куарга кирәк малакасусны мәдрәсәдән! — дип хупладылар.

Шонаси тавышлар тынганын көтеп торды да сөйләвендә дәвам итте:

— Һәр мәсьәләне хәл кылганда, әфәнделәрем, үзегез беләсез, иң кимендә ике юл була: берсе — эшне кичектермичә гамәлгә ашыру,

икенчесе — азрак сабыр итү. Киләсе айның урталарында мәдрәсәбездә имтиханнар башланачак. Әгәр без хәзер үк Галимҗан шәкертне «Галия»дән куарга кирәк дигән карар чыгарсак, мәдрәсәдә нинди җәнҗал кубачагын үзегез күреп торасыз. Мәдрәсәбезнең иң өметле, иң сәләтле шәкертләре: «Галимҗанны кусагыз, барыбыз бердән мәдрәсәне ташлап чыгабыз, ни өчен киткәнебезне газеталарга язабыз!» — дип торалар. Без, ягъни Зыя әфәнде, мин һәм башка эчке идарә әгъзалары, үзара киңәшеп шул карарга килдек: имтихан алдыннан мәдрәсәдә җәнҗал чыгармас өчен, Галимҗан шәкертне хәзергә мәдрәсәдән кумый торырга кирәк. Шәкертләр тынычланып имтиханнарга хәзерләнсеннәр. Шулай итсәк, халык алдында мәдрәсәнең абруен төшерәчәк җәнҗалдан да котылырбыз...

Закир бай Шонасигә таба кулын сузып, бармак янады һәм ачулы тавыш белән:

— Туктагыз, туктагыз, Габдулла әфәнде! Аны мәдрәсәдә калдырыр өчен тагын бер хәйлә таптыгызмы?! Бу дәһри, бу мөртәтне кумаска кирәк, ул башка шәкертләрне дә диннән яздырсын димәкче буласызмы? — дип кычкырды.

Тышкы идарәнең башка әгъзалары да бер Шонасигә, бер Закир байга, бер Зыя Камалига аптырап карадылар. Закир бай кычкыруыннан туктагач, Шонаси, гадәтенчә, ашыкмыйча, сабыр тавыш белән тагы сөйләп китте:

— Мин хәзергә, — диде ул, «хәзергә» сүзенә аеруча басым ясап, — кумыйк, хәзергә сабыр итик, дидем. Галимҗан шәкерттән «Белем җәмгыяте»нең утырышларын ясамаска, «Аң» дигән газетасын чыгармаска, бу китабын шәкертләргә укырга бирмәскә дип сүз алсак, имтиханнарны тавыш-кычкырышсыз, тыныч кына кабул итәчәкбез дә, шәкертләр өйләренә таралып китәчәкләр. Ә инде көз көне уку башланганда, мәдрәсәгә кемне кабул итү, кемне кабул итмәү — безнең үз кулыбызда булачак.

Закир бай тагын сүзсез калмады:

— Аңардан сүз алсак, имеш! Ул диненнән язган мөртәт сүзендә торачак дип беләсезме? Минемчә, аны иркәләп утырганчы, тотарга да үзен бөтен иярченнәре белән бергә жандарм кулына тапшырырга, вәссәлам! Анда бик яхшы итеп акылга утыртырлар үзләрен!

— Балигъ булып, акылга утырганчы, яшьлек азагына кадәр уйланмаган күп тилелекләр эшләтә, — диде Зыя Камали бу сүзгә каршы. — Башында акылың булса, сакал-мыек чыккач, бу эшләреннән үкенәсең дә, ояласың да. Галимҗан шәкертнең бу эшләре дә шул яшьлек тилелеге дип уйлыйм мин. Ләкин бу эшләренә карамастан, ул әйткән сүзеннән кайтмый торган егет. Шонаси әфәнде санап чыккан эшләрне имтиханнарга хәтле кылмыйм дип сүз бирсә, сүзендә торачагына ышанырга мөмкин. Әгәр инде сүз бирмәсә, ул вакытта — икенче мәсьәлә. Бернәрсәгә карамастан кискен чара күрергә мәҗбүр булыначак, ягъни имтиханнар башланганчы ук аны мәдрәсәдән чыгарырга мәҗбүр булачакбыз!..

Закир бай, әлбәттә, бу карарга күңеленнән риза түгел иде, ләкин ул, сүзе үтмәячәген белеп, яңадан каршы чыгарга теләмәде. Башкаларның:

— Ярар, алайса, шулай булсын!

— Аллага тапшырдык! — дигән сүзләреннән соң гына:

— Шулай булсын дисәгез, шулай булсын. Сүземне тыңламадыгыз. Соңыннан үкенечкә калсагыз, мине гаепләмәссез! Имтихан мәсьәләләрен үзегез генә дә хәл кылырсыз. Минем артык вакытым юк, — дип, урыныннан кузгалды.

## 7

Соңгы дәрес беткәч, Галимҗан, китап-дәфтәрләрен Вәсимгә калдырып, остазы Камали чакыруы буенча, идарә бүлмәсенә керде. Башка шәкертләр дә дәресләр бетте дип төрлесе төрле якка таралмадылар, Галимҗанның кайтканын көтәргә булдылар.

Бер сәгать тә үтмәгәндер, сыйныф ишеге ачылып, Галимҗан килеп керде. Ул, Вәсим янына барып, китапларын җыештыра башлады. Аның кайтканын сабырсызлык белән көткән иптәшләре, моны күреп:

— Ник дәшмисең?

— Ни өчен чакырган?

— Әллә мәдрәсәдән куабыз дип әйттеме? — дип сораша башладылар.

Галимҗан кулына алган китапларын кире куйды, күтәрелеп иптәшләренә карады:

— Юк. Әлегә куабыз дигән сүз булмады. Җәмгыятебезгә дә, газетабызга да, минем китабыма да тышкы идарәнең бик каршы булганын үзегез дә беләсез. Зыя әфәнде дә, минем китабым шәкертләрне диннән яздырырга хезмәт итә, дип карый икән. Имтиханнар беткәнче, «Белем җәмгыяте»н җыймаска, газетабызны чыгармаска, китабымны бер шәкертнең дә кулына бирмәскә кирәк, диде. Шул турыда миннән сүз алды. Барыбер, имтиханнарга хәзерләнү вакытында да, имтиханнар вакытында да җәмгыятьне дә җыеп булмас, газетаны да чыгарып булмас дип, мин сүз бирдем.

— Китабыңны кайтардымы? — дип сорады Салих.

— Юк, кайтармады. Үзе әле укып чыкмаган икән. Укып чыккач та кайтармас төсле күренә. Һәрхәлдә, мәдрәсәдән чыгып кит дигән сүз булмады. Шуның өчен тыныч кына имтиханнарга хәзерләнә башларга кирәк, — дип, Галимҗан артык сөйләргә теләмәгән сыман, китапларын кулына алды.

— Тукта, ашыкма әле, — диде Фәтхел, Галимҗанның кулыннан тотып. — Китапны ничек тә Зыя әфәндедән алырга кирәк бит!

Шәһит тә Фәтхелгә кушылды:

— Нинди дә булса юл табып, китапны кайтарып алырга кирәк!

— Имтиханнарга хәтле байтак вакыт бар әле. Бу мәсьәләләр турында берәребезнең фатирында очрашып сөйләшербез. Кайтаруын сорасаң, бәлки Зыя әфәнде китапны үзе дә кайтарып бирер, — диде Галимҗан сүлпән генә һәм, иптәшләренең җавабын да көтмичә, ишеккә таба юнәлде.

Ләкин шәкертләргә ике-өч көн эчендә очрашып сөйләшергә туры килмәде, чөнки көтелмәгән бер вакыйга бөтен мәдрәсәне тетрәтте.

Мәдрәсәдә яшәгән шәкертләр барлык эшләрен эшләп, сөйләшәсе сүзләрен сөйләшеп, җырларын җырлап, ниһаять, тынычланып, тирән йокыга талганнар иде. Төнге сәгать бер тирәләрендә кемнәрдер бик каты шакып тышкы ишекне ачтырдылар. Мәдрәсәгә зәңгәрсу шинель кигән жандармнар, кара шинельле городовойлар кереп тулды.

Жандармнар арасында зуррак дәрәҗәле булып күренгәне, кәзәки астыннан ыштан балаклары күренеп торган назирның куркынган, агарынган йөзенә карап:

— Урамга чыга торган тагын нинди ишекләр бар, шәкертләрнең йоклый торган бүлмәләре кайда, барысын да күрсәт! — дип, тупас тавыш белән әмер бирде.

Ул арада икенче катка менә торган баскычта кайсы куркынган, кайсы каушаган, кайсы кызыксынган кыяфәтле шәкертләр күренде. Алар да, назирлары кебек, киенеп өлгермәгәннәр. Кайберләре пинҗәкләрен җилкәләренә генә салган, кайберләре юрганнарына уранган иде. Боларны күрү белән, әлеге жандарм:

— Барыгыз да үз урыннарыгызга марш! — дип кычкырды.

Шәкертләр күз ачып йомганчы баскычтан юк булдылар. Назир инде бераз исен туплап өлгергән иде. Ул калтыраган тавыш белән жандармга мөрәҗәгать итте:

— Баш мөдәррис Зыя әфәнде Камалины чакыртырга мөмкин булмасмы икән? Мин бит бернәрсә дә белмим. Мин барлыгы тик назир гына!..

Назирның шул сүзләрен генә көткән шикелле, ишектән Зыя әфәнде килеп керде. Аның артыннан тәбәнәк буйлы, таза гәүдәле дворник күренде. Ул жандармга карап:

— Ваше благородие! Әйткән кешегезне китердем, инде китсәм дә буламы? — дип сорады.

Жандарм аңа:

— Юк, китмә! Танык булырсың, понятой! — дип җавап бирде дә назирга: — Мин сиңа ни әйткән идем? Бар, урамга чыга торган ишекләрне күрсәт. Аннары йокы бүлмәләрен күрсәтерсең. Синең белән городовой Матвеев барыр! — дип җикерде.

Жандармның алдына Зыя Камали килеп басты:

— Ваше благородие, монда нинди дер аңлашылмаучылык булырга кирәк. Бу — «Галия диния» исемле татар мәдрәсәсе. Монда дини фәннәрне укучылардан башка кешеләр тормый,— дип аңлата башлаган иде, башлык кырт кисте:

— Һичбер төрле анлашылмау да, ялгышлык та юк. Менә прокурорның ризалыгы,— дип, Камалига мөһер басылган рәсми бер кәгазь тоттырды.

Чыннан да, ялгышлык юк икән. Прокурор «Мәдрәсәи галия диния»дә тентү ясау кирәклеген раслаган. Зыя әфәнде, аптырап, кәгазьне тагын бер тапкыр укып чыкты, аның тискәре ягын әйләндереп карады. Шул вакыт кылт итеп ике идарәнең соңгы утырышында Закир байның әйткән сүзләре исенә төште. Ул бит:

«Минемчә, аны иркәләп утырганчы, тотарга да бөтен нярченнәре белән бергә жандарм кулына тапшырырга кирәк!» — дигән иде. Чынлап та, Закир бай шул дәрәҗәдә түбәнлеккә төштеме икән?

Жандарм башлыгының кычкырып:

— Тентүне йокы бүлмәләреннән башларга! — дип әйтүе Зыя Камалины күңелсез уйларыннан айнытып җибәргән кебек булды.

Жандармнар бөтен мәдрәсәнең астын өскә китереп, барлык әйберләрне актарып, тузгытып, нинди кульъязма күрсәләр, шуны беркетмәгә кертеп, шәкертләрне тәмам алҗытып бетерделәр. Алар беренче катка төшкәндә, сәгать алтынчы иде инде. Чыгып китәр алдыннан, жандарм башлыгы Зыя әфәнденең кабинетына кереп, шәкертләрнең мәдрәсәдәге исемлеге белән бүгенге көндә тентелгән шәкертләр исемлеген чагыштырып карады.

Ул, үзенең исемлегендә Галимҗан белән Фәйзерахманның фамилияләрен тапмагач, бик җентекләп, бу шәкертләрнең ни өчен читтә яшәгәнлекләре, әхлаклары, ата-аналары кем икәнлекләре турында сорашты. Зыя әфәнде бу ике шәкертне мөмкин кадәр уңай яктан сыйфатларга тырышты:

— Бик тырыш, зирәк, акыллы егетләр. Өч ел буена һичбер төрле әхлаксызлык, әдәпсезлек күрсәтмәделәр, — диде.

Жандармны бу ике шәкерт аеруча кызыксындырганлыгын аңлагач, Зыя Камалиның Закир байдан шикләнүе тагын да артты. «Сүземне тыңламадыгыз, соңыннан үкенмәгез»,— дигән иде. Ул вакытта аның шундый янауларына илтифат итмәгән идек. «Нинди вөҗдансыз, оятсыз бәндә икән! Мәдрәсәнең абруе аның каршында бер тиенгә дә тормый!» — дип уйланды Зыя әфәнде, ачудан йөрәге тетрәнеп. Ләкин хискә бирелеп утыра торган вакыт түгел. Имтиханнар якынлашып килә иде,

ә жандармнар, тикшерергә дип, шәкертләрнең дәфтәрләрен, китапларын төяп алып киттеләр. Бу китап-дәфтәрләрдә хөкүмәткә каршы һичбер төрле сүз булмаганын Зыя Камали бик яхшы белә иде. Шуңа күрә ул:

— Тикшерергә дип алынган китап-дәфтәрләр соңыннан кайтарылачакмы? — дип сорады.

— Хөкүмәткә, әхлакка каршы язылган зарарлы фикерләр булмаса, кайтарылыр.

Жандармның бу җавабы Камалины беркадәр тынычландыра төште. Ул тагын:

— Аларны тизрәк карап, тизрәк кайтарып бирергә булмасмы, чөнки ул китаплар — барысы да дәреслекләр, ә дәфтәрләрдә дәресләрнең конспектларыннан башка нәрсә юк,— диде.

Камалиның бу сүзен ишеткәч, жандарм: «Бу әфәнденең үтенеченнән минем үземә берәр файда чыгарып булмасмы?» — дип уйлады. Шуннан соң кармак салып карарга булды:

— Китапларны тизрәк кайтарыр өчен тәрҗемәчегә көн-төн эшләргә кирәк булачак, ә тиешеннән артык эшләгән вакыты өчен түләргә жандармериянең мөмкинлеге юк,— диде ул.

Жандармның тел төбендә ни булганын Зыя әфәнде шунда ук аңлап алды.

— Тәрҗемәчегә түләргә кирәк икән, баш өсте, без үзебез түләрбез, тик, тәхминән [1], күпме акча түләргә кирәклеген әйтсәгез иде, ваше благородие! ..

Ике көннән соң илле сум түләп китап-дәфтәрләрне барып алырга килештеләр. Ниһаять, Зыя әфәнде Камали көтелмәгән, чакырылмаган кунакларны тышкы ишеккә чаклы озатып куйды.

## 8

Фәтхел белән Вәсим, иртәгәсе көнгә дәресләрен хәзерләп бетергәч, өс-башларын киенеп, урамга чыктылар.

Тышта якты иде әле. Көннең яхшы ук озынайганы сизелә. Кышның инде чатнап торган суыклары узган, ләкин әле җылы килеп җитмәгән. Шулай да юл читендәге көртләр күзгә күренерлек булып иңгән, кыш уртасындагы аклыкларын югалтып каралганнар. Һавада яз башының якынлашуы билгесе — күңел дәртсендергеч дымсу бер җиләслек сизелә башлаган иде. Мәдрәсә баскычыннан төшеп, урамга аяк басу белән, егетләр туктап, күкрәкләрен киереп, тирән-тирән итеп сулу алдылар. Шуннан соң гына ашыкмыйча атлап китеп бардылар.

Галимҗанның фатиры шул ук мәхәлләдә, мәдрәсәдән ерак түгел иде. Әкрен атласалар да, шактый тиз барып җиттеләр. Ишекне Галимҗан үзе ачты.

Ишекне ачып бүлмәгә керделәр. Бүлмә бик кечкенә иде. Уң кулда «солдат караваты» дип йөртелә торган тар, тәбәнәк тимер карават. Өстенә чуар ситсыдан сырган юрган ябылган. Шундый ук тышлы мендәр. Бүлмәнең бердәнбер тәрәзәсе буенда — иске өстәл. Тәрәзә төбе, өстәл өсте, сул як стенага кагылган киштә китап белән тулган.

Фәтхелнең дә, Вәсимнең дә бу бүлмәнең фәкыйрьлеген күрүләре беренче түгел иде. Шулай да Фәтхел:

— Ни дип мондый сасы өйдә яшисең, Галимҗан? Уфада чистарак фатир табылмас идемени? — дип сорады.

— Чистарагы гына түгел, зиннәтлерәге дә бардыр. Ләкин андый фатирларның хакы да үзләренә күрә зур бит, ә мин аена ун тәңкәдән артык хәрәҗәт итә алмыйм... — диде Галимҗан...

[1] Тәхминән — чама белән.

— Аена ун тәңкә хәрәҗәт итәм дисең. Шундый фатирда торгач, ул кадәр акчаны кая куеп бетерәсең? — дип, Вәсим сорамыйча түзмәде.

Галимҗан көлемсерәп куйды да:

— Бик кызыксынсаң, исәпләп кара, — дип сөйләп китте: — Аена ике тәңкә мин шушы фатирга түлим. Китап, дәфтәр, кәгазь алу кебек хәрәҗәтләргә ай саен иң кимендә бер тәңкә-тәңкә ярым китә. Кер юдырту, аяк киемен ямату кебек эшләргә тагын бер-ике тәңкә куй. Моннан башка өс-баш, кием-салым дигән нәрсә дә бар бит әле. Шундый хәрәҗәтләрдән соң ай буена ашау-эчүгә биш тәңкәдән артык калмый. Бу — көненә унбиш-унҗиде тиен дигән сүз. Әгәр авылдан ара-тирә күчтәнәч килгәләмәсә, аяк сузарга мөмкин. Менә шулай, туган, ай саен ун тәңкә оча да китә!..

Галимҗан сүзен әйтеп кенә бетерде, ишектән Шәһит белән Фәйзерахман килеп керделәр. Өс-башларын салып, Галимҗан янына караватка утырдылар.

Сүзне Шәһит башлап җибәрде:

— Я, син чакырдың, без килдек, Галимҗан. Әллә син Зыя әфәнде сөйләгән сүзләрнең сыйныфта барысын да әйтмәгән идеңме, яки тентүдән соң Зыя әфәнде сиңа тагын ни булса да әйттеме?

— Үзегез беләсез, Зыя әфәнде каты сөйләргә яратмый, — дип сүзгә кереште Галимҗан. — Ләкин кирәк урында йомшак түшәсә дә, ятарга катырак чаклар да булгалый. Ул көнне дә шулайрак булды. Мин аның тел төбендәге сүзләреннән шуны бик яхшы аңладым: «Киләсе уку елы башланганда нинди дә булса бер сәбәп табып, мине мәдрәсәгә алмаячаклар. Инде тенту мәсьәләсенә килсәк, бу, әлбәттә, бүтән беркемнең дә түгел, тик Закир байның кабахәтлеге. Бу этлекне ул мине һәм сезне жандармерия кулына биреп, мәдрәсәдән кудыру нияте белән эшләгән. Ләкин ни өчен ул мәдрәсәдән читтә яшәгәннәрнең, ягъни безнең адресларыбызны биреп, бездә дә тенту ясатмады — моны мин аңлап бетермәдем. Бәлки кайда торганыбызны белмәгәндер. Әмма мәдрәсәнең ишеге киләсе уку елында минем өчен ябык булачагы бик билгеле. Димәк, үземне бүгеннән үк «мин мәдрәсә шәкерте түгел» дип исәпләргә хаклымын.

Фәйзерахман Галимҗанның җиңенә ябышты:

— Әллә син бүген үк мәдрәсәне ташлап китмәкче буласыңмы?! Безне шуны әйтер өчен чакырдыңмы?!

Башкалар да аптыраган төсле күренә иде. Галимҗан «юк» дигән мәгънәдә башын чайкады.

— Бүген үк китәргә җыенмыйм, — диде ул, — ләкин якын арада, имтиханнар сәбәбеннән иркенләп сөйләшергә вакыт булмас дип, сезне бүген чакырдым. Үзегезгә мәгълүм, әгәр мин бүген үк чыгып китсәм, мәдрәсәдә, бигрәк тә безнең сыйныфта шау-шу күтәреләчәк. Мин исә моңа сәбәпче булмам дип, Зыя әфәндегә сүз бирдем. Димәк, теләсәмтеләмәсәм дә, имтиханнар беткәнче ташлап китә алмыйм. Ләкин көзгә мәдрәсәгә кайтмам инде...

— Башка берәр мәдрәсәгә керергә уйлыйсыңмы? — дип сорады Фәтхел.

Галимҗан мәдрәсәне ташлагач ни эшләячәген алдан уйлап куйган икән.

— Башка мәдрәсәгә керергә исәбем юк, — диде. — Безнең «Галия» җәдит мәдрәсәләр арасында иң яхшылардан хисаплана. Шулай булгач, моннан начар мәдрәсәгә барып керүдән ни файда? Безнең мәдрәсәләрнең иң яхшысы да русларның гимназияләре, реальное училищелары биргән белемне бирә алмый. Берәр студентнымы, учительнеме яллап, көн-төн укырга да «аттестат зрелости» дигән кәгазь алырга кирәк. Аннан соң университетларның да ишеген шакып карамакчымын. Мин үземә шул юлны сайладым...

— Ә-ә-х! Бу юл һәркемгә насыйп түгел шул! Студенты да, учителе дә сине бушлай укытмас бит! Ул акчаны каян аласың?! — дип, Вәсим үкенечле кыяфәт белән башын чайкады.

Фәйзерахман да шул ук сүзне куәтләде:

— Чыннан да, Галимҗан, укыткан өчен учительгә түләүдән башка, ашарга-эчәргә, өс-башны карарга, фатирга түләргә кирәк бит. Ул хәтле акчаны каян алмакчы буласың?

— Тормышым җиңел булыр дип уйламыйм,— диде Галимҗан,— ләкин бу көнгәчә студентка да түләп килдем, ялангач та йөрмәдем, бик үк туеп, теләгәнемне ашап-эчмәсәм дә, ачтан үлмәдем. Мәдрәсәдән киткәч тә шулай яшәрмен әле. Яза башлаган бер-ике хикәям бар. Шуларны язып бетергәч, берәр нәшрият басарга кабул итсә, тормышны башлап җибәрергә булыр. Гомумән, әдәби эш белән шөгыльләнеп көн күрермен дип уйлыйм...

— Шул-шул! — диде Фәтхел дә, башын кагып.— Һәркемнең әдип булырлык сәләте юк шул! Безнең кебекләрнең җәй буе эшләп тапкан акчасы кыш буе ачлы-туклы яшәүдән артмый. Фатирга чыгып, учительләр яллап яшәү безгә кая инде!..

Галимҗан, иптәшен юаткан сыман:

— Мәдрәсәдән тыш үзлегеңнән укырлык имкянияте булмаган кеше бер син генә түгел, — диде.— Шуның өчен мин Зыя әфәнденең имтиханнарны тыныч кына үткәреп җибәрергә кирәк дигән фикеренә каршы килмәдем һәм башкалар белән беррәттән имтиханнарга хәзерләнергә дә сүз бирдем.— Шулай дигәч Галимҗан бераз тукталып торды да тагын дусларын юаткан сыман сөйләп китте: — Мәдрәсәне бетергәч, ни дисәң дә, мөгаллимлек хокукын биргән кәгазь кулыңда булачак, ә мөгаллим булып, аена егерме биш-утыз тәңкә акча китерә торган урын тапсаң, учительгә дә җитәр, тамагың да тук, өс-башың да бөтен булыр...

Фәйзерахманның хәтере калды:

— Үзең мәдрәсәдән китәсе булгач, безне, шул шәһадәтнамәне алыр өчен, идарә әгъзалары алдында баш иеп, ни дисәләр шуңа күнеп, буйсынып яшәргә үгетлисеңмени?!

— Әмма дә уттай дөрләп китәсең үзең, Фәйзерахман дус! — дип, Галимҗан кулын аның җилкәсенә куйды.— Тынычлан! Сезне чакыруымның сәбәбе — мин киткәч, мәдрәсәдә башлаган эшләребезне ничек дәвам иттерү турында киңәшү иде. Ничек итеп «Белем җәмгыяте»н, «Аң» газетасын, тышкы идарәнең тешe-тырнагыннан саклап, дәвам иттерергә? Мәдрәсәгә үзебезнең ана телебезне, тарихыбызны, рус телен, рус әдәбиятын укытырлык мөгаллимнәр алдыру юлында башлаган көрәшебезне ничек туктатмый дәвам иттерергә,— менә шул турыда сөйләшергә кирәк! Бу бары тик синең вә минем өчен генә кирәк эш түгел. Синнән вә миннән башка да белем алырга теләгән, чын мәгънәсендә кеше булырга омтылган татар яшьләре күп бит...

Бик озак сөйләшеп-киңәшеп утырдылар алар. Һәркайсының өстенә алган вазифасы тәмам ачыклангач кына таралыштылар.

Галимҗан бер дәрестән дә калмыйча, һәркөнне мәдрәсәдә күренгәч, югары сыйныфларның шәкертләре дә тынычландылар. Имтиханнарга хәзерләнә башладылар. Имтихан көннәре дә тыныч кына үтеп китте. Укулар беткәч исә, Галимҗан, иптәшләре белән саубуллашып, мәдрәсәгә инде бүтән кайтмау нияте белән, авылы Солтанморатка юл тотты.

Аның тормышындагы мәдрәсә чоры шуның белән тәмам булды.

*(Беренче китап бетте)*

1967—1973,
Сәмәрканд.

## Әхсән Баянов

# КЫШКЫ ЧӘЧӘКЛӘР

### Шагыйрь мәхәббәте

Җәй.
Ерак җәй.
Айлы тын кичләрдә
Тәрәзәдән якты бөркелә.
Тәрәзәдән нурга кушылып чыга
Шагыйрь сүзе дөнья иркенә.
Төнгә ап-ак моң тарала.
Июль йөрәк җылысы белән төренә.
Җәй хөрлеге, туар көннәр бәхете
Ак каеннар төсле күренә.

Сахраларда агач башларына
Менгән чакта — зәңгәр моң ява.
Без җитәсе биеклектән карап,
Тагын-тагын шагыйрь елмая.

Инде карыйм еллар түбәсеннән.
Ул һаман да күктән өн бирә.
Биеклекләр серен эзләп бугай,
Керәм аның чоры, гомренә.

*
* *

Төн.
Ерак төн.
Җир балалары йөрделәр
Кып-кызыл утлар тотып.
Йөрделәр шомны яндырып, һәр караны куркытып.
Сәнгатьнең шәрә тәненнән кара кәфенне йолкып
Ташлады да,
Әверелдереп төнне җырга кем кинәт
Игълан атты урамнарга?
Утлы игълан:
— Хөррият!

Искелек үлде, җиңелде,
Без элдек күккә байрак.
Салкыннан, җилдән калтырап
Тормас ул үксеп яңгырда,
Корычтан ныклык алыр да
Гел алга җилпер канат.
— Чаң, чаң, чаң! —
Тетрәде таң.
Сандалларда тапталып,
Искелек үлде. Яңаны
Шаулашып яшел җәй төсле,
Чыгардылар актарып.

*
* *

Таң.
Таң атса, бакты күзләр
Бер-берсенә аптырап:
Гап-гади бер егет йөри җыр таратып:
— Хөррият!

Килде шулай шигъри илгә
Ул пәйгамбәр төслерәк...

*
* *

Таң.
Таң капкасын чыккач...
Аның белән бергә
Инде күпләр җырлап киләләр.
— Чың-чың-чың-чың! —
Корыч тавышларын
Күк чыңына эретә беләләр.
Җырчы дуслар күкләр галилеген
Тараталар гади күзләргә:
— Җир иреге безгә, эш иреге —
Зынҗырларны сындыр, өзгәлә!

Ә су яклап килә «Пәри кызы»:
— Җан иреге — минем кулләрдә.
— Син кем, кызый?
— Бәхетең дә, үлемең дә
Минем тирәдә.
— Син кем?!
— Әйдә! —
Атлый шагыйрь кыз артыннан...

*
* *

Җир йөзенең барлык рәссамнары,
Сез моңа тиң төсләр тапмассыз.
Тапсагыз да, күзләр балкышына
Мондый кайнар хисләр якмассыз.
Фәрештәләр, сез дә ярышмагыз,
Су кызыдай гүзәл булмассыз.

Ап-ак тәне аның шундый тере,
Сезнең кебек ләкин гөнаһсыз.
Тау-ташларны эретердәй шәфкать
Балкый кызның төпсез күзендә.
Газраил дә, тәңре хөкемен онытып,
Кире китәр килгән җиренә.
Китәлмәсә, белештерми үзен,
Аягына кызның ташланыр.
Аннан... җанын бирер... Шигырь туар.
Һәм мәхәббәт мәңге яшь калыр.
Башны башка куеп торыр икәү
Мәңгелеккә калган рәсемдә.

Рәсем ясый шагыйрь... Ә юк,
Яши бары...
Рәсемнәр тик минем йөрәктә.
Сөя бары...
Сөеп, яшәп шулай
Ил күгенә яза исемен дә.
Мәхәббәте белән атлый бергә,
Ай нурлары ябынып өстенә.

Атлый җәйләр, атлый көзләр аша.
Белмәгәндәй кызның чын атын,
Язып куя карга «Галия!» дип.
Тәңкә карлар ява.
Дөнья тын.

*
* *

Ап-ак карга басып атлый алар,
Артларыннан ияреп бара җил.
Өйгә кергәч алар, җиргә ятып,
Чыкканнарын көтеп кала җил.
Алар икәү, кызык итеп җилне,
Тәрәзәдән карый урамга.
Борын тертеп карга, сикерә-сикерә,
Мазмай белән уйный җил анда.

Алар өйдә.
Чыкканнарын көтеп,
Сабырлыгын җуйган җил исә —
Елый-елый төндә тәрәз кага.
Алар икәү көлешә-көлешә,
Бер бүлмәдә кала төнката.
Алданудан җил, йокысын җуеп,
Бурап йөри дөнья буйлата.

*
* *

Таң.
Таң атса, алда — гади Казан.
Таш урамда ята салкын кыш.
Карлар белән бергә күмә сине
Мәшәкатьләр, күмә эш, тормыш.
— Әкият, хуш...

Беләм, беләм, Казан урамнарын
Мин аныңча сөям-яратам.
Аңарга да кемдер ташлар аткан,
Я, сөюен кушып, кар аткан.
Пәри кызы, юлларына чыгып,
Утлы гөлләр куйган үстереп.
Ул гөлләрне шагыйрь җыйгандыр да,
Аһ иткәндер минем төсле үк.
Әх, нинди җыр!.. Җырга каршы ләкин
Кара тавыш килә. Кай яктан? —
Кабактан...
— Минем күкрәк — барабан: даң, даң, даң,
Дөберди гыйшкым яман:
Даң, даң, даң, даң, даң, даң! —

Җырчы егет таныш тавышлы —
Лап-лоп килгән таныш Яуышны
Чак сыйдырды урам:
«Даң, даң, даң...
Мәхкүм инде, дөнья, син үлемгә —
Кояшыңны тотып суйдым мин.
Йолдызларың койдым, аеңны да
Биек дарга асып куйдым мин».

Атыла шагыйрь аңа каршы:
— Кем ул
Кәкере кулын суза йолдызга?
Ай, Кояш та калсын үз урынында.
Күкрәп инде яңгыр узды да —
Юды җирне, күкне, йолдызларны,
Дөнья калды чиста һәм зәңгәр.
Күз яшьләре белән юып илне,
Сөю төсле кайнар әләмнәр
Элдек әнә күккә, күрегез!
Инде җанга һәм акылга хөрлек
Биргән тормыш үзегез төзегез.

Шаулый мәйдан. Акырып мәйдан аша
Җанга лап-лоп керә өч исем:
Сәлмән, Сәгыйть, аннан Яуыш үзе.
Һәм бер диеп уйла өчесен.
...Шау-шу тәмам...

Иртәгесен... шагыйрь күрә, үзенең
Кара исемен күрә гәзиттә:
«Коллык сандугачы!» диеп язган Сәлмән,
Һәм имзасын салган Сәгыйть тә.

*
* *

Әкиятләрдән кайткач, күрә шагыйрь:
Ахры, Яуыш аңа тиңдәштер.
Кылыч итеп кулын, телә күкне,
Дус булмаса, бәлки көндәштер...

Трибунада шагыйрь урынын алып,
Ул аннан да яман кычкыра.
Ә шулай да... мәҗлес азагында,
Башын иеп, тыйнак, тын тора.
Яуыш чаклы модный булмаса да,
Бик сынатмый икән Сәгыйть тә:
Шагыйрь генә түгел, тәрҗемәче
Һәм мөхәррир үзе гәзиттә.
Ә шулай да... Сәлмән кем дисезме?
Язмаса да, ул да — чын даһи.
Казанның бар каләм әһелләрен
Дер селкетеп тота, билләһи.

Дуслык вәгъдә итеп, иллә мәгәр,
Котлап алар өйгә килгәннәр.

Сәлмән канат җәйгән:
— Әй, тиң, пар икәнсез —
Коммунистик гаилә төзегез.
Яуыш көлә:
— Кайда әле
Безнең гыйсъян диган сүзебез?
Без — ирекле яшьлек, бетсен оят,
Кал ялангач, киемең булса да.
Безнең сөю — тән һәм җан иреге.
Тик бер алла — табын гыйсъянга!

Теләк әйтми каламы соң Сәгыйть:
— Бирешмәгез, дуслар, Яуышка —
Гакыл белән Ирек сугышсалар,
Җиңеп чыксын Сөю ярышта.

Теләкләрнең юк чамасы, саны.
Иң татлысы шуның — кич житте.
Өйгә тулды тагын бөек мәгънә —
Икәү генә калу бәхете...

*
* *

Тукталгандай тоелса да Вакыт,
Тормыш агыла тагын үзенчә.
Галиясе йөри рабфагына,
Шагыйрь эзли... акча, көн килсә.
Эзли, таба. Җилкәсендә — тормыш,
Сөенә-сөенә бара күтәреп.
Вакыт — бәхет, мәшәкатьтән артып —
Шигырьгә дә хәтта житәрлек.

*
* *

Кар-чәчәкләр язын шаулап ага,
Чын чәчәкләр каплый томандай:
Болыннарга төшә, бакчаларга.
Томаннарны җилләр куагандай,
Таҗлар сибелеп, нәни өмет чыга,

Һәм ярала бәби җимеше дә.
Мәхәббәттән ашып инде җиргә
Аваз сала нәни кеше дә.
— Минә балам, кояш тирәсендә
Бер планета туды өр-яңа.
Ул сугышчан булыр — Марс сыман,
Гакыл иреге даулар дөньяга!

Ә шулай да... Мәңге сыный тормыш,
Диплом бирми... уза белмәсәң.
Ятлагыз дип, язды минә тагын
«Аерылышу» дигән бер мәсәл:
Бергә чакта кем дә матур тора,
Карагыз сез аеры яшәп тә.
Мәхәббәтнең нәрсә икәнлеге
Ачылып китәр башка җәһәттән.

Җәйләр узып, көзләр җитте исә,
Галия китә Мәскәү вузына.
Каникуллар дигән бәйрәм генә
Кыш салкынын баса. Кулына
Ак чәчәкләр тотып Галия кайта —
Кайнар сөенеч тула тын өйгә.
Ата белән бергә сабый көлә —
Яшь бәрәндәй сикерә, йөгерә.
Бу көнне дә бер рәсемгә төшеп
Истәлеккә салып куялар:
Ата, бала, ана...
Никтер, өчесе өч якка
Карап торалар.
Галия анда ап-ак тунын кигән —
Пакь карлардан тукып тегелгән.
Шагыйрьнең дә чуар якасына
Шул чәчәкләр бугай сибелгән.
Бала, шлем кигән ай шикелле,
Киләчәктән карап елмая.
Һәм теләк тә кала истәлеккә:
«Безгә кара, Галия, моңайма».
Шигырь туа: «Шушы өч гомерне
Өчкә кисеп аерып ташлама».
Саубуллашу. Вокзал. Моңаюлар,
Сагынулар тагын башлана.

* * *

Сагынулар, аһлар, уфтанулар
Сыяр димсең әллә хатларга?
Хатлар, хатлар ашыга ике яклап:
— Алыштырма, бәгърем, ятларга.
— Алыштырма!

Сәгыйть хәбәр китерә:
«Синең хатын анда...»
Зәңгәр күзләр берни
Аңламыйча карап тик тора.

— Ялганлама!
— Син бит Акыл яклы!
— Теләсәң нәрсә сөйлә, ышанмыйм.
— Акылыңа кил, шагыйрь!
— Ышанмыйм!

Галиянең саф күзләре белән карап,
Сабый аяк тибә:
— Ышанмыйм!
— Ышанмыйм!

*
* *

Ләкин ерә көн-төн ми түрендә
Әнчек маэмай булып көнче шик.
Һәм җанына шагыйрь, ачу итеп,
Баш кадәрле йозак элде тик.
«Чәбә!» диеп куа торды шикне,
Бусагадан аны кертмәде.
Ак ышаныч тулы хыяллары,
Гәзитләрнең бизәп битләрен —
Төзегәндә матур, яңаны,
Ил буйлата яңгырап таралды.

Аның тавышы ерак киткән саен,
Усаллашты яман «дуслар» тик.
Шигырь чыкса бер көн, икенче көн
Көт мыскыллы тиргәү, көт тәнкыйть.
Юл аралый сыйнфый хата табып,
Акырулары артты Сәлманнең:
— Хатыннарны тиңли мәчеләргә,
Кулакларны шагыйрь сәламли.
Шагыйрь күңеле меңгә тетелсә дә,
Рәнҗешләре кучми шигырьгә:
— Бар нәрсәгә ирек — эшкә, мәхәббәткә,
Ирек хәзер хәтта өрергә!

*
* *

Кичереш китә бары хатка тезелеп:
«Әллә юкмы, Галиям, саулыгың?
Өч хат яздым сиңа. Ә син? Нигә,
Ник җавапсыз тагы калдырдың?
Сау булмасаң, язсын иптәшләрең...
Хуш, сөеклем, исән бул инде.
Җибәрермен тиздән туныңны —
Туңып йөрмә».

*
* *

«Күңеле булып минем тиргәлүдән,
Борыны күккә тигән Сәлманнең:
— Шауласыннар диеп, сүгелә торган итеп
Язасың син юри әллә,— ди.

«Кем тырышсын юри тукмалырга,
Үзең тырыш шулай, дивана».
Башка килгән шул сүзне дә ләкин
Әйталмадым никтер мин аңа.
Ә үзләре? Кайда оялулар!
Суга тора «буржуй!» тамгасын.
Ал чапанга астар иткән алар
Кара ният: «Шагыйрь язмасын».
Ә мин тынсам, кырлар, мәйданнарга
Нык яңгырар Сәгыйть, Яуышлар.
Алар белән бергә Сәлмәннәре
Эләгеп калыр алтын тарихка...
Сыйнфыймы бу хәйлә? Беләм, шулай
Бер шагыйрен үтереп сыйныфның,
Кабак җырларына һәйкәл кою
Сыйнфый ният булмый ни булсын?
Минем җавап:
— Җитте күзегез —
Сары яфрак оча, күрегез.
Алтын ява диеп белдегез дә
Абына-абына җыя йөрдегез,
Дон-Кихотлар, непман һәм мещаннар,
Хлестаковлар! Әйдә, җыегыз!
Казыныгыз! Шушы булыр ләкин
Соңгы туегыз.

Бу җырларны Сәлмән ишетми:
«Яшәп ята мәчең ничек?» — ди.

— Мин җырлаган мәчеләр, казлар — бүтән,
Син — хулиган дигән паспортны
Ертып атам, тагын тилерсеннәр.
Минем иман — сөюем халыкны.
Казларымны, песи малайларын
Басуларга илтәм — күмәк кыр.
Минем белән бергә авылымның
Киләчәген җырлый трактор.
Йотып көнче дуслык әчесен,
Тракторны черки чәнчесен...»

*
* *

«Минем җавап үземә кире кайта —
Сүзләр синең хакта... чын хата
Кыла күрмә, бәгърем...
Бала терелә, көлә.
Сокланырга куркам, күзсенә.
Син булмагач, тормыш суык безнең,
Бушлык сизелә бүлмә эчендә.
Утын алдым, күпкә җитмәс ләкин —
Акча ягы... бигрәк аз алдым.
Сине сагынып туңа Казаным.
Сиңа акча салдым...»

*
* *

«Синең хакта уйлап уза гомер,
Ахры, җилгә оча җырларым.
Йөрәгемә тула гыйсъян бары,
Мәңгелеккә, ахры, тынармын.
Җырларыма охшап инде туа
Сиңа языла торган хат кына.
Хатларымны сакла — дастан булып
Калсын керсез сөюем хакында».

*
* *

«Үзем иҗат иткән синең рәсем
Урының алып кайгым тарата.
Үзеңнән дә чибәр һәм акыллы
Һәм мине гел сагына, ярата.
Чәчләремнән сыйпап, көнләшүсез
Тугрылыгын саклый белә ул.
Усал сүзләр белми, хыянәтсез күңелем
Дулкынлатып сөя, көлә ул.
Алыштырсаң мине башкаларга,
Синнән генә усал көләчәк.
Беркем күрми үзен... үлсәм генә
Үзем белән бергә үләчәк».

*
* *

Җиде хатка килде тик бер җавап.
Укыса да шагыйрь ничә кат,
Аңламады:
«Деканатка килде сәер хат —
Син икәнсең, имеш, дворян улы.
Сиңа кулым, йөрәгем биргән өчен
Дошман булып чыктым ап-ансат.
Күрсәтеләр хатны — язуы таныш.
Кул куйса да бары «Чаткы» дип,
Сәлмән дусың... Ә син...
Нигә фаш итмисең шуны
Адәм актыгын?..

Галия».

*
* *

«Нинди хәйлә! Гәзитләрдә әллә
Мине кыйнап инде туйдылар.
Тотындылар сезгә. Дошман нәселе дип,
Техникумнан башта кудылар
Сеңелемне минем.
Хәзер сине... Ә юк,
Исемең чиста калыр, бирелмә!
Алдап бер юл шигырь язганым юк —
Ышаналар мeңнәр. Синең дә
Ышанырлар изге сүзеңә.

Техникумда язу беркеткәннәр
«Дворян кызы!» диеп сеңелемне.
Бу сүзләрне кемнәр тараталар?
Җырлы кәрәш шушы түгелме?
Җырлы, сыйнфый кәрәш!
Таш диварга яздым:
— Безнең әткәй тик бер икәнне
Авыл белә... Әнкәй безнең аңа
Әллә инде хыянәт иткәнме?
Ана сөте белән ант итәм — юк!
Ана намусын яклый алырбыз.
Дворян түгел, гади сукачы карт
Балалары булып калырбыз. —

Ишеттеләр сүзем, техникумның ишеге
Сеңелебезгә кабат ачылды.
Белем — сыйныф биргән хокук безнең!
Түкмә яшеңне».

*
* *

Ләкин...
Факультетта җыелыш. Галия шунда.
Керфекләре туктый биюдән:
«Аермагыз мине тик белемнән,
Баш тарттым мин инде... иремнән...»

*
* *

Ир тик моны артык соң беләчәк...
«Юлга дәшкән — йөрәк чаңыдыр...»
Якын булса, күреп торса да бит
Ул ышанмас иде барыбер.
Чумып мена Мәскәү шау-шуына,
«Пәриенең» торган җиренә
Килсә тиз-тиз генә, Галиясе
Өлгермәгән кайтып өенә.
Галиясенең дус кызлары башта
Никтер пышан-пышан килделәр.
Ә аннары:
— Кайтып җитәр тиздән, — диделәр.

Шагыйрь инде үзе түзалмыйча,
Әрле-бирле килә бүлмәдә.
Кич. Караңгы. Кызлар йоклар тиздән...
Шуны сизә дә,
Ул урамга чыгып көтә хәзер.
Сәгатьләрнең саны бутала.
Тәрәзләрдә якты сүнгән саен,
Үз-үзеннән йөрәк ут ала.
Яныл, көтеп аргач, шагыйрь читкә,
Карт тирәккә килеп сөялде.
Караңгыда дөп-дөп типте йөрәк:
«Ятларны ул әллә сөяме?»
Караңгыда күренә якты сукмак —
Кешеләр инде сирәк үтәләр.
Таныш гәүдә... Юк, ышанма, шагыйрь,

Ялгыз түгел, икәү бит алар.
Таныш гәүдә... Ах, ят булса шәүлә!
Бу чаклы да ник соң таныш ул?
— Галия! — ишетмәде шагыйрь,
Ишетмәде үзенең тавышын.
Тегеләр дә һичбер ни сизмичә
Туктaлдылар ишек янында.
Ишек янындагы тар урында
Якын кешең ятка сарыла...
— Галия! — Салкын, юеш каралыкта
Тавыш, никтер, тагын адаша,
Якын кеше — ятлар кочагында...
Алдашадыр күзләр, алдаша?
— Галия! — Тавыш чыкмый күкрәгеннән.
Галиясе, көлә-шаяра торгач,
Яулыгының җиргә төшкәнен
Сизми әллә? Әллә онытканмы
Үзенең ул Галия икәнен?
— Галия! —
Кинәт... Ишетте дә исемен,
Басып калды тораташ сыман
Өч күләгә. Өчесе дә тора
Читкә китеп вакыт агышыннан.
Җирдә яткан ак яулыкка карап,
Өч сукмакта тора өчесе.
Өчесе дә таныш... Яңгыр гына, тиле,
Юмак булып гыйбрәт әчесен,
Коя, коя...

Юк, юылмас ләкин мондый пычрак,
Яулыкларны юа алсак та.
Галия! Бөек исемең әнә
Аунап ята пычрак асфальтта.
Тәндә көч һәм җанда үч беткәнче
Таптаргамы тилереп бер аны?
Таш-асфальтта шагыйрь мәхәббәте,
Ышанычы, иң ак еллары
калды...

Күтәрде дә тик яулыкны шагыйрь
Караңгыга кереп югалды.

*
*   *

Казан.
Ул язасын үзем язам.
Мондый чакта дусны кем ташлар?
Күләгәләр, гүя кайтып алдан,
Өенә килгән, гүя юлдашлар.
Күләгәләр аннан гафу сорый,
Әйләнмәкче булып хак дуска.
Хәтерләтә берсе Галияне,
Икенчесе охшаш Яуышка.
Икенчесе китә бу ишектән
Кермәс өчен бүтән.
Ә Галия? Дәшмә аңа да!
Ак яулыгын өйдә тапкан булып,
Ник кул суза әле балага?

Кул суза да тизрәк алып кача
Җаннан-тәннән йолкып ул аны.
Өйдә кала ачы бушлык бары —
Бүлмә салкын, дөнья томанлы...

Күләгәләр хәзер тәрәз кага.
Таныш түгел хәзер, чит алар.
Ыңгырашып тора-торалар да
Далаларга качып китәләр.
— Галия!

*
* *

Тик еpактан аның тавышы җитә:
— Нинди рәхәт йөздек җан иреге,
Тән иреге дигән күлдә без.
Син артык тиз арган өчен генә хәзер
Хәсрәт атлы диңгез гизәбез.
Кабат, әйдә, кайтыйк шул күлләргә,
Бүтән сөю җирдә эзләмә, эзләмә!
— Күрәм, ирек чиксезлеген эзләп
Узган сукмакларга кан тама.
Мин аларга кереп адашмасам,
Кадамаслар иде аркама
Хыянәтең беләң...

*
* *

Төннәр үтә. Инде кояш...
— Чыкма, елмайма!
Җирдә салкын, карлы яңгыр ява,
Юк мәхәббәт, җылы юк анда.
Тау башына күз ат — канлы дар,
Канлы дардан мәет алдылар.
Ул кем? Ул кем?
— Үлгән мәхәббәт!
— Аны күмгәч, мин дә тынармын.
Яфрак ярмас анда җырларым.

Яфрак ярса, чәчкә ата алмас,
Кояш, кач, кач! — Кояш качмады:
— Күкне ярат, ярат җирне кабат,
Син бит әле... шундый яшь әле!

Күзен ачты шагыйрь. Тәрәз ачты.
Шаулап керде тыштан шат җырлар.
Таш урамнан бара атлылар:

— Атлар килә атлап-атлап,
Юллар тузанын таптап.
Дошманнардан илне саклап,
Без киләбез кабатлап:
Армия, әзер бул,
Дошманнар сузалар кул.
Армия, әзер тор,
Мылтыгыңны каты кор!

— Чык дөньяга, шагыйрь, кил мәйданга,
Синнән сүз көтә мәйдан!
— Зур көрәш алда һаман, алда һаман!

Һәм син... таныш ак яулыкны
Чытырдатып кыстың:
— Җирдә бар шәфкать —
Дөньяда бар ай-кояшлы хәят,
Бүтән ирек, бүтән мәхәббәт!

*
* *

Җан һәм тән иреге дигән илне ташлап,
Көнгә чыктың. Кемнәр киләләр?
Барысы таныш... корыч тавышларын
Күк чыңына эретә беләләр.
Җырчы дуслар күкләр галилеген
Өләшәләр гади күзләргә:
— Җан ирեген китерә эш иреге.
Гыйсъяннардан аны эзләмә!

«Пәри» түгел, инде чын кыз көлә,
Гади бер кыз!
Исеме гәрчә тагын Галия...
Ул — ирекне тугрылыкка кушкан
Бүтән тормыш, бүтән идея:
«Җанга — ирек, аны әмма да
Хыянәт иреге дип аңлама».

Чын азатлык һәм мәхәббәт әнә
Шаулап тора күмәк кыр төсле.
Чирәмнәрдә йөри: «пип-би-би-би!» —
Тормыш төсле, эшле җыр төсле.
Ул мәхәббәт чыңлый, Чибәрниса
Чулпылары чың-чың килдисә.
Таныш өйләр, урман, кырларыңа
«Хушыгыз!» дип бунтарь җил исә.
Ул мәхәббәт тар сукмаклар буйлап
Зур юлларга табан атлаган
Чабаталы танышларың булып
Агыла яңа таңнарга табан.
Ул мәхәббәт төзелеш кырларында
Цемент булып кирпеч беркетә.
Күмер базларында, мартеннарда
Ташлар айкый, тимер эретә.
Чабаталы инженерлар анда
Яңа тормыш адымын исәпләп
Баскычлардан менгән чакта — кабат
Шигырь төсле көлә мәхәббәт.

Сандугачны телгә китерә торган
Мәңгелек моң инде шушыдыр.
Яратудан яратылган дөнья,
Яратудан ярала шигырь...

*
* *

Кырларымда шигырең шаулап торган
Заманымнан сәлам җибәрәм:
Исемен җуеп үткәннәргә китте
Синең җырны «аңлый белмәгән»
Танышларың...

*
* *

«Ә «Пәриең»?
Ул кияүгә чыккан.
Монысын үзең белеп киткәнсең.
Җан иреге шулай кушкан диеп,
Бәлки әле гафу иткәнсең.
Тик иректе күлләренә «Пәриең»
Артык тирән чумып яшәгән.
Тик хатларың аннан чыкмак булып,
Кисәү сыман очкын чәчәләр...

Бунтарь дигән хөрлек азак килеп
Изгелеккә кыла хыянәт.
Әманәткә кем хыянәт итсә,
Йөзенә ат аның мең нәләт.
Кем ул? Ул кем? Синең йөрәгеңнән
Сүзләр булып аккан каннарны
Утка салган нинди яман куллар?
Бармак эзе көлдә каламы?
«Җинаятьче — мин!» дип кем дә хәзер
Килеп чыкмас җавап тотарга.
Хатлар әмма янган... Мин үземчә тагын
Күләгәләр күрәм...
Ут яна.

Яфрак һәм җил төсле, хатлар белән
Өйдә балаң уйнап йөргәндер.
Ят атаның янмыш күзләрендә
«Пәриең» көнче сөрем күргәндер.
Һәм көлгәндер:
— Улым, әйт әле, я,
Яратасың кайсы атаңны?
Икесен дә?
Яна микән, яле,
Кәгазьләрең утка ат әле...

Ут — балага әгъва һәм хат яна:
— Шундый матур яна, күрсәнә! —
Көлә бала... Диварларда — шәүлә...
Соңгы мәртәбә
Үрсәләнеп төтен әчесеннән,
Сүзләр чәчи, сүзләр буыла:
«Бала терелә...
Рәсемең йөрәгемдә...
Инде хатны язам улыма.
Бармаклары белән тиясен белеп
Өзгәләнәм... Бирегез кулына,
Ертса тик ул ертсын... Үтәрсезме?
Үтенечем бары шул гына».

*
* *

Өйдә тып-тын. Өч кешелек гаилә
Сүзсез карый берсе берсенә.
Өйдә төтен... «Пәри» сөртә битен,
Корым йоккан гүя битенә.
Елый бала:
— Кая китте хатлар,
Кая китте әтием сүзләре?
Бирегез миңа! — ул кычкырган чакта, күрәм,
Соңгы ялкын күккә үрләде.
Соңгы ялкын җилпенде дә кинәт
Утлы бер сүз очты:
— Хыянәт! —
Әманәткә кем хыянәт итсә,
Йөзенә ат аның мең нәләт.
— Нәләт, нәләт!

Корым, сөрем... Инде кулыгыздагы,
Йөзегездәге, җаныгыздагы
Зәһәр ул корымны бетерә торган,
Юа торган сабын, су бармы?
Җитмәс моңа океан сулары!
Юалмассыз,
Юалмассыз мәңге сез аны!
— Хыянәт!

*
* *

Бу сүзләрне инде без кычкырдык.
Ишетмәдең. Шулай шәбрәктер.
Юкса сүрелеп бу дөньяга гыйшкың,
Чолгап аны Галәм нәфрәте,
Язылмаслар иде бүтән хатлар
Чорны, җирне сөюең хакында.
Ә ул җырлар, бәйрәм салюты күк,
Туар таңнар күгенә атыла.

*
* *

Мин чорыңнан кайткан чакта, күрәм
Җырларыңны еллар яңарта:
Үз йөрәге хәтле итеп кенә,
Кызга егет япь-яшь кар ата.

1972—1974.

## Барлас Камалов

# ҖИР ХАКЫ—ИР ХАКЫ

Хикәя-монолог

I



Карчыгы белән телефоннан сөйләшкәч, Минһаҗ абзый өчен Казанда кунак булуның яме-тәме калмады. Ул ашыгып авылга кайтырга булды. Улы белән килененә сый-хөрмәтләре, ачык чырайлары өчен рәхмәтләр укыды да юлга җыенды.

— Кайтам, балалар, кайтам, — диде ул, кырт кисеп.— Әнкәгез дә озаклама дип әйтте. Аннары бит, иртәгә булмаса берсекөнгә дигәндәй, чәчүгә чыгачаклар. Җитмешне җыйсам да, кирәкмәгән китек балта түгел бит әле мин дә! Басу контроле әткәгез, сыйфат инспекторы... Насыйп булса, балалар, көзге мәлне тагын килеп әйләнермен. Синең тәҗрибә участогына да барырбыз, улым. Сез сыный торган яңа сорт бодайның ничегрәк булып туачагын күрәсем килә. Әгәр чыннан да башак авырлыгы белән сабак авырлыгын тигез итә алсагыз, бу бит, үзең беләсең...

Минһаҗ абзый вагонга кереп бер читкәрәк кенә елышып утырды да уйларына уралды. Миендә утлы тамчы булып биегән төп уе төпчеге Мөнҗиягә кайтып кала иде. Шул уй аның еллар ярган маңгай буразналарын тагын да тирәнәйтә төшә, тулы түгәрәк битенә күләгә сала, әле дә булса көче-кодрәте сызып бетмәгән дәү гәүдәсен чүктерә иде шикелле. Картның зур соры күзләренә кичәле-бүгенле аптырау катыш сагыш кереп оялады.

Купедагы күршеләре җәелеп китеп гәпләштеләр, ниндидер мәзәк сөйләп көлделәр. Минһаҗ абзый исә тамырлары бүртеп торган кул аркаларын угалаштырды, көмеш түгәрәк сакалын сыйпап куйгалады, тыптын калып, күңеленнән генә сөйләшеп кайтуында булды.

«...И-и, бала, бала! Хәерлегәме синең бу эшләрең?! Тездә чакта сөйдерә, тездән төшкәч көйдерә дисәләр дә, бүгенгәчә дүртегезнең бере дә бәгырьне туракларлык хәсрәткә салганы юк иде әле.

Дүрт багалма кебек тәгәрәшеп үстегез. Укуыгыз уку төсле булды, мәктәптән яман сүз ишетмәдек. Кул арасына бик иртә кердегез, әнкәгез артыгын биртелмәде. Һөнәр сайлаганда кырык тарафка кырык карап тормадыгыз, җиргә ихласыгыз нык булды.

Иң өлкән абыең эшне тракторчылыктан башлаган иде, бүген, күр, чирәм җирдәге зур совхоз директоры. Узган көзне язган идеме Казагыстан миллиардына безнең өлеш тә зур булды дип? Күкрәгендә орден хәзер, Ленин ордены! Моңа ничек куанмассың?! Хәтереңдәдер, хөкүмә-

тебезнең иң югары бүләген бирделәр дип язган хаты килгәч, мин күз яшемне сездән яшереп тә тормадым...

Уртанчы абыең кая китте! Галимнәр дөньясында, яңа сортлар чыгара, илгә-көнгә ризык бирүчеләрнең алгы сафында. Моңача башкарганы да аз түгел, иллә мәгәр планнары-хыяллары тау тикле әле аның...

Кече абыең да җир сагында. Ул — пограничник-офицер. Туган җирне саклый. Андый балам белән дә мактанырга хакым бар минем, бар! Күгебезгә козгын булып күтәрелергә, суыбызга акула булып керергә, басу-кырларыбызга саранча булып төшәргә ниятләүче җаннар бар заманда гаскәриләрсез дә булмый...

Үзең дә син, төпчегем, атаң һәм агаңнар юлын сайладың бит. Берәү дә үгетләмәде, мәҗбүр итмәде, үз ихтыярың белән авыл хуҗалыгы техникумына барып кердең. Колхоз стипендиаты булдың, авылдашларың тәрбияләшеп укытты сине. Кулыңа диплом тотып кайткач, дүрт елны заяга үткәрмәгәнеңне эштә күрсәттең. Район колхозларындагы агрономнар арасында яхшы чутта йөрдең. Баш агрономыбыз мактап туялмый иде үзеңне. Ә менә көннәрнең берендә чыгымчыладың да куйдың. Тик үтә авыр булса да, әйтергә мәҗбүрмен: һәммәсенә үзең гаепле, бала! Пырдымсызлыкның да бер чиге була, инде акылына килдеме дисәм, син тагын авызлык чәйнәп ярсына башлагансың. Әнкәң тикле әнкәң алдында: «Җир хакы дип тә тормыйм, ир хакы дип тә тормыйм, шәһәргә китәм. Берәр елга баланы алып кал», — дип гайрәт чәчкәнсең. Әниең әйтте әнә, диваналар булып калдым шул сүзләрне ишеткәч, ди. Безнең беребезнең дә — әнкәңнең дә, минем дә — балаларга кул якканы булмады. Ә минем алда шулай лаф орсаң, белмим, мин чыдап кала алган булыр идемме икән?

Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә дигәннәр. Синең сүзең уен-муен түгел, димәк ки, җиде кат уйласаң да чакка киләсе.

«Җир хакы!..» Бу сүз белән җиңел селтәнерлек булгач, кызым, син әле аны бүгенгесе көнгә хәтле бөтен тирәнлеге белән аңламагансың. Мин дә гаепле, җир хакының ни икәнен азаккача синең җаныңа да, җелегеңә дә сеңдерә алмаганмын. Минем балам авызыннан чыгарга тиешле сүзләр түгел синең әйткәннәрең. «Мин» дигән сүз көфер ди торганнар иде без яшьрәк чакта. Мәгәр мин «көферлек»тән курыкмыйм, чөнки тузан кадәр дә арттырмый әйтәм: җир хакына минем тирем дә, каным да түгелде, гомерем дә өзелә язып калды.

...Колхоз оешкан гына ел иде, Октябрь революциясенең унөч еллыгына багышлап үткәрелә торган кичәгә җыелдык. Мин — бригадир һәм партячейка секретаре — кыска гына итеп доклад сөйләдем. Яшьләр «Галиябану»ны куярга хәстәрләнгәннәр иде. Беренче пәрдә башланып биш-ун минут үттеме икән, халык белән шыгрым тулы кечкенә клубның ишеген каерып ачтылар да кычкырдылар:

— Бригадир Минһаҗ! Тиз бул, йортың яна! Урынымнан куптым, йөгерү түгел, атлар хәлем дә юк. Алпан-тилпән килеп, тар тыкрыкка җиттем. Бүтәннәр дә кузгалганнар иде булса кирәк (тамаша өзелде инде!), артымда шау-шу ишетәм. Тик кешеләр тавышын мылтык тавышы күмеп китте. Ике тапкыр атканнарын беләм, сөрлегеп җиргә ауганым истә, бүтәнен белмим. Аңыма килгәндә Кыят больницасында ята идем инде. Олы абыеңның күкрәк баласы чагы. Аны кочаклаган әниең, елап шешенеп беткән килеш, минем янымда утыра. Атканнан соң бишенче көн икән инде. Җир өчен, ызаннарны сөрдергән өчен, колхоз дип җан атып йөргән өчен кулакларның миннән үч алулары иде бу. Таза идем, сөлек кебек идем, әҗәл мине җиңә алмый калды. Авылдашлар йорт та әмәлләштеләр. Беләсең, безнең халык бик бердәм, ярдәмчән. Үлем-китем булганда, йорт-җир янганда, мал-туар казалаганда һәркайсы хәл-хәленчә булышмый калмый.

Җир хакына кан түгүемнең икенчесе миллионнар белән бергә булды. Сугыш ачылганның иртәгесен үзем теләп фронтка киттем. Бу вакытта колхоз председателе идем инде, азгамы-күпкәме калдырып та торырлар иде. Калырга теләмәдем.

Сугыш чыраен күргән кешеләр белә: фронтта чүрәкәй уйнамыйлар, анда кәбестә башы кырылмый, кеше гомере өзелә. Үлем һәр көн синең янәшәдә. Дәһшәт дигәнең җитәрлек. Шулай да бик күп очрак арасында гомер буе онытылмый торганнары була.

...Кырык өченче елның көзе иде. Днепрның уң як ярында, Ржищево тирәсендә, ике биеклек бар. Аларның берсе исемсез, икенчесе фронт карталарында «193,1» дигән нокта иде. Җитмеш алтынчы гвардия артиллерия полкының батарея командиры булганым хәлендә, ике көн буена мин шул биеклекне саклаштым. Ике көн буе ут, металл яңгыры астында шул бер кисәк җиргә ябышып яттык. Аны һичничек фашистка бирергә ярамый, бирә калсак, алар тагын да эчкәрерәк үтәчәкләр, корбаннарыбыз күпкә артачак иде. Минем батарея бу бәрелештә бер ротага якын фашистның башына җитте, үзйөрешле тупны яндырды һәм бер танкны сафтан чыгарды. Үзем бик каты яраландым. Бу — минем өчен сугышның соңгы эпизоды булды. Шуннан соң елдан артык гомер госпитальдә узды. Кырык бишнең башына өйгә кайтып ирештем.

Җир хакы, җирдә эшләүчеләр хакы белән хисаплашу миңа сугыштан соң да «күчтәнәч» бирә язып калды. Чак кына партбилетымнан колак какмадым. Янә председатель итеп сайланган чагым иде. Иген күкрәп уңды. Сугышның буеннан-буена соңгы центнерларга кадәр ашлыкны фронтка озата-озата ипигә зарыккан колхозчы ризыкка тиенде. Тиенде дип, алай ансат кына булмады ул. Язын авылдашларга биргән вәгъдәмдә тору кыймммәткә төште.

Дәүләткә ашлык тапшыруны безнең «Энтузиаст» колхозы беренчеләрдән булып башлады, беренче булып тәгәлләде. Шуннан соң хезмәт көненә аванс бирәсе иттек. Шөкерләр әйтеп, халык келәтләр буена килә башлаган иде, син ишет тә мин ишет, районнан звонок. Безгә өстәмә план. «Тагын өч йөз центнер!» — диләр. Аңлатып карыйм, артта баручылар өчен ник без шәрәләнергә тиеш, дим. Колхозны күтәрик дисәк, игенченең үзен ашатырга кирәк ләбаса, дип ялварам. «Бюрога кил! Шунда сөйләшербез»,— диелде миңа.

Бардым, эшнең ничек икәнлеген аңлаттым.

— Район интересларын уеңа да кертеп карамыйсың, башбаштаклык итәсең, — диләр. Колхозчыларга ашлык бирүне туктатырга кушалар.

— Биреп бетердек бит инде, — дим.

Һәм, үз белдеге белән эш итеп яраксыз практика кулланганы, дәүләт мәнфәгате белән хисаплашмаганы өчен, дип, мине партиядән чыгару турында тәкъдим кертелә. Күз алларым караңгыланды, йөрәгемне умырып алдылар диярсең шул минутларда.

Шунда — кем диген! — хәзерләүләр буенча район вәкиле — уполминзаг Бикмөхәммәтов сүз алды. Ул карт коммунист, бик абруйлы иптәш, саф күңелле, туры куллы, принципиаль кеше иде.

— Туктагыз әле, иптәшләр! — диде ул карлыкканрак зәгыйфь тавыш белән. Исәнлеге шәптән түгел иде. — Менә дигән уңыш үстереп, ил алдында бурычын беренче үтәгән колхоз председателен партиядән чыгарырга җыенасыз түгелме? Бара торган атның башына сукмыйлар бит! Аннан соң бит Минһаҗ Гаделҗанов иптәш ашлыкны үз өсәгенә кайтарып бушатмаган. Хезмәт көненә аванс итеп игенчеләргә биргән. Безнең илдә һәр хезмәткә хак түләнә... Сугыш елында кичергәннәрдән соң, ниһаять, иркен тын алып, икмәк кабарга кирәктер бит...

Бәхәс китте, тик Бикмөхәммәтов агай үз сызыгыннан карыш та чигенмәде. Азактан мине кисәтергә дигән карарга килделәр. Коммунистла-

рыбыз арасында җир хакы өчен әнә шулай көрәшә белүче кешеләр күп булу белән көчле бит без.

Синең дә, балам, изге туфрак, чиксез-чамасыз кадерле булган ипи турында заманча аек акыл йөртүеңне, ризык бирүче булуың белән горурлана белүеңне теләр идем мин. Безнең «Җир! Икмәк» димәгән сулышыбыз булмаска тиеш...

Инде, кызым, икенче хак сүземә колак сал.

Миңа бу турыда сүз кату ансат түгел. Бик нечкә, нәзберек мәсьәлә ул ир белән хатын арасындагы хәлләр. Шулай да тел тешләп кала алмыйм. Ата хокукы, коммунист булуым үз фикеремне туп-туры әйтергә кушып тора. Мәсьәләне без «Ир хакы — тәңре хакы» дигәнчә куймыйбыз. Безнең илдә хатын-кызның тигез хокуклылыгы күз алдында. Иллә мәгәр тормыш юлдашы, арка таянычы, бала атасы дигән җәһәттән караганда, кызым, ир ризасы бик олы. Кадыйр кияүне юкка рәнҗетәсең. Аңа карап кына кәкре сукмакка өндәп керткән юлдашыңның бәясе артмас. Әткәй кат-кат тукыган иде диярсең, ул сиңа тугрылыклы ир, балаңа әйбәт ата була алмаячак. Аның шул яшькә тикле гаилә кора алмый йөрүе генә дә сагаерга куша. Нәселе бүтән аларның, ыруы башка...

Син көннәрнең берендә җиңел уйлап куюың һәм саксыз атлаган адымың белән ничә кеше йөрәген яраладың? Исәп биргәнең бармы? Иң әүвәле Кадыйр күңеленә тиз генә уңалмаслык җәрәхәт салдың. Югыйсә, бит сине бирәү дә кодалап, юмалап яки этә-төртә бирмәде. Үзең теләп, ошатып чыктың. Сигез ел бер класста укыган кешеләр сез. Техникумда чагыңда да аның белән багланышың бетеп тормады. Без картларны да авылдашлар алдында бик тә җайсыз хәлгә куйдың. Дөрес, күзгә терәп бирәү дә бер сүз әйтми, тик сүзсез аңлашыла торган хакыйкать тә бар бит дөньяда. Балаң әлегә ни дә төшенми, сабый. Тик аң булып тор: килер бер көн, син аның каршында җавап тотарга тиеш булырсың. Аның йөрәк ярасын дәвалау мөмкин дә булмас...

Җир хакы белән хисаплашмаска маташкан сүзләреңнең башы кайда? Ир хакы турында оныткан минутларыңда. Шәһәрдә көн күрүче сабакташың белән мавыгуыңның тирәнгә китүендә. Шул хәлләр телдәнтелгә пышылдап күчә башлавы сине туган туфрагыңнан куа. Теләсәңтеләмәсәң дә, кешеләрдән бер читкәрәк тайпылып торырга омтыласың. Кешеләрдән посып торырга да мөмкиндер, шәт, әмма үзеңнән кача алмассың бит. Инде шундый сәгать сукты, соңгы кабат ныклап уйланырга тиешсең! Авылдан кубып китүең кире кайтыр юлыңны бөтенләйгә бикләмәгәе...»

## II

Яз. Зөядә боз акканга да берничә көн. Аксыл-зәңгәр күктә кояш кинәнеп елмая. Басу өсләреннән пар күтәрелә, ерактагы урман рәшә пәрдәсе аша тибрәнеп күгелҗемләнә. Коймa буйларында җете-яшел үлән кыяклары тернәкләнеп маташа. Җылы яклардан кайткан кошлар мәш килә. Куакларның яфрак бөреләре шундый бүртенеп тулганнар, менә-менә чыртлап ачылырга торалар.

Күңелләрдә яз яктысы, язгы уяну, язгы кыбырсы. Сөйләгәндә сүзнең җорын, җырлаганда җырның дәртлесен җырлыйсы килә торган чак.

Аръяктагы чәчүлек орлык амбарларыннан төшке чәйгә кайтып килүче Мөнҗия генә яз ямен тоймыйдыр төсле. Ул, моңсулап, балтасын әле генә суга төшергән кеше төсле, Зөя ярында туктап калган. Аның чырае киткән, юка иреннәре кипшеренгән, карлыгандай күзләрендә һәрчак диярлек уйнаша торган очкыннар каядыр китеп югалган. Куллары төз-сылу гәүдәсенә сыланып торган плащы кесәсенә тыккан. Башындагы ефәк кыекча яулыгының очы белән җил шаяра.

Мөнҗиянең күзләре язгы болганчыклыктан арынып бетмәгән агымсуда, уйлары еракта. Җитмәсә, ул уйлар язгы су сыман буталчык.

Зөядә, яр кырыенда гына, юлдашының яшь бәбкәләр ияртеп чыгар сәгатьләрен көтеп зарыккан ата үрдәк бакылдый. Ялгызлыгыннан зарланамы, су күплеккә сөенеп бетә алмыймы, белмәссең. Яшел хәтфәле башын суга тыгып, җим эзләгән була да, кыска муенын боргалап, ярга карап куя. Гүя ул Мөнҗиягә текәлеп сорый: «Син дә ялгызмыни соң?»

Һәм Мөнҗия уйлана башлый.

«...Гомеремдә моңача булмаган ялгызлык кичерәм мин бу язда. Япан чүлдә бер үзем калганмын төсле. Әлегә кадәр һәр яз диярлек миңа сөенеч кенә китерә иде.

Моннан биш ел элек, Беренче Май бәйрәменә туры китереп, туй иттек. Шундый бәхетле идек без: Кадыйр күзләрендә үземне туй киемнәреннән килеш күргән минутларда йолдызларга ашкан төсле хис иткән идем. Әти-әнинең, туганнарның (туйга абыйларның өчесе дә кайтты), дусларның котлау сүзләре, тәбрикләре сихри музыка сыман ишетелде. Колхоз председателебезнең: «Уңган механигыбыз белән булган агрономыбызның кызыл туена гаилә тантанасы дип кенә әйтү аз, күмәк хуҗалыгыбызның уртак бәйрәме ул, җир хуҗаларының бәйрәме!» — дигәне әле дә колактан китми.

Нефть якларыннан отпускыга кайткан Сәүбәннең килүе дә туйга ямь өстәде шикелле. Ул бит әйбәт баянчы да, җырчы да. Мәҗлесне күтәрә торган кеше. Аның үзе уйнап:

Әй, тал нечкә, тал нечкә,  
Талдин билләрең нечкә;  
Талдин нечкә билләреңә  
Күз салдым үкенечкә,

— дип җырлавына берәү дә әллә ни игътибар итмәгән иде. Кадыйрның да гамендә дә булмады. Хәер, аның да бәхеттән исергән сәгатьләре иде шул.

Моннан дүрт ел элек, апрель азагында, улыбыз дөньяга килде. Мондый хәлдәге шатлыкны беренче баласын кулына алып сөю бәхетенә ирешкән ата-ана гына татып беләләр.

Ә былтыргы язда шомлы шатлык кичердем.

Үз машинасы белән авылга кайтып төшкән Сәүбән, Кадыйрның РТСта куна калуын белгәч, кичен минем су буена килүемне үтенде. Бу миңа мәзәк тоелды, мин кычкырып көлдем. Аннары гамьсез көлүемне ачу алыштырды. Ачуга алмашка хурлану тойгысы килде. «Чыннан да, ни дип әрсезләнүе әле бу чибәр егетнең? — дип уйладым. — Юк, чыкмаячакмын мин су буена! Кыз-кыркын чагыммыни? Кеше күзенә чалынсам, нәрсә әйтерләр?..»

Караңгы капкач, күңелне сәер бер кыбырсу биләп алды. «Әйтер сүзе бар микәнни? Бәлки төшеп караргадыр Зөя буена. Нинди яшерен сер икән шул тикле? Көндез үк: «Юк, чыкмыйм!» диясем калган икән дә соң, ул бит җавап көтеп тә тормады, кара мыек астыннан елмаеп, кул изәде дә, машинасын алга әйдәде».

Зөя буенда, текә яр астында, ул мине сөенеп каршылады. Мин ни хәл итәргә дә белмичә, әйттем:

— Килүен килдем, тик минем болай итәргә хакым юк. Хәзер үк китәм. Сүзең булса әйт! — дидем.

Ул сабыр итүемне сорады.

— Кайсы очтан керешергә дә белми торам әле, Мөнҗия. — Сәүбән пышылдап кына сөйли башлады. — Минем сине мәктәптән бирле яратып йөргәнемне бөтенләй сизми калгансыңдыр. Беткән баш бет-

кән! Гомерем буе үкенечтән саргаеп, ялгызым каңгырып яшәгәнче дип, сиңа сүз кушасы иттем. Соң булса да, бик соң булса да, сиңа тәкъдимем: бул минем белән, китик Азнакайга! Балаң ятим булмас, үзеңне учымда гына йөртермен. Аңла, Мөнҗия...

— Акылыңдамы син, Сәүбән? — дидем мин. Бүтән бер сүз дә әйтмичә, әйтә алмыйча, уңга-сулга карамастан, өйгә йөгердем.

Иртәгесен дә, аннары да Кадыйрга сыңар сүз дә әйтмәдем. Гөнаһым юк иде, тиктәскә кеше җанына шик орлыгы саласым килмәде. Ә үземнең тынгым югалды. Ашым аш булмады, йокым йокы түгел иде. Кадыйр кагылганда да Сәүбән иркәләгән төсле тоелган минутларым булды.

Уракка төшәр алдыннан бер-ике көнгә генә Сәүбән тагын кайтты. Бу юлы ул миңа тәмам сыланды һәм, машинасына утыртып, Каенлык урманына барырга күндерде. Ярты көн шунда булып кайттык. Күреп калучылар табылды. Кадыйрга җиткерделәр. Ул минем күземә кадалырдай булып сорады:

— Чынмы шул хәбәр? Чын икән, нишләвең бу?

Миңа каян нинди кыюлык килгәндер, икеләнүләрне онытып, алдынартын уйламыйча җавап бирдем:

— Без бер-беребезгә бары тик дөресен генә сөйләргә дип вәгъдәләшкән кешеләр, Кадыйр. Шуңа әйтәм: дөрес бу хәбәр. Мин Сәүбәнне яратам, — дидем.

Аны яшен суккандай булды. Ул беркавым тораташ төсле утырды. Аннары кинәт сикереп торды да минем каршыма каракоштай очып килде һәм кыргый бер тавыш белән кычкыра, сүгенә, яный башлады. Шашынып ярсыды-ярсыды да, хәлдән тайган төсле, тагын бер читкә китеп утырды. Озак, бик озак уйланды, җәфаланды, газап чикте. Соңыннан бик иплән, яшь баланы назлап күндерергә җыенгандай, миңа вәгазь укый башлады. Үз абруем, бала язмышы, ир хәле, ата-ананы борчу турында сөйләнә. Сүзләренең хаклыгын акылым белән аңлап торсам да, йөрәгем аларны кабул итмәде.

Кадыйрдан чыкты микән, бүтән берәрсе ирештердеме, Сәүбән белән минем арадагы хәлләрнең ың-шыңы туган йортка да барып җитте. Иң әүвәле үтә бала җанлы әнкәй сорашып-сөйләшеп бакты, оялтырга теләде. Аңа башлы-күзле җавап кайтарырга да өлгермәдем, әткәй кайтып керде. Ул чамасыз кырыслык күрсәтте.

— Өч абыең да илгә-көнгә өлге итеп күрсәтерлек семья корды, хатыннары белән гөрләшеп көн итәләр. Син картаймышлы көнебездә безне рисвай итәргә телисеңме?! Азып-тузып юлдан язар булсаң, бу йортның бусагасы сиңа, хәрам! — диде. Аннары тәмам ярсынып өстәде:

— Кем белән диген, кем белән яманат чыгарасың! Алар бит нәселләре белән...

Әйтеп бетермәгәне дә аңлашыла иде. Сәүбәннең турыдан-туры бөртек тә гаебе булмаганга гына авыз тутырып әйтмәве әткәйнең. Колхоз оешкан елны әткәйгә аткан кеше Сәүбән әтисенең бертуган абыйсы булган.

Әрепләшергә телем күтәрелмәде. Нигә икәнен үзем дә абайламыйча, ләкин никтер вакыт отарга, иң каты каһәрне шул көнне ишетмәскә теләп, сүзне түгәрәкләп куярга тырыштым.

— Башка хәсрәтегез булмаса, куегыз әле шул гайбәтне. Күреп торасыз ич, ирем янымда, балам алдымда, — дип кенә әйтә алдым.

Әткәйне алай гына тынычландырып булмасы ачык иде.

— Башка хәсрәтегез булмаса, имеш! Моннан зурысын эзләргә чыгыйммыни?! Кара аны, бала! Күзгә карап сөйләшер җаең калмаган. Җил исми яфрак селкенми,— диде.

Мин Сәүбәнне көттем. Ул Октябрь бәйрәменә кайтып алырга, барлык төеннәргә шул көнне балта чабарга тиеш иде. Кайтмады. Яңа елда

да күренмәде. Январь уртасында безне республика киңәшмәсенә чакырдылар. Шуннан бер генә көнгә мин Азнакайга барып кайттым. Сәүбән янына. Гаҗәбемә каршы, ул авылдагыча түгел иде. Дөрес, елмайды, көлде, назлады, минем килүемә шатлануын әйтте. Ләкин эчке бер сиземләү белән сизеп тордым, ул мине тизрәк озату ягын карады.

— Март урталарыннан, иң соң дигәндә беренче апрельдән дә калмый кайтып алам мин сине. Шунсыз монда кабат килеп йөрмә, яме.— Шулай юатты.

Бүген апрельнең егермесе. Сәүбән юк. Хат-хәбәр дә җибәрмәде. Инде анык беләм: ул кайтмаячак! Шушы уй мине аяктан еккандай итә.

Халык телендә гайбәт. Кадыйр күңелендә нәфрәт. Әти-әни йөрәгендә каргыш. Кичә мәктәптә укыткан, хәзер инде пенсиягә чыккан апа килгән иде.

— Утырган ботагыңны бөтенләй кисеп төшергәнче кайт ирең янына! — дип үгетли.

— Кадыйр үтендеме әллә минем яныма килүегезне, апа? Әйтегез әле, ичмаса, дөресен. Бераз җиңелрәк булыр иде,— дигән идем, орышып ук алды.

— Әллә тагын аның, бер гаепсез кешенең каршыңа килеп тезләнүен көтәр идеңме? Ирең — ир кеше синең. Алай түбәнсенмәс. Син үзең гафу сорап кайтсаң, аяусызланмас. Олы йөрәге бар аның. Җибәрүен ул җибәрмәде, аның сыкравын сизеп үзем килдем,— ди.

Нишлим? Бу килеш мин барыбер авылда калалмыйм...

Бүген, тагын ике сәгатьтән, әткәй кайтып җитәчәк. Аның ни әйтәсен, ничек әйтәсен сүзгә-сүз белеп торам. Мәрхәмәт көтәр урын юк...

### III

Минһаҗ карт өендә хөкем бара. Иптәшләр суды да түгел бу, халык суды да. Гаилә суды.

Хөкем каршына басарга мәҗбүр кеше нишләр? Нинди юл сайлар?

1974

## Роберт Батулла

# ҖИТМЕШ ҖИДЕ ПӘҺЛЕВАН

**Әкият**

Азатлык өчен корбан булган барлык каһарманнар истәлегенә атап яздым.
Автор

## Өч угыл



Бер агайның өч углы булган. Өч углы булганчы әле аның бер углы да булмаган. Балаларны бит я коедан, я кәбестә арасыннан, я урманнан табып кайталар. Бер үзеңә генә бала алып кайтуы кыен булган ул заманнарда. Шуңа күрә агай, бергәбергә эзләве күңеллерәк булсын дип, өйләнмәк булган. Ләкин бик тә фәкыйрь булган ул. Шул кадәр ярлы яшәгән, аны гел кеше рәтенә дә кертмәгәннәр. Ул вакытта, бу агай яшәгән заманда, хатын алу өчен калым түләргә, мал-мөлкәт, байлык җыярга кирәк булган. Әмма теге агайның кырык тәрәүле ызбасыннан башка бер нәрсәсе дә булмаган. Әле җитмәсә, үз хәлен үзе белмичә, бай кызына гыйшык тотып йөри икән мескен. Шуннан яучы карчыкны бер әчмуха чәй, бер гөрәңкә он белән яллап, бай кызын кодалатырга җибәрмәкче булган бу. Яучы карчык рәхәтләнеп көлгән аңардан. Бөтен авылга таралган бу хәбәр. Байлар да, ярлы-ябагай да бу фәкыйрьдән мыскыллап көлә башлаганнар. Шундый ачуы чыккан бу адәмнең тегеләргә. Ачуы чыкса да, нишләсен инде! Шуннан соң төкерәм мин аның байлыгы белән кызына дигән дә бу — ярлы гына бер кызга өйләнгән. Теге әчмуха чәйне кайнатып, гөрәңкә онны туглап, коймак пешереп, үзләренчә туй ясаганнар. Чәй эчкәндә агай хатынына ишеттереп хыяллана икән:

— Угылларыбыз булса, имана җире дә тия, ярдәмче дә була! — ди икән.

Угыллар эзләргә тотынганнар болар. Тик угылны ансат кына табып булмый икән шул. Яшь килен коймактан калган оннан камыр туглаган. Әкияттәге сыман, камырдан угыл ясарга уйлаганнар. Ләкин могҗизалар әкиятләрдә генә була! Мич башына куйган камырлары кәкрәеп кибеп каткан. Шуннан уйлашканнар да болар угылны тыштан эзләргә булганнар. Озак та бармыйлар болар, бер коедан бер малай табып кайталар. Шатлыгыннан агай шыркылдап көлеп тә җибәргән, биеп тә алган. Шатланырсың шул! Угыл табылсын әле! Угыл-

лары угыл шикелле генә булса икән! Тап-таза! Авырлыгы егерме гөрәңкә булган, ди. Хәзергечә әйткәндә, угыллары сигез кило була... Әкияттәге сыман, ел үсәсен ай үсеп, ай үсәсен көн үсеп, типсә тимер өзәрлек баһадир булып җиткән бу. Ун суканың барын бергә җигеп, сабан өстенә атасын, анасын һәм сукыр песиләрен утыртып, берүзе бакча сукалаган. Шулай итеп, болар хәйран гына хәлләнеп китәләр. Тишек-тошыкларын ямыйлар.

— Әйдә, карчык! — дигән агай хатынына.— Тагын әйләнеп кайтыйк әле! Тагын бер угыл табылмасмы!

Китәләр болар. Бу юлы коедан таба алмаганнар шул. Чөнки һәммә кеше коедан балалар ала торгач, кое саегып калган, ди. Шуннан бәрәңге бакчасы аша бик кәефсез генә кайтып барганда, алланың рәхмәте, бәрәңге сабаклары арасыннан тагын бер малай табып алалар бит. Кайтып керүләре булган ишектән, әлеге табылдык әнисенең кулыннан сикереп тә төшкән, җилпучтагы онны учлап ашарга да тотынган.

— Булырдайның биленнән билгеле, ди. Бусы, мөгаен, тегермәнче булыр! — дигән агай.

— Амин берүк, амин берүк! — дигән анасы.

Чыннан да, икенче угыллары үсеп җитү белән тегермәнче булып киткән. Бик баеп, хәлләнеп җитәләр болар. Бә-әк шәпләп ике катлы, зиннәтле йорт салып куялар. Ишегалларына асфальт җәйдертәләр. Телевизор алалар... Әй, авызыма саескан төкергән икән, ул вакытта асфальт та, телевизор да булмаган бит әле... Булмаса булмас, бик череп баеганнар, дип сөйләгәннәр иде.

Тавык симерсә, йомырка салмый башлый, диләр бит. Хактырмы бу, юкмы, тик бу агай да баегач, бик саранланып, комсызланып киткән. Үзенең хәерче, сәләмә-йолкыш чакларын оныткан. Әле тагын да ныграк баю өчен, өченче угыл эзли башлаган. Һаман саен майлы бутка булмый шул ул! Күпме эзләсәләр дә, таба алмаганнар. Бакчада да, коеда да гел кыз балалар гына чырылдашып ята икән. Шуннан, мич алдында кайгырышып утырганда, мич авызыннан дөмберррт итеп бер төргәк тәгәрәп төшә боларның алдына. Төргәкне сүтеп карасалар — малай! Тәрәзәдән карыйлар, күктә торналар очып бара икән. Шул торналар ташлап киткәндер инде бу угылны.

Бу углы да байлык җыярга оста булыр, дип өметләнгән агай. Ләкин бу углан сабанга да тотынмаган, умырып он да ашамаган. Бәлки урманчы булыр дип, этисе аны урманга да алып барып караган. Малай этисе теләгәннәрне эшли алмаган. Берүзе калса, ул бик моңлы итеп көйли, сызгыра яки җырлый торган булган. Әллә торналар ташлап киткәнгәме, ул бик тә моңлы бала булган. Иркенлекне, болыннарны, сахраларны яраткан һәм гаҗәп матур итеп җырлый белгән. Аның җыры урманнар, сахралар, күк йөзе, торналар турында булган.

Беләсезме, бу өч угыл яши торган ил «Дәрьям-Ана йорты» дип атала икән. Ни өчен алай аталганын хәзер сөйлим...

## Дарьям-Ана йорты

...Борын-борын заманнардан да борынрак Тимер-Кыя исемле бер батыр яшәгән, ди. Ул гаять озын гомерле булган. Йөз ел яшәгән, мең ел яшәгән. Гомере буе Тимер-Кыя кешеләргә яхшылык кылган. Аның биш баласы булган. Бишесе дә үсеп җиткәч, үләр алдыннан Тимер-Кыя балаларын үз янына җыйган да һәрберсенә мирас игълан иткән:

— Берегезгә дала бүләк итәм! Дала бай ул, иркен, гүзәл, әгәр

яши белсәң... Аң бул, Дала хуҗасы, халкың рәхәт яшәсен! — дигән. Икенчегезгә әманәт итеп Тау Илен калдырам... Таш өстендә чәчәк, җиләк-җимеш үстер, йортыңны дошманнардан сакла, дигән... Өченчегез өлешенә урман алыр. Кош-корт, җәнлек-җанвар, агач-үлән үрчет урманда, дигән. Дүртенчегез өлешенә чыкты бар һава, күк гөмбәзе, дигән... Дала, урман, тау-ташларны һәм һаваны туендырыр, саклар өчен, барча елга-инеш, дәрья-диңгезләрне сиңа тапшырам! — дип, Тимер-Кыя төпчек кызы Дәрьяны чакырган.— Терек Суы синең кулда кала, Дәрьям. Терек Суын сакла яман күздән...— Шуннан Тимер-Кыя Дәрья колагына Терек Суы яшерелгән җирне әйткән.

Барысы да риза булган бу мирастан... Ләкин Зар-Зария атлы кызы гына киреләнгән, башка нәрсә өмет иткән өлешенә:

— Һава белән нишлим, ата? — дигән Зар-Зария.— Аны эчеп тә, ашап та, киеп тә булмый, хәтта сатып та булмый һаваны! Миңа булсын болын, җәйләү, киек-җәнлек булсын. Сатып алып, баеп булсын!

Шуннан әйткән Тимер-Кыя:

— Өлешеңә тигән көмешең. Мин сезгә сатыла торган байлык бүләк итмим. Алар халыкныкы, күз алмагыз кебек саклагыз!

— Мин һаваны алмыйм, ата! — дип кычкырган Зар-Зария һаман.— Күл сулары сеңелем Дәрья белән уртак булсын, бүлеп бирсен миңа барсыннан да!

— Биргәнемә риза булмасаң ирекле кал! Һаваны калган туганнарыңа бүлеп бирәм! — дигән Тимер-Кыя.— Мин йортымны ышанычлы улларыма, кызларыма тапшырам. Бу дөньяда йомышым калмады! — дигән дә Тимер-Кыя шунда зур тауга әверелгән!

Әткәсенә һәм дә туганнарына ачу ташлап, Зар-Зария читкә чыгып киткән. Күп еллардан соң төрле сихерләргә өйрәнеп кайткан. Игеннәргә агу чәчкән, туганнар арасында ызгыш-талаш тараткан. Инде дә туганнарын җиңә алмагач, биш башлы аждаһаны өстергән йортыбызга. Сугыштан Зар-Зария тәм таба икән. Күз яшьләреннән, һәлак булган батырларның канынннан агу ясый башлаган ул. Шуннан соң Дала Илендә, Тау Илендә, Урман Илендә, Дәрья Илендә җитмеш җиде пәһлеван күтәрелгән бу аждаһага каршы. Аждаһаның башларын гына түгел, койрыкларын да турап салганнар. Сугыш туктау белән, Зар-Зария дә җан биргән. Ләкин аның рухы исән икән, җисеме дә сугыш көтеп ята икән, дип сөйлиләр бабайлар. Илләр, халыклар бер-беренә каршы сугыш ачсалар, мәкерле җан Зар-Зария тагын терелəчәк икән. Аңа сугыш, орыш, ызгыш кирәк. Имеш, мәкерле Зар-Зариянең җаны сугышта, ди. Дәрьям-Ана гомере буе Зар-Зариягә каршы сугыша, ди. Менә шуңа күрә бу ил «Дәрьям-Ана йорты» дип атала...

## Гүзәлия

Баягы өч угылның берсен — типсә тимер өзәрдәен — Чукмар дип йөртәләр икән. Байлык җыючысының исеме Барыш булган. Төпчек угылның аты Муса икән. Менә шул өч угылның күршесендә генә Гүзәлия исемле бер матур кыз үсеп килә икән. Өч ир туган өчесе дә Гүзәлиянең матурлыгына сокланып туя алмыйлар, ди. Өчесе дә кызны үзенә каратырга хыяллана икән. Көч белән генә кызны үземә каратырмын, дип уйлый Чукмар, шуңа күрә бик зур йодрыклар үстерә. Байлык белән генә Гүзәлиянең күңелен яулап булыр, дип уйлый Барыш, шуңа күрә иртә таңнан торып мал җыя. Төпчек Муса йодрык та үстермәгән, байлык та тупламаган, ул Гүзәлиягә матур-моңлы җырлар җырлаган. Шуңа күрә Гүзәлиянең күңеле Мусада булган, ди...

Көннәрдән бер көнне болар җыйнаулашып урманга барганнар. Барыш та, Чукмар да, Муса да, Гүзәлия һәм башкалар да урманга таралганнар.

Барыш комсызланып җиләк җыйган, тырысына алма тутырган. Чукмар һәр тапкан җиләген ашый барган. Көч-куәт туплаган. Гүзәлия белән Муса исә чәчәкләр җыйганнар, күбәләкләр куып уйнаганнар. Муса урманнарны яңгыратып Гүзәлиягә матур җырлар җырлаган.

— Син шундаен матур җырлыйсың, хәтта урман шаулавыннан туктады. Син шундаен матур җырлыйсың, хәтта сандугачлар сайравыннан туктады...— дигән Гүзәлия.

Муса әйткән:

— Абыйларым миңа җырламаска куша. Һич туктамый алар мине кимсетә... Бәхетсез бала бугай мин, Гүзәлия... Берсе усал, берсе комсыз. Көн-төн битәрлиләр, кимсетәләр җырымны... Мондый хәлгә, белмим, кем түзәр...

Гүзәлия аны болай дип юаткан:

— Курыкма син, Муса, багалмам... Бу урманда сиңа беркем тимәс, һичкем кыерсытмас сине, читкә кага алмас! Бу урманда Дәрьям-Ана яши диләр!

— Дәрьям-Ана? — дип сораган Муса.

— Әкиятче бабай әйтте, Дәрьям-Ана, изге ана, илебезнең җаны — Дәрьям-Ана. Бу дөньяда шул бәхетле, диде бабай, шул олуг җанлы була...

— ...Әгәр дә ки аның юлында очраса Дәрьям-Ана... ышанасыңмы син дә, Гүзәлия, шул матур риваятькә, әби-баба сөйләгән әкияткә?

— Ышанам! — дигән Гүзәлия.— Ышанам, бик нык ышанам! Бар ул Дәрьям-Ана...

Шуннан соң Гүзәлия белән Муса Дәрьям-Ана турында тагын да матуррак, тагын да моңлырак җырлар җырлаганнар аланда. Ләкин алар озак җырлый алмаганнар. Яннарына Барыш белән Чукмар килеп чыккан. Чыкканнар да Мусаны ачулана башлаганнар.

— Әй, син, җилкуар! Нигә авыз күтәреп җырлап утырасың? Мин аулыйсы җәнлекләрне өркетеп бетердең бит!..— дип акырган Чукмар.

— Атай сиңа нә боерды! — дип кычкырган Барыш Мусага.— Утын кисеп алып кайт! — диде.— Бер ботак та чапмагансың. Эш рәте белмисең, ничек көн күрмәк буласың?

— Аның каравы, ул матур итеп җырлый белә! — дигән Гүзәлия.

Барыш белән Чукмар мыскыллап көлә башлаганнар:

— Җыр белән тегермән тарттырып буламыни?! Җыр белән җир сөреп буламыни? Ачтан үләрсең син болай булгач!

Шуннан Барыш белән Чукмар Мусаны кыйнамакчы булганнар. Чукмар Мусага бер орган, Муса бил тиңентен җиргә батып кергән. Күпме генә ялынса да Гүзәлия, абыйлары Мусаны кызганмаганнар, шул килеш калдырып кайтып киткәннәр.

— И раббем,— дип елаган Гүзәлия, Мусаны кызганып.— Кем сиңа ярдәм итәр?!.

Шул вакыт әкияти аһәң яңгырый башлаган. Урман аланында Дәрьям-Ана пәйда булган.

— Аманлык телим сезгә, балалар! — дигән Дәрьям-Ана.

Шулай әйтү белән җир аерылып киткән, Муса баткан җиреннән чыккан. Чыккан, ләкин атлый алмаган. Дәрьям-Ана әфсүн укыган, Мусаның аяклары шундук төзәлгән.

— Мәрхәмәтең өчен олуг рәхмәт сиңа, Дәрьям-Ана! — дип, балалар Дәрьям-Ананы хөрмәтләп баш игәннәр.

— Дәрьям-Анабыз! — дигән Гүзәлия салмак кына.— Ышанырганы, ышанмаскамы, син чынлап та бармы дөньяда?

— Бар, оланнар,— дигән Дәрьям-Ана.— Мин һәр вакыт бар!

— Хакмы, Дәрьям-Ана,— дип сораган Муса,— имеш, син үлемсез, имеш, син җитмеш җиде пәһлеванның туган әнкәсе?! Халык арасында риваятьләр йөри, шагыйрь шигырь яза синең турыда, Дәрьям-Ана. Җырчы җыр чыгара синең турыда, Дәрьям-Ана, синең турыда күпме дастаннар бар...

— Хак, оланнар! — дигән Дәрьям-Ана.— Хак сүз сөйли халык!

— Кайда соң ул җитмеш җиде пәһлеван, Дәрьям-Ана? — дип сораганнар балалар.

— Шуның өчен килдем сезнең янга, оланнар! — дигән дә Дәрьям-Ана Гүзәлия белән Мусаны серле сукмаклардан урман эченә алып киткән:

— Әнә, күрәсезме теге Тауны? — дигән Дәрьям-Ана.— Минем эткәм Тимер-Кыя булыр ул. Шушы тау куышында, аста, илебезнең җитмеш җиде батыры йоклый. Бу мәгарә халык батырлары йорты булыр. Терек Суы кыя төбеннән бәреп чыга... Халык өчен, туган йорты өчен фида булырга әзер торучы батырлар алар. Төрле халыкларның баһадирлары. Көр Углы, Гасәр Батыр, Чура Батыр, Әмирани, Манас Пәһлеван, Калевала, Алпамша, Давыт Батыр һәм тагын күптин-күп каһарманнар, йортыбызда яшәүче җитмеш җиде халыкның җитмеш җиде углы, балалар...

Дәрьям-Ана Гүзәлия белән Мусаны мәгарә эченә алып кергән. Ни күзләре белән күрсеннәр: мәгарә эчендә җитмеш җиде батыр йоклап ята икән. Яннарында хуш исле чәчәкләр, ди.

— Биш башлы аждаһаны җиңгәннән соң, алар мәрткә киттеләр. Мәкергә, афәткә каршы торырлык көч-куәт җыярга дип ял итәләр. Җитмеш җиде батырга җитмеш җиде гүзәл көн саен чәчәк китерә. Гүзәлләр китергән чәчәкләр исеннән пәһлеваннарның яралары төзәлер, куәтләре артыр.

Мәгарәдән чыккач, Дәрьям-Ана балаларга янә әйтте:

— Сез, оланнар, бәхетле илдә яшисез. Ләкин дөнья тынгысыз. Кайдадыр мәкерле кешеләр җәтмә үрәләр. Батырларны, илгә афәт килсә, халык арасыннан чыккан батыр уятыр. Тыныч йокласыннар батырлар. Менә шуңа күрә дә халык үз батырлары турында онытмый, риваятьләр, дастаннар чыгара, җырлар җырлый...

— Дәрьям-Ана! — диде Муса.— Шулар кебек пәһлеван булу өчен, халык дастанына кереп калу өчен нәрсә эшләргә кирәк?

Дәрьям-Ана әйтте:

— Халкың өчен корбан булу җитә, углан!

— Алайса, мин бүген үк үләргә риза! — диде Муса.

— Үлүне аны кем дә булдыра ала,— диде Дәрьям-Ана.— Синең үлемең халкыңа җиңү китерсә генә мәгънә бар үлемдә. Бәхетле булыгыз, оланнар! — дигән дә Дәрьям-Ана юкка чыккан.

Күпме генә эзләсәләр дә, Гүзәлия белән Муса Дәрьям-Ананы табалмаганнар. Караңгы төшә башлагач, Гүзәлия белән Муса кайтыр юлга борылганнар.

## Хач-Бөркет

Дәрьям-Ана йортыннан ерак-еракта яши иде Хач-Бөркет. Хач-Бөркетнең тугры хезмәтчеләре дә бар иде. Берсе Җасус атлы, икенчесе Шамҗар исемле, өченчесе, иң мәкерлесе, Зар-Зария, аннан кала иң зурысы, ягъни башлыклары Фәрман-хуҗа иде. Хач-Бөркет коточкыч

куркыныч патша булган, дип сөйлиләр. Ләкин аны беркем дә үз күзе белән күрмәгән. Аны күргән кешенең коты алына, йөрәге ярылып үлә, имеш. Хач-Бөркет тәхетенә бары тик аның тугры хезмәтчесе Фәрман гына керергә хаклы булган. Менә көннәрдән бер көнне Фәрман-хуҗа Хач-Бөркет тәхетеннән чыкты. Чыкты да Җасус белән Шамҗарны чакыртып болай кычкырды, ди:

— Хач-Бөркет патша каты авыру! Патшабызны коткарырга бер генә юл бар! Сөеклебез Хач-Бөркеткә дөньядагы яхшы кешеләрнең йөрәкләрен пешереп ашатырга кирәк! Безнең илдә бер генә яхшы кеше дә юк. Шулай булгач, сугыш кирәк! Яхшы кешеләр иленә һөҗүм итәргә кирәк, тубал башлар! Сугыш кирәк!

Фәрман-хуҗа бу сүзләрне Зар-Зария котырыгы илә кабатлаган.

Шуннан соң барабаннар кагып, музыка уйнатып, Хач-Бөркет сарае каршыннан коралланган гаскәрләр бер-бер артлы уза башлаган. Фәрман-хуҗа аларны сугышка рухландырып, котыртып, алга өстереп торган.

— Хач-Бөркетне коткарып калу өчен ун мең, йөз мең, миллиард кешенең йөрәге кирәк! Без тәкъдир тарафыннан халыкларның язмышын хәл итәргә җибәрелгән Хач-Бөркет балалары. Без аяусызлар, без ул илне эһ дигәнче тар-мар итәрбез! Дала да, Урман да, Тау да, Дәрья да безнеке булырга тиеш. Алга! Дәрьям-Ана йортына!..

Дәрьям-Ана йортында бар да йоклап беткәч, таң алдыннан йокының иң-иң тәмле чагында Хач-Бөркет гаскәрләре сугыш башлаганнар...

## Батырлар, торыгыз!

— Һи! — дип уйлаган Барыш.— Гаскәр башлыкларына ун капчык он бирәм дә котылам, миңа тимәсләр!

Шуннан соң озак та узмаган, яу килеп җиткән. Барыш олау-олау капчык төяп дошман гаскәрләрен каршы ала. Гаскәр иксез-чиксез агыла да агыла. Шулай итеп, Барышның тузаны да калмый. Барыш, нишләргә белмичә, дошманнарга әсир төшкән.

Барыштан соң Чукмар яуга каршы чыккан. Беренче чыгышында Чукмар дошман гаскәрләрен куып тараткан. Дошманнар тагын һөҗүм иткәннәр. Бер тукмаган, ике тукмаган Чукмар Хач-Бөркет гаскәрләрен. Ләкин Хач-Бөркет гаскәрләре иксез-чиксез агыла торган. Чукмарның тәмам куәте беткән. Гаскәр йортка бәреп кергән. Башланган суеш, үлеш, талаш, кырыш.

Гаскәр узган саен сыерлар, сарыклар, тавыклар ябыгып кала икән. Авыл урыннарында көлләр генә тузгып кала икән.

— Хач-Бөркет гаскәре басып алды илебезне. Куркаклар да, саф йөрәкләр дә әсир булды, кайда соң илнең башка батырлары? Кайда соң Дәрьям-Анабыз?

Шул мәлне үк җиңелгән ил өстендә Дәрьям-Ана пәйда булган.

— Мин барын да күреп торам! — дигән Дәрьям-Ана.

— Дәрьям-Ана, нигә соң ярдәм итмисең? Нигә уятмыйсың баһадирларыңны? — дигәннәр ил аналары.

Шуннан әйткән Дәрьям-Ана:

— Әкиятнең шарты шулай куша, халык батырларын халык арасыннан чыккан кеше генә уята ала. Баһадирларын уята алмаган халык халык түгел. Андый халык үләргә мәхкүм.

— Ир-егетләр бу сугышта башларын салдылар! — дигәннәр ил аналары.— Күмер-кисәү арасында ялгыз калдык... Кайда соң ул халык, кайда?

Шул чак Гүзәлия хәбәр китергән:

— Хач-Бөркет гаскәрләре тагын килә. Калган аналарыбызны әсирлеккә алырга киләләр...

Яу капкага хәтле килеп җитә язган. Шул чак көчле җыр тавышы ишетелгән.

— Әнә! — дигән Дәрьям-Ана.— Әнә, батырларны уятучы килә!

— Бу — Муса! — дип кычкырган Гүзәлия.— Бу — төпчек Муса!

Муса шундый итеп җырлаган ки, бар сәләтен, бар булдыклылыгын, бар моңын, бар сагышын шушы җырга салган! Бу җырны кошлар туктап тыңлаганнар. Бу җырны ишеткән җан иясе, мәшәкатьләреннән аерылып, онытылып тыңларга мәҗбүр булган. Җырны иң беренче дошман гаскәре башлыгы Фәрман ишеткән. Ишеткән дә барган җиреннән шып туктаган. Атларга дигән аягы күтәрелгән килеш һавада асылынып калган. Селтәнгән кулы сузылып каткан. Аннан соң гаскәрнең туплам башлыклары шул хәлдә туктаганнар. Аннары дошманның бөтен гаскәре тораташ булып каткан. Хәтта мәкерле Зар-Зария дә берни эшли алмаган. Бу җырны ишеткәч, Тимер-Кыя мәгарәсендә йоклаучы җитмеш җиде пәһлеванның җитмеш җидесе дә берьюлы уянган, ди. Уянганнар да сугыш кырына киткәннәр. Җыр, көчәйгәннән-көчәеп, бөтен дөньяны тутырган. Бу көчле тавыштан басу капкасындагы сакчылар уянганнар, кешеләр торып басканнар, куркакларның йөрәгенә батырлык иңгән.

Муса җырлаган да җырлаган. Иң беренче булып дошман явының гаскәр башы Фәрман исенә килгән. Чөнки аның колагын кигәвен тешләгән. Гаскәр башлыгы шунда гына абайлап алган һәм:

— Гаскә-әр! Яу-га-а! — дип кычкырган.

Ләкин аны беркем дә ишетмәгән. Гаскәр башлыгы кынысыннан агулы ук алып җәясенә куйган һәм төзәп атып җибәргән. Ук төпчек угыл Мусаның күкрәгенә барып кадалган. Егет җиргә егылган.

Җыр туктаган.

Ләкин ул арада халык баһадирлары Көр Углы, Гасәр Батыр, Чура Батыр, Әмирани, Манас Пәһлеван, Калевала, Алпамша, Давыт Батыр һәм тагын күптин-күп каһарманнар, халкыбызның җитмеш җиде пәһлеваны килеп җиткән. Җырны баһадирлар күтәреп алганнар. Шул җыр белән алар сугышка кергәннәр һәм дошман явын Дәрьям-Ана иленнән куып алып китеп, үз өнендә тар-мар иткәннәр. Хач-Бөркетнең оясын бөтенләй туздырып ташлаганнар батырлар.

Җырчы Муса, җәрәхәтенә чыдый алмыйча, җан биргән.

Бар халык үкереп-үкереп елаган аның мәете өстендә. Гомер буе бер тамчы яшь түкмәгән каты бәгырьле адәмнәр дә бу кайгыдан елаганнар, ди. Ата белән анасы да нык үксегәннәр. Торна ташлап киткән төпчек угылларын югалту хәсрәтеннән алар кара кайгыга сабышканнар. Бигрәк тә Гүзәлия кан-яшь түккән Муса өчен...

## Бөек җиңү бәйрәме

Шул чак Дәрьям-Ана пәйда булган. Терек Суын Муса өстенә бөркегән, Муса сау-сәламәт килеш торып баскан, ди.

Шуннан Дәрьям-Ана әйткән:

— Муса, син җитмеш сигезенче дастан батырына әвереләдең, син үлемсез! Халык батырларын үлем алмый! — дигән дә юк булган.

Сугыш беткән сөенечтән бөтен халык бәйрәм итә башлаган. Бу бәйрәмне «Бөек Җиңү көне» дип атаганнар. Егетләр-кызлар, әбиләр-бабайлар, апалар-абыйлар Дәрьям-Ана турында һәм дә халкыбызның җитмеш сигез пәһлеваны хакында җырлар җырлаганнар, халык батырлары ядкаре итеп Тимер-Кыядан да зур һәйкәл салганнар. Дәрьям-Ана йортында бәхетле тормыш башланган.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**1974 ЕЛ, ФЕВРАЛЬ**

КамАЗда урнашкан традиция буенча, миллионынчы квадрат метрны тапшыру хокукы өчен уннарча бригада — ташчылар, монтажчылар, штукатурчылар бригадалары ярышты. Главмосстройның Чаллы идарәсеннән А. М. Московцев бригадасы ярышта җиңеп чыкты.

Яңа квартирага күчүчеләр бүлмәләрнең бик яхшы бизәкләнгән булуына чын күңелдән рәхмәт әйтәләр. Миллионынчы квадрат метр тулай торакны тапшыру уңае белән тантаналы митинг булды. Мәскәүлеләр «юбилейлы» квартира хуҗасына зурлап ачкыч тапшырдылар. Ул КамАЗның иң яхшы эшчеләреннән берсе — сварщик Николай Палах булып чыкты.

«Правда», Мәскәү.

«Автозаводстрой»ның СМУ-1 нең икенче участогы монтажчылар бригадасы тимерчелек заводының соңгы корпусының түбәсен ябалар. Анатолий Лемешев җитәкчелегендәге бу коллективның мондый эштә тәҗрибәсе зур. Шуңа күрә эш тиз бара. Узган айда бригада план буенча 500 урынына конструкциянең 800 элементын монтажлады. Бу көннәрдә монтажчылар шулай ук энергияле эшлиләр.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Забайкалье юлларында «КамАЗ» автомобильләренең тәҗрибә үрнәкләре сынау үтәләр. Яңа автомобильнең барлык системалары түбән температура шартларында сынала. Беренче рейслар «КамАЗ»ның кырык градуслы салкында да ышанычлы эшләвен күрсәтте.

ТАСС, Чита.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты төзелеш оешмалары белән бергә 1973 елда бөтен союз удар төзелешләренең яшь коллективлары социалистик ярышына йомгак ясады. Ярышта җиңүче дип табылган коллективлар арасында «Стальконструкция» трестының Чаллы төзү-монтаж идарәсе дә бар. Ул КамАЗда һәм Минмонтажспецстройда иң алдынгы идарәләрнең берсе.

Җиңүчеләргә ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм тиешле министрлыкларның күчмә Кызыл байраклары тапшырылды, ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамоталары һәм акчалата бүләкләр бирелде.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Кишиневтагы «Медприбор» заводы больницаларны һәм поликлиникаларны җиһазлау өчен бик күп җайланмалар әзерли. Медсестрага яки врачка берьюлы

18 авыру белән ике яклы элемтәгә кирәргә мөмкинлек бирүче транзисторлы приборларның беренче партиясе КамАЗның медицина учреждениеләренә җибәрелде.

ТАСС, Кишинев.

Актаныш район культура йортының «Агыйдел» җыр һәм бию халык ансамбле төзүчеләргә үзенең премьерасын — «КамАЗ турындагы сюита»сын күрсәтте. Тамашачылар кунакларны җылы каршыладылар, үзешчән артистлар белән сувенирлар алыштылар.

Киногруппа «КамАЗ университетлары» дигән шартлы исемдәге фильм төшерә башлады. Хәзер илебездәге егермеләп шәһәрнең уку базаларында Кама автозаводы комплексы өчен производство кадрлары әзерләнә. Тиздән Чаллыда уку үзәге дә ачылачак. Бу кинолента укучыларга, профессиональ белем алучыларга багышлана.

«Татарстаным» дигән милли музыкаль программа «Энергетик» культура сараена килгән биш йөзләп кызларга һәм егетләргә күрсәтелде.

«Социалистическая индустрия»
на строительстве Камского автозавода».

Праганың төгәл электроника заводы КамАЗның тимерчелек-пресс цехы өчен термик һәм электр белән җылытыла торган җиһазлар җибәрә. Бу цехны тулы мәгънәсендә завод белән чагыштырырга мөмкин — анда ун мең кеше эшләячәк. Чехословакия җиһазлары белән беррәттән цехта Италиядә, Көнбатыш Германиядә, Швейцариядә әзерләнгән агрегатлар да урнаштырылачак.

Тимерчелек-пресс производствосының бүген бөтендөнья практикасына билгеле булган барлык яңа җиһазлары монда бергә җыйналачак, дип әйтергә мөмкин. Моннан тыш КамАЗның тимерчелек-пресс цехында кайбер принципиаль яңа технологик процесслар үзләштереләчәк.

Чехословакия КамАЗ өчен кирәкле җиһазлар биреп кенә калмый, бәлки яңа производство проектларын технологик эшкәртүдә дә катнаша.

АПН, Прага.

Ярославль мотор төзүчеләре бик җаваплы задание өстендә берничә ел эшләделәр: «КамАЗ» автомобиле өчен двигатель төзеделәр. Авырлыгы һәм күләме ягыннан «КамАЗ»ның дизель двигателе гадәти бензин двигателеннән аерылып тормаска тиеш дигән бурыч куелган иде. Шулай иткәндә аны «ЗИЛ»га, «УралАЗ»га да куярга мөмкин булачак. Шул ук вакытта Кама автомобиленең корыч йөрәге башка машиналарның двигательләреннән куәтлеге буенча берничә тапкыр өстен булырга тиеш.

Ниһаять, беренче тәҗрибә үрнәкләре — сынаучыларда. Яңа дизель имтиханны уңышлы үтте. Дәүләт комиссиясенең нәтиҗәсе мондый: «Двигатель чит ил техникасының иң яхшы үрнәкләреннән калышмый. Кама автомобиленә куелган таләпләргә тулысынча туры килә».

ТАСС, Ярославль.

Бүген Чаллы — халкының саны буенча Татарстанда икенче шәһәр. Беренче январьга 162.000 кеше теркәлгән. Узган айда гына да 618 бала туган. 1973 елда балалар өчен тугыз комбинат төзелгән. Бишьеллыкның дүртенче елында төзүчеләр мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен тугыз учреждение салачак. Сәүдә предприятиеләре челтәре киңәя. Продуктлар магазины, универсам, ресторан әзер инде.

«Советская Россия», Мәскәү.

Ун ел элек хәзер Түбән Кама торган җир бөтен җилләргә ачык дала иде. Ул вакытта нефть-химия комбинаты төзелә башлады. Төзелеш темпы легендар Магниткаьыкына тиң иде. Хәзер химиклар шәһәренең яңа предприятиесе КамАЗ өчен шин чыгара башлады. Ул шиннарның планета буйлап беренче юлы шушында ук, Кама буе далаларында башланачак.

«Советская культура», Мәскәү.

КамАЗның иртәдән төнгә кадәр эшләре бетми торган кешеләре белән танышырга тырышып кара әле?! 7 нче «А» классының шефлары интернатка чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көнне дә килергә вәгъдә иттеләр, ә үзләре бары тик якшәмбе

көнне генә килеп чыга алдылар. Интернатка барысы да аз-азлап шефлык итәләр икән. Бер идарә аларга помидор, икенчесе спорт инвентаре китерә. Яңа елга кемдер апельсин һәм алмалар җибәргән, икенче берәү культура сараена чыршы бәйрәменә билет алып килгән.

Әмма иң мөһиме бүләкләр түгел, билгеле. Зурлар интернатка балалар белән сөйләшергә, шәһәргә ияләшү өчен ярдәм итәргә киләләр. Буш вакыт табып, «Орфей» әдәби берләшмәсеннән шагыйрьләр дә килеп китте.

**«Пионерская правда», Мәскәү.**

«Энергетик» культура сараенда «КамАЗ турында хикәя» исемле документаль фильмның премьерасы күрсәтелде. Комсомол конференциясе делегатлары аның беренче тамашачылары булдылар.

Фильм КамАЗ тарихы, фәнни-техник революциянең колачы, коллективның туплану процессы, тугызынчы бишьеллыкның иң мөһим төзелешенә бөтен илнең ярдәме турында сөйләүче сигез новелладан тора. Ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое Алексей Улесов, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Новолоцкий, яшь бригадирлар Виктор Филимонов, Виктор Шатунов, Вазыйх Мәүликов һәм башкалар — картинаның геройлары. Объектив Чаллы кешеләренең тормышын һәм көнкүрешен, художниклар, композиторлар, артистлар, олимпияче спортчылар белән очрашуларны, яшьләр кичәләрен һәм халык бәйрәмнәрен төшереп алган.

**«Советская культура», Мәскәү.**

Чаллы турында тагы бик күп нәрсәләр сөйләргә, күптән сафка баскан төзелешләрне санап үтәргә була. Хәлбуки, күптән дип әйтү ел-ел ярым вакыт кына ул. Монда вакытның үз үлчәве бар. Поликлиника, бала табу йорты, мәктәпләр, төзүче инженерлар институтының филиалы, техникумнар, пионерлар йорты, главтелеграф салынды.

Иртәгәге көнгә күз салсаң, тиз йөрүче трамвайның яңа линиясен, стадионны, Камадагы су-спорт базасын, кош фабрикасын, КамАЗның үзен дә күрергә мөмкин. КамАЗ үзенең мәһабәт гәүдәсе белән җирдән калкып чыкты инде. Комплексның кайбер заводлары эшли дә башлады.

Чаллы болар белән генә үзенә җәлеп итми. Шәһәр кеше кебек бит ул. Кайберсенә карыйсың — матур, ә рухы тупас. Кешенең күңеле матур булса, аның йөзендәге сипкелләре дә килешеп тора. Һәр шәһәрнең үз рухы, ягъни кешеләре була. Камадагы яңа шәһәр беренче чиратта үзенең кешеләре белән күңелне җәлеп итә.

**«КамАЗ» исемле җыентыктан. Мәскәү,**
**«Молодая гвардия», 1974.**

**Мирхәт Хөснимәрдәнов**

# СОЛДАТ ХАТЛАРЫ

Очерк

> Хатлар белән ара якыная,
> Хатлар белән күңел тоташа,
> Сагыну кимә, җылы хисләр кайта
> Чын күңелдән язган хат аша.



Җитмешенче еллар комсомоллары! Ниндиләр алар? Алар күзгә күренеп саф чәчәкләр кебек үстеләр. Вакыт дигән нәрсә тыныч елларда талгын су кебек сизелмичә ага. Күз карасы кебек саклап үстергән ата-аналары да сизми калды, яшьләр инде тормыш дилбегәсен үз кулларына алдылар. Очерк шуларның берсе — өстенә солдат шинеле кигән, кулына Ватан-ана биргән куәтле коралны кысып тоткан яшь егет турында. Хатларында аның, көзгедәге кебек, тормышка карашы ачыклануы, характеры формалашуы чагыла.

## I

«Кадерле әнием, әтием, энем һәм сеңелем!

Сезгә кайнар солдат сәламе җибәрәм... Бераз үзем турында. Без билгеләнгән җиргә килеп җиттек. Мин чын хәрби хезмәт тормышы башладым. Килү белән машина бирделәр. Хезмәт урыным бик әйбәт. Тиздән парад формасы да алабыз. Әлеге бик каты политик һәм хәрби кәзерлек бара. Шунлыктан беренче хатымны озын язып булмады. Менә бу каен яфракларын мин кайтканчы саклагыз. Алар мин хезмәт иткән җир — ГДР җирендәге агачларныкы. Бездәге каеннардан һичбер аермасы юк. Кайнар сагыну сәламе белән...

16 май, 1973 ел».

Яшь солдатның бу беренче хаты иде. Җилкәсенә солдат биштәрен киеп, дуслары, туганнары, ата-анасы белән саубуллашып, хәрби ко-

миссариат капкасын беренче тапкыр атлап кергән көннән соң унбиш тәүлек үткәч язылган ул. Шушы ярты ай эчендә башына нинди уйлар килгәндер, нинди хисләр кичергәндер — билгесез. Ул алар турында язмый. Унсигез ел буена әти-әнинең җылы канаты астында җилянгыр татымыйча, берниндн хәсрәт-кайгысыз яшәргә күнеккән меңнәрчә егетләр өчен армия хезмәте белән тормышларында яңа чор — үзлегеннән яшәү чоры башлана. Төп хезмәт урынына барып җиткәнче, егет туган илебезнең күп шәһәрләре аша үткән, чит ил җирләрен, шәһәр-авылларын, ят булган кешеләрен күргән. Безнең әтиләр, абыйлар ул араны — Мәскәү — Сталинград — Берлин арасын — кулларына корал тотып сугыша-сугыша үткәннәр, Ватаныбызның бәйсезлеген саклап калганнар. Европаның бик күп халыкларына, шул исәптән Германия халкына да, азатлык яулап биргәннәр. Әнә шул каты сугыш, кайнар кан коеп яулаган изге нәрсәне — азатлыкны һәм тынычлыкны уяу яклап синең улың — безнең әтиләребезнең оныгы сакта тора. Ул солдат бүген. Совет армиясе сугышчысы. Аңа ил ышана, халык ышана. Әтисе ышана. Ышана һәм горурлана.

...Без бит балаларга һәр вакыт бала итеп кенә карарга күнеккәнбез. Нәрсәнедер алар без олылар аңлаганча аңлап бетерми торганнардыр, дип уйлыйбыз. «Бездән башка ничек яшәрсез икән соң сез?» — дип, аларга борчулы шелтә белдерәбез. Карасаң, Ватан-ана алар кулына дәһшәтле корал ышанып тоттырган, хәрби машина биргән һәм ил сагына бастырган. Һәм менә инде аның шуннан беренче хаты килгән. Туган илен сагына башлауның беренче билгеләре итеп ул хезмәт иткән җирендәге ак каен агачының яз ачылган тәүге яшел яфракларын конверт эченә салып җибәргән, «мин кайтканчы саклагыз», дип үтенгән. Каеннар алар сагыну билгеләре шул... Ә без күп вакыт улларыбызны хискә бирелми, андый нечкәлекләргә исе китми торган кырыс күңеллерәк бала дип күз алдына китерәбез.

...Ул май башында китте. Инде бездә дә агачлар яшеллеккә күмелеп баралар иде. Күңелле иде. Аларга Казанда ук хәрби форма бирделәр. Әйе, беренче марш-бросок. Күнекмәгән аяклар, йөреп таушалмаган яңа итекләр. Җилкәдә юлга бирелгән ашамлыклар салынган һәм аның янында төреп бәйләнгән шинель... Без дә улыбызны көчкә таптык. Кузгала башлагач, вагон тәрәзәсен ачып, безгә кул суузды. Ул кулларның, ул бармакларның әле мин тал бөресе кебек нәни һәм ефәктәй йомшак чакларын хәтерлим. Башында яшел пилотка, өстендә гимнастерка. Килешеп тора шикелле. Вокзал тулы халык. Һәркемнең үз баласы, үз мәшәкате, һәркемнең ниндидер әйтелмәгән сүзе кала, бирелмәгән күчтәнәче кала. Бала — бавыр ите шул. Берничә секунд һәм паровоз уфылдап кузгала башлый. Менә инде ул койрыгын сузып күздән дә югалды. «Киттеләр малайлар җырлашып, калдылар аналар җылашып» дигән күптәнге бер җыр сүзләре искә төште. Солдат-шагыйрь Гали ага Хуҗиныкымы соң әле бу сүзләр? Ә менә болары төгәл аныкы:

Мондый чакта җанга тынгы кайда,
Онытыла ял, йокы, ашларың,
Юллар, юллар... юллар еракларга
Алып китә солдат башларын.

Әйе, мондый чакта җанга тынгы бармы соң! Ул төнне күзебезгә йокы кермәде. Ул йоклаган бүлмә буш иде. Солдат улыбызның ничек үсүен, туганыннан башлап бу көнгә кадәр булган кечкенә генә үзгәрешләрне дә хәтерләп, аларга үзебезчә, олыларча бәя биреп, бүлмәсендә туйганчы сөйләшеп утырдык. Башка балалардан, бүтән кеше-

ләрнекеннән бернәрсәсе белән дә аерылып тормады ул. Бакчада тәрбияләнде, мороженое яратты, бик шук булды. Яше җитү белән бер дә соңга калмый укырга керде. Беренче елларында ударник та булгалады. Соңга таба үзенең бүтән яшьтәшләре белән рәттән атлады. Артык күтәрелеп макталмады, аста калып тапталмады, уртача укыды. «Бишле» алдым дип алай борын күтәрмәде, «икеле» дип артыгын үртәлмәде. Тәртип бозган, «дневник» битләрен ерткан чаклары да булмады түгел, булды. Һәр малай-шалай шикелле сугыш турындагы, солдат тормышы турындагы киноларны мөкиббән китеп яратып карады. Шулай итеп ул үсә барды, без олыгая төштек. Әмма, шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «озак үсә кеше, күпме кирәк әле тәпи басканчы, кеше булганчы!» Хәзерге һәр нәрсәгә мул тормышта бала тәрбияләүнең ни кыенлыгы бар аның. Ипикәй бар, сөт-катык күңелең теләгәнчә, конфет-шикәр туйганчы... Иң читене, иң четереклесе — кеше тәрбияләү, аңа дөрес юл күрсәтә белү. Ил тормышы, семья хәле зарланырлык булмаса да, тирә-якта гел яхшылык кына түгел, әшәкелек тә сагалап йөри, кая гына керер сыенырга икән, дип буш урын эзли. Ә бала күңеле буш капчык ул. Аңа теләсә нәрсә тутырып була. Бала үстергән кеше белә инде: һәр баланың үзенә генә, бары тик аңа гына хас булган четерекле һәм йомшак яклары була. Юкка гына «бала-чага» дип әйтмәгәннәрдер. Чаккан чаклары да була аның, хәсрәткә батырган чаклары да... Безнеке дә ал да гөлләрдән түгел иде.

Әле дә хәтердә. Җиденче классны тәмамлап килгән көннәрдә сызымнан «икеле» чыгарам дигәне өчен, класс җитәкчесенә ачу итеп, өйгә кайтмады. Беренче көнне туганнардадыр дип уйладык. Ә аннары... Көн арты көн узды... Ничек кенә, кайлардан гына эзләмәдек без аны, кемнәргә генә хәбәр итмәдек... Милиция органнары аша вокзаллардан, пристаньнардан, барып чыгарга мөмкин булган төрле шәһәрләрдән эзләттек. Көн саен моргка йөрдек, ни генә уйлап бетермәдек... Коточкыч! Баланың югалуы ата-ана өчен иң зур, иң кара кайгы. Биш, ун, унбиш көн узды. Малай да юк, аның турында бернинди җылы хәбәр дә юк. Суга батса, калкыр иде, машинага тапталса, табарлар иде. Димәк, исән. Кече улыбыз да: «Сез аны барыбер эзләп таба алмассыз, ул үзе кайтыр. Менә күрерсез...» дигән сүзләре белән безне юатырга, тынычландырырга тырыша иде. Чыннан да... югалып торуына унсигезенче тәүлек киткән иртәне, сәгать бишләр иде бугай, ишек шакыдылар. Бу аның шакуы иде. Ачып җибәрсәк, каршыбызда улыбыз басып тора. Тап-таза, чип-чиста... Битләре генә кояшта янып кара-кучкыл буяу сөрткән шикелле булган.

Сорашмадык. Әрләмәдек. Юындырып ашаттык та йокларга яткырдык. Берничә көннән соң ул барысын да бәйнә-бәйнә үзе сөйләп бирде. Кемнәрдер «булдыра алмыйсың, куркак син» дип котырткannar. Яшүсмер күңелен тетрәтә торган сүзләр бит бу. Үзенең алай түгеллеген шунда ук исбатлау теләге кабынган. Казаннан Камага китә торган пароходка утырып ул агымга каршы менгән һәм ике тәүлеккә якын барганнан соң Дирбешка пристанена төшеп, Пермьнән югарыдан килә торган турист теплоходына күчеп утырган. Шулай итеп, Идел буйлап түбән таба «сәяхәткә» киткән, Волга-Дон каналы аша үтеп, Ростов-Дон шәһәренә барып җиткән. Диңгездә коенган, кояшта кызынган. Шул ук теплоход белән әйләнеп тә кайткан.

— Нәрсә ашап йөрдең? — дип сорыйбыз.

— Ә менә ашаттылар. Проводница апага палуба юыштым. Савыт-сабалар чистарттым, баласын карадым. Хәтерлисезме, үткән ел без авылга кайтканда аның пароходында кайттык. Кечкенә малае белән танышып уйнап йөрдек. Шуны очраттым. Үз каютасыда йоклатты.

Кичләрен салонга кереп пианино уйнадым. Ял итүчеләр биеделәр, җырладылар. Үз булып киттем. Төпләп сораштыручы булмады.

— Безне күпме борчуга салганыңны беләсеңме соң?

— Хәзер беләм инде. Ярамаган эш эшләгәнемне Кара диңгез буенда ялгыз калгач кына аңладым. Кычкырып елыйсым килде. Бүтән кабатламам. Кичерегез...

...Менә шулай. Кичердек. Бала бит. Ач күзеңне — дөнья бу, диләр. Ата-ана фатихасын алмыйча юлга чыккан кешенең юлы бервакытта да уңмый аның. Кичерүен кичердек без аны. Әмма, үзе дә сизмәстән, атна-ун көн үткәч, аны Актаныш районындагы абыйларга озаттык. Тал чыбыгын вакытында әйбәт якка бөгәргә кирәк иде. Ике ай буе колхозда урып-җыюда эшләгән ул. Шушы җәйнең безнең өчен хәвефле булган вакыйгалары, авылдагы хезмәт аның яшь күңелен уңай якка үзгәртә башлаган иде. Яшүсмернең характеры формалашуында күчеш чоры дип аңлаталар моны педагоглар. Авылның тәэсире шактый көчле булган, күрәсең. Тугызынчы классны тәмамлагач, унынчыны төгәлләү өчен ул бөтенләй авылга кайтып китте. Хаты-хәбәре еш килде. Әйбәт яза иде. Машинада эшләве турында рухланып яза иде. Шунда гына без аңа машина «җене» кагылганын аңладык. Ел дәвамында ул берничә тапкыр Казанга кайтып китте. Самолет белән нибары сәгать ярымлык юл бит. Тик ул безне борчып беркайчан да, «билет алып бирегез, озатып куегыз», дип аптыратмады. Һәммәсенә үзе йөрде. Яратмый иде ул артык иркәләүне. Тугыз ел буе рус телендә укып, унынчы классны авыл яшьләренең кечкенә мәктәбендә татар телендә тәмамлау аннан нинди түземлелек һәм тырышлык сорагандыр, ул аларны үзе генә белде, сөйләргә яратмады. Без дә артык төпченеп тормадык.

Бер елдан ул әйләнеп кайтты. Кулында аттестат һәм колхоздан бирелгән уңай характеристика: «Эш сөючән, тыңлаучан һәм тәртипле, кешеләргә мөгамәләсе яхшы», диелгән иде анда. Ул тракторда, комбайнда эшләгән, һәртөрле машина серләренә төшенгән. Бу араларда инде аны берничә тапкыр повестка белән хәрби комиссариатка да чакыргаладылар. Яше тулып килә. Гаиләдәге көндәлек сөйләшүләрдә «солдат», «армия» сүзләре көн үткән саен ешрак телгә алына башладылар.

Озак та үтмәде, улыбыз токарь булып заводка эшкә урнашты һәм беренче хезмәт хакын алып кайтып әнисенең кулына тоттырды. Без аннан канәгать идек.

2

«Кадерле әтием, әнием, энем һәм сеңелем!

Хезмәтем дәвам итә. Хәрби ант кабул итәргә әзерләнәбез. Ватан алдында тугры хезмәт итү турында тантаналы ант бирәчәкбез. Парад формасы алдык инде. Тиздән биш йөз километрлы походка чыгабыз. Ике хәрби техника белән идарә итү бәхете туры килде миңа. Хатыгызны алдым. Чит җирдә яшәгәндә Туган илдән килгән сәлам хатлары аеруча кадерле икән ул. Әнкәем, мине төшеңдә бик борчулы күрдем дип язгансың, һич тә хафаланма. Ул бит төштә генә. Ә өндә исә бөтенесе әйбәт. Хезмәтем отлично бара. Кием яхшы, ашаудан зарланган юк. Көн саен иртән физзарядка. Сөякләрне язабыз. Күнек-

кәнче кул-башлар, буыннар сызлый иде, ә хәзер физзарядка ясап кергәч, күңел күтәренке, кәеф шәп, аппетит яхшы. Бүген ату кырына барабыз. Мин инде автоматны биш бармагым кебек беләм. Аннан соң пулемет өйрәнә башлыйбыз. Ул минем бронетранспортерга да куелган (бу корал сер түгел). Шунысын да әйтәм, мине хәрби ансамбльгә алдылар. Бер көнне замполит, сафка бастырып: «Кемнәр музыка коралында уйный белә?» — дип сораган иде, күп уйлап тормастан, мин дә ике адым алга атладым. Клубка алып кереп уйнатып карадылар. Ошаттылар, ахрысы. Беренче концертны ант кабул иткән көнгә әзерлибез. Ансамбльдә төрле милләт кешеләре бар. Мин немец органолында татар һәм рус көйләрен башкарам...

5 июнь, ГДР».

Бу хат юлда килгән сигез-тугыз көн арасында безнең малайлар инде хәрби ант кабул иткәннәрдер һәм беренче походларына чыккannардыр. Концертта да катнашканнардыр, үзе яраткан органолда да уйнагандыр ул. Ә бит гаиләдә аның музыка яратуына артык игътибар да ителмәгән. Кайсыдыр класста, бишенчеме, алтынчыдамы укыганда, ул кулына саксофон тотып кайтып кергәч, без аптырап, «кайдан алдың моны?» дип гаҗәпләнеп сораган идек.

— Мин музыка мәктәбенә язылдым. Шуннан бирделәр.

Ничек тапкан, ничек сөйләшкән, диген. Әмма безнең катгый таләбебез буенча аңа бик теләп алып кайткан музыка коралын кире илтеп тапшырырга туры килде. Без аңа: «Синең төп бурычың гомуми мәктәптә уку. Шул җиткән»,— дип каршы төштек. Ихтимал, бик үк акыллылык күрсәтмәгәндербез. Шулай да ул музыка белән мавыгуын ташламады, үзлегеннән рояльдә уйнарга өйрәнде. Нинди генә яңа көй ишетмәсен, ул аны шунда ук отып ала һәм рояльдә өйрәнә башлый. Бер тапкыр кайсыдыр бәйрәмдә барлык туганнар мәҗлескә җыелгач, ул: «Советлар Союзы Гимнын уйнап биримме үзегезгә?» — дип, кунакларга мөрәҗәгать итте. Аның бу сүзләрен башта уенга алдылар. Ул да булмады, улыбыз рояль артына утырды һәм бик җиңел генә уйнап та күрсәтте. Бу кичтә аннан белгән барлык көйләрен уйнаттылар. Аптырап калдык. Чыннан да, уйный белә... русчасын да, татарчасын да. Кайчан өйрәнеп өлгергән соң әле ул. Бармаклары да җитез йөри, ялгышмый. Тормышта «егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз» дигән мәкальне малайлыгы белән аңлап та җиткермәгәндер әле ул чакта

Ә тора-бара... Токарь булып эшли башлавы турында әйтелгән иде инде. Аңа икенче разряд бирделәр, комсомолга кабул иттеләр. Ленин рәсеме төшкән билет алып, значок тагып кайткан көнне ул аеруча күтәренке иде. Үзе ул моны сиздермәскә тырышты. Ата-ана күңеле нечкә скрипка кылы кебек бит ул. Шунда ук сиздек без аны.

— Нинди поручение үтәрсең икән инде? — дип сорадык без аннан.

— Миңа беренче поручениене комсомол билеты белән бергә биреп кайтардылар,— диде ул, бераз һаваланган булып.

— Нindине?

— Цехта оркестр оештырырга куштылар.

— Оркестр? Ничек итеп?

— Белмим әле. Малайлар белән киңәшергә кирәк.

Тотынган эшен, уйлаган уен җиренә җиткермичә ярты юлда калдыра торган гадәте юк иде аның. Бу юлы да зур күтәренкелек белән һәм чын күңелдән бирелеп, ул үзенең беренче комсомол поручениесен үтәргә керешә. Магазиннан инструментларны лимит буенча бирә торган тәртип бар. Кайсыдыр мәктәпнең ниндидер сәбәпләр белән алынмый калган инструментлары барлыгын белгән. Ансамбльгә үзе кебек музыкага гашыйк малайлар җыелган. Шул инструментларны төяп алып кайтканнар болар. Киностудия дирекциясенә мөрәҗәгать итеп прокатка микрофон да тапканнар. Үткән елның Октябрь бәйрәменә багышланган тантаналы кичәдә аларның беренче концерты яңгырады. Шактый оста һәм күңелле килеп чыкты.

Алар уйнаган саен остардылар. Остара барган саен аларны мәктәпләргә, төрле клубларга чыгыш ясарга чакыра башладылар. Музыка малаебыз рухи тормышының аерылгысыз бер өлеше булып әверелде. Армиягә китәсе иртәдә ул сиздермәстән генә рояль артына утырды һәм безнең гаилә өчен тирән мәгънәсе булган, безнең иң яраткан көйләребез «Урман кызы»н һәм «Агыйделкәй буе камышлар»ны уйнады. Шундый бирелеп һәм онытылып уйнады ул бу көйләрне! Без аңладык: малаебызның безнең белән саубуллашуы иде бу. Бәлки бу минутларында ул соңгы елларда күңеленә тирән булып кереп урнашкан ямьле Агыйдел буйларын, андагы серле булып тоелган ак каен урманнарын, салкын чишмәләрне күз алдына китергәндер. Авылда бер ел эшләп һәм укып кайтканнан соң менә бит ул ничек сөйләгән иде: «...Тракторда төнге сменада эшлим. Иртәгәсе көнгә чәчү өчен җир әзерлибез. Бу чакта инде төннәр шактый кыскарган була. Кояш бер яктан зур кабак кебек тәгәрәп төшә дә икенче яктан йокымсыраган кыяфәттә күтәрелә дә башлый. Башта әле алсуланып таң ата. Әле генә яшеллек төсе керә башлаган ак каен урманы өстеннән күтәрелеп килә торган кояшның беренче нурлары пәйда була. Мин аларны гигант сәңгегә охшатам. Нурлар, офыктагы болытларны төрле төсләргә манчып, алар арасыннан күз кысып балкыганнан-балкый баралар. Нинди генә төсләр юк ул нурларда! Әйтерсең лә кемдер урман эченнән мең төрле фейерверкларны һавага чөйгән. Күзләрне йокы баскан була, керфекләр кургаш кебек авыр, йомылырга гына торалар. Ә иртәнге нурлар аларга йомылырга ирек бирмиләр, ирексездән күзне ачтыралар. Әнә инде кояш каен ботаклары арасыннан күзләрен җемелдәтеп ашыга-ашыга күтәрелә башлый. Гүя ул: «Һәммәгез дә күрәсезме мине?» — дип туктаусыз елмая. Безгә бигрәк тә. Чөнки без аны беренче булып кырда — басуда каршылыйбыз. Нинди гүзәл икән бу дөнья, табигать. Мондый матурлыкны әле минем беркайчан да күргәнем юк иде. Шәһәрдә бу кадәр иртә торылмый шул. Торылса да, кояшны зур йортлар каплый. Кайчан һәм ничек чыкканын абайламый да каласың».

...Ә без балаларга бала итеп карарга гадәтләнгәнбез. Дөньяны белмиләр, аңламыйлар, матурлыкны тиешенчә күрмиләр шикелле. Без аларны чәчләрен озын йөрткәнгә «килбәтсезләр» дип ачуланабыз, кайчак «яшәүнең кадерен белмисез» дип тиктомалга әрләп тә ташлыйбыз. Ләкин, чыннап уйлап карасаң, хаталанабыз икән. Алар исә өр-яңа буын икән. Аларның матурлыкка карата үз мөнәсәбәтләре тәрбияләнгән икән. Алар безне кабатларга тиеш түгел, рухи тормышлары белән безнең дәрәҗәдә генә калмаска, үз сүзләрен әйтергә, үзләре белеп тормыш корырга тиешләр икән һәм шуңа омтылалар икән. Юк, кемнәрдер уйлаганча, бу ата белән бала арасындагы капма-каршылык түгел. Бу — үсеш диалектикасы. Үзебездә булган бөтен яхшылыкны без аларга күчерәбез. Ләкин яхшылыкның чиге юк. Алар туры юлда, дөрес юнәлештә. Алар безнекеләр, үзебезнекеләр... аларда безнең кан, коммунистлар каны.

3

«Кадерле әтием, әнием һәм энем белән сеңелем!

Хезмәтем яхшы гына дәвам итә. Хәрби ант кабул иттек. Мин аның соңгы сүзләрен русча язам: «Если я нарушу эту мою торжественную присягу, то пусть меня постигнет суровая кара Советского закона и презрение трудящихся». Без бит боларны чын күңелдән әйттек. Димәк, инде без чын-чынлап солдатлар. Күптән түгел ату кырында булдык, атып та карадык. Гаҗәпләнерлек булса да әйтим: мөмкин булган 30 очкодан мин 29 ны җыйдым. Строй алдында майор миңа беренче «благодарность» белдерде. Әгәр шундый биш мактау алсак, туган илгә берничә көнгә кайтып килергә рөхсәт бирәләр икән.

...Немецлар биредә совет солдатларын ихтирам итәләр. Бер эссе көнне машина йөртү буенча өйрәнү вакытында бер немец хатыны безгә су чыгарып бирде. Сорамаган да идек. Нәрсәдер әйтте дә безгә баш иеп савытын сузды. Мондыйлар күпләр. Машиналар да күп монда. Төрле маркалы. Бер-берсенә һич охшамаганнар. Кая гына барма — юллар яхшы, асфальтланган. Йортлар гадәти түгел, ниндидер шомартылган таштан ясалганнар. Кибетләрендә затлы киемнәр күп. Беренче фоторәсемемне җибәрәм. Барлык туганнарга күрсәтегез һәм аларга миннән кайнар сәлам тапшырыгыз.

18 июнь, 1973 ел».

Бу хатны укыгач, без строй алдында мактау сүзе ишетү белән, «Советлар Союзына хезмәт итәм» дип җавап биргән солдат улыбызны күз алдына китереп сөенештек. Аңа «рәхмәт, балам, тап төшермә» дип әйтәсе, хуплау сүзебезне ишеттерәсе килде. Мин үзем дә солдатта булган кеше. Бәхеткә каршы, тыныч заманда. Безне — егерме сигезенче елгыларны — кырык бишенче елның көзендә алырга тиешләр иде. Каралырга да барган идек инде. Ә сугыш язын — май аенда бетте һәм шуңа күрә безнең чоргылар солдат шинелен соңлабрак киделәр. Туган илдән килгән җылы хатның никадәрле кадерле булуын бик яхшы беләсең анда. Аны өстән-өстән генә укый алмыйсың, озак итеп, тәмләп, кат-кат укыйсың. Шагыйрь сүзләре искә төшә:

Күр нинди ләззәт белән ул хат укый кырын ятып.

Солдатның үзеннән килгән хатлар да туган илдә шулай укыла. Һәр язган хаты саен без улыбызның «күзе ачыла» баруын, дөньяга, тормышка карашы камилләшә төшүен күңелебез белән сизеп торабыз. Күрәсең, ул тирә-якка гади күз белән генә түгел, күңел күзе белән, һәрнәрсәгә ниндидер мәгънә биреп карый, күзәтә белә, үзенчә нәтиҗә чыгара. Ә машиналарга игътибары турында әйтеп тә торасы юк инде.

Шулай туры килде... Ул үскән чакта ике малайга бер велосипед иде. Икәү атланып чаба торгач тиз ваттылар, ташладылар. Яңасын алып булмады. Үсмер яшькә җиткәч, мотоцикл алып бирүебезне үтенсә дә, курыктык. Шәһәр зур, машиналар тыз-быз, аварияләр дә булып тора. Кирәкмәгән бер мавыгу дип улыбызга чын күңелдән аңлатырга тырыштык. Аңладымы, юкмы, әмма «алмасагыз алмас-

сыз, мин барыбер машина йөртәчәкмен», дия иде ул. Ә без аның саен: «Рулен син тоткан машинага утырып йөрергә барыбер шикләнербез», — дип шаяртуга борып килдек. «Машинадан бер дә куркырга кирәкми,— дия иде ул безгә җавап итеп,— бүредән курыксаң, урманга гына бармыйсың».

Малайларның «куркак» дигән сүздән котлары чыга. Ни әйтсәң дә «ир кешеләр» бит. Улыбыз да яшьтәшләре әнә шундый начар тамга чәпәмәсеннәр өчен җае туры килгән саен үзенең куркусызлыгын ничек тә булса сиздерергә тырыша иде. Курка дип әйтмәсеннәр өчен дүртенче каттагы балконнан кухня тәрәзәсе аша өйгә кергәнен белгәч, без аны «дуамаллык бу» дип тиргәдек. Өч катлы мәктәп түбәсеннән карга сикергәнен ишетеп, укытучылар тревога күтәрделәр. Авылда чагында күк күкрәп каты яңгыр яуган кичтә бүтәннәр калтыранып өйдә утырган вакытта абыйның: «Кем хәзер мунча керергә бара ала, кем батыр?» — дигән шаяртуын ишеткәч, аны чынга алып сикереп тора да, иске чикмән ябынып, мунчага чыгып йөгерә һәм чабынып кайта. Ә үзе көлә икән: анда бит яшен яшьнәве дә күренми, күк күкрәгәне дә ишетелми. Күз күрмәгәч, колак ишетмәгәч, ни куркынычы бар аның. Кышкы буран котырганда колхоз егетләре белән тракторга тарттырып бүрәнә алып кайтырга кушкач та ул һич карышып тормыйча юлга чыккан. Ә безгә: «Командировкада булдым. Бүрәнә алып кайтканда тракторыбыз карга чумып ике тәүлеккә якын утырды»,— дип, исе китмәгәндәй генә язды. Безне борчыйсы килмәгәндер, күрәсең.

Хәрби комиссариат аңа ДОСААФның үзәк клубында шоферлар курсына барырга тәкъдим иткәч, ул бер дә икеләнмичә риза булып кайткан. Көндезен станокта, кичен төнге унбер сәгатькә кадәр укуда... Алты ай буе шулай. Кинолар, телевидение тапшырулары, кыз озатып йөрүләр (анысы да башланган иде инде) бер читтәрәк калды. Ял итүгә бик аз вакыт бүленә. Өстәлендә техник китаплар, машина йөртү кагыйдәләре... Армиягә китәр алдыннан имтихан. Йөртү буенча бишле, ә теориядән сыната бу. Материалны белсә дә, сөйләп бирү сәләте җитенкерәми. Тагын укый, хәзерләнә, тагын имтиханга керә. Ниһаять, биреп чыга. Армиягә китәр алдыннан комиссариат таләп иткән документлар арасына шоферлык правасы да теркәлә. Эш урыныннан бирелгән характеристикада шундый юллар: «Хезмәтне яратып башкара. Үзен яхшы яктан гына күрсәтте. Җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Иптәшләре арасында тиз арада ихтирам казанды».

Авылда мин аның өлкән абый белән бергәләп печән өйгәнен күзәтеп торганым бар. Печән чүмәләсе өстенә сәнәкне нәкъ авыл егетләренекечә оста итеп кадый да, җайлап кына каерып күтәреп ала һәм аны өемгә югарырак ыргытырга тырыша. Күренеп тора: сәнәк сабы сыгылса да, билләре түзә, билләр нык. «Алай ук авыр күтәрмә»,— дип аңа абый кисәтеп тора. Ә үзе аның эшеннән канәгать. Елгырлыгы өчен ярата ул аны. «Рәт чыгар моннан»,— дип куанып сөйләнә һәм малаебызны бөтенләй авылда калырга димли: авыл хуҗалыгы институтында укып, авыл инженеры булып кайтырсың. Өйләнерсең. Каен урманы читеннән йорт салып бирербез үзеңә. Бабаларыңның нигезе монда бит. Нигезне корытырга кирәкми.

Абыйның бу сүзләренә ул каршы килми. «Әле бит армиягә барасы бар, дөньялар күрәсе... — дип, җавап кайтара ул. — Калган туганнар ни әйтер, әти-әниләр»... Димәк, төпле фикер йөртә белә. Кешеләр: «Бу малаегыз сезнең бигрәк тә туган җанлы»,— дип мактыйлар икән, балаң турында шундый сүзләр ишетү ата-анага ифрат та күңелле һәм рәхәт икәнлеген сөйләп торуның кирәге бармы соң?! Һәр хатында ул «өлкән апаның хәле ничек, ул ялгыз, аңа булышырга

◆ СОЛДАТ ХАТЛАРЫ ◆ МИРХӘТ ХӘСНИМӘРДӘНОВ

кирәк», «авылга — абыйларга хат яздым, хәлләрен белештем», «Факия апаның сәламәтлеге ничек?», «Рөстәмнең аягы төзәлдеме әле? Эшендә уңышлар бармы?» һәм башка шундый бик күп сораулар яудыра. Аңа җавап хатын кыска гына итеп язармын дип уйлама да...

4

«Кадерле әнием! (Бу хатын ул бары тик әнисенә генә атап язган иде.)

Сезгә олы солдат сәламе җибәрәм. Хезмәтнең авыр чоры башланды, диләр. Миңа калса, түзәрлек. Безнең ансамбль нишли анда? Әллә таралamы? Бер дә язмыйлар. Кайткач аны тагын барыбер җыярбыз. Инструментларны гына сакласыннар. Туган ил сагындыра икән шул. Һәммә нәрсә искә төшә. Ничек әле теге җырда: «Без бүген авыр хезмәттә, Россиядән еракта, Туган илдән еракта»,— дигән сүзләр бар иде. Хәтерлисезме, безнең ансамбль башкаруында...

...Шушы айлар эчендә без җирле халык алдында берничә концерт бирдек. Чәч алынган килеш тамашачы алдына чыгуы, органолга тотынуы баштарак ничектер уңайсыз иде. Хәзер чәчләр бераз үсә башлады. Ни әйтсәң дә, стаж арта бара. Хәер, хәзерге немецлар, бигрәк тә яшьләр үзләре дә безнең тыныч солдатларга күнегеп беткәннәр. Менә шундый хәлләр... Сагынычлы сәлам белән...»

5

Соңга таба айга якын хат килми торды. Без инде борчыла башлаган идек. Төрлесен уйлыйсың бит. Кеше балалары гына ул армиядән бик тиз өйләнеп кайткандай булалар. «Тутырып та кайттыңмыни?» — дип сораганыңны сизми дә каласың. Ә үзеңә кагылгач... көннәрне иртә дә, кичен дә саныйсың. Солдат улың да аларны көн саен әллә ничә санап календарь битендә билгеләп бара торгандыр. Без шулай итә идек.

Бер-бер артлы рәттән өч хат килеп төште. Язуына караганда кәефе яхшыдыр шикелле. Хәер, никадәр авыр булса да, зарланмый ул. Андыйларга «авызында кан булса да кеше алдында төкермәс» диләр. Солдат тормышына күнегү ул кешедән зур түземлелек, ихтыяр көче, рухи күтәренкелек һәм үз бурычыңны бөтен тирәнлеге белән аңлауны һәм шуны турылыклы үтәүне таләп итә. Бу сыйфатлар улыбызның соңгы хатларында аеруча чагыла. Чыннан да әнә шулай дөнья күрә-күрә, үзлегеннән яши башлаган тормыш тегермәнендә чарланып акыл керә бара торгандыр. Ә без балалар дибез... Алар бездән зиһенлерәк булганнар инде. Без кабатлаган ялгышлыкларны кабатламасыннар, без башкарып җиткерә алмаган игелекле эшләрне ахырга кадәр түземлелек белән илтеп җиткерсеннәр.

Соңгы хатларына аерым-аерым тукталып тормыйм. Мин аларның кайберләрен берләштереп кенә тәкъдим итәм.

«...Бик ашыгыч язам. Тәнәфестә генә. Без бик ерак юлда булдык. Әле генә кайттык. Частька әләгү белән почтага йөгерәсең инде. Анда мине биш хат көтеп торган. Эссе ва-

кытта сусаганнан соң су эчеп туя алмаган шикелле, йотлыгып хат укыйсың...»

«Хезмәтем әйбәт бара. Парад формасыннан фотога төшкән идем. Җибәрәм. Миңа килешә диләр андый форма. Июль ахырында бездә фестиваль башлана. Безнең илдән дә бик күп делегатлар киләчәк икән. Фестиваль үзенә ул. Ә бездән тулы сугышчан хәзерлек, икеләтә-өчләтә уяулык таләп ителә. Төрле илләрдән никадәр кеше җыела бит.

Әле мин мондагы җирләрнең матурлыгы турында язганым юк. Төнлә бигрәк тә романтично. Ерак та түгел зур шәһәр утлары балкый. Музыка яңгырый. Немецлар көне-төне музыка әйләндерәләр. Яхшысы да, яманы да бар...»

«...Минә инде өч ай узды. Тагын 640 көн. Вакыт тиз уза. Тиздән әтинең туган көне — 4 август. Алдан ук тәбриклим, кадерле әткәем, открытка җибәрәм, сәламәтлек һәм эшеңдә зур уңышлар телим».

«...Илнурның хатын алдым. Ул тугызынчыны бетергәч лагерьда берничә көн булуы турында яза. Ашханәгә өч километр чабып барабыз, чабып кайтабыз, дигән. Чүп нәрсә ул. Кем әйтмешли, «әле ул аның баласы гына, мичтә ята анасы». Уйла: йөгерергә армиягә барганчы ук өйрәнсәң әйбәтрәк икән. Югыйсә, күнекмәгән килеш тының бетеп, сулышың кысылып егылып калырга мөмкин».

«...Күптән түгел безнең өчен дә, немецлар өчен дә кайгы көне булды. Вальтер Ульбрихт үлде. Аның кем икәнен яхшы беләсез. Эрнст Тельманның көрәштәше. Аларның гадәтләре буенча, бу көнне музыка уйнау, җырлау, бию тыела икән. Хатымны тәгәллим. Сугышчан постка басар сәгать җитте. Тыныч күңел белән китәм. Хушыгыз. Хат көтәм. Сезне сагынучы улыгыз Илгиз. Хәрби часть. ГДР».

Әйе, безнең комсомолец солдат улыбыз сугышчан постта тора. Тынычлыкны саклый. Ул киткәннән соң дөнья күләм булып үткән зур вакыйгалар арасында икесе безнең өчен аеруча әһәмиятле иде. Май аенда КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев ГДРда Берлинда булып кайтты. Андагы очрашулар турындагы тапшыруларның һәркайсын без телевизор аша карап бардык. Тәртип саклаучылар арасында бәлки ул да күренеп китәр төсле (минә бит ул ата-ана өмете). Ә яшьләрнең унынчы Бөтендөнья фестивале барган көннәрдә без телевизордан күзебезне дә алмадык. Кайдадыр шунда, фестиваль барган стадион артында, башкалар белән рәттән безнең улыбыз да сакта торадыр, тәртип саклыйдыр шикелле тоела иде.

Соңгы хатлар инде олы кеше хатлары дип әйтерлек. Ул аларда хезмәт итүче иптәшләре, дуслары турында, солдат дуслыгы турында горурланып яза. Алар батареясы соңгы өйрәнүләрдә «Сугышчан һәм политик хәзерлек отличнигы» дигән исемне яулаган. Һәр бәйрәм саен частьларда һәм төрле шәһәрләрдә концерт белән чыгышлар ясыйлар. Инде ике төрле һөнәр үзләштергән. Кайткач югары уку мәктәбенә керү турында хыяллана. Энесен дә шуңа үгетли. Әйе, хатларда инде сагыну гына түгел, ә кулына коралны нык тотканын белгән, аңлаган ир кешенең уй-фикер йөртүе. Аларда үз иле белән чын күңелдән горурлана торган, үз иленең солдаты дигән мактаулы һәм җаваплы

бурычны үтәүгә бөтен җаны-тәне белән бирелгән унсигез-егерме яшьлек комсомолец егетнең корычтай чыныга барган ихтыяр көче, ныклы характеры сизелеп тора.

Үзәк киностудияләрнең берсендә режиссер булып эшләүче В. Роговой үзенең әле күптән түгел генә экраннарга чыккан «Төньяк флоты юнгасы» дигән фильмы турында сөйләгәндә солдат тормышы турында шундый сүзләр әйткән иде: «Хәрби кешеләр кебек игелекле, яхшы күңелле, шул кадәр дус була белә торган, үзенең сүзенә һәм эшенә шул кадәр тугры булган бүтән кешеләрне очратканым юк әле минем. Солдат тормышының кырыс хезмәте, хәтта ул тыныч заманда үтсә дә, батырлыкка, үлем тәвәкәллегенә барырга әзер тору аларның барысын да нииндидер башка калыптагы кешеләргә әверелдерә һәм шуның белән бергә алардагы кешелеклелек сыйфатларын үстерә. Армия һәр ир кеше тормышында иң кирәк булган этап, ул аның характерын формалаштыра, аны корычтай нык, батыр һәм алга омтылышлы итеп ясый. Армиядә яңадан туалар һәм һәр төрле кирәкмәгән нәрсәләрдән арыналар. Хезмәткә барасы егетләр өчен моны аңлау бик әһәмиятле».

Бу фикерләрне без малаебыз хатларыннан да укыган идек. «Армия хезмәте малай чактагы иләс-миләслекне бик тиз селеккәли һәм алардан арынырга ярдәм итә»,— дип язган иде ул. Шундый акыллы фикерләре булган өчен дә без аның хатларын бер папкага теркәп җыя бардык. Сагынган саен папканы алып актарабыз, хатлар укыйбыз. Һәр укыган саен яңа мәгънәләр табабыз шикелле.

Китаплар шүрлегендә ул җибәргән каен яфраклары...

Радио бүген, бу очеркны тәгәлләп утырганда, Берлинда 23 градус җылы һәм тыныч һава дип хәбәр итте.

Бездәге кебек...

Дөньялар гына тыныч булсын!

## Самат Шакир

# ПОЛК КОМИССАРЫ



1941 елның августы. Алма-Ата шәһәре. Бакчалар, скверлар, парклар хуш исле чәчәкләргә күмелгән. Урамнарга, трамвай тукталышларына: «Немец басып алучыларына үлем!», «Ватан-ана чакыра!», «Син бүген фронт өчен нәрсә эшләдең?» дигән плакатлар эленгән.

Олы урам халык белән шыгрым тулы. Алар фронтка китүчеләрне озатырга килгәннәр. Ап-ак чәчле, йөзен җыерчык баскан ябык кына әби үзенең оныгын озата. Ул калтыравык тавыш белән:

— Дошманны тизрәк дөмектереп кайтыгыз! — ди, күз яшьләрен сөртә.

— Тыныч бул, әбекәй,— ди оныгы, әбисенең аркасыннан сөя-сөя,— ата-бабалар йөзенә кызыллык китермәбез!

Әби янындагы хатын сүзгә кушыла:

— Синең әтиең, улым, унсигезенче елны немецларга каршы сугышта һәлак булды. Онытма син аны, аның үчен, халык үчен алырга барасың.

Әби кабат күз яшьләрен сөртеп ала һәм, оныгының башыннан сыйпап:

— Исән-сау кайт, балакаем! — ди.

Менә көчле музыка яңгырый. Хәрби киемдәге кешеләр сафы нык адымнар белән алга кузгала. Аларга озатырга килгән халык иярә. Вокзалга җитәрәк агач аяклы, зур гәүдәле бер кеше, фуражкасын селки-селки:

— Җиңеп кайтыгыз, туганнар! Әгәр аягым булса, мин дә сезнең белән китәр идем!— дип кычкырып кала.

Кызлар егетләренә, хатыннар һәм яшь киленнәр ирләренә, ата-аналар улларына, кияүләренә хәерле юл телиләр.

Алма-Ата урамнарыннан халык агыла. Алар панфиловчыларны фронтка озаталар.

Музыка йөрәкнең иң түренә үтеп керә, аяклар бердәм атлый. Олыраклар арып туктый да, бәлки соңгы тапкыр күрүемдер дигәндәй, улларының артларыннан үрелә-үрелә карап кала.

Кояш шул кадәр кыздыра, кешеләрнең битләреннән һәм аркаларыннан тир ага, күлмәкләре юешләнеп аркаларына ябышкан. Малайлар майкаларын салып кулларына тотканнар.

Вокзал ишеге төбендә озын буйлы, кара мыеклы, илле яшьләрендәге генерал Панфилов басып тора. Аның янында полк комиссары



Әхмәтҗан Мөхәмәдьяров, полк командиры Илья Васильевич Капров, тагын башка командирлар, партия, комсомол һәм хөкүмәт вәкилләре. Алар вагоннарга таба үтүче кызылармеецларны күзләре белән озаталар һәм әледән-әле кул сәгатьләренә карап алалар.

Оркестр хәрби марш уйный. Сугышчылар һаман эшелонга таба уза... Вокзалны яңгыратып, радио соңгы хәбәрләр тапшыра:

«...Безнең гаскәрләр Коростень, Сольцы, Умань һәм Смоленск юнәлешләрендә дошманга каршы каты сугышлар алып баралар».

Бу сүзләр һәркемнең йөрәгенә уктай барып кадала, һәркемдә дошманга каршы үч, нәфрәт ташый.

Фашистлар Смоленскига һөҗүм итә. Димәк, алар Мәскәүгә куркыныч тудыралар. Димәк, алар Ватаныбызның йөрәгенә үрмәлиләр. Һәр солдат Ватанына, халкына турылыклы булырга, соңгы тамчы канга кадәр сугышырга күңеленнән ант итеп, вагоннарга урнаша.

Шулай итеп, генерал И. В. Панфилов командалыгындагы 316 нчы дивизия олы юлга кузгала.

*

* *

Паровоз каты итеп кычкыртканнан соң, әкрен генә кузгалды. Озатучы халык хәерле юл, җиңү теләп, соңгы вагоннар күздән югалганчы куллар изәп, яулыклар болгап калды. Поезд Алма-Ата шәһәрен артта калдырып, кызулаганнан-кызулый барды.

Сугышчылар вагон тәрәзәләреннән, ачык ишекләрдән тирә-юньне күзәтеп баралар. Бер кызылармеец ерактагы күгелҗем-зәңгәр Алатауга күрсәтеп авыр сулады да:

— Каласың бит, гүзәл Алатау!— дип, әкрен генә җырлый башлады. Далада туып-үскән бу егетнең моңы вагондагыларга шул кадәр тәэсир итте, алар тын да алмыйча тыңладылар.

— Ну, дус, матур җырлыйсың икән.

— Кил әйдә, Мусабек, берәр партия домино сугып алыйк!

Ләкин Сеңгербаев домино уйнарга теләмәде. Ул Григорий Шемякин янына утырып, хәл-әхвәл сораша башлады. Бераздан татар егете Моратов та алар янына килеп утырды. Алар өйдә калган әти-әниләре, туган-тумачалары турында сөйләштеләр. Башларыннан кичкән төрле кызыклы вакыйгаларны искә төшерделәр. Арада иң җор сүзлесе Мусабек иде.

Әкрен генә кичке караңгылык җәелде. Кинәт зәһәр җил исеп куйды, коры дала өстендә бөтерелеп тузан күтәрелде. Шактый ерак-та йөк тәялгән өч-дүрт дөя тимер юлдан читтәге сукмак буйлап килә иде. Аларны күргә, Сеңгербаев тәрәзәгә үрелде. Ул үзенең даласына, андагы дөяләргә, дөяләрне җитәкләп барган кешеләргә чын ихлас белән карап барды.

Уртача буйлы, аксыл йөзле, саргылт чәчле политрук Клочков, вагондагы сугышчыларны бер урынгарак җыйнап, газета хәбәрләрен

укыды. Анда гитлерчыларның Брест шәһәрендәге ерткычлыклары турында язылган иде. Бер кызылармеец авыр сулап башын түбән иде.

Политрук аннан:

— Нәрсә булды, дус кеше? — дип сорады.

— Брестта минем апам тора... Ә анда илбасарлар тыныч халыкны кыралар.

— Минем дә абыем Брест шәһәрендә, армия сафында хезмәт итә иде. Сугыш башлангач бары бер хаты килде,— диде өченче сугышчы. Политрук аларның кайгыларын уртаклашты.

— Әйе, фашистларның кабахәтлекләре чиктән ашты,— диде Клочков.— Тиздән моның үчен алырбыз, дусларым! Кеше каны җирдә ятмас!

Поезд бер станциягә җитеп туктады. Вагоннарның ишекләрен киң итеп ачтылар. Вагонга генерал Панфилов һәм полк комиссары Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров керделәр. Сугышчылар аягүрә басып честь бирделәр. Генерал кызылармеецларның хәлләрен сорашты:

— Ну, егетләр, кәефләр ничек?

— Бик яхшы, иптәш генерал!

Панфилов шаяртып алды.

— Хәлләрегез әйбәт булгач, немецларны да бик әйбәт кыйныйбыз инде!

— Исәп юк түгел,— диде Моратов. Шул ук җавапны Григорий Шемякин да бирде. Клочков зур йодрыгы белән көнбатышка таба селтәнде.

— Ул кеше ашаучыларның азу тешләрен җимерербез, иптәш генерал! — диде ул.

Бераз сөйләшкәннән соң генерал Панфилов һәм командирлар башка вагоннарга юнәлделәр. Полк командиры Капров белән комиссар Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров сугышчылар янында калды. Бераздан Капровны штаб-вагонга чакырып алдылар.

Комиссар Мөхәммәдьяров Моратов янына килеп сорау бирде:

— Сугышка кадәр сез телефонист-монтер булып эшләгәнсез икән? Кайда укыдыгыз?

Егет комиссарга күтәрелеп карады һәм җавап бирде:

— Ташкент элемтә техникумын тәмамладым.

— Бик яхшы,— диде комиссар.— Әти-әниләрегез исәннәрме?

— Ташкентта яшиләр. Яшь вакытларында Казанда эшләгәннәр. 1921 елгы ачлык аларны Урта Азиягә куган.

Сүзгә Григорий Шемякин да кушылды. Җанлы әңгәмә шактый дәвам итте. Клочков барысының да уртак фикерен әйтеп салды:

— Монда руслар, украиннар, казакълар, татарлар, башкортлар, кыргызлар җыйналган икән. Безнең полк интернациональ полк. Ә максат бер — Ватаныбызга кул сузган немец илбасарларын тизрәк тар-мар итү!

— Бик дөрес, иптәш Клочков! — диде Мөхәммәдьяров.— Без дошманның алга баруын туктатырга һәм аны тар-мар итәргә тиешбез! Шулаймы, дусларым?

— Дөрес, дөрес! — дигән тавышлар яңгырады.

Сеңгербаев кысык күзләрен тагы да кыса төшеп полк комиссарына карап алды да сорау бирде:

— Сез үзегез кайсы яктан?

— Мин үзем Казагыстанда Тимер шәһәрендә туганмын. Бик яшьтән Кызыл Армия сафына киттем,— дип, ул үзенең тормышын сөйләп китте.

Сугышчылар комиссар Мөхәммәдьяровның сүзләрен зур кызыксыну белән тыңладылар. Сөйләшү-әңгәмә тәмам булганнан соң Моратов шатлыклы хәлдә сөйләп китте:

— Минем бабамның бабасы татар-башкорт кавалерия полкында хезмәт иткән һәм 1812 елгы Ватан сугышында катнашкан.

Ул тагын да җанлана һәм тавышын күтәрә төшеп сүзләрен дәвам итте:

— Ә бит татар-башкорт кавалерия полклары 1814 елда Парижны алуда катнашканнар!

— Әйе, бик дөрес, иптәш Моратов! — диде комиссар Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров.— Безнең бабайлар илбасарларның арт сабакларын укытканнар!

Поездның китәсен белдереп, паровоз озын итеп кычкыртты. Вагоннар әкрен генә кузгалдылар...

*
* *

1941 елның көзе.

Немец армиясе салкын кыш җиткәнче Мәскәүне алырга исәпли. Свастикалы козгыннар шәһәрне һәм шәһәр тирәсен бомбага тота.

Совет Армиясе һәм Совет халкы мәкерле дошманга каршы нык торды. Ватаныбыз йөрәге Мәскәүне саклау өчен халык ярдәм күтәрелде. Ополчениегә олы яшьтәгеләр, хатын-кызлар, хәтта яшүсмерләр дә язылды. Алар кулларына корал алып алгы сызыкка килделәр.

Гүзәл һәм горур Мәскәү! Борынгы заманнардан ук тарихка данлы сәхифәләр язган бөек шәһәр! Кремль, Кызыл мәйдан, Ленин мавзолее... Сезнең өчен канлы сугышлар бара.

Көн саен фронтка китүче сугышчыларның көчле җырлары яңгырый:

Вставай, страна огромная,
Вставай на смертный бой...

...Бик каты сугышлардан соң, октябрь башларында фашистлар армиясе Мәскәү исемендәге каналга килеп чыкты. Дошман колонналары Волоколамскига таба үрмәләде.

Соңыннан Совет хөкүмәте кулына төшкән яшерен документларга караганда, фашистларның Мәскәү юнәлешенә иң көчле дивизияләрен җибәргәнлеге билгеле булды. Алар Советлар Союзы башкаласын «яшен тизлегендә» басып алуны планлаштырганнар. Бу план «Тайфун» дип атала. Аны төзүдә Гитлерның иң ышанычлы, хәрби техниканы һәм стратегияне бик яхшы белгән генераллары һәм фельдмаршаллары катнашкан.

Фашистик Германия Мәскәүне алу өчен 51 дивизия туплады. Мәскәү тирәсендәге шәһәрләргә һәм авылларга гитлерчылар 3300 туптан аттылар, меңнәрчә самолетлардан бомба ташладылар, 1500 танк белән һөҗүм иттеләр.

Фашистлар радиодан үзләренең зур җиңүләре, тиздән Россиянең башкаласында булачаклары һәм Кызыл мәйданда җиңү парады үткәрәчәкләре турында шапырындылар.

Ләкин Совет халкы һәм Совет Армиясе дошманга каршы корыч стена булып күтәрелде, дошманның юлына аркылы төште.

*
* *

Октябрьның күңелсез, ачы җилле, яңгырлы көннәре. Күк йөзендәге кара болытлар җир белән тоташкан. Аяк атлаган саен сутлы балчык итек һәм ботинка олтаннарына сылана. Шинельләр, бүрекләр

лычма су... Ләкин сугышның үз законнары бар шул. Нәкъ менә шундый көннәрдә фашистларга һич көтмәгәндә удар ясарга кирәк тә.

Броняга төренгән дошман, кара афәт булып, изге җиребезне канлыкка манчып, һаман эчкәрәк үтә.

Волоколамск юлында каты сугышлар бара. Казагыстаннан килгән 316 нчы дивизия дә алгы сызыкта. Генерал Панфилов командалыгындагы бу дивизия солдатлары һәм офицерлары сугышларда тиңдәшсез батырлыклар күрсәттеләр. Армия генералы Рокоссовский арысландай сугышкан баһадир ирләргә берничә тапкыр рәхмәт белдерде.

Ноябрь башлары. Кар катыш яуган яңгыр суы окопларга, блиндажларга тулды. Тиздән суытып җибәрде, җир өстен лом белән дә вата алмаслык итеп туңдырды. Землянкага килеп кергән полк комиссары Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров, кулларын уа-уа, ишекле-түрле йөренеп:

— Әгәр дә таш юлдан шар җибәрсәң, һичшиксез, Мәскәүгә хәтле тәгәрәр,— диде.

— Мәскәү бик якын,— диде бер сугышчы, тимер мичкә утын өстәп.

— Ну, хәзер немецларның да кикриге шиңде! — диде Моратов.— Табаннарын кырмыска тешли башлады.

Комиссар Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров сугышчылар белән әңгәмә үткәрде. Кичә булып узган каты бәрелешләрдә үзләренең батырлыклары белән танылган сугышчыларны тәбрикләде һәм киләчәк сугышларда зур уңышлар теләде.

Аннары ул полк штабына юнәлде. Үзенең Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәшеп йөрүләрен күз алдына китерде...

Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров 1904 елда Казагыстанның Тимер шәһәрендә эшче семьясында туды. Әтисе Латыйф ага улын укытучы итәргә теләде. Әмма Әхмәтҗан хәрби эшне ярата иде. Ул кечкенәдән үк командир булырга хыялланды. Тимер шәһәрендә татар һәм башкортлар күп иде. Менә шул татар һәм башкорт малайлары белән ул сугыш уеннары уйнаганда командир була иде. Үсә төшкәч, Әхмәтҗан үзе теләп Кызыл Армия сафына китте. Ул вакытта басмачыларга каршы сугышлар бара иде. Кавалериядә хезмәт итүче Әхмәтҗан каты сугышларда катнашты. Җөнәид хан һәм Ибраһим бәк бандаларын тар-мар итәргә булышты. Монда күрсәткән батырлыклары өчен эскадрон командирыннан рәхмәтләр алды. Әхмәтҗанның да борынгы бабалары татар-башкорт кавалерия полкларында хезмәт иткәннәр һәм 1812 елгы Ватан сугышында катнашканнар. Латыйф ага үзе дә 1914 елда немецларга каршы сугышкан.

Гражданнар сугышыннан соң кызыл кавалерист Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров Казагыстанда хәрби комиссариатта эшләде һәм, Бөек Ватан сугышы башлангач, Алма-Атада оешкан Панфилов дивизиясенә полк комиссары итеп билгеләнде.

Әнә шул көннән бирле ул сугышчылар белән бергә озын походлар узды, Мәскәүне саклау өчен каты бәрелешләрдә катнашты.

*

* *

Иртәнге якта кар яуды һәм көчле давыл күтәрелде. Панфиловчылар, дошман атакаларын кире кайтарганнан соң, землянкаларда ял итәләр иде. Башкорт егете — Стәрлетамактан килгән Тукаев — бик моңлы итеп җыр сузды:

Исә җилләр, исә җилләр,
Кем туктатыр җил көчен.
Егет җанын кызганырмы
Туган-үскән ил өчен.

Аның янына Моратов килеп утырды. Шемякин, Сеңгербаев, Есибулатов һәм Клочков бер почмакта домино уйныйлар. Кинәт землянка ишеге киң ачылды һәм киемнәренә кар сырышкан туңган разведчиклар кайтып керде. Аларның өчесе яралы иде.

Разведчиклар фашистларның зур көч туплап һөҗүмгә әзерләнүләрен әйттеләр. Панфиловчылар да дошманга удар ясау өчен кирәкле чараларны күрделәр.

Полк комиссары Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров алда зур сугышлар торганлыгын, дошманның сан ягыннан өстен булган көчләрен тар-мар итү өчен баһадирларча көрәшергә кирәклеген аңлатты. Алгы сызыкта булган бәрелешләрдә ул үзе дә катнашты, полкны берничә мәртәбә атакага алып барды.

Немецлар, танклар ярдәмендә, Дубосеково разъездына якынлаштылар.

251,0 биеклеге!

Бу сан язылган әһәмиятле ныгытма штаб карталарында зәңгәр һәм кызыл карандаш белән өч-дүрт тапкыр тамгаланды. Фашистлар, шушы мөһим биеклекне алып, Волоколамск юлыннан Мәскәүгә килергә исәплиләр икән.

Дошман һөҗүмгә күчте. Бу — 16 ноябрь көне иде.

Иң элек фашистларның «юнкерс»лары кара козгыннар кебекябырылдылар һәм сугыш кырына авыр бомбаларын койдылар. Озак та үтмәде, гитлерчылар артиллериясе җир өстенә зур-зур чокырлар казыды. Минометлар ухылдады, пулеметлар тырылдады... Сугыш кыры җимерелгән дотлар, үтерелгән атлар, кешеләр белән чуарланды.

Иртән башланган гарасаттан соң, немецлар акырып-бакырып атакага күтәрелделәр. Алар автоматлардан ата-ата якынайганнан-якынайдылар... Аларның «Нах Москау!» дип тамаклары карлыкканчы кычкырынулары, сүгенүләре, Совет сугышчыларына янаулары ишетелде.

Фашистлар теземе инде бик якын, алгы окопларга йөз метр чамасы гына иде. Кинәт «Ут ачарга!» дигән команда яңгырады һәм бик каты сызгыру ишетелде. Совет сугышчылары пулеметлардан һәм винтовкалардан ут ачтылар. Алгы окоплардан гранаталар ыргыттылар... Немецлар, кар өстендә йөзләрчә мәетләрен калдырып, чигенә башлады. Озак та үтмәде, кара тәреле танклар килүе күренде. Аларны санадылар. Барысы егерме танк иде. Танкларга каршы каты сугышлар башланды. Бу коточкыч сугыш барган вакытта яңадан утыз танк күренде.

Панфиловчылар, бер-берсенә тотынып диярлек, корыч стена булып бастылар. Клочков шинелен салып ыргытты да, иптәшләренә таба борылып, ялкынлы һәм калын тавыш белән:

— Яңадан утыз танк! — диде.— Кеше башына икешәр танк, дусларым. Россия зур зурын, әмма чигенер урын юк. Артыбызда— Мәскәү!

Политрук ажгырып килүче зур танкка гранаталар бәйләмен ыргытты. Башкалар да гранаталар ыргыттылар, танкка каршы ата торган мылтыклардан ут ачтылар... Сугыш озак дәвам итте.

Дубосеково разъездында һөҗүм итүче фашист танклары тимер-томыр өеменә әйләнде. Гитлерчылар кырып ташланды. 50 танкка каршы каһарманнарча сугышкан 28 панфиловчыга үлгәннән соң Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде. Бу батырлар Илья Васильевич Капров, Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров җитәкчелегендәге полк сугышчылары иде.

Дивизиягә яңа килгән яшь сугышчыларга комиссар Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров болай диде:

— Сез исемнәре алтын хәрефләр белән тарихка язылган баһадирлар тәрбияләнгән полкның сугышчылары булдыгыз. Сез алардан үрнәк алыгыз! 28 панфиловчы-баһадир немец һөҗүмен туктатты һәм үзләре һәлак булдылар. Алар Ватаныбызның йөрәге Мәскәүне саклап, яшь-яшь гомерләрен бирделәр. Онытмагыз сез аларны!

Яшь сугышчылар соңгы тамчы канга кадәр гитлерчыларга каршы сугышырга ант итте. Әйе, алар антларына турылыклы булдылар һәм, фашистларны куа-куа, Берлинга барып җиттеләр. Панфилов дивизиясе, башка дивизияләр белән берлектә, фашизмны үз оясында тар-мар итеште. Гитлер Германиясе тәмам җиңелде.

Исән калган сугышчылар туган җирләренә кайттылар. Панфилов дивизиясе солдатлары һәм офицерлары да тыныч төзелешкә керештеләр. Алар арасында Әхмәтҗан Мөхәммәдьяров та бар иде.

Полк комиссары Әхмәтҗан Латыйф улы Мөхәммәдьяров хәзерге көндә Чиләбе шәһәрендә яши. Легендар Панфилов дивизиясенең полк комиссары зур батырлыклары өчен Ленин ордены, ике тапкыр Кызыл Байрак ордены, ике тапкыр Кызыл Йолдыз ордены, сигез медаль белән бүләкләнде. Бу баһадир комиссар турында фронт һәм үзәк газеталарда язып чыктылар. Күренекле рус язучылары Александр Бек «Волоколамск юлы», Александр Кривицкий «Мәскәү янындагы каравыл», мәшһүр казакъ язучысы Бауржан Момыш улы «Безнең артта — Мәскәү», Александр Селивановның «Панфиловчылар» дигән китапларында Мөхәммәдьяровның батырлыгы турында да язылды.

Панфиловчы башкорт егете Тукаев һәм татар егете Моратов каты сугышларда һәлак булдылар. Сугыштан соң 28 панфиловчының дүртесе исән калуы билгеле булды. Аларның икесе сугыштан соң вафат булды, икесе — Григорий Мелентьевич Шемякин һәм Иван Демидович Щадрин — Алма-Ата шәһәрендә яши.

Панфиловчылар батырлыгы халык күңелендә мәңгелек урын алды!

**Наталья Кравцова,**
элекке очучы, Советлар Союзы Герое

# БАГЕРОВОГА ТАБА



Багерово — Керчьтан көнбатышка табарак якта кечерәк кенә тимер юл станциясе. Немец эшелоннары килеп туктый торган җир. Алар фронтка өстәмә көчләр, кораллар, снарядлар алып киләләр.

Безнең бирегә беренче генә очуыбыз түгел, аны бомбага тотуы кыен икәнен беләбез. Безнең «ПО-2»ләрнең станциягә якынлашуы була, шунда ук прожекторлар кабынып китә һәм аның дәһшәтле озын нурлары самолетка таба йөгерә башлый. Станция тирәсендәге калкулыклардан зениткалар бәрергә тотына.

Узган юлы күк йөзе минә дигән иде: йолдызлы кара күк йөзе, ник бер болыт булсын. Андый төндә тавыш-тынсыз очып килергә мөмкин: җаның теләгән хәтле югарыга күтәрел дә күтәрел, аннан соң моторларны сүндереп, планир булып оч, цельне яктырт та бомбаларыңны ташла. Ә калганы инде бәхетеңә карый. Һәрхәлдә, прожекторлар самолетны эләктереп алганчы штурман бомбаларны ташлап өлгерә ала.

Ә бүген... Юк, Багеровоны бомбага тоту өчен җайлы төн түгел бүген! Кабинага утырганда минем штурманым Нина Реуцкая салкын тигәннән карлыккан тавышы белән:

— Кара әле, Наташа, ай калка! Җирдәге бар нәрсә безгә күренеп торыр,— диде.

— Безнең үзебезне дә җирдән бик шәп күрерләр,— дидем мин аңа каршы.— Күрәсеңме, болытлар ничек түбән йөзә?

Нина әле бик яшь штурман. Көтелмәгән җирдән килеп чыккан куркынычны сизеп алырлык тәҗрибәсе юк әле аның. Ул, гомумән, дөньяның яхшы ягын гына күрергә өйрәнгән. Миңа күп вакыт аның күңелен кайтарырга туры килә.

Минем җавабымнан соң ул бераз гына уйланып торды да сак кына сорап куйды:

— Багерово өстендә дә шундый ук төн булыр дип уйлыйсыңмы?!

— Әйе.

Ай нуры белән яктыртылган юка гына болытлар бергә кушылып якты пәрдә барлыкка китергән. Алты йөз метр гына биеклектә бөтен күк йөзен каплап ул әкрен генә йөзеп бара.

— Болытлардан түбәнрәк төшеп бомбага тотарга туры килерме икәнни? —дип куя тынгысыз Ниночка.

— Шуннан бүтән чара юк.

Бик түбәнгә төшеп якты болытлар фонында бомбага тотканда самолет экрандагы кебек күренеп торачак. Билгеле, Нина да моны яхшы белә. Ул күк йөзен тагын бер кат җентекләп карый һәм бераз дәшмичә утыра.

Минем штурманның башына күңелсез уйлар бик сирәк вакытта гына килә. Килсә дә бик аз вакытка гына. Берничә минут үтүгә ул инде ай һәм болытларны, зениткаларны онытып, берни дә булмагандай, ниндидер бер күңелле көй шыңшый башлый.

Дөрестән дә, ул хаклы: нигә дип вакытыннан алда борчылырга?

Нина полкка кырык өченче елны, без инде ел ярым сугышканнан соң килде. Аңарчы фронтта элемтәче булып эшләгән. Буе белән безнең кызларның барысыннан озын булса да, аңа әле унтугыз яшь тәтулмаган. Ул бик яшь, бик самими, аның бит алмалары чокырланып тора, нурлы күзләре бар нәрсәгә яратып, ышанып карый. Безнең барыбызның да сөйкемле кызны, балаларны иркәләгән кебек, иркәлисебез килә.

Ул беркайчан да төшенкелеккә бирелми, ачуланмый. Авырлыкны да, куркуны да белми ул.

Баштарак мин дөньяда явызлыкның, куркынычлыкның, бәхетсезлекнең барлыгын Нина белми әле дип уйлый идем. Соңыннан, мин аны яхшырак төшенә башлагач, иялэнгәч, аңладым, Нина бәхетле характер кешесе: теләсә нинди эшкә ул бик теләп һәм шатланып тотына. Нина, башка кызлар белән бергә махсус группада өйрәнеп, полкка килгәч кенә штурман булды. Ул бик кинәнеп оча һәм ни өчендер миңа, минем осталыгыма ышана иде. Мин үземнең көчемә алай ук ышанмасам да, штурманыма моны сиздерми идем.

Очарга чират җиткәч тә мин моторны кабыздым һәм, өч-дүрт минут та үтмәде, без Керчь бугазына таба юнәлеш алдык.

Алдыбызда диңгез ялтырап китте, караңгыланып яр буе сызыклары күренде. Бугазны үткәч тә Керчь ярым утравы башлана.

Фронт сызыгын без болытлардан югарырак очу өчен, шактый биеккә күтәрелеп, сигез йөз метрдан үттек.

— Артык югарыга менүнең зыяны юк,— дидем мин Нинага,— түбән төшәргә кайчан да өлгерербез.

Биредән, югарыдан, без немец прожекторларыннан көлеп барабыз. Болытлар астыннан шуып йөргән якты таплар аларның самолетны эләктерергә тырышуларын күрсәтә.

Менә түбән төшәр вакыт та җитте. Мин, моторларны сүндереп, биш йөз метрга кадәр төштем. Без болытлар астына килеп чыктык. Станция уч төбендәге кебек җәелеп ята. Тимер юл линиясе ай нурында ялтырап күренә. Таш йортларны, төрле якка киткән юлларны күрәбез. Цельгә барып җитәр өчен ике минут очарга кирәк. Биеклекне саклау өчен мин әкрен генә газны арттырам. Самолет борыны белән көпшәк болытларга бер кереп, тагын чыгып оча да оча.

Без бик күптән очабыз. Безнең «ПО-2» ай яктырткан болыт фонына килеп кергәч, мин үземне урамнан күлмәксез баргандай хис иттем.

Кайчандыр шундый төш күргән идем: күлмәк киярга онытканмын икән... Барысы да миңа карыйлар, ә качар урын юк, имеш.

Нина да үзен шундыйрак бер хәлдә сизде булса кирәк:

— Әйдә, тагын әз генә болыт эченнән очыйк әле,— диде ул.

Ә станция якынлаша да якынлаша. Хәзер безне күрәчәкләр. Хәер, анда, түбәндә, мотор тавышын ишетәләрдер дә инде. Якынрак килгәнне көтәләрдер. Бик чирканыч бер минут була: бөтен дөнья тын, җирдә дә тыныч, ут ачмыйлар, әмма белеп торасың, аермачык

ата башлаячаклар. Һәм син көтәсең: менә хәзер... тагы бер секунд... Юк, ике... Я инде, нигә акрынлыйлар соң!?

Тып-тыныч. Шундый тынлык, хәтта күнегеп беткән мотор тавышы да каядыр югала. Ләкин күз ачып йомганчы хәлнең үзгәрүе мөмкин. Андый минутларда туңып киткәндәй булам. Әйтерсең лә лайлалы, салкын бака йотканмын да, ул эчемдә үрмәләп йөри. Белеп торам — бака курку ул. Гап-гади курку. Хәзер башланачак зил-зиләдән шүрләү. Һәм үземә үзем ачуым килә. Белеп торам бит, алда көткән зил-зиләгә барыбер барып керәчәкмен.

Һәр вакыттагыча, прожекторлар кинәт кабындылар. Шулай буласын алдан белеп торсам да, сискәнеп киттем. Безнең самолетны эзләп тә торырга туры килмәде аларга, шунда ук эләктереп алдылар.

Нина яктырткыч бомба ташлады. Тагын берне. Алар һавада эленеп калдылар һәм гадәттән тыш якты булып китте. Юллардагы эшелоннар безгә бик ачык күренә. Прожекторларга әһәмият бирмичә, Нина бомба ташларга әзерләнә. Мин як-ягыма, прожекторларның көзгеләре ялтырап янган җир өстенә карамаска тырышып, цель өстендә очам.

Безнең «ПО-2» нурлар кисешкән җирдә, ә миңа курстан әз генә борылырга да ярамый. Юкса — бомбаның читкә төшүе бар. Кинәт мин бөтен җаным-тәнем белән шундый бер тойгы кичерәм: әйтерсең лә кемдер берәү каты бармаклары белән бугазымнан буып алган, ә минем каршы килергә мөмкинлегем юк...

Беренче зенитка шакылдады. Аның артыннан — тагын берсе. Снарядлар каядыр югарыда ярылдылар. Ләкин зенитчиклар хаталарын тиз төзәттеләр. Якты шартлаулар самолет янына ук килеп җитте. Нәкъ алдымда снаряд ярылгач, үзеннән үзе читкә борыласы килде, үлем белән күрәшү, нур тасмаларыннан ычкыну теләге туды!.. Бу теләктән котылуы шундый кыен. Секундлар... секундлар... Кайвакыт алар сәгатьләр кебек озын тоела.

Ниһаять, цель безнең аста. Самолет чайкалып куйды. Бомба ташлаганда шулай була.

— Булды,— диде Нина, һәм, гадәттәгечә, кабинадан яртылаш үрелеп җиргә карады. Мин, бомбасы артыннан үзе дә төшеп китмәгәе дип, гел куркам аннан.

Самолетны кинәт кыңгырайттым. Аста, станциядә шартлау күренде, дөрләп ялкын күтәрелде.

— Эләкте! — дип кычкырды Нина, карлыккан тавышы белән.

Ләкин мин нәрсәнең януын күреп өлгермәдем, карап торырлык вакыт юк. Самолет янында ук шартлап снарядлар ярыла. Әле бер якта, әле бер якта. Дары, төтен исе килә. Уйлар һаман бер тирәдә чуала: тизрәк китәргә, ут астыннан чыгарга... Самолетны бер яктан бер якка ташлап, снаряд тиюдән сакланырга телим. Аларның кай тирәдәрәк ярыласын чамалап, бөтен көчем белән тизлекне арттырам. Колакта җил сызгыра, самолетның калтыранганы сизелә, ләкин ул миңа һаман бер җирдә асылынып торадыр кебек тоела.

Баштарак Нина, тотлыга-тотлыга, самолетны ничек алып барырга кирәген әйтеп торды. Соңыннан тынып калды — файдасы юк иде.

Без төньякка, диңгезгә таба киттек. Фронт сызыгына караганда бу якка юл кыскарак, җил дә каршыга исми.

Зениткаларның һәр залпыннан самолет чайкалып куя. Йомарланып, кабинаның түренәрәк яшеренәсе килә. Ирексездән башымны түбән иям...

Артта утырган Нина да дәшми. Минем аңа сүз әйтергә дә вакытым юк. Кинәт ул бер-бер хәл булганга дәшмидер кебек тоелды. Куркуымнан мин сөйләшү трубкасына акырып җибәрдем:

— Нина! Нина!

— Нәрсә булды? Наташа, сиңа ни булды? — дип пышылдады ул, борчылып.

— Юк, берни дә юк,— дидем мин. Ул кычкырып тавышын бетергән, ахры, шуңа күрә дәшми утырадыр әле.

Самолет бик тиз генә түбән төшә башлады. Биеклекне югалту хисабына гына ут эченнән чыгарга мөмкин иде. Прибор 400 метрны күрсәтте... Аннан соң 300... 200...

Алда, бик якында гына, корыч шикелле ялтырап диңгез күренде. Без әкрен генә аңар якынлашып килəбез. Инде су өстенә төшеп җитә яздык, ә прожекторлар безне һаман ычкындырмыйлар. Инде зениткалар да атудан туктады. Инде самолет канаты астында ак башлы дулкыннар йөгерә башлады. Ә прожектор нурлары, әле һаман самолетны җибәрмичә, безнең белән түбәнгә төшкәннән-төшә барды. Нур тасмалары калкулык битләрен, яр буендагы берәм-сәрәм агачларны яктыртып, җиргә ук яттылар. Немецлар безнең суга төшкәнне көттеләр, ахры.

Ниһаять, нурлар сүнде. Нина белән без котылуыбызны аңладык.

— Я, кәефең ничек? — дип сорадым мин аннан.

— Нормально,— дип чырылдады ул. — Яссылыкка кара әле!

Мин түбәнге канатта ике зур тишек күрдем. Югарысы да үтә күренә. Лонжерон сынган. Перкаль кисәкләре байрак кебек җилфердәп тора.

— Зыян юк, кайтып җитәрбез,— дип әйтәм мин, тыныч күренергә тырышып. Ә үзем рульне әйләндереп карыйм. Юк, идарә итү аппараты бозылмаган, төзек эшли.

Мин самолетны ярга якынрак бордым һәм озакламый безнең аста үзәннәр, траншеялар белән яргаланып беткән Кырым җире йөгерә башлады. Каядыр шунда фронт сызыгы үтәргә тиеш.

Кинәт бөтен тәнем хәлсезләнде, тезем калтырый, аягым кабина идәнендә бии башлады. Аягымны педальдән алдым. Кулым белән тезләремне кысып карадым. Аннары сузып җибәрдем — һич ни ярдәм итми. Аякларым мине тыңламый, бииләр дә бииләр.

Күңелсез булып китте. Куркыныч хәлләр артта калды, без өйгә кайтып барабыз, нәрсә булды соң әле миңа? Һич тынычлана алмыйм. Ләкин Нинага берни дә әйтмим.

Шул вакыт аның карлыккан тавышын ишетәм:

— Наташа, әйдә кычкырабыз.

«Кычкырабыз» дигән сүз ул, газны киметеп түбәннән генә очып үтү һәм шул чакта җирдәге гаскәрләрне сәламләү. («Саумы, пехота!» — дип кычкыру, яки шуның кебегрәк берәр нәрсә әйтү). Очучыларның күбесе пехота кычкырганны ишетә дип ышана һәм, алгы сызыкта түбәнәеп, һәр вакыт «кычкырып» үтә. Нина белән без дә җае туры килгәндә шулай эшлибез.

Ләкин бу юлы минем бөтенләй «кычкырасым» килмәде. Хәтта Нинаның шаярамы, юкмы икәнен ачыкларга да теләгем юк иде. Һәм мин аңа ачуланып: «Үзең кычкыр, синең тавыш яхшырак ишетелер»,— дидем.

Шулай да аның тавышы мине кыен хәлдән чыгарды. Аякларым әкренләп тынычланды.

Бугаз өстендә болытлар юк иде инде. Диңгез суында ай юлы ялтырый. Аэродромга кадәр без чалт аяз күк йөзендә кайттык. Әкрен генә, тыныч кына йолдызлар җемелдәде.

Ерактан ук җирдәге утлар күренде. Берничә урында янган тонык кына утлар. Анда безне көтәләр. Анда безнең йортыбыз.

*«Безнең батарея сугышчылары» дигән китаптан.*

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

*1976 елның февралендә илебез һәм республикабыз җәмәгатьчелеге матур җырлаган батырыбыз — күренекле татар шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулу бәйрәмен билгеләп үтәчәк.*

*Юбилей уңае белән әзерләнәсе, оештырыласы һәм үткәреләсе чараларны башкару өчен КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы карары белән үткән ел республика комиссиясе оештырылды. Аның составында — иҗат оешмалары, культура һәм мәгариф министрлыклары, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан вузларының тел-әдәбият кафедралары, комсомол һәм профсоюз оешмалары, газета һәм журналлар вәкилләре. Юбилей комиссиясенең председателе — КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, председатель урынбасары — «Казан утлары» журналының баш редакторы, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре шагыйрь Зәки Нури.*

*Шагыйрьнең иҗат бәйрәменә аның әсәрләренең яңа басмаларын шактый күпләп чыгару күздә тотыла. Татарстан китап нәшриятында, мәсәлән, татар телендә 4, рус телендә 1 томлы җыелма һәм «Моабит дәфтәре»нең бүләк өчен художестволы итеп эшләнгән махсус басмасы, Муса Җәлилнең публицистика китабы, Муса Җәлил сүзләренә язылган җырлар альбомы һәм геройның тормышы белән иҗатына багышланган фотоальбом чыгарылачак. Аерым китаплар итеп Муса Җәлилнең СССР халыклары телләренә тәрҗемә ителгән бер шигыре тупланмасы, шагыйрь турында истәлекләр һәм аның балалар өчен язылган яки балаларга багышланган шигырьләре һәм поэмалары әзерләнә.*

*Күп тираж белән чыгарырга шагыйрьнең фотопортретын эшлиләр, ә кино осталарыбыз аның турында ике бүлекле документаль фильм булдырачак. Шәйхи Маннурның «Муса» дигән романы Казанда татар телендә, Җәлилнең үз китаплары рус телендә Мәскәүдәге «Художественная литература», «Советская Россия», «Современник», «Молодая гвардия», «Детская литература», «Малыш» һ. б. нәшриятларда чыгарга тиеш. «Дөнья халыклары Җәлил турында» дигән җыентык эшләү Татарстан китап нәшрияты белән Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтына, Җәлил шигырьләрен рус һәм татар телендә грампластинкаларга яздыру, республикабыз театрлары сәхнәсендә «Үлемсез җыр», «Муса», «Алтынчәч» һәм «Җәлил» спектакльләрен яңадан әзерләп куйдыру Культура министрлыгына тапшырылды. Дәүләт һәм сәнгать музейларыбыз юбилей күргәзмәләре оештыра, элемтәчеләр Җәлилгә багышланган конвертлар, открыткалар һәм маркалар бастыра, Художниклар союзы шагыйрьнең яңа бюстен эшли һәм күп санда чыгарта. Опера һәм балет театры бинасында бер бүлмә Муса Җәлил музее ителәчәк. Бәйрәмнең йомгак өлеше иттереп Казанда фәнни-теоретик конференция, Казанда һәм Мәскәүдә тантаналы җыелышлар, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, авыл һәм шәһәр клублары белән культура сарайларында әдәби кичәләр, укучыларның әдипләр белән очрашулары уздырылачак.*

# ҖӘЛИЛНЕҢ «ХӨСӘЕНИЯ» ЧОРЫ

Сөекле шагыйребез Муса Җәлил белән, аның зур иҗат мирасы, бай тормыш юлы белән күпләр кызыксына. Нәтиҗәсе күз алдында: аңа багышлап язылган әдәбият-сәнгать әсәрләре, фәнни-популяр китаплар һәм гыйльми хезмәтләр санап бетергесез. Шулай булуга да карамастан, шагыйрьнең тормыш юлына караган материалларда әледән-әле төрле характердагы төгәлсезлекләр очрап тора.

Моннан ун еллар элек, Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулу уңае белән, Оренбург шәһәрендәге «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасына истәлек тактасы куелды. Мәрмәр тактага түбәндәге сүзләр язылган: «В этом здании в 1918—19 гг. учился Муса Джалиль, известный татарский поэт, Герой Советского Союза, Лауреат ленинской премии».

Инде шул ук елларда Татарстан китап нәшрияты чыгарган альбомга мөрәҗәгать итик. Альбомның 17 нче битендә шул ук бина рәсеме. Рәсем астында аңлатма язуы: «Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе, революциядән соң Татар халык мәгариф институты. Муса анда 1913 елдан 1922 елга кадәр укый».

Боларның кайсы дөрес, бу даталарның кайсына ышанырга? Шул мәсьәләгә ачыклык кертү максаты белән, без Оренбург дәүләт архивындагы материалларны тикшереп чыктык. Архив материаллары арасыннан 1912—17 елларда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыган шәкертләрнең исемлеге табылды. (Оренбург өлкәсенең дәүләт архивы. 213 фонд. 1 тасвирлама. 30 эш. 16, 21, 24 битләр.) Архив кәгазьләренә караганда, Муса Җәлил бу бинада 1914 елдан алып 1923 елга кадәр укыган булырга тиеш.

1914—15 уку елында ул башлангыч мәктәпнең III классында, 1915—16 уку елында башлангыч мәктәпнең IV классында, ә 1916—17 уку елында урта мәктәпнең 1 классында укый. Укыган өчен акча түләми, урта мәктәптә укыганда гомуми торакта яши. (Шунда ук, 57 эш. 222 бит.)

Бөек Октябрь революциясеннән соң «Хөсәения» мәдрәсәсе Татар халык мәгариф институтына (ТИНО) әйләндерелә. 1919—23 елларга караган документларда Муса Җәлил исеме еш очрый. Документлардан күренгәнчә, 1921—22 уку елында ул күп авырый. Шуңа карамастан, барлык фәннәрдән диярлек яхшы билгеләр алып бара. (Шунда ук, Р-470. 1 тасвирлама. 4 эш. 52 бит.) Муса дәрестән тыш күп укый, бик күп мәсьәләләр белән кызыксына. Архивта Муса Җәлил укыган китаплар исемлеге (Шунда ук, 213 фонд. 1 тасвирлама. 40 эш. 344 һәм 66 битләр.) саклана. Ул укыган әсәрләр арасында «Фәнни фокуслар», «Америка фикерләре», «Умарталыкта», «Надан ата», «Ярлылар», «Кошлар хакында», «Явызлыкның җәзасы», «Ибтидаи мәктәптә кул эшләре» исемле китаплар, «Шура» журналы һәм башкалар бар.

Муса Җәлил исеме очраган документларның соңгысы 1922—23 уку елына карый. Институтта укучы студентлар исемлегенә ул 93 нче кеше булып теркәлгән. (Оренбург өлкәсенең дәүләт архивы. 213 эш. 1 тасвирлама. 57 эш. 160 бит.) Димәк, 1922—23 уку елында шагыйрь әле Оренбургта булган. Муса Җәлил хакында язылачак хезмәтләрдә югарыда китерелгән мәгълүматлар искә алынып дип ышанасы килә.

**Мәдинә РӘХИМКУЛОВА,**
**Оренбург.**

# ҮЛЕМСЕЗ ДУСЛЫК

**Муса Җәлил һәм Павло Тычина... Исемнәре дә, сокландыргыч иҗатлары да миллионнарга яхшы таныш булган бу ике шагыйрь — ватандашлар, фикердәшләр генә түгел, якын каләмдәш дуслар да. Алар калдырган иҗат мирасы күп яклары белән аеруча аһәңдәш, рухи яңгырашлары белән күп җәһәттән уртак.**

**Журналыбызның бу санында без украин шагыйре П. Тычина иҗатын тикшеренүчеләрдән берсе, Киев дәүләт университеты аспиранты Иван Ильенконың ике зур шагыйрь арасындагы шушы иҗади дуслык турында язылган мәкаләсен урнаштырабыз. Автор Павло Тычинаның Муса Җәлил турында татар укучысына бик үк билгеле булмаган язмалары белән таныштыра.**

Павло Тычина белән Муса Җәлилнең дуслыгы хакында шактый язылды. Украин һәм татар халыклары арасындагы рухи туганлыкның мәңге җуелмас сәхифәсе ул.

1970 елда Павло Тычинаның әдәби мирасыннан «Күңелемдә минем» дигән җыентык басылып чыкты. Анда «Муса Җәлилгә» һәм «Муса Җәлил Киевтә» (1939) дигән ике бик матур шигырь урнаштырылган. Һәр ике шигырь 1966 елда, әдипнең инде каты сырхаулаган һәм әҗәленә бер ел калган көннәрдә язылган. Ул әйтерсең дусты каршында үзенең соңгы бурычын үтәп калырга ашыккан...

1966 елның февралендә Украина язучылар союзы Муса Җәлилнең тууына 60 ел тулуга багышланган кичә үткәрә. Павло Тычина кичәне кереш сүз белән ача. Кызганычка каршы, бу дулкынландыргыч чыгышның кулъязма тексты тулы килеш сакланмаган. Билгеле өлеше «Прометей туганы» дигән исем астында П. Тычинаның «Үткәннән — киләчәккә» (Киев, 1973 ел) исемле китабында басылып чыкты.

«Җәлилне талантлы татар халкы тудырган, үзенең чын-чыннан баһадир улы белән ул хаклы рәвештә горурлана, аны чиксез ярата,— дип башлый Тычина сүзне.— Әмма, шуның белән бергә, Советлар Союзының барлык халыклары — руслар, украиннар, белоруслар, латышлар һәм башкалар да Мусаны туганыбыз, кадерлебез һәм сөеклебез дип атыйлар...»

Муса Җәлил исеме украин халкы күңеленә утә якын булуын билгеләп үткәннән соң, шагыйрь 1939 елны Шевченкога багышлап үткәрелгән Бөтенсоюз пленумында аның белән очрашуларын хәтеренә төшерә, Җәлилнең бөек Кобзарь иҗатына карата зур мәхәббәт саклаганлыгын әйтә. Украинада Муса Җәлилнең «Шевченкодан өйрәник» дигән чыгышын яхшы хәтерлиләр. Татар шагыйре ул чак барлык язучыларны Шевченкодан халыкчанлыкка һәм осталыкка өйрәнергә, «җиңеп чыккан батыр халык турында аның кебек үк талантлы әсәрләр тудырырга» чакырды. Тычина да 1939 елда язган «Кеше хакына» дигән шигырендә шундый ук чакыру ташлый.

**Тарасның күкрәүле тавышы кирәк**
**безнең көнне данлау өчен һәр тарафта.**

Үзенең чыгышында Тычина Муса Җәлилнең Украинага багышланган «Туганлык» шигырен рәхмәт хисе белән искә ала. Шигырьдәге менә бу юлларны аерым билгеләп үтә:

**Татарстан — синең туган энең,**
**Дуслык антын эштә ныгытты.**
**Йортсыз калган ятим улларыңны**
**Кайнар кочагында җылытты.**

**Ул чакырды батыр егетләрен**
**Синең кырлар буйлап үтәргә.**
**Һәм, дошманны куып Днепрдан,**
**Туганнарны азат итәргә.**

«Муса Җәлил — чын-чыннан Прометей туганы,— дип дәвам итә Тычина.— Ул безнең ватандашларыбызның азатлыгы һәм бәхете өчен генә түгел, илебез чикләренең тышында фашист коллыгы астында калган барлык кешеләрне яклап көрәште. Мусаның үлемсез батырлыгын Европадагы алдынгы кешеләр тагын да киңрәк бәялиләр». Һәм автор шунда ук Луи Арагонның сүзләрен, «Правда» газетасы биргән бәяне китерә. Аларда бу батырлыкның интернациональ характерда булуы, дөнья күләмендәге яңгырашы күрсәтелә.

Чыгышының ахырында Тычина, «барыбыз өчен дә кадерле батыр ир Муса Җәлил шигыреннән батырлык аңкып торган юлларны» укый.

**Мин ант иттем җанны кызганмаска,**
**Саклар өчен халкым, илемне.**
**Йөзәү булса гомрең, син барсын да**
**Шушы юлга бирмәс идеңме?**

«Бөек шагыйрьгә нинди сыйфатлар хас? — дип сорый Тычина.— Бу аның уй-теләкләренең һәм кылган эшләренең бер булуы. Тормышы һәм иҗатының берлеге».

Шундый шагыйрьнең тормышы, иҗаты куркусызлыкка, фидакарьлеккә, тугрылыкка өйрәтә — аның васыяте бу, ди Тычина.

Украин шагыйренең архивында Муса Җәлилгә Ленин премиясе бирелү уңае белән махсус язылган һәм матбугатка әзерләнгән бер мәкалә бар. Ул тикшеренүчеләргә әлек билгеле булмаган күп кенә нәрсәләрне, мәсәлән, П. Тычинаның татар шагыйре белән ничек танышуын ачыкларга ярдәм итә.

«Аны мин күптән белә идем,— дип яза Тычина,— тик йөзгә-йөз очрашулар бик кыска була иде. 30 нчы елларда ук аның иҗатын игътибар белән күзәтеп бардым (Татарстан республикасыннан даими төстә газета һәм журналлар алдыра идем), ә тиздән миңа матбугат аша аның украин классиклары әсәрләрен тәрҗемә итүе һәм «Совет әдәбияты» журналында бастыруы мәгълүм булды, гениаль украин җырчысының[1] тууына 125 ел тулу уңае белән чыккан җыентыкларда Җәлилнең актив катнашуы да мәгълүм».

Мәкаләдән күренүенчә, Тычина Муса Җәлил шигырьләре урнаштырылган журналларны һәм шулай ук Мусаның аңа кешеләр аша биргән бер запискасын саклаган. Кызганычка каршы, шагыйрьнең китапханәсе һәм архивы оккупация вакытында Киевтә калып һәлак булганнар. Бары 1930 елны Мәскәүдә татар телендә чыккан «Сигнал» исемле бер җыентык кына исән калган. Анда М. Җәлилнең Ленин турындагы мәгълүм шигыре дә бар.

Үлем көткән хәтәр сәгатьләрдә дә аны искә алган Муса Җәлил каршында Тычина үзен гаять бурычлы сизә. Әлеге мәкаләсендә ул: «Бу хакта аның хатынының мәкаләсеннән укыгач, минем җаным тетрәнде»,— ди.

«Муса Җәлилнең шундый зур игътибарын мин ни белән казандым? — дип сорый шагыйрь.— Моны нәрсә белән аңлатырга? Мөгаен, тик бер генә нәрсә: халыклар арасындагы ленинчыл дуслык хисләре, украин халкына туганнарча мәхәббәт белән аңлатырга мөмкин. Муса Җәлил үзе дә «Туганлык» дип аталган фронт шигырендә шушы хакта сөйли».

Шагыйрь мәкаләсендә шигырьнең соңгы юлларын китерә:

**Бер ананың туган балалары —**
**Ташкын булып бергә кузгалдык.**
**Һичкайчан да, һичбер көч алдында**
**Җиңелмәс бу изге туганлык.**

«Нинди канатлы сүзләр бу! Агрессорлар Көнбатышта яңа сугыш башларга хыялланган бер вакытта Муса Җәлилнең бу сүзләрен туктаусыз кабатлыйсы килә: «Җиңелмәс бу изге туганлык»,— дип тәмамлый мәкаләсен П. Тычина.

...Павло Тычинаның китапханәсе. Түрдә — Муса Җәлил портреты, янәшәдә аның китаплары. Шуларның берсендә (М. Җәлил. «Сайланма әсәрләр». Мәскәү. 1955 ел.) Тычина каләме белән билгеләп куелган, украин туганының исеме телгә алынып, көрәшче шагыйрьнең соңгы теләге күндерелгән сүзләр бар... Хәтергә берьюлы «Муса Җәлилгә» шигырендәге мәңгә бу ихлас күңелдән язылган юллар килә:

**Син текәлеп карадың**
**украин күзләремә минем...**
**Ә мин исә —**
**татар күзләреңә синең...**
**Шулай очраштык без**
**беренче кат, иптәш, синең белән...**

[1] Сүз Т. Г. Шевченко хакында бара.— Ред.

Һәм шушы да инде
    синең өчен җиткән,
Искә алыр өчен мине
    хәтәр бер чакта,
Менә-менә Моабитта
    үлем сине
    егар вакытта...

(Сүзгә-сүз тәрҗемә.)

Татар дусты, шагыйрь һәм сугышчы Муса Җәлил хакында Павло Григорьевич күп нәрсәне әйтергә өлгермәде. Ләкин әйтелгән кадәресе дә аның Муса Җәлилне чын күңелдән яратуы, аның иҗатын, тормыш батырлыгын югары бәяләве хакында сөйли.

Иван **ИЛЬЕНКО**,
Киев шәһәре.

# ШАГЫЙРЬ ТОРМЫШЫННАН БЕР СӘХИФӘ

Муса Җәлил хакында басылган хезмәтләрдән билгеле булганча, 1925—26 елларда шагыйрь Оренбург губернасының комсомол органнарында эшли. Аның бу чордагы тормышы һәм эшчәнлегенә караган мәгълүматлар әлегә күп түгел. Шуңа күрә Оренбург дәүләт архивыннан шагыйрьнең үз кулы белән язылган һәм аның шушы чор тормыш-яшәешенә кагылышлы хат табылуы һәркемдә дә кызыксыну уятмый калмас дип уйлыйбыз. Ул 1926 елның июнендә язылган.

Башта шагыйрь турындагы билгеле мәгълүматларга мөрәҗәгать итик. Рабфакны тәмамлагач, ВУЗга киткәнгә кадәр «белемне тормышка ялгау», практик тормыш тәҗрибәсен баету максатыннан ул бер елга отпуск ала. Туган авылы Мостафага кайтып, анда комсомол ячейкасының секретаре булып эшли. Тиздән комсомолның губерна комитеты аны Орск өяз комитетына инструктор итеп билгели. Соңрак ул комсомолның губерна комитеты члены булып та сайлана. 1926 елны Муса Җәлил партия сафына кандидат итеп алына. Актив җәмәгать эшчәнлеге белән бер үк вакытта, ул Казан, Мәскәү шәһәрләренең әдәби тормышы белән кызыксына, бигрәк тә матбугат органнары белән элемтәне өзмәскә тырыша, газета-журналларны күзәтеп бара, шигырьләрен җибәрә, хатлар яза.

Әмма шулай да бу чорда Муса Җәлилнең әдәби иҗат өчен вакыты тар була. Ул бөтен күңеле белән комсомол эшенә бирелә. Аның фидакарьлеге һәм кайнап торган энергиясе гаҗәпкә калдыра. Кави Нәҗмигә җибәргән бер хатында эше турында ул болай яза:

«Күптән инде юньле бер нәрсә дә язганым юк югын. Юк, вообще, язу өстендә утыра алганым юк. Өяздә йөрим. Бер-бер артлы әле губерна, әле өяз конференция, съезд, киңәшмәләргә чабам».

Җилгә-буранга карамый, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында Муса юлда була. Авылларда ул комсомоллар белән төрле оештыру эшләре үткәрә, пропаганда һәм агитацияне җәйга салырга булыша, өяздә пионерлар хәрәкәтен оештыруга да ярдәм итә. Шунысын да искәртеп үтик: үз вакытында «Мостафа авылы балалар оешмасы»н төзегән, авылында комсомол ячейкасы оештырып, аның секретаре һәм комсомолның волость комитеты члены булган, төрле кичәләр һәм лекцияләр, спектакльләр үткәргән, язма газета һәм журналлар чыгарган Муса Җәлил бу чорда, комсомол эшлеклесе буларак, шактый тәҗрибә туплап өлгерә. Азчылык милләтләр арасында эшләүче инструктор Муса яшьләрне халыклар дуслыгы рухында тәрбияләүгә күп көч куя.

Һәм менә шундый көннәрнең берсендә РКП(б) Орск өяз комитеты һәм өяз советы башкарма комитетының «Известия...» газетасында (1926 ел, 6 июнь саны) Муса Җәлилгә кагылышлы көтелмәгән бер кечкенә генә хәбәр басылып чыга. «Руль» дигән псевдоним белән язучы автор анда Җәлилне кыргыз авылларының берсенә (дөресе — казакъ.— М. М.) «пионерлар өчен китаплар, кулланмалар, кызыл галстуклар»

җибәрергә вәгъдә итеп тә, әлегә кадәр сүзендә тормауда гаепли. Автор үзе шул ук вакытта мәсьәләне ачыклап бетерми, «Муса Җәлилов дигән кеше»-нең бу авылга килгән аен да, анда ничә тапкыр булуын да ялгыш күрсәтә.

Өяз газетасында үзенә мондый урынсыз «гаеп» ташлауны Муса Җәлил җавапсыз калдыра алмый һәм тиздән редакциягә М. Җәлиловтән менә шундый хат алына.

«Известия» газетасы редакторына ачык хат. Ип. «Рульгә» җавап.

Беренчедән, Орск волостеның дүртенче авылына уку елының башында түгел, ә ахырында — март аенда чыгылды. Һәм бер генә түгел, ә ике тапкыр; һәр ике очракта да авылда балалар хәрәкәтенең торышы хакында балалар түгәрәге җитәкчесе һәм комсомоллар белән әңгәмә үткәрелде.

Икенчедән, дүртенче авылда бернинди пионер отряды һәм пионерлар юк, ә 1926 елның мартында мәктәп һәм ВЛКСМ ячейкасы каршында тик балалар түгәрәге генә оештырылган иде. Аны оештыруның максаты, кыргыз балаларын ВЛКСМ ячейкасының турыдан-туры җитәкчелегендә акрынлап әзерли торып һәм пионер рухында тәрбияләп, соңрак пионер отряды итеп үстерү. Ә әлегә исә алар, әзерләмәгән, пионер итеп теркәмәгән һәм тантаналы ант бирмәгән килеш, пионерлар булып исәпләнмиләр.

Димәк ки, без галстуклар вәгъдә итә дә, бирә дә алмыйбыз.

Инструктаж ясаганда, «вәгъдә» дигән метод бездә кулланылмый, ә хәлне ачыклаганнан соң практик күрсәтмәләр бирелә. Бу түгәрәк белән дә эш шулай булды. Галстуклар вәгъдә ителмәде. пионерлар кемнәр алар, аларның үзләре арасындагы закон һәм гадәтләре, салют бирүнең, галстукның h. б. ның әһәмияте дигән темага җитәкче тарафыннан әңгәмә үткәрелде.

Түгәрәккә ана телендә үрнәк планнар, эш формалары тәкъдим ителде. Берничә тапкыр иптәшләрчә хатлар яздык. Яшь пионерларның өяз бюросы азчылык милләт пионер хезмәтчәннәренең көче белән бу түгәрәкнең эшен ана телендә алып барырга ниятли.

Кыргызча (монда казакъ теле күздә тотыла — М. М.) пионер әдәбияты бөтенләй юк. Шулай булса да, Укомол югары органнар аша кыргыз телендә мөмкин кадәр әдәбият юнәтүне үтенә. Һәм КСМ ячейкасына бу хакта шулай дип әйтелгән иде дә.

Әнә шуңа күрә, «Руль» иптәш, корреспонденцияләрне түшәмнән йолкырга ярамый, ә язарга тотынганчы фактлар һәм чынбарлык белән нигезләргә кирәк.

**Җәлилов».**

«Шушы җавап хәбәрен газетада урнаштыруларын үтенеп», Муса Җәлил редакциягә мөрәҗәгать итә һәм ВЛКСМның Орск Укомы азчылык милләтләр буенча инструкторы Җәлилов Муса, К. Маркс урамы, 16 нчы йорт дип имзасын һәм адресын куя.

Хат Оренбург өлкә архивының әлеге газета редакциясе фондында саклана [1].

Муса Җәлилнең бу автографы шактый әһәмияткә ия. Чөнки ул шагыйрь биографиясенең аз өйрәнелгән чорына карый, казакъ балалары арасында пионер отрядлары оештыру, аларны интернациональ рухта тәрбияләү буенча ул башкарган эшнең конкрет бер сәхифәсен ачыкта. Шушы кечкенә язмада да без Мусада чын күңелдән инанган интернационалист сыйфатларын күрәбез.

Дүртенче номерлы авыл хәзер Оренбург өлкәсенең Яңа Орск районы, Тукай авыл советы карамагына керә. Оренбург якларында тату бер семья булып илебезнең барлык милләт вәкилләре диярлек яши һәм эшли. Бу дуслыкның нигезләрен коруда шагыйрь Муса Җәлилнең дә өлеше бар.

**Майя МОХТАРОВА,**
**Оренбург шәһәре.**

---

[1] ГАОО, ф. 496, оп. 1, д. 75, л. 118—118 об.

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре кандидаты

# КАЮМ НАСЫЙРИ ИҖАТЫНДА МОРАЛЬ-ЭТИК МӘСЬӘЛӘЛӘР

Энциклопедист галим буларак, Каюм Насыйри — татар культурасы һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган кеше. Аны фәлсәфи-сәяси мәсьәләләр дә, гыйльми-педагогик, әдәби-эстетик һәм мораль-этик мәсьәләләр дә якыннан кызыксындырган. Алай гына да түгел, шуларның һәркайсы буенча ул тирән фикерле әсәрләр язган. Шуның белән бергә, мәгърифәтченең бай һәм күпкырлы иҗат мирасында әдәп, әхлак мәсьәләләре иң күренекле урынны алып тора. Аның «Тәрбия китабы», «Әхлак рисаләсе», «Әхлак рисаләсе вә һәм фөруз мәгътәкадәт рисаләсе» һәм «Тәрбия» кебек хезмәтләре турыдан-туры шул мәсьәләләргә багышланган. «Фәвакиһел-җөласә» һәм «Кырык бакча» исемле китапларында әхлак мәсьәләләре үзәк урынны били. Әлеге мәсьәләләр мәгърифәтченең башка хезмәтләрендә һәм ел саен чыгарып килгән календарьларында да кузгатыла. Әхлакның төп нигезләре, кешеләрнең тәртип нормалары һәм принциплары, җәмгыять тормышы кагыйдәләре кебек мәсьәләләр аларда төрле яктан килеп карала.

К. Насыйриның әдәп һәм әхлак мәсьәләренә булган мөнәсәбәте аның иҗтимагый яңарыш һәм шәхес кебек мәсьәләләргә мәгърифәтчелек позицияләреннән торып якын килүе белән билгеләнә. К. Насыйри фикеренчә, торгынлыктан һәм арталыктан котылу, яңарышка һәм алдынгы культура казанышларына тартылу, кеше шәхесенең чәчәк атуына ирешү, аны караңгылыктан һәм кыргыйлыктан коткару өчен, мәгариф эшен үстерү һәм фәнни белемнәрне тарату белән бергә, кешеләрне әхлак ягыннан камилләштерергә һәм мораль-этик мөнәсәбәтләр өлкәсендә урта гасырлардан калган «йөктән» азат итәргә кирәк. Галим, әхлаклылык җәмгыять тормышына көчле йогынты ясый һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыта, дип саный. Ул, җенси мәхәббәттән алып иҗтимагый-политик эшчәнлеккә кадәр, кешеләр тормышының барлык өлкәләренә кагыла һәм җәмгыять, халык, Ватан бәхете хакына аларны яхшы эшләргә оештыручы фактор ролен үти. Әгәр сәламәт әхлак кешеләрне югары күтәрә һәм яңарыш эшенә булыша икән, бозыклыклар кайгы һәм хәсрәтләрнең бер сәбәбе булып торалар, гаделсезлек, власть изаләренең изүе һәм башбаштаклыгы өчен уңдырышлы туфрак ролен үтиләр. Рас шулай икән, әхлакый камиллек, кешеләрне бозыклыклардан коткару котылгысыз төстә җәмгыятьнең сәламәтләнүенә, иҗтимагый явызлык һәм гаделсезлек күренешләрен җиңәргә булыша.

Иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә мәгърифәтчелек күзлегеннән карау К. Насыйриның әхлакның табигатен һәм чыганакларын, әхлакый таләпләрнең эчтәлеген һәм аларның җәмгыять тормышындагы әһәмиятен аңлавына да мәгълүм бер эз сала. Шуның белән бергә, ул диннең әхлак нормалары алла тарафыннан иңдерелгән диган күрсәтмәсен читләтеп уза. Дөрес, аңарда дини моральне турыдан-туры тәнкыйтьләү

юк диярга мөмкин. Әмма, үзенең әхлакый карашларын аңлаткан чагында, К. Насыйри алланы да, динне дә исәпкә кертми һәм тулысыча дөньяви мораль тудыра. Өстәвенә, әхлакның реаль нигезләрен эзләгәндә ул кешенең үзенә һәм аның табигате белән бәйле көчләргә мөрәҗәгать итә. К. Насыйри карашынча, кеше башкарган һәм яхшы, һәм начар эшләрнең нигезендә нәкъ әнә шул көчләр ята. Аныңча, кеше табигатенә ике төрле көч хас. Аларның берсе — танып белгеч-фикерләткеч көч; икенчесе — хәрәкәтләндергеч-уяткыч көч. Үз чиратларында әлеге көчләр тагын ике тармакка: беренчесе теоретик һәм практик, ә икенчесе хисси һәм ачу-ярсу тармакларына бүленә. Кеше эшчәнлегенең нигезендә әнә шул көчләр ята һәм ул башкарган яхшы эшләрне дә, начарларын да шул көчләр китереп чыгара. «Вә дүрт куәт адәмнең бәдәнендә эш кылучы булып,— ди мәгърифәтче,— ничә төрле фигыльләр содурына сәбәп булырлар» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. Казан. 1884 ел. 412 бит). Шулай, теоретик көч эшенең нормаль нәтиҗәсе зирәклек кебек яхшылык булыр, практик көчнеке — гаделлек, хисси көчнеке — намуслылык һәм әхлакый чисталык, ачулы көчнеке тәвәккәллек һәм батырлык булыр. Әмма бу көчләрнең хәрәкәте нормадан узып китәргә дә, я булмаса нормага килеп җитмәскә дә мөмкин. Мондый очракларда кешедәге асыл көчләрнең хәрәкәтен начар фигыльләр билгеләячәк. Әйтик, теоретик көчнең нормадан артып китүе хәйләкәрлекне, ә нормага килеп җитмәве аңгыралыкны, ахмаклыкны белдерәчәк; хисси көчнеке — җенси бозыклыкны яки ваемсызлыкны; ярсулы көчнеке — тотнаксызлыкны яки куркаклыкны; практик көчнеке теге очракта да, бу очракта да гаделсезлекне белгертәчәк.

Өстәвенә, кешенең төп көчләре тарафыннан кузгатылган (тудырылган) фигыльләрнең характеры аларны сайлаганда кешенең акыл белән эш иткәнме, юкмы икәнлегенә бәйләнгән. К. Насыйри этикасында акыл фигыльләргә мөнәсәбәттә хәлиткеч урынны били. Акыл һәм гыйлем нәтиҗәсе булган фигыльләр генә югары әхлаклы була. «Гакыл, — ди К. Насыйри, — адәмнең бәдәнендә падишаһ мәнзиләндә вә адәмнең күркәм фигыльләре вә күркәм холыклары рәгыйять мәнзилендәдер. Әгәр гакылда зәгыйфь пәйда булса, күркәм фигыльләргә хәләл хасил булыр» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 61 бит). К. Насыйриның акыл һәм әхлакның бердәмлеге турындагы фикерләрендә үзенең башлангычын Әл-Фараби мирасыннан ала торган идеяләрнең йогынтысы сизелә. Әлеге борынгы фикер иясенең философиясендә әхлак аерылгысыз төстә акыл белән бәйләнгән һәм акылның аерылмас бер өлеше буларак алга баса. Үзенең акылы аркасында яхшыны яманнан аера ала, беренчесен хуп күреп, икенчесеннән тайпылып кала торган кеше яхшы санала, ди ул. «Зирәклеге өстенә акыллы да булган, шуның өстенә ул зирәклеген яхшы фигыльләр башкарганда куллана да белгән кеше, — дип яза Әл-Фараби, — акыллы санала» («Вопросы философии» журналы. 1970 ел. 8 сан. 137 бит).

Тикшерә торган мәсьәләгә К. Насыйри да нәкъ шулай якын килә: югары әхлаклылык кешенең акылы һәм зирәклеге хакында сөйләүче күрсәткеч булып тора. «Гакыйл шулдыр, — ди ул, — үзенең гакылыннан наши холыкны иршаддә вә дираятеннән наши холыкка имдаддә булып, сүзе тугры вә фигыле күркәм булган кешедер» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 62 бит). Әгәр акыл һәм гыйлем күркәм фигыльләрнең һәм гүзәл омтылышларның чыганагы булып торса, наданлык исә бозыклык һәм әдәпсез эшләргә сәбәпче була. «Җаһил шул кешедер ки, — дип яза мәгърифәтче, — сүзендә күп ялган вә буш сүзләр вә тәгамендә миннәт вә сәләмендә саранлык вә итагатендә ялкаулык һәм итагатьсезлек булып, халыкка фахиш сүзләр белән хитаб кылып, золым вә тәгадди кылган кешедер» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 380 бит).

Кешенең табигатен һәм акылын әхлакның төп нигезе һәм чыганагы дип санау, билгеле, фәннилектән ерак тора. Кешенең үзен, аның төп көчләренең формалашуын һәм әхлакның нигезен иҗтимагый тормыш билгели. К. Насыйри бу хакыйкатьне аңлауга кадәр күтәрелеп җитми, шуңа күрә әхлакның табигатен, аның җәмгать тормышындагы урынын һәм әһәмиятен дөрес аңлата алмый. Шуңа да карамастан, ул әхлакның реаль, табигый нигезләрен эзли һәм этика мәсьәләләрен дини аң тәэсиреннән азат итүдә мөһим адым ясый. Диннән аермалы буларак, моральнең нигезенә ул алланы түгел, кешенең үзен, аның төп көчләрен куя. К. Насыйри мораль һәм акылның бердәмлеге идеясен күтәреп чыга, әхлак кануннары алла тарафыннан түгел, ә гыйлем, кеше интеллекты тарафыннан билгеләнә, ди. Аның бу фикерләре татар этик фикере-

нең мөһим казанышы булып исәпләнергә тиеш. Моның белән мәгърифәтче фәлсәфи-этик фикернең Б. Спиноза, Н. Г. Чернышевский кебек күренекле вәкилләре тарафыннан алга сөрелгән позицияләренә баса. Мәгълүм булганча, боларның этикасы гыйлемгә, интеллектның үсешенә нигезләнгән булган. «Яхшылык һәм акыллылык, — дип яза, мәсәлән, Н. Г. Чернышевский, — асылда бер мәгънәдәге терминнар. Бу бер үк фактларның бер үк сыйфаты» (Н. Г. Чернышевский. Полное собрание сочинений. Рус телендә. 14 том. 645 бит). Яхшы фигыльләр Б. Спиноза өчен дә, Н. Г. Чернышевский өчен дә бер үк вакытта акыллы, ә начарлары акылсыз саналган. Күргәнебезчә, К. Насыйри да шул ук позицияләрне яклап чыга.

Акылны, интеллектны моральнең нигезе төсендә күтәреп чыгу этик тәгълиматлар тарихында дин башлыкларының язмыш турындагы өйрәтмәләренә каршы көрәштә мөһим роль уйный. Татар иҗтимагый фикере тарихында да ул шул ук функцияне башкара. Мөселман динендә ,бигрәк тә суфичылык тәгълиматында, язмыш турындагы өйрәтмәләр төп урынны алып торган. Акыл һәм гыйлемне моральнең нигезе дип күтәрү белән, К. Насыйри мораль-этик мәсьәләләрне чишкәндә мөселман дине басымыннан котылу өчен мөһим таяныч булдыра. Рационализм принципларына таянып, ул кеше фигыльләренең характеры тәкъдир язмышына түгел, ә кешеләрнең акылына һәм никадәр белемле булуларына, димәк ки, аңлы чараларга бәйле диган нәтиҗәгә килә. Кешеләр бозык фигыльләрне тәкъдир кушканга түгел, томана булулары, яхшыны яманнан аера алмаулары аркасында эшлиләр. Гыйлем — кешегә бозыклыклардан арынырга ярдәм итә. Акыллары ярдәмендә, фәнни танып-белү юлы белән, алар үз фигыльләре белән идарә итә һәм үз-үзләрен тотуның әдәпле юлын сайлый алалар. Белемле булулары аркасында алар үз фигыльләренең нинди нәтиҗәләргә китерәчәген алдан күрәләр, ә «эшнең ахырын фикер кылмак вә ахырына нәзар кылмак нәҗатка сәбәп вә василәдер» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөлӘсә. 21 бит). Үтә мөһим мәсьәләне никадәр генә беркатлы аңлатмасын, бу фикернең үз заманы өчен әһәмияте бәхәссез.

К. Насыйри этикасы гуманизм хисе, кеше шәхесенең намусы һәм дәрәҗәсе өчен тирәнтен кайгырту рухы белән сугарылган. Кешенең ирегеН кысу, хезмәт кешеләренең кимсетелүе һәм власть даирәләренең аларны мәсхәрә итүе аның ачуын һәм нәфрәтен уята. Аның карашынча, тигезсезлек, бер кешенең икенче кеше өстеннән хакимлек итүе, шәхесне мәсхәрә итү, кешеләрнең намусына һәм кешелек дәрәҗәсенә кул сузу төбеннән бозыклык санала. «Берәүдән мәсхәрә кылмак, — ди ул, — вә берәүне хакарәт вә тахкыйрь, вә берәүдән көлмәк гаять хәрам эштер вә мәзмүм сыйфаттыр» (К. Насыйри. Әхлак рисаләсе вә һәм фөрүз мәгътәкадәт рисаләсе. Казан, 1890 ел. 16 бит).

Дөрес, мәгърифәтче әле тигезсезлекнең, кешенең ирегеН, намусын һәм шәхесен изүнең социаль-экономик сәбәпләрен күрми. Аның фикеренчә, кешенең җәмгыятьтәге урыны, аның намусы һәм дәрәҗәсе, барыннан да элек, кешенең үзенә, аның нихәтле белемле һәм мәгърифәтле булуына бәйле. Томаналык шәхеснең дәрәҗәсен төшерә, ә гыйлем күтәрә. Моннан үзеннән-үзе шундый нәтиҗә килеп чыга: кешеләрне кимсетелгән хәлдән коткару өчен, аларны мәгърифәтле итү һәм интеллектларын үстерү җитә икән. Сүз дә юк, бу катлаулы социаль мәсьәләне гадиләштерүдән башка нәрсә түгел. Әмма ни генә булмасын, үз заманы өчен аның әһәмияте шиксез зур, чөнки ул кешеләрне аңлы һәм актив төстә үз намусларын һәм дәрәҗәләрен яклауга юнәлтә, аларны власть кешеләре каршында каушап калмаска өйрәтә. «Икмәгеңне ашап өеңдә утыруың,— дип яза К. Насыйри,— кеше хезмәтендә алтын кәмәр баглавыңнан артыграктыр» (К. Насыйри. Тәрбия китабы. Казан. 1898 ел. 5 бит).

К. Насыйри этикасының гуманистик характеры кешеләрнең реаль мәнфәгатьләре хакында кайгыртуында да ачык күренә. Моральнең теләсә кайсы дини системасы кебек үк, мөселман дине, вакытлы һәм түбән мәнфәгатьләр дип, аларга кимсетеп карый, табигый материаль ихтыяҗларга төкереп карарга, теге дөньяда рәхәт яшәү бәрабәренә барлык кыенлыкларга һәм авырлыкларга түзәргә өнди. Кеше К. Насыйрига тәне һәм каны булган, дөньяви омтылышлар белән яшәүче, дөньяви бәхеткә һәм ләззәтләргә ашкынучы һәм газаплардан качарга тырышучы җан иясе булып күренә. Инде шулай булгач, мәгърифәтче фикеренчә, аларның шул теләк-омтылыш-

ларын якларга һәм сакларга тырышуларында, иминлеккә һәм дөньяви ихтыяҗларын канәгатьләндерергә омтылуларында гаеп саналырлык берни дә юк.

Ләкин кеше шәхси ихтыяҗларын һәм иминлеген канәгатьләндерергә омтылганда, беренчедән, чамадан артык кыланмаска тиеш. «Кирәк нәрсәдән баш тартмаска, әмма һәр нәрсәдә чама белергә кирәк», — ди К. Насыйри. Күрәсез, бу очракта мәгърифәтче, кеше үз ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, ләкин чамадан артык кыланмаска тиеш, дип карый. Бу мәсьәләгә анализ ясаганда аңарда тыйнакчыл эпикуризмга хас авазлар ачык сизелеп кала. Әлеге мәктәпнең күп кенә вәкилләре кебек үк, ул кеше ләззәттән баш тартмаска, әмма шул ук вакытта үз карамагында булган байлыклар белән канәгатьләнә белергә тиеш, дип саный. Аның фикеренчә, «канәгать дигән нәрсә дәхи кешегә рәхәт вә игътибар китерә торган изге бер сыйфаттыр... Канәгать иясе булган адәм дөньяда күп зәхмәт чикмәенчә вә мал күбәйтмәк дәртенә төшмәенчә газиз гомерен рәхәтлек илә, тынычлык илә кичерер» (К. Насыйри. Әхлак рисаләсе. Казан. 1911 ел. 11 бит).

Икенчедән, үзенең иминлеге турында кайгыртам дип, кеше башкаларның һәм тулаем бөтен җәмгыятьнең омтылышларына каршы эш итмәскә тиеш. Үз мәнфәгатьләрен яклаганда ул саклык чаралары күрергә, ә кирәк булганда хәтта хәйләгә дә барырга мөмкин, дип саный К. Насыйри. Әмма боларның берсе дә башкаларга зыян китерергә тиеш түгел. Киресенчә, нинди генә хәлләрдә калганда да кеше үз тирәсендәгеләрнең һәм тулаем җәмгыятьнең омтылышлары хакында кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш. Әгәр кеше үзенең шәхси интересларын гомуми интереслардан аерып карый, үз интересларын халык интересларына каршы куя икән, мондый кешене әйбәт дип булмый. Халык, җәмгыять өчен файдалы эшләр генә әйбәт, яхшы эшләр дип санала ала. Бәс шулай икән, «яхшылыгыңны кызганма, халыкка ярдәм итү өчен, көчеңнән килгәннәрнең һәммәсен эшлә»,— ди К. Насыйри (Кавагыйд кыйраәте руссия. 21 бит). Кешеләргә игътибарлы булу, аларга ярдәм итәргә әзер торуны ул адәм баласына хас иң кыйммәтле сыйфатларның берсе дип саный. Халык, җәмгыять кешене башкалар файдасына башкарган эшләре буенча бәяли һәм гомуми мәнфәгать өчен кайгырткан кешенең образын гасырлар буена хәтерендә калдыра. Башкаларга яхшылык эшли алмаган, исән чагында халыкка ипи-тоз күрсәтмәгән кешене үлгәннән соң беркем дә искә алмаячак. «Тереклеге белән сөендермәгән кешенең, — ди ул, — үлеменә дә кайгырмаслар» (К. Насыйри. Календарь. 1892 ел. 39 бит).

Шушы сыйфатлары белән К. Насыйри этикасы индивидуалистик һәм эгоистик шәхси файда принцибына нигезләнгән утилитаризм этикасыннан тамырдан аерыла. Күргәнегезчә, мәгърифәтче кешенең үз мәнфәгатьләре хакында кайгыртырга хаклы барын таный, ләкин моны һич тә иҗтимагый мәнфәгатьләргә каршы куймый. Киресенчә, халык һәм җәмгыять файдасына башкарылган эшләрне яхшылыкның иң матур чагылышы дип саный. Аның фикеренчә, таза әхлак кешенең табигый омтылышларына каршы килми һәм шуңа күрә аларны канәгатьләндерүгә юнәлгән эшләрне ул аклап чыга.

Күп кенә башка мәсьәләләрдәге кебек үк, К. Насыйри мораль һәм этика мәсьәләләре буенча булган карашларында Көнбатыш, шул исәптән рус мәгърифәтчелеге вәкилләре кебек үк, дөньяви мораль тудыра, әхлакның реаль нигезләрен эзләгәндә кешенең табигатенә мөрәҗәгать итә, кешеләрнең табигый интересларын яклап чыга һәм, ниһаять, этик карашларын гуманизм идеяләре белән сугара. Әмма шуның белән бергә, К. Насыйри этикасына җитди аерымлыклар да хас. Көнбатыш мәгърифәтчеләре, үзләренең этик карашларын нигезләгәндә, кеше эшчәнлегенең мотивларын ачуга басым ясыйлар. К. Насыйри исә игътибар үзәгенә мотивларны түгел, ә кешенең мораль йөзе мәсьәләсен куя, аның тәртибе ничек булырга тиешлеген, әхлак таләпләренең эчтәлеген җентекләп тикшерә. Шуның белән бергә, этиканың башка мәсьәләләрендәге кебек үк, ул гуманизм идеяләренә таяна. Гуманизм позицияләреннән торып, ул шул чор җәмгыятенә хас булган алдашу, икейөзлелек, монафикълык, хыянәт, көнләшү, мин-минлек, үчлелек, рәхимсезлек, тупаслык, ялагайлык, ялкаулык кебек әхлакый бозыклыкларны тәнкыйть итә. Намуссыз һәм вөҗдансыз кешеләр, шәхси мәнфәгатьләреннән башка берни турында уйламый торган, үз мәнфәгатенә ирешү өчен теләсә нинди этлеккә сәләтле кешеләр мәгърифәтченең ачуын һәм нәф-

рәтен уята. Ул фикер хөрлеге кысылган һәм полиция күзәтүләре көчәйгән шартларда киң таралган әләкне, яла ягуны һәм гайбәтне рәхимсез фаш итә. Мәгърифәтче, әлеге ямьсез эшләр кешелек җәмгыятенә төзәтеп булмаслык зыян китерәләр, дип саный. «Гаммазлык, нәммамлык, гайбәт, сәгайять итмәк,— ди ул,— әхлак зәминенең дә иң яманрагыдыр, һәлак кылучы бер фәсаддыр ки, гаммазлык сәбәпле никадәр җан, никадәр мал тәләф булмак ихтималдыр, вә ни газиз кешеләр хур булмак ихтималдыр; хуҗалар кол булмак, вә никадәр кан түгелмәк, ир белән хатын аерылмак, дуслар дошман булмак ихтималдыр... Дуслык вә мәвәддәт угрыларыннан сакланыгыз... Алар нәмам вә сәгайять кылучы бозык кемсәләрдер. Зира угрылар мал вә җиһаз урларлар, әмма болар халыкның бер-берсе арасындагы дуслыкны вә мәхәббәтне вә хөсне өлфәтне, вә хөсне мәгашәрәмне урларлар, ягъни дуслыкны кисәрләр» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 261 бит).

К. Насыйри хосусый милекчелек мөнәсәбәтләре һәм дини мораль тудырган әлеге бозыклыкларга җәмгыятьне әхлак ягыннан төзәтүгә юнәлдерелгән мораль-этик принципларны каршы куя. Бу мәсьәләдә ул халык массаларының әхлакый тәҗрибәсенә һәм үткәндәге әхлак мирасына таяна, игътибарын, барыннан да элек, үткәндәге мирасның җәмгыятьне ныгытуга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне сафландыруга хезмәт итә торган якларына юнәлтә. Аның фикеренчә, җәмгыять нормаль яшәсен һәм әхлак ягыннан сәламәтләнсен өчен, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр һәм кешеләрнең иҗтимагый тәртибе түбәндәге принципларга нигезләнергә тиеш:

**1. Гаделлек һәм кешелеклелек.** Дөрес, әлеге принципны күтәреп чыгуына карамастан, К. Насыйри кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм кешенең үзен идеаллаштырудан ерак тора. Аның өчен кешеләр фәрештә түгел, аларның үзара мөнәсәбәтләрендә тегеләйме-болаймы чагылып китә торган җитешсезлекләре булуы бик табигый хәл. «Адәмнәрдән һич кем гаепсез кеше булмас, — ди ул. — Әгәр адәм дә булып, гаебе дә булмаса, ул кеше үлмәс иде» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 276 бит). Шуңа күрә үз фигыльләрен аңлы төстә сайлый алган һәм башка кешеләрнең, шулай ук бөтен җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен истә тотып эш иткән кеше генә әхлак ягыннан дөрес адым ясаган була.

**2. Намуслылык һәм дөреслек.** Кешеләр мөнәсәбәтендәге намуслылык һәм дөреслектән башка бернинди кешелек җәмгыятенең булуы мөмкин түгел, дип уйлый К. Насыйри. Чөнки дөреслектән тайпылу, алдау һәм ялган гаделсезлеккә китерә, кешеләрне әхлак ягыннан ярлыландыра һәм аларны газап утларына сала. Шуңа күрә теләсә генә нинди очракта да кеше гадел һәм намуслы булып калырга тиеш. «Тугрылык әдәпнең рөкене вә мөрәүвәтнең асылы, — ди К. Насыйри. — Тугрылыкта үлмәк ялганчы булып озак яшәмәктән хәерлерәктер» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 285 бит).

**3. Сүзгә һәм бурычка тугрылык.** Тугрылык кешеләрнең мөнәсәбәтен яхшырта, аларның бер-берләренә ышанычын ныгыта, ди мәгърифәтче. Намуслылык һәм дөреслек белән бергә, бу сыйфатларны ул кешенең бөеклеге хакында сөйләүче иң мөһим күрсәткеч, дип саный. «Кемнең күңелендә вафа булса, хәя һәм анда, — ди К. Насыйри. — Вафасызда хәя юк, хәясездә вафа юк. Кемдә бу икесе дә юк, анда иман юк. Вә кемдә иман юк, анда адәмилек юк» (Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан. 1968 ел. 204 бит).

**4. Дуслык һәм туганлык.** Дуслыкта кешелек мөнәсәбәтләре ныгый, дуслар тормыш юлында терәк булып торалар, ди К. Насыйри. Хәтта дуслар белән бергә утырып ашау да ялгыз ашаганга караганда күбрәк ләззәт бирә. Шуңа күрә «кешенең дөньяда хасыйл иткән нәрсәләренең хәерлерәк вә файдалырагы хак вә тугры дуслары дыр» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 398 бит). Инде шулай икән, кеше дуслыкка тугры булырга, аны саклый белергә һәм намуслы, саф күңелле дуслар эзләргә тиеш.

**5. Үзара ярдәм.** «Изге холыкларның берсе — кешегә ярдәмчел һәм шәфкатьле булу», — ди К. Насыйри. Өстәвенә, бу әхлак принцибы милли кысалар белән дә һәм дини кысалар белән дә чикләнми. «Берәүнең бер көче җитми торган вә үзенең кулыннан килми торган бер мәслихәте булса вә синнән ярдәм эстәсә, урынына күрә, кодрәтеңнән килгән кадәр, аның диненә карамаска, кирәк мөселман булсын, кирәк кайсы халыктан булсын, ярдәм вә шәфкать ит. Кирәк кул вә көч илә, кирәк акча вә

теленң илә булсын, ярдәм вә шәфкать итмәк...— гаять изге эштер... Кешегә ярдәм кулы сузарга кирәк булганда бу фәкыйрь, мин бай димә» (К. Насыйри. Әхлак рисаләсе. Казан. 1911 ел. 15 бит).

Кешелек җәмгыятенең нигезендә яткан һәм җәмгыятьнең нормаль яшәвен билгели торган әлеге принциплар белән бергә, кешенең әхлак йөзен сүз һәм эш берлеге, батырлык, кыюлык, иптәшлек, картларны хөрмәт итү, яшьләрне санга сугу, кунакчыллык, инсафлык, тыйнаклык, түземлелек, ныклык һәм пөхтәлек кебек сыйфатлар билгели, ди К. Насыйри. Бу сыйфатлар кешеләрнең үзләрен һәм алар арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшырта, җәмгыятьтәге әхлакый атмосфераны тазарта, кешенең дәрәҗәсен күтәрә. Тыйнаклык, мәсәлән, К. Насыйри тарафыннан «гыйззәт вә шәрәфнең баскычыдыр» дип бәяләнә.

Дөрес, кеше шәхесенең әхлакый нигезләрен бәяләгәндә, К. Насыйри үз чорының улы булып кала, шул заманда хакимлек иткән иҗтимагый мөнәсәбәтләр һәм моральэтик карашлар йогынтысыннан тулысынча котылып җитә алмый. Бу, барыннан да бигрәк, аның әхлакый явызлык күренешләренә килешеп карарга һәм әхлак ягыннан бозык кешеләрне гафу итәргә өндәвендә чагыла. «Явызлык иткәнгә мөмкин кадәр изгелек итәргә тырыш, — ди ул. — Кешегә үч итмәк вә кешедән үч алмак ирлек вә мөселманлык эше түгелдер» (К. Насыйри. Әхлак рисаләсе. 10 бит). Өстәвенә, ул үрнәк әхлакның тәрбияви роленә артык зур өметләр баглый һәм аны бозык кешегә тәэсир итүнең бердәнбер чарасы дип саный. Дөрес, К. Насыйриның әлеге вәгазьләре, барыннан да элек, власть ияләренә юнәлгән һәм аларны ул юлдан тайпылган, яки гаепле кешеләргә карата мәрхәмәтле булырга өнди. Шул ук вакытта алар гарип иҗтимагый мөнәсәбәтләр тарафыннан тудырылган бозыклыкларга карата килешеп карау тенденциясеннән дә азат түгел. Шул заманда хакимлек иткән иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең һәм мораль-этик карашларның К. Насыйрига булган тәэсире шулай ук мөлкәт туплауны аклауда, сакчыллыкка чакыруда, мөлкәткә бәйле алыш-бирешләр вакытында намуслы һәм гадел булырга, үзеңә ышанып тапшырылган байлыкны саклап тотарга өндәүдә дә ачык сизелә. Сакчыллыкны әхлак принциплары дәрәҗәсенә күтәреп, К. Насыйри болай яза: «Хәләлдән килгән малыңны саклап тот, хәрам җиргә сарыф итмә. Малны сакламак мал җыймактан мөшкелрәктер» (К. Насыйри. Тәрбия китабы. 1898 ел. 21 бит). Әмма бу очракта да мәгърифәтче буржуаларча байлык җыюны аклаудан ерак тора. Биредә аңарда җәмгыятьнең хезмәт иясе катлаулары, барыннан да бигрәк, крестьяннар һәм вак һөнәрчеләр арасында таралган настроениеләрнең тәэсире нык сизелә. Бу, аерым алганда, мәгърифәтченең хәләл көч белән мал җыюны хуплавында һәм карунлыкны, комсызлыкны, ерткычлыкны кискен төстә көкем итүендә ачык күренә. Соңгыларын ул кешене ярлыландыра, әхлак ягыннан гариплә‌тә торган нәрсәләр дип саный. К. Насыйри фикеренчә, мал өчен мал җыю төрле шакшылар һәм үләксәләр белән ләззәтләнүгә тиң, ә комсызлык һәм ерткычлык — коллыкның бер чагылышы. Шуның белән бергә, «кол өч төрледер: колның колы, шәһвәтнең, тамгының колы». Алар арасында иң түбәне — комсызлык колы. Чөнки «тамгысыз кеше кол булса да азаттыр, тамгылы кеше азат булса да колдыр... Хирыслык адәмнең кадерен киметер, әмма ризыгын арттырмас» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 422 бит).

Крестьян массалары һәм вак һөнәрчеләр арасында таралган әхлак принципларының тәэсире сакчыллыкка чакыруда, исрафчылыкны, типтереп яшәүне гаепләүдә дә сизелә. «Исраф иясе — шайтанның карендәшедер», ди К. Насыйри. Мал өчен мал җыюны да, шулай ук исрафчылыкны да ул әхлаксыз фигыль дип саный. Материаль байлыклар кешеләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәк. Шуңа күрә, исрафчылыкны тәнкыйтьләү белән бергә, К. Насыйри артык саран булуны да өнәми. Әмма материаль байлыкларга ия булган кеше аны үз рәхәте өчен генә тотмасын, юмартлык күрсәтеп, өлешсезләргә дә ярдәм итсен. Юмарт кешеләрнең егетлеген ул баһадирлык һәм кыюлык белән бер рәткә куя һәм «юмартлык белән баһадирлык бер чишмәдән агар ки, ул куәт чишмәсе вә һиммәт чишмәседер», — дип яза (К. Насыйри. Фәвакиһел-җөләсә. 155 бит).

Хезмәтне әхлакның нигезе итеп аңлату К. Насыйриның этик карашларындагы иң мөһим һәм хәлиткеч пункт санала. Хезмәткә ул кеше тормышының зарури факторы дип карый, рас шулай икән, «кешенең бер-бер кәсептән буш вә маләйәгъни белән

булмакы мэзмүк эштер», ди (Фэвакиһел-җеласә. 92 бит). Димәк, житештерүчән хезмәт белән шөгыльләнү хезмәткә яраклы һәр кешенең беренче бурычы икән. Хезмәт кешене бизи һәм күтәрә, ялкаулык исә кешенең кадерен җуюга китерә, төрле бозыклыклар китереп чыгара. Тормыш өчен кирәкле нәрсәләрне үз хезмәте белән булдырган очракта гына кеше чын мәгънәсендә кеше дәрәҗәсенә лаек. Шул уңай белән К. Насыйри 1892 елгы календаренда ике туган турындагы хикәяне китерә. Аларның берсе падишаһ хезмәтендә булып байлыкта йөзә, икенчесе үз хезмәте белән яши. Беренчесе, туганына мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Әй, борадәр, ник падишаһ хезмәтенә кермәйсең, каты хезмәттән котылыр идең». Икенчесе болай дип җавап бирә: «Син ник кул хезмәте белән тереклек кылмайсың, хезмәтче булу хурлыгыннан вә тәнәззелдән котылыр идең...» (К. Насыйри. Календарь. 1892 ел. 31 бит.)

Хезмәтне К. Насыйри шәхси бәхет һәм ләззәт чыганагы дип саный. «Тормыштан ләззәт теләсәң, үз хезмәтең, гыйлемең һәм фәнең белән яшә», ди ул. Шул ук вакытта хезмәт иҗтимагый әһәмияткә дә ия, чөнки җәмгыятьнең иминлеге аның членнарының намуслы хезмәтенә бәйле. Шуның белән бергә, К. Насыйри җәмгыять өчен игенче хезмәтенең роленә аеруча нык басым ясый. «Игенче халык гадел булмак кирәк,— ди ул,— дөньяның тереклеге алардан... һәр җирдә кылса алар хәрәкәт, мәхлукка куәт кертеп ирештерер ризыкларына бәрәкәт. Дәһкан гаделлек белән орлык сачар... Мәмләкәтне дә тотучы — дәһкандыр» (К. Насыйри. Фәвакиһел-җеласә. 111 бит). К. Насыйри хезмәтнең әхлакый әһәмиятен пропагандалый, ялкаулыкны, исрафчылыкны, комсызлыкны һәм ерткычлыкны гаепли, төбендә боларның һәммәсе эксплуататор сыйныфларның паразитлыгына һәм гамьсезлегенә каршы юнәлдерелгән була. Ул эшсезлекне һәм кеше хезмәте исәбенә яшәүне әхлакый бозыклык дип саный. Шуның белән бергә, ул яңарышның һәм кешелек җәмгыятенең нигезе булган хезмәткә дан җырлый.

К. Насыйриның этикасы үзенең эчтәлеге белән прогрессив, ә тарихи әһәмияте белән дини мораль һәм урта гасырчылык карашларыннан арыну юлында мөһим бер адым була. Дөрес, үзенең әхлакый карашларын нигезләгәндә ул һәр чакта да эзлекле түгел, алда әйтелгәнчә, аерым очракларда артка чигенә, икеле-микеле раслаулар һәм формулировкалар җибәрә. Ләкин мәгърифәтче этикасын мондый чигенүләр түгел, ә аларның дөньяви эчтәлеге билгели. Барыннан да бигрәк, бу чигенүләрне заманга ташлама ясау һәм, аерым очракларда, үз карашларын пропагандалауның уңай формасы дип бәяләргә кирәк. Ә төбендә К. Насыйриның этик карашларында дини мораль белән уртак берни дә юк. Дини моральдән аермалы буларак, ул сукыр иманга түгел, ә кеше акылына таяна. Дин өйрәтмәләренә капма-каршы барып, ул кешенең үзен дә реаль ихтыяҗлары булган җан иясе дип саный. Мөселман дине һәм суфичылык идеологиясенең аскетлык рухындагы вәгазьләрен кире кагып, ул кешеләрнең табигый ихтыяҗларын һәм җир бәхетенә омтылуларын яклап чыга.

Дини мораль кешенең акылын һәм ирекен кимсетә, аны гөнаһлы зәгыйфь җан иясе һәм үз нәфесенең колы дип атый. Моңардан аермалы буларак, К. Насыйри кешенең акылын да, ирекен дә югары күтәрә, аларны үз нәфесләрен һәм тышкы көчләрне җиңәргә сәләтле җан иясе итеп сурәтли. Шуның белән бергә, үз нәфесен тыярга сәләтле булу, тышкы көчләрне җиңәргә сәләтле булу кебек үк, кешегә хас иң мөһим яхшылык итеп бәяләнә. «Шәһвәтенә галиб кеше, — ди ул, — ялгызы бер шәһәр фәтех кылган кешедән дә куәтлерәктер» (Фәвакиһел-җеласә. 192 бит).

Моральнең нигезен кешенең табигатеннән, аның акылыннан һәм төп көчләреннән эзләп, Н. Насыйри тарихи шартлардан һәм сыйнфый мөнәсәбәтләрдән читкә китә. Әмма моңа карап кына һич тә аның этик карашлары иҗтимагый тормыш ихтыяҗларыннан тулысынча аерылган булган дип уйларга ярамый. Күрәсең, үзенең этик тәгълиматын тудырганда, мәгърифәтче үз чорының иң үткен мәсьәләләрен хәл итәргә омтыла. К. Насыйри каршы чыккан иске мораль иҗтимагый тормышның үзгәрмәс булуын яклый, артталык һәм торгынлыкның идеологик терәге булып тора. К. Насыйри этикасы исә урта гасырчылык һәм патриархальлеккә каршы чыга, массаларны иҗтимагый тормышның гасырлар буена килгән нигезләрен җимерергә юнәлдерә, халыкны иҗтимагый үзгәрешләргә хәзерләүне максат итеп куя. Аның тәгълиматы гуманистик идеяләр, гади халыкка, беренче чиратта, хезмәт кешеләренә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләре белән сугарылган, ул кеше шәхесенең абруен һәм җир бәхетенә

омтылуны яклый. Аның этикасы гаделсезлек һәм изүгә кискен протест белдерүе, власть ияләренең башбаштаклыгын, изүне, икейөзлелекне, ялганны, мин-минлекне, исрафчылыкны, ерткычлыкны, көнчелек һәм эгоизмны кискен хөкем итүе белән аерылып тора.

Социаль тигезсезлекне, властьтан явыз максатларда файдалануны, кешенең кайгы һәм хәсрәтләрен әхлакый бозыклык нәтиҗәсе итеп аңлату, шуннан чыгып, әхлакый камилләшүне, мәгариф эше белән бергә, җәмгыятьне яңартучы һәм халыкны бәхеткә илтүче төп юл дип уйлау шулай ук ялгыш була. Ләкин ул заманнарда әхлакый факторны күпертеп күрсәтүнең тарихи җирлеге дә була, чөнки ул иҗтимагый үсешнең төп мәсьәләләре һәм социаль изелүдән, газаплардан котылу турында халык хыяллары белән органик төстә бәйләнгән була. Мәгърифәтченең этик карашлары асылда урта гасырчылык мөнәсәбәтләрен, шулай ук изүче катлаулар арасында киң таралган бозыклыкларны мораль яктан акларга тырышуга каршы юнәлдерелгән була һәм социаль гаделсезлеккә, явызлыкка каршы протест авазы булып яңгырый.

**Әбрар Кәримуллин,**
филология фәннәре кандидаты

# КАЮМ НАСЫЙРИНЫҢ «ТАҢ ЙОЛДЫЗЫ» ПРОЕКТЫ

**Вакытлы матбугат өчен көрәш тарихыннан яңа сәхифәләр**

Татар телендә газета һәм журналлар чыгаруга омтылыш XIX йөзнең беренче елларында ук башлануын, бу эшкә беренче булып прогрессив карашлы рус галимнәре И. П. Запольский, М. Г. Никольский, күренекле татар галиме Ибраһим Хәлфин, революцион-демократ журналистлар П. И. Пашино, Вл. С. Курочкиннар керешүен инде без яхшы беләбез [1].

Халкыбызны караңгылыктан мәгърифәт дөньясына алып чыгуда Каюм Насыйриның да вакытлы матбугатка зур өметләр баглавы билгеле. Аның «Таң йолдызы» исемле газета чыгарырга тырышуы хакында профессор М. Х. Гайнуллин хезмәтләрендә искә алына. Мәгърифәтче галимебез проектлаштырган газетаның программасы нидән гыйбарәт булган, бу эшкә ул кемнәр белән берлектә керешкән, ни өчен ул газета дөнья күрми калган? Яңа табылган документлар әнә шушы сорауларга ачыклык кертергә ярдәм итәләр. Икенче яктан, алар татарларның үз мәгърифәтчеләре беренче булып газета чыгару эшенә кайчан керешүләрен төгәл аныкларга мөмкинлек бирәләр.

Ләкин ул документлар хакында сөйләрдән элек, Хөсәен Фәезхановның берничә хатына мөрәҗәгать итик. Хөсәен Фәезхановның Петербургтан Н. И. Ильминскийга язган ул хатларында татарлар арасыннан газета-журнал чыгару эшенә керешүчеләр турында беренче хәбәрләр китерелә. Казан университетында яңадан ачылган төрки-татар телләре кафедрасы укытучысы Ильминскийга ул: «Бу көннәрдә Сез башлык берничә әһел мәгърифәт татар телендә гәзит бастыралар, дип ишеттем. Мондый хәбәрдән ирексез голәмә таифәсене, гомумән, вә шәрык телләре галимнәрене, хосусән, котламак кирәк буладыр. Күп вакыттан диярлек бу уй минем вә дәхи ничә кешеләрнең

[1] Кәримуллин Ә, Тормышка ашмаган планнар, «Казан утлары», 1970, № 7, 147—159 битләр.

күңелендә уйный иде» [1],— дип яза, аңа рәхмәт белдерә, үзенең сөенече белән уртаклаша. Бу хат 1862 елның 9 январенда язылган. Ә инде 1863 елның 7 апрелендә язган хатында газета чыгаруда киртәләр туугa борчылуы сизелеп тора: «Монда (Петербургта — Ә. К.) дәхи бер хәбәр бар, якын арада Казандан, Мәхмудовтан хат алдым. Анда берничә кеше (татарлардан) татарча гәзит бастырырга тырышып кермешләр, имеш. Бу хосуста прошение бирептеләр. Белмәдем, начальство рөхсәт бирерме?» [2]. Шул ук елның октябренда (датасы күрсәтелмәгән) язган яңа хатыннан газета чыгару мәсьәләләренең башка яклары да ачыклана төшә: «Казанда татарлардан кампания булып ике-өч кеше гәзит бастырмак булып йөриләр икән, хәзер кәгазьләре Министр внутренних дел Советында икән. Белмәдем, аны бирерләрме? Аларның берсе литография остасы, әүвәл дәфгадә литография кылырга телиләр. Язардан кешеләр табылачак. Ильминский һәм аларга нәсихәтләре белән ярдәм бирәчәк, ушандык Мәхмудов вә гайреләр» [3].

Бу хатлардан газета чыгару өчен бер коллектив төзелүе, алар арасында литография остасы, каллиграф, художник та булганлыгы күренә. Бу эшне башлап йөрүчеләр кемнәр булган соң?

Каюм Насыйриның да татарча газета чыгарырга тырышып йөргәнлеге алда әйтелгән иде инде. Бу турыда М. Х. Гайнуллин: «К. Насыйри 1871 елда ярым журнал рәвешендә еллык өстәл календаре чыгара башлый. Шул ук елларда аңарда газета чыгару теләге туа... Газетасын «Таң йолдызы» дип исемләргә теләве мәгълүм» дип күрсәтеп үтә [4]. Без алда күреп үткән хатларда шушы ук мәсьәләләр 60 нчы еллар башында кузгатылганлыгы күренә. Ләкин, елларның төрлечәрәк күрсәтелүенә карамастан, һәр ике очракта да сүз бер үк газета, бер үк кешеләр турында бармыймы? Бу сорауларга ачыклык кертү өчен газета чыгарырга рөхсәт итүне сорап язган үтенечләрне табу кирәк иде. Эчке эшләр министрлыгы архивында эзләнүләр нәтиҗәсез булды. Соңыннан без Матбугат эшләре белән шөгыльләнүче Үзәк цензура материалларын карап чыктык һәм, ниһаять, анда шушы мәсьәләгә ачыклык кертә торган документларга юлыктык. Мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм мәдәният тарихыбыз өчен гаять кызыклы бу материалны без биредә тулысынча тәрҗемә итеп китерүне кирәк таптык.

«Казан хәрби губернаторы Генерал-лейтенант һәм Кавалер Петр Федорович Козлянинов әфәнде Галиҗәнабләренә

**Литография хуҗасы, Казан мещанины Мөхәммәдвәли Мозаффар углы Яхин һәм Казан духовное училищесы татар теле укытучысы, дәүләт крестьяннары сословиясендәге Габделкаюм Насыйровтан**

**Үтенеч**

Россия империясендә рус булмаган милләтләр арасында татарлар иң күп санлы халыкларның берсе булуына карамастан, аларның үз телләрендә әлегә хәтле вакытлы матбугатлары юк. Шунлыктан аларга Хөкүмәтнең һәм урындагы даирәләрнең татарларга кагылышлы күрсәтмәләре икенче кулдан, колактан колакка гына барып житә. Хәзерге көндә зур тизлек белән үсеп килүче промышленность һәм сәүдә мәсьәләләренә караган яңалыклар белән алар бик соңга калып танышалар. Ә бу — сәүдә, промышленность эшләренә аерата һәвәс татарларның эшчәнлегенә зур комачаулыклар тудыра. Ниһаять, үзләренең гадәтләре һәм дине буенча татарлар башка халыклар белән бик үк аралашып яшәмәсәләр дә, кеше табигатенә хас гадәт-яңалыклар белән кызыксыну аларга да ят нәрсә түгел.

Татарларның күпчелеге рус грамотасын белми, рус газеталарын укып барырлык дәрәҗәдә рус телен белүчеләр аз. Татар телендә газета чыгару югарыда күрсәтелгән уңайсызлыкларны бетерергә ярдәм итәр иде.

Шушы максатлардан чыгып, без газета оештырырга телибез. Анда без нигездә «Санкт-Петербургские ведомости», «Северная почта», җирле губерна газеталары һәм

---

[1] БИЛ (Всесоюзная библиотека СССР им. В. И. Ленина), фонд рукописей, фонд 424, 2 коробка, лист 21.
[2] БИЛ, фонд 424, 2 коробка, лл. 23—24.
[3] БИЛ, фонд 424, 2 коробка, л. 23. Х. Фәезханов хатлары белән безне археограф һәм тарихчы М. Госманов таныштырды. Аңа чын күңелдән рәхмәтебезне белдерәбез.
[4] Гайнуллин М. Х. Татар әдәбияты. XIX йөз. Казан, 1968, 132 бит.

башка шундый органнарда басыла торган хәбәрләрне яктыртырга уйлыйбыз. Безнең уебызча, газета түбәндәге бүлекләрдән торачак:

1. Галиҗәнаб Манифестлары.

2. Галиҗәнаб Указлары. Хөкүмәт һәм җирле властьларның татарларга карата турыдан-туры яки өлешчә күрсәтмәләре.

3. Сәүдә, промышленность яңалыклары.

4. Россиядә татарларны кызыксындыра торган мәсьәләләр турында хәбәрләр, чит илләрдәге аерата кызыклы яңалыклар.

5. Тормыш өчен кирәкле, төрле өлкәләргә караган популяр мәкаләләр, этнографик язмалар, ял сәгатьләрендә уку өчен хикәяләр.

6. Ниһаять, төрле характердагы игъланнар.

Күләме ягыннан басма «Губернские ведомости»дан артмаячак, бер-ике табак зурлыкта атнага бер тапкыр чыгарылачак.

Нәшир һәм редакторлык җаваплылыгын үз өстебезгә алабыз.

Сез Галиҗәнаблардән «Таң йолдызы» исеме белән татарча газета чыгарырга безгә рөхсәт бирүне яклап Эчке эшләр министрына үтенечебезне җиткерүегезне түбәнчелек белән сорыйбыз.

Декабрьнең (?) көне, 1862 ел.

Үтенечкә кул куйдылар:

Литография хуҗасы, Казан мещанины Мөхәммәдвәли Мозаффар углы Яхин (имзасы).

Казан духовное училищесы татар теле укытучысы Габделкаюм Насыйров (имзасы)»[1].

Димәк, «Казанда татарлардан кампания булып» газета бастырырга йөрүчеләр М.-В. Яхин белән К. Насыйри булып чыга. Архивларда К. Насыйри һәм башка кешеләрнең бу елларда газета чыгарырга рөхсәт сорап язган башка үтенечләре юк. Шулай итеп, К. Насыйри татарча газета чыгару эшенә 60 еллар башында ук керешкән икән. 1871 ел өчен чыгарылган календаренда ул үзенең бу эшкә кайсы елны, кемнәр белән бергә керешүен әйтмәгән. Табылган документта да, «Календарь»да да сүз бер үк «Таң йолдызы» турында бара. Шулардан чыгып, татарлар үзләре турыдан-туры газета чыгару эшенә беренче тапкыр XIX гасырның 60 нчы еллары башында ук керешкән дип әйтә алабыз.

Бу еллар Россиядә революцион-демократик хәрәкәтнең иң кульминацион чорына туры килә. Бу яктан газета чыгарырга омтылу илдә барган революцион хәрәкәт белән бәйләнештә, аның татарларга йогынтысы яктылыгында каралырга тиешлеге күренеп тора. Моның шулай булуын күзалларга мөмкинлек бирә торган башка фактлар да бар. «Таң йолдызы» газетасын чыгарырга патша хөкүмәте рөхсәт бирмәгәч, революцион-демократик журналистлар П. И. Пашино 1864 елда, Вл. С. Курочкин 1865 елда Петербургта татарча газета-журналлар чыгарырга рөхсәт сорап төрле инстанцияләргә мөрәҗәгать итүләрен искә төшерик[2]. Пашино бу эшкә К. Насыйрилардан соң ук керешә. П. И. Пашино — Казан университетының «Шәрык разряды»нда укый башлаган, ул факультет пайтәхеткә күчерелгәч, Петербург университетының төрки-татар бүлеген тәмамлаган, татар халкының этнографиясе, фольклоры, тарихы буенча күп материаллар туплаган, хезмәтләр язган шәрык белгече, университетта Х. Фәезхановтан сабаклар алган студент. К. Насыйри белән М.-В. Яхинның планнары тормышка ашмагач, Х. Фәезханов татарча газета чыгару фикерләре белән, ихтимал, үзенең шәкерте П. И. Пашинога мөрәҗәгать иткәндер. Пашинога да рөхсәт бирелмәгәч, бу эшкә Вл. С. Курочкин керешә.

Пашино һәм Курочкин проектлаштырган татар газеталарының программалары тәңгәл килүен, аларның үзара якын таныш булуын, икесенең дә Н. Г. Чернышевский даирәсе кешеләре икәнлеген искә алсак, татарча газета чыгаруга омтылышның илдә барган революцион хәрәкәт йогынтысы астында тууын, Х. Фәезхановның да бу даирә кешеләре белән танышлыгын танырга туры килә. Шунысын да онытмыйк, Н. Г. Чернышевский тырышып татар телен өйрәнгән, татарларның иске Россиядә аерата изелүен, җәберләнүен күргән. Татарларның Е. Пугачев восстаниесендә иң актив катнашучы

[1] ЦГИАЛ, ф. 775, оп. 1, дело 255, лл. 3—5.
[2] Кәримуллин Ә, Күрсәтелгән хезмәт, 148—152 битләр.

халык булуы аңа бик таныш булган. Петербургта чыгачак татарча газета аша ул татарларны да революцион хәрәкәткә тартуны күздә тотмадымы икән дип уйланырга урын бар. Югыйсә, Н. Г. Чернышевский татар телен, тарихын гадәти кызыксыну белән генә өйрәнгән дип карау дөрес булмас иде.

«Таң йолдызы» белән П. И. Пашино һәм Вл. С. Курочкин газеталарының программалары да тәңгәл килә. Бу үзе күп нәрсәләр турында сөйли. Аларның барысында да сүз сәүдә, промышленность яңалыклары, эчке яңалыклар, чит ил хәбәрләре, тормыш өчен кирәкле төрле мәсьәләләргә караган информацияләр, этнографик һәм әдәби әсәрләр бастыру, халыкны төрле законнар белән таныштырып тору турында сүз бара. Хәтта газеталар өчен материалларның бер үк чыганаклардан алыначагы да тәңгәл килә. Программаларның гомуми эчтәлегенә күз салып үтик. Анда күтәрелгән мәсьәләләр тулысынча дөньяви темаларга карый. Билгеле булганча, XX йөз башында дөньяга килгән татар вакытлы матбугатының күбесендә дин мәсьәләләрен яктырту аларның программаларына кертелеп килә. Бу яктан «Таң йолдызы» үзенең халыкчанлыгы, демократик юнәлеше белән аерылып тора.

Программадан күренгәнчә, газетаның төп максаты — авыл хуҗалыгы, көнкүреш, практик тормыш өчен кирәкле яңалыклар, фән, техника ачышлары белән таныштырып бару. Шул ук вакытта «Таң йолдызы», Пашино һәм Курочкиннар да теләгәнчә, әдәби һәм этнографик әсәрләр бастырып халыкның зәвыгын үстерүне, аны тарих буенча хезмәтләр белән таныштыруны да күздә тота. Аларның программалары газета аша халык мәгърифәтенә хезмәт итү, гасырлар буенча каплап торган караңгылыкны таркату, халыклар арасында дуслыкка максат тоту турында сөйлиләр.

Программаларда сәүдә, промышленность мәсьәләләрен дә яктырту бурычы куелуы әле яңа туып килүче татар буржуазиясенең дә интересларына туры килә, ләкин ул, заманы өчен табигый күренеш буларак, газета чыгарырга йөрүчеләрнең чикләнгәнлеге дип кенә карала алмый.

Күреп үткәнчә, үтенеч Казан хәрби губернаторы исеменә язылган. Аннары ул 1863 елның 28 августында Эчке эшләр министрлыгы янындагы китап эшләре буенча Министрлар советы карамагына җибәрелгән. Петербург цензура комитеты шушы Совет исеменнән Казан губернаторына җибәргән җавабында, «яңа цензура уставы кабул ителмичә, газетаны басарга рөхсәт бирелә алмавын Яхин һәм Насыйровларга җиткерергә» [1], дип үтенечне кире кага. Бу исә газета чыгарырга юл куймау өчен уйлап чыгарылган бер сылтау гына була. Аның нигезендә патша администрациясенең «махсус әдәби органнар ачарга рөхсәт бирү Империя составына кергән төрле вак милләтләрнең үзбаш яшәвенә китерәчәк, бу исә хөкүмәтнең күз алдында торкан планнарына туры килми» [2] дигән политикасы ята иде.

Татарча газета чыгару буенча Н. И. Ильминский тоткан позицияне дә аңлатып үтү кирәк. Ни өчен соң Ильминский башта үзе хуплаган бу эштән читләшкән? Билгеле булганча, 60 нчы еллар башына кадәр ул төрки телләрне өйрәнүдә шактый зур эшләр башкара, казакъ, татар, чыгътай телләре буенча берничә хезмәт яза, «Ир Таргын», «Кыйссаи Робгузи», «Бабер намә» кебек әдәби һәйкәлләрне фәнни комментарийлар белән бастырып фән дөньясына алып керә. Ильминский үзенең шушы хезмәтләре белән татар мәгърифәтчеләре арасында ихтирам казана, шуңа күрә алар газета чыгаруда аның ярдәменә мөрәҗәгать итәләр.

Ләкин Ильминскийның позициясе илдә башланган революцион хәрәкәт нәтиҗәсендә бик тиз үзгәрә. Аерым алганда, социаль һәм милли изүгә каршы көрәшнең бер формасы буларак, керәшен татарларының бу елларда күпләп мөселманлыкка кире кайтуы аңа зур йогынты ясый. Ильминский бу күтәрелешнең самодержавие иминлеге өчен зур куркыныч тудырганлыгын күрә һәм аны бастыруда патша гаскәрләренә булышлык күрсәтә. 60 нчы еллар башында ул изелгән халыкларны чукындыру, алар арасында православие тарату эшенә җиң сызганып керешә, шул юл белән керәшен татарларын һәм православиегә күчкән башка халыкларны илдә барган революцион хәрәкәттән аерып алырга тырыша. Татарча газета-журналлар чыгару халык арасына революцион-демократик идеяләр үтеп керүгә юл ачачагын Ильминский яхшы аңлый. Инде газета ачарга революцион-демократлар да керешкәч, Ильминский бөтен

[1] ЦГИАЛ, ф. 775, оп. 1, дело 255, л. 1.
[2] ЦГИАЛ, ф. 776, оп. 5, дело 168, лл. 7—8.

көче белән бу эшкә каршы чыга һәм гомеренең калган өлешен бу халыкларның алдынгы рус культурасы, иҗтимагый-сәяси фикере белән танышуына каршы көрәшкә багышлый, шушы максатка синод, патша чиновниклары, миссионерлар армиясен туплый. 60 нчы еллардагы революцион хәрәкәттән коты алынган Ильминский халык мәгърифәтен буу, Россиянең башка изелгән халыкларының да революцион хәрәкәттә актив катнашуына юл куймас өчен бу газетаны чыгармаска сорап пайтәхеткә донослар яза.

Танышып үткән материаллар «Таң йолдызы»н ачу өчен көрәшнең моңа хәтле билгеле булмаган яңа якларын да ачарга ярдәм итә. Беренчедән, без газета ачуга омтылышның нинди тарихи чорда баруын күрдек. Икенчедән, газета чыгаруны оештырырга тырышучылар бер К. Насыйри гына булмаган, ул — күп кенә татар мәгърифәтчеләренең эшчәнлеге нәтиҗәсе. Бу эшкә иң актив катнашучыларның берсе Х. Фәезханов икәнлеге дә ачык күренә. Хәтта газета ачу идеясен күтәреп чыгучы, башлап йөрүче ул булгандыр дип уйларга да нигез бар. «Таң йолдызы»н басу өчен рөхсәт бирелмәгәч, Х. Фәезханов тагын бер кешегә — И. Г. Нофальгә дә мөрәҗәгать итеп карый. Чит ил эшләре министрлыгындагы Азия департаментында тәрҗемәче булып эшләүче бу кеше 1864 елда Петербургта «Шәрык» исемле русча, татарча, гарәпчә газета ачарга рөхсәт сорап үтенеч белән керә. Газетаның программа өлешендә «4. Хөкүмәтнең мөселманнарга караган күрсәтмәләрен татар теленә тәрҗемә итү һәм татарча басманы редакцияләү өчен Петербургта Хөсәен Фәезханов исемле, Санкт-Петербург университетының татар теле диалектлары буенча лектор хезмәтен үтәүче гаять булдыклы кеше бар. Ул бу эшкә бик теләп керешергә тора» [1], дигән юллар Х. Фәезхановның газета чыгару өчен нихәтле янып йөрүен, тырышуын тагын бер кабат раслый.

Ни өчен Х. Фәезханов газета чыгару өчен үзе үтенеч белән мөрәҗәгать итмәде икән дигән сорау туа. Билгеле булганча, патша законнары нигезендә, дәүләт учреждениеләрендә эшләүче кешеләргә типография тотарга, вакытлы матбугат ачарга рөхсәт бирелмәгән. Аның университетта эшләвен, ул уку йортының дәүләт учреждениесе булуын искә төшерсәк, мәсьәлә ачыклана. Хөсәен Фәезханов бик яшьли, 38 яшендә, вафат була, әгәр ул озаграк яшәгән булса, бу хыялын тормышка ашыру өчен төрле юллар эзләп караган булыр иде.

Газета чыгарырга йөрүчеләр арасында Мәхмудов дигән фамилия дә искә алына. Бу — һичшиксез, Казан университетында гарәп, төрки, фарсы телләре укыткан, художник, каллиграф Мөхәммәдгали Мәхмудов (1824—1891). Университетның шәрык разряды Петербургка күчерелү уңае белән, Мәхмудов бу елларда Казандагы беренче гимназиядә өлкән укытучы булып эшли. Дәүләт эшендә булу сәбәпле, газета чыгару өчен язылган үтенечтә аның фамилиясе күренми [2]. Ул газета оештыручыларның берсе булган, анда корреспондент буларак кына түгел, газета текстын таш басма өчен күчерүдә катнашырга да уйлаган.

Үтенечкә кул куйган Мөхәммәдвәли кем соң? Моңа җавап бирү өчен татар басмачылыгы тарихына күз салыйк. 1845 елда патша указы белән Казанда татар китаплары басу тыелгач, бердәнбер татар матбугасы булган Рәхимҗан Сәгыйтов типографиясе яшәүдән туктый. 1851 елда Шаһи Яхин дигән бер кеше зур авырлыклар белән литография ачарга рөхсәт алуга ирешә. Ләкин ул китап басу буенча зур эшләр башкара алмый. Мөхәммәдвәли Яхин шул литографияне үзенә күчерү өчен 1859 елның 6 маенда рөхсәт ала [3]. Бу литография, һичшиксез, проектлаштырган газетаны басу өчен ачыла. «Таң йолдызы»н чыгарырга рөхсәт бирелмәгәч, М-В. Яхин зур авырлыклар белән ачкан литографияне тотудан ваз кичә, губернаторга литография эшеннән кире кайтам дип хәбәр итә. Бу литография 1872 елга кадәр аның исемендә яши, шул 13 ел эчендә анда нибары 19 китап кына чыга; М-В. Яхин литографияне китап басу өчен ачкан булса, анда басылган китаплар бу дәрәҗәдә аз булмас иде, чөнки ул чорда татар китаплары басу өчен Казанда басмаханәләр җитешми.

[1] ЦГИАЛ, ф. 775, оп. 1, д. 200, л. 17. И. Г. Нофаль Бейруттан килгән гарәп христианы, соңыннан Россия подданые, 32 елдан соң, 1896 елда ул яңадан шушы газетаны чыгару өчен үтенеч белән Эчке эшләр министрына керен карый. Царизмга, патша чиркәвенә турылыклыгы өчен орденнар белән бүләкләнгән, татар халкы өстеннән провокацион донослар язу белән дан алган шушы турылыклы ялчысына да патша хөкүмәте татар телендә газета чыгарырга рөхсәт бирми. Кара: ЦГИАЛ, ф. 776, оп. 8, дело 975, 1896 год, лл. 1—19.

[2] Үтенеч бирү белән Қ. Насыйри да духовное училищеда эшләүдән туктый.— Ә. К.

[3] ЦГА ТАССР, ф. 1, оп. 3, дело 243, л. 49.

Таш басма ысулы белән чыгару өчен проектлаштырылган газетаның текстын М-В. Яхин, каллиграф буларак, үзе дә таш басмага күчерергә җыенган, моңа художник-каллиграф М-Г. Мәхмудовның да актив катнашуы күздә тотылган.

Каралып үткән документлар татар мәгърифәтчеләренең газета булдыруга гаять зур әһәмият бирүләрен, аны чыгару эшенә төрле яклап хәзерләнүләрен күрсәтә. Газета оештыруга, исемнәре әйтеп үтелгән мәгърифәтчеләрдән тыш, тагын башка зыялыларның да катнашы булырга тиеш.

Бу документлар татар халкын мәгърифәт юлыннан үстерү эшенә рус халкының алдынгы вәкилләренең дә актив катнашуын күрсәтүләре белән әһәмиятле. Икенче яктан, алар Х. Фәезханов, К. Насыйри, М-Г. Мәхмудов, М-В. Яхиннар арасындагы бердәмлек, дуслык-теләктәшлекне, халык мәгърифәте өчен аларның кулга-кул тотынып көрәшүләрен, мәгърифәтчеләребез армиясенең шактый зур булуын да раслыйлар.

Шуның өстенә, бу документлар татар мәгърифәтчелеге тарихын киңрәк планда, вакытлы матбугат тудыру өчен барган көрәшне илебездәге революцион хәрәкәт үсеше белән берлектә, рус революцион-демократлары белән дә бәйләнештә карау кирәклеге турында да сөйлиләр.

Кызганычка каршы, газета һәм журналлар чыгарырга омтылулар, «Таң йолдызы»на хәтле һәм аннан соң да, патша самодержавиесенең изелгән халыкларны караңгылыкта тоту, бигрәк тә христиан булмаган халыкларны аерата җәберләү политикасы киртәләрен үтә алмаган. Россия халыклары арасында иң беренчеләрдән булып китап басу эшенә керешкән татарлар, бик соңга калып, бары тик Беренче рус революциясеннән соң гына газета-журналлар ачарга мөмкинлек алдылар. Әгәр бу проектларның берәрсе генә тормышка ашкан булса, халкыбызны алдынгы рус әдәбияты, революцион-демократик фикер үсеше, фән, дөнья культурасы белән таныштыру никадәр тизрәк барган, матбугат битләрендә күпме яңа әдипләр, мәгърифәтчеләр үсеп чыккан булыр иде.

Татар халкының озак вакытлар буенча торгынлыкта яшәве, фән, техника, культура ягыннан артта калып килүе ислам дине һәм мулла-монтагыйларының халык аңын томалавына, шулай ук царизмның татар халкына карата тоткан аерата рәхимсез политикасына, китабын буу, газета-журналлар чыгарырга рөхсәт бирми килүенә, «сукырны алдавы ансатрак» дигән милли колониаль изү политикасына бәйләнгән.

Беренче рус революциясе нәтиҗәсендә татарлар газета һәм журналлар чыгару мөмкинлекләре алды, ә Октябрь социалистик революциясеннән соң исә халкыбызның культурасын, сәнгатен, әдәбиятын, матбугатын үстерү өчен бөтен шартлар тудырылды.

Солтанморат Акбиев

# КАЮМ НАСЫЙРИ ҺӘМ ӘБУСУФЬЯН АКАЕВ

Мәгълүм булганча, үз халкының мәдәниятен, фән һәм әдәбиятын үстерү өчен көрәшкәндә үткән заманның күренекле галим һәм әдипләре башка мәдәниятләрнең прогрессив вәкилләренә дә таянганнар, алар туплаган белем һәм тәҗрибәне үз практикаларында файдаланганнар. Аларның эшчәнлеге мәдәни һәм әдәби казанышларның бер халыктан икенчесенә үтеп керүенә ярдәм иткән.

Бер әдәбиятның икенчесенә үтеп керүе һәм, шул рәвешчә, аларда охшаш мотивларның туу юлларын билгеләп, академик Н. И. Конрад болай ди: «Бер халык әдәбияты башка әдәбиятка бары тик ике формада — төп нөсхәдә яки тәрҗемәдә генә үтеп керә дип уйларга ярамый». Ул башка рәвештә дә булырга мөмкин, әйтик, «бер халык язучысы иҗат иткән әсәрнең эчтәлеген һәм мотивларын икенче халыкның иҗатында җанландыру» [1] формасында.

[1] Н. И. Конрад. Көнбатыш һәм Көнчыгыш, М. 1966, 343 бит.

Этник яктан, тел һәм тарих-культура ягыннан якын торган ике халык — татарлар һәм кумыкларның культура һәм әдәби багланышлары тарихын тикшергәндә, шушы характердагы процессларны без ачык күрәбез. Бу ике әдәбиятның үзара элемтәләре ерак үткәнгә барып тоташа. Тарихи яшәеш шартлары, аерым алганда, Көнбатыш белән Көнчыгышны тоташтыручы сәүдә юлларында утырган булу аларга бер-берсе белән аралашуда ярдәм иткән, төрле халыкларның рухи культурасы казанышларын үзләштерү, бер-берсе аша әдәби хәзинәләр кабул итү эшен җиңеләйтергән. Шәрыкның борынгы культура җимешләре Идел буйларына кумык җире аша да үтеп кергән, ә кумыклар исә татарлар аша Европа культурасы белән аралашу, бигрәк тә бөек рус әдәбиятын үзләштерү мөмкинлегенә алганнар.

Татар һәм кумыкларның культура багланышлары XIX йөзнең беренче яртысы ахырларыннан аермачык күренә. Һәм бу элемтәләр барыннан да бигрәк, социаль-политик, экономик яктан артта калган халыкларда мәгърифәтчелек хәрәкәтенең башлануы, татар һәм кумык халыкларының үз милли мәдәниятләрен яңарту һәм үстерүгә омтылышлары көчәю белән бәйләнгән.

Татарлардан Ибраһим Хәлфин, Гали Мәхмудов, Хөсәен Фәезханов, Каюм Насыйри, кумыклар арасыннан М-Э. Османов, Нухай Батырмурзаев, Әбусуфьян Акаев кебек күренекле мәгърифәтчеләрне уртак максат — хезмәт ияләре массаларына аң-белем бирү, милли әдәбиятларны алдынгы халыклар әдәбиятлары югарылыгына күтәрү максаты берләштерә.

Яңа типтагы мәктәпләргә нигез салу, уку-укытуның яңа методикасын гамәлгә кертү, алфавит һәм язу кагыйдәләренә реформа ясау, ана телләрендә дөньяви юнәлештәге китаплар бастыру, матур әдәбият, тарих, педагогика китапларын, газета-журналлар тарату буенча алар алып барган киң колачлы эшчәнлек эзлекле рәвештә бу мәгърифәтчеләрне иҗади хезмәттәшлеккә этәргән.

Татар эстетик фикеренә нигез салучыларның берсе Фатих Әмирхан XX йөзнең башында тормыш бездән чын европалы кеше булуыбызны таләп итә дип язган иде. Татар мәгърифәтчеләре, бөек рус демократик культурасы казанышларын үзләштереп, Россиянең мөселман халыклары, хосусан, кумыклар арасында, алдынгы идеяләрне таратуга җитди этәреш ясадылар. Татар китабы, татар әдәбияты әсәрләре белән бергә кумык мөхитенә Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйриның мәгърифәтчелек идеяләре, ә бераз соңрак Ф. Әмирханның эстетик карашлары, халык шагыйре Г. Тукай шигырьләре үтеп керә башлый. Рус демократик әдәбияты белән бергә (ул шулай ук татар әдәбияты аша да кергән), бу галим һәм эшлеклеләрнең хезмәтләре кумык әдәбиятында һәм мөхитендә мәгърифәтчелек хәрәкәте формалашуда зур роль уйнаган [1].

Шунысын да әйтергә кирәк ки, һәр ике халыкның алдынгы интеллигенциясе тарафыннан алга куелган проблемалар уртак һәм актуаль булса да, саны буенча да күбрәк, Европа һәм рус культурасына да якынрак торган татар мәдәнияте эшлеклеләре күп мәсьәләләрне хәл итүдә кумыклардан 15—20 елга алдарак барганнар. Шулай итеп, татар әдәбиятының һәм эстетик фикеренең әнә шундый югарырак үсеш алган хәле кумыклар ирешергә тиешле булган дәрәҗәне күрсәтеп торган...

«...һәр милләт башкалардан өйрәнә ала һәм өйрәнергә тиеш» [2],— дип яздылар К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Кумык иҗади интеллигенциясе дә югарырак баскычта торучы күршесеннән өйрәнгән, борынгы татар культурасының прогрессив традицияләрен үзләштергән.

Бу чорларда татарлар белән дагстанлылар арасында экономика-сәүдә мөнәсәбәтләре, мәдәни элемтәләр тизлек белән үсә башлый. Дагстанлылар, һәм бигрәк тә кумык зыялылары, шәрык халыкларының мәдәният һәм сәүдә үзәкләреннән берсе булган Казан, шулай ук Әстерхан, Саранск, Самара кебек Идел буе шәһәрләренә еш киләләр. Алар югары уку йортларында, рухани семинарияларда һәм татар мәгърифәтчеләре эшләгән мәктәпләрдә укыганнар, туган җирләренә әйләнеп кайтканда, алган белемнәренә өстәп, мәгърифәтчелек юнәлешендәге дөньяви китаплар һәм матур әдәбият әсәрләрен алып кайтканнар. Дагстанга татар мәгърифәтчеләренең хезмәтләре әнә шулай килә.

---

[1] Бу хакта кара: С. Акбиев. Мәдәни бергәлек. «Казан утлары», 1972 ел, 6 нчы сан.
[2] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Соч. т. 23, 10 бит.

Бу мәкаләдә без татар һәм кумык халыкларының мәдәниятләрен тудыру һәм үстерү юлында онытылмаслык хезмәтләр калдырган мәгърифәтче-галимнәр плеядасының иң калку фигуралары — Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаевның иҗат эшчәнлекләрендәге типологик охшашлык билгеләрен күрсәтеп, ике тугандаш халык арасындагы күпьяклы мәдәни-тарихи бәйләнешләрнең бер аспектын ачу максатын куйдык.

Каюм Насыйри — дистәләрчә фәнни һәм популяр хезмәтләр язган һәм бастырып чыгарган галим, педагог, әдип. «Кумык теле грамматикасы» авторы профессор Н. К. Дмитриев К. Насыйрины «татар халкының яз хәбәрчесе», «татар мәгарифен шәрыктан көнбатышка таба борган кеше» дип атады [1].

Каюм Насыйриның мәгърифәт һәм мәдәниятне үстерү, шул заманның әдәби һәм фәнни казанышларын үзләштерүне барлык халыклар алдында торган зарури бер бурыч итеп куюы төрки телендә сөйләшүче халыкларның алдынгы карашлы укымышлылары теләкләренә авааздаш һәм якын булган.

М. Гайнуллин, Ф. Мөхәммәдьяров, Н. К. Дмитриев һ. б. ларның хезмәтләрендә Каюм Насыйриның әсәрләре төрле яклап тикшерелгән. Әнә шуңа күрә, К. Насыйри хезмәтләрен киң күләмдә анализлап тормыйча, аның кумык мәгърифәтчесе Әбусуфьян Акаев иҗатына һәм күпкырлы эшчәнлегенә булган йогынтысы мәсьәләсенә тукталыйк.

Кумык әдәбияты һәм телен фәнни тикшеренүчеләрнең тәүгеләреннән берсе профессор Б. Чобан-задә Ә. Акаевны үз заманының энциклопедик белем иясе, өлкән буын кумык интеллигенциясенең иң укымышлы вәкилләреннән берсе дип атады. Аның фикеренчә, дагстанлылар Европаның һәм шәрыкның прогрессив культура җимешләре белән Әбусуфьян Акаев эшчәнлеге аша танышканнар [2].

Әйткәнебезчә, Ә. Акаев үз вакыты өчен киң белемле галим була, җирле телләрне белү өстенә гарәп, рус телләрен дә өйрәнә, тарих, әдәбият, медицина, табигать фәннәре, педагогика белән шөгыльләнә. Ул «Аджам шиъруланы мажмуасы» (Халык җырлары, мәкаль-әйтемнәре һәм аерым кумык авторлары әсәрләре җыентыгы, (1903). «Җагърапия» (1903), «Башлангыч тарих», «Әлифба» (1905), «Гъисап китап» (1905), астрономия, табигать белемнәре, игенчелек, сәүдә буенча фәнни-популяр кулланма булып хезмәт иткән «Юз йыллыкъ тынч рузнама» («100 еллык календарь», 1904), әхлакый мәсьәләләргә багышланган «Къылыкъ китап» (1908, 1914), төрле сүзлекләр, медицина буенча төзелгән «Хазир дарман» (1910) китабын, шулай ук «Бүзегет», «Таһир һәм Зөһрә», «Йосыф һәм Зөләйха», «Калила һәм Димна» кебек шәрек әдәбияты әсәрләрен эшкәртеп бастыра. Болардан башка ул борынгы кумык культурасы һәм әдәбияты, кумык шигыренең төзелеше, төрки халыкларның тарихи элементләре хакында дистәләрчә мәкаләләр яза. И. А. Крылов мәсәлләрен, А. С. Пушкин шигырьләрен, пролетар гимн «Интернационал»ны кумыкчага тәрҗемә итә.

К. Насыйри һәм Акаев китапларын чагыштырып карагaнда, алар арасында форма буенча типологик охшашлык билгеләрен, эчтәлекләрендәге эчке логик якынлыкны күрмәскә мөмкин түгел.

Әбусуфьянның карашлары үз эпохасының идеологиясенә бәйле рәвештә идеализмга нигезләнгән булуына карамастан, аларда, һичшиксез, материализм элементлары да бар. Дөньяны танып-белү мәсьәләләренә ул зур игътибар бирә, фәннең тәрәккыятенә, чынбарлыкны өйрәнүдә кеше акылының мөмкинлекләренә ышаныч белән карый.

Насыйри шикелле үк, Акаев та үз халкын тирәнтен ярата һәм гомере буена алдынгы халыклар белән дуслык идеясен алга сөрә. Төрле әсәрләргә сүз башы рәвешендә язылган һәр мәкаләсендә диярлек, Әбусуфьян татар мәдәнияте эшлеклеләрен югары бәяли һәм аларны үрнәк итеп куя. Мәгърифәтченең үз әйтүе буенча, ул Казан татарларының хезмәтләренә еш мөрәҗәгать иткән [3].

Әбусуфьян Акаев, Каюм Насыйри кебек, башлангыч белемне үз өендә һәм мәдрәсәдә ала. Мәчет каршындагы мондый мәктәпләрдә уку-укыту эшенең куелышы аны канәгатьләндермәгәнлектән, ул гасыр башында инде укыту системасын үзгәртү юлла-

---

[1] Н. К. Дмитриев. Каюм Насыйри — филолог. Кара: Каюм Насыйри. 1825—1945 (туууна 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары). Таттосиздат. Казан. 1948. 41 бит.

[2] Б. Чобан-задә. Кумык теле һәм әдәбияты. Ж. «Маариф ёлу». (Путь просвещения). № 23, 1925. 24 бит.

[3] Әбусуфьян Акай, «Къылыкъ китап» (Книга о нравственности), Тимер-Хан-Шура. 1914. 2 бит.

рын эзли башлый. Шушы эзләнүләр аны Казанга алып килә. Монда ул татар мәгърифәтчеләре һәм иҗади интеллигенциясе белән аралаша, аларның эшләрендә актив катнаша һәм ул шушында дөньяви мәктәпләрдә укытуның яңа ысулларын үзләштерә.

1900—1903 һәм 1906—1908 елларда Казанда яшәгән чорларда Акаев К. Насыйри хезмәтләрен өйрәнгән һәм, безнең уйлавыбызча, татар галименең үзе белән таныш булган. Акаев хезмәтләренең эчтәлеге әнә шул хакта сөйли. Мәдәният, әдәбият һәм педагогика өлкәләрендә ул бу олы мәгърифәтче — үзенең элгәресе раслаган идеяләр һәм фикерләрне яклап чыга, аларны Дагстан шартларына карата үстерә.

Безнең кулыбызда вакыт үтү белән саргайган бер фоторәсем саклана. Анда үзләренең остазлары белән бергә кырыклап шәкерт Казандагы бер уку йорты бинасы каршында басып торалар. Алар арасында түбән рәттә кулына китап тоткан яшь Әбусуфьян да бар. Бинаның тышкы архитектурасы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен хәтерләтә. Каюм Насыйриның педагогик карашлары, дәреслекләре һәм фәнни хезмәтләре нәкъ менә шушы уку йортында, шәкертләр арасында киң таралганнар. Акаев та шушында укыган һәм соңрак Казан мәктәпләре турында дәртләнеп сөйләгән. «Казан мәктәпләрендә (дөньяви мәктәпләрдә — С. А.) укыту Дагстан белән чагыштырганда, бик яхшы хәлендә. Казанда укыту эшенең ничек куелганлыгын әйтеп бирү дә кыен миңа. Татарларның фәнгә омтылышларын үз күзең белән күрергә кирәк»,— дип яза ул «Къылыкъ китаб»ында.

1903 елны Акаев туган ягына кайта һәм үз авылында татар мәгърифәтчеләре үрнәгендә ике сыйныфлы дөньяви мәктәп ача. Кешеләр аңында дини идеология хөкем сөргән шартларда дөньяви белемгә юл ачу җиңел булмый, әлбәттә. Моның өчен үз халкыңны Насыйри һәм Акаев кебек яратырга, аның кайгысы, рухи ихтыяҗлары белән яши белергә кирәк. «Безнең балаларыбыз, — дип яза Акаев, — мәктәп һәм мәдрәсә стеналары эчендә күп еллар утырсалар да, ни өчен һәм нәрсә укуларыннан хәбәрсез калалар, чөнки аларга фәнни белемнәр бирү хакында берәү дә кайгыртмый». Мәктәпләрдән томана килеш чыккан шәкертләр, мәгърифәтче әйтүенчә, «сырхауларына даруны бары докторлар гына белгән авыруны хәтерләтәләр» [1].

Мондый кешеләрне «савыктыру» һәм дөньяви белемнәр бирүнең файдасын аңлату өчен К. Насыйри һәм Ә. Акаев кебек мәгърифәтчеләргә гаять зур пропаганда эше алып барырга туры килгән. Әбусуфьян ачкан мәктәп менә шул максатка хезмәт итәргә тиеш була да.

Каюм Насыйриның һәм Әбусуфьян Акаевның мәктәпләре мәгърифәтчеләрнең үз тырышлыклары белән генә яшәгән, патша хөкүмәте азчылык милләт балалары өчен мәктәпләр ачу, ана телендә дәреслекләр булдыру өчен һичнинди кайгырту һәм ярдәм күрсәтмәгән. Китап һәм уку әсбапларын гына түгел, кием-салым һәм башка кирәк-яракларны да ярлы балаларына мәгърифәтчеләр еш кына үз кесәләреннән түләп юнәтергә мәҗбүр булганнар.

Әбусуфьян мәктәбе Насыйри мәктәбе үрнәгендә төзелеп, җирле шартларга яраклаштырылган була, нигездә ул шул заманның гомум белем бирүче рус мәктәпләре тибына туры килә. Балалар ана телендә иҗекне-иҗеккә кушу ысулы белән укытыла, арифметика, әдәбият, табигать белеме, тарих, география дәресләре керә. Бу Дагстан мәгарифе тарихында беренче үрнәк мәктәпләренең берсе була. Мәктәптә шулай ук һөнәр дәресләре дә бирелә. Укучылар кул эше белән шөгыльләнәләр, сәүдә эшенә өйрәнәләр. Мәктәпне тәмамлаучылар югары баскычтагы башка уку йортларына яки кая да булса хезмәткә керү мөмкинлеге алганнар. Акаевның яңача укыту методына карашлары Каюм Насыйри фикерләренә тулысынча туры килә.

Ә. Акаев мәктәбе зур уңышка ирешә, монда укырга күрше авыллардан да балалар килә башлый. Бу хәл дини фанатикларның ачуын кабарта. Шушы мәктәпнең элекке укучылары Дагстанның атказанган укытучысы һәм язучысы Мөхәммәт Хангишиев, персональ пенсионер Казбек Чакальскийларның әйтүенчә, тирә-юньдәге мәчетләрнең муллалары халык арасында Әбусуфьянга һәм аның укыту системасына каршы коткы тараталар, «яңа ысуллы мәктәптә укыган балалар мөселман диненең изге эшләреннән читләшәчәк, имансызлар булып үсәчәк», диләр. Шөбһәгә төшкән ата-аналарның балаларны бу мәктәпкә йөрүдән тыю очраклары да булгалый. Ләкин дөньяви белемнәр-

[1] Ә. Акай, Юз йыллыкъ тынч рузнама, Порт-Петровск. 1904, 6 бит.

тә омтылучы яшьләр, аталарыннан яшеренеп булса да, мәктәпкә йөрүләрен дәвам итәләр. Җир идәндә түгел, ә парталарда утырып уку-язу, һәр дәрес саен яңа нәрсәләр ишетү, күрү, карталар һәм глобусларны өйрәнү һ. б. аларның күңелләренә хуш килә. Кичләрен, укытучылары белән бергәләп, балалар авыл читенә чыгалар һәм телескоп аша күк җисемнәрен күзәтәләр. Укытучының өендә литография китапларын басу машиналары да була. Балалар монда таш басма эшен үзләштерәләр, укытучы абыйларына китап төпләргә булышалар.

«Дагстан халыкларының якты тәрәккыят юлына чыгачакларына ул нык ышанды», — дип искә ала аның шәкертләреннән берсе Нуретдин Гаджиев.

Кичләрен Әбусуфьянның йортына өлкән кешеләр дә җыела. Мәгърифәтче авылдашларына мәдәни һәм техник яктан алга киткән халыклар турында сөйли. Күршебез татарлар үрнәгендә беренче чиратта безгә мәктәпләр ачарга, халыкны укый-язарга өйрәтергә, фән-гыйлемгә күзен ачарга кирәк, ди.

К. Насыйри кебек үк, туган тел һәм әдәбиятны өйрәнүгә, ана телендә китаплар чыгаруга Ә. Акаев та бик зур әһәмият бирә. Каюм Насыйри сүз һәм төшенчәләр байлыгы, барлык төзелеше буенча татар теленең зур потенциаль мөмкинлекләргә ия булуын күрсәткән булса, кумык теле хакында Ә. Акаев: «...безнең телебез башка халыклар телләреннән һич тә ярлы түгел. Тик безнең телдә моңа чаклы дәреслекләр бастыру, борынгы кумык культурасын һәм тарихын өйрәнү җайга салынмаган. Туган телебездә матур әдәбият китаплары чыгару — культурабызны аякка бастыру юлы менә шул»[1], — дип яза.

Туган телгә, тарихка багышланган хезмәтләрендә Әбусуфьян кумыкларның халык авыз иҗатын һәм җанлы сөйләм телен нигез итеп ала, туган телнең сафлыгы өчен көрәшә. Каюм Насыйриның рус сүзләрен урынлы-урынсыз куллану рус телен әйбәт белүне күрсәтми, дигән мәгълүм фикерен куәтләп, «Къылыкъ китаб»ында Акаев болай ди: «Үз туган телендә сөйләшкәндә икенче бер телдән сүзләр кыстыру килешми. Ул сүзләр үз телебездә булмаган тәкъдирдә әле моңа күнәргә мөмкин. Ләкин үзебездә «ушатмакъ», «къабул этмак» яки «янгъылыш», «хата» дигән сүзләр була торып, ник «принимать», «ошибка» дип сөйләшергә? Безгә рус теле бик кирәк тә, ләкин аны үзебезнең тел белән бутамыйча файдаланып булмыймы икән?»

Туган телнең сафлыгы өчен көрәш К. Насыйри һәм Ә. Акаев өчен тар милли кысаларга бикләнүне аңлатмый. Киресенчә, алар татар һәм тау халыклары арасында рус телен өйрәнүне, рус реалистик әдәбиятын пропагандалауны бурыч итеп куялар, рус халкының культура мирасына мәхәббәт һәм ихтирам тәрбиялиләр. Шушы максатлар белән К. Насыйри 1890 елда «Россиянең кыска тарихы»н татарчага тәрҗемә итә, тарихи хезмәтләрендә рус халкының күренекле эшлеклеләренә җанлы характеристикалар бирә. Ул русларны да, мөселманнарны да тумыш һәм табигатьләре белән тигез саный. «...Россия кешесе мөселманнар белән бер җирдә торган һәм бер җирдә үскән, бер икмәкне ашап үскәнлекләре сәбәпле, бу ике халык бер-берсенең гадәтен вә мөгамәләсен яхшы беләләр»[2], — дип яза ул.

Акаев та шундый ук карашта тора. Аның сүзлекләрендә русларның җанлы сөйләм теленә шактый урын бирелә. Акаев шәрык халыкларының классик әдәбияты үрнәкләрен дә туган телендә эшкәртеп бастыра. «Барлык кеше дә тумыштан тигез хокуклы, шуңа күрә һәркемгә дә бер үк төрле караш булырга тиеш», — дип яза ул «Къылыкъ китаб»ында.

Һәр ике мәгърифәтче халык авыз иҗаты җәүһәрләрен җыюга зур игътибар итә. Алар туган җирләренең бик күп төбәкләрендә булганнар, халык арасында йөргән тарихи риваятьләрнең, җыр, мәкаль һәм әйтемнәрнең бик күбесен иң башлап язып алганнар. К. Насыйри үзенең календарьларында, «Кырык бакча» (1880), «Фәвакиһелҗөләса» (1884), рус матбугатында чыккан «Казан татарларының халык әдәбияты үрнәкләре» (1896) дигән һ. б. хезмәтләрендә хезмәт халкының күп төрле һәм гаять бай иҗат хәзинәсен туплаган һәм фәнни эшкәрткән. Ә. Акаевның «Аджам шиърулары маҗмуасы» дигән антологиясе дә шундый ук зур хезмәт нәтиҗәсе. Монда кумыкларның биш йөзләп мәкаль һәм әйтемнәре, кырык табышмак, йөзләрчә халык җырлары, туй-йола җырлары һәм тарихи җырлар, шулай ук кумык әдәбияты классигы

[1] Абусуфьян Акай, Юз йыллыкъ тынч рузнама, Порт-Петровск, 1904, 3 бит,
[2] Каюм Насыйри, (Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары.) Таттосиздат, Казан, 1948, 135 бит.

Йырчы Казакъ әсәрләре кергән. Китабына биргән кереш сүздә Акаев болай ди: «Җырларны өйрәнеп һәм тикшереп башка халыклар[1] йөз еллык, мең еллык тарихларын күз алларына бастыралар. Безгә дә шундый вакыт килеп җитте дип уйлыйм».

Ә. Акаевка, педагог буларак, Насыйриның укыту һәм тәрбия мәсьәләләре буенча хезмәтләре дә зур тәэсир ясаган. Остазы К. Насыйри кебек, Акаев укытучыны җәмгыятькә ни дәрәҗәдә файда китерүеннән чыгып бәяли. Аның аңлавынча, укытучы киң белемле, үзенең эшенә чын күңелдән бирелгән кеше булырга, уку-укытуда яңа методика кулланырга тиеш. Яшь буынны тәрбияләүгә гомерен багышлаган кешегә халык тарафыннан ихтирам күрсәтелергә тиеш. «Кызганычка каршы, — ди ул «Әлифба» китабында, — бездә укытучы хезмәтен бәяли белмиләр, аларга хөрмәт юк. Чөнки бездә байлыкны гыйлемнән артыграк күрәләр».

«Кырык бакча»сында К. Насыйри «һәрбер нәрсәнең чиге бар, акылның чиге юк» дигән булса, Әбусуфьян «Яшлагьа насихат» (1913) исемле философик-эстетик поэмасында гыйлем һәм акылның файдасы турында шул ук идеяләрне үстерә.

К. Насыйри үзенең хезмәтләрендә балаларны кече яшьтән тәрбияләү таләбен куя. Балаларның үз-үзләрен белә башлаган чагыннан алып мәктәпне тәмамлаганчыга кадәр булган вакытны Насыйри тәрбия эшендәге иң кадерле, иң мөһим чор дип атый. «Әлифба»сының «Укытучыга бернечә сүз»[2] дигән бүлегендә Әбусуфьян: «Балаларны мәктәпкә җиде яшьтән бирергә кирәк. Башлангыч мәктәптә алар ике ел укырга тиешләр. Беренче елда көнгә дүрт дәрес, икенче елда — биш дәрес үткәрелергә тиеш. Дәресләр расписание буенча бара, тәнәфес һәм каникуллар мәҗбүри», — дип яза.

Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаев әхлакый тәрбия мәсьәләләренә даими игътибар бирәләр. Әхлакыйлык аларның бөтен педагогик концепциясенең нигезен тәшкил итә. һәм ул концепция эшлекле, дөньяви, иҗади характерда булуы, кешенең үз-үзен расларга ярдәм итүе белән әхлак мәсьәләләренә дини-идеалистик карашлардан нык аерыла.

Табигать белемнәрен, медицина, география, тарих, филология һ. б. фәннәр ирешкән казанышларны популярлаштыруда К. Насыйриның роле яхшы билгеле. Ә. Акаев, аның үрнәгендә, халыкка фәнни белемнәр тарату буенча эшчәнлеген шулай ук киң җәелдергән, календарьлар чыгарган, төрле фәннәр буенча китап һәм брошюралар бастырган. «100 еллык календар»енда ул бик күп төрле фәннәрдән мәгълүматлар җыйган, авыл хуҗалыгы, медицина буенча, европача һәм гарәпчә ел исәбе, төрле йолалар, халык ышанулары һәм ырымнары турында, табигать күренешләре, күк җисемнәре, педагогика, тарих, иҗтимагый фәннәрдән белешмәләр туплап биргән. Аның календаре халыкның күп гасырлык акыл хәзинәсен, белем һәм тәҗрибәсен эченә ала.

Каюм Насыйри һәм Әбусуфьян Акаевның бер үк типтагы матбугат органнары оештыру буенча эшчәнлекләре дә игътибарга лаек күренеш. Насыйри «Таң йолдызы» газетасын чыгарырга әзерлек алып барган булса, Акаев Дагстанда «Таң чолпан» исемле демократик юнәлештәге беренче әдәби журнал оештыруда актив катнашкан һәм аның битләрендә үзенең мәкаләләрен, халык иҗаты әсәрләрен бастырган.

Әнә шулай итеп, әдәбият, педагогика, тарих, медицина, табигать белемнәре һ. б. өлкәләрдә татар мәгърифәтчесе башкарган хезмәтләр аның кече замандашы Ә. Акаев эшчәнлегендә дәвам итә һәм типологик планда алга үстерелә.

К. Насыйриның карашлары һәм эшчәнлеге Ә. Акаевка гына түгел, кумык демократик әдәбиятын һәм мәдәниятен тудырган мәгърифәтчеләрнең бөтен бер плеядасына йогынты ясый. Алар арасында Д-М. Шихалиев (1811—1880), М-Ә. Османов (1839—1904), әтиле-уллы Батырмурзаевлар — Нухай (1864—1919) һәм Зайналабид (1897—1919), М. Казанбиев (1865—1930), Т. Бейбулатов (1879—1942), С. С. Казбеков (1887—1919) һ. б. ларны күрсәтергә мөмкин. Алар барысы да тегә яки бу дәрәҗәдә татар мәгърифәтчеләре һәм революцион-демократлары Х. Фәезханов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Камал, М. Вахитов, Г. Ибраһимовлар эшчәнлеге белән бәйләнештә булганнар. Аларның кумык мәдәнияте эшлекле ләренә иҗади йогынтысы — Иделнең Каспий диңгезенә коюы кебек үк ачык булган бер хакыйкатьтер.

---

[1] «Башка халыклар» дип язганда Акаевның күз алдына иң элек татар халкы, аның тарихы килеп баса, чөнки ничә тапкыр Казанда булган һәм анда укыган мәгърифәтче бу тарихны бик яхшы белгән.— Автор,

[2] Ә. Акай, Иршадуалсупян (Әлифба), Тимер-Хан-Шура, 1903. 5 бит,

Нурмөхәммәт Хисамов

# ЗАМАН һӘМ ШАГЫЙРЬ

**Җырларым үсте үрелеп**
**Шаулы чор хисләренә.**

Зәки Нури хәзерге татар поэзиясенең әйдәүче шагыйрьләреннән берсе санала. Шагыйрьнең тормышы — гомум халык көрәшенең аерылгысыз өлеше, иҗаты исә шул көрәш юлының шигъри елъязмасы булып күз алдына килә.

Зәки Нури туган Төке авылы Идел буе халыкларының аралашуы юлы өстендә ята. Аның бер ягына өскә авам дип торган Алатырь урманнары килеп терәлсә, икенче ягында — Чүпрәленең Сембер далаларына барып тоташкан кара туфраклы көпшәк җирләре. Шуңа күрә Зәки Нури әсәрләрендә илебез халыкларына яңа язмыш алып килгән Ленин образы аерым урын алып тора. Бөек юлбашчыга булган рәхмәт һәм олылау хисләренә, якташ буларак, аның белән горурлану да килеп кушыла. Ленин темасы шагыйрьнең шигъри дөньясына алып керә торган иң якты, иң туры юл булып тора. Бу тема, Зәки Нури иҗатын эчтән яктыртып, аны чорга аваздаш итә, аның ил һәм дөнья күләмендә барган вакыйгаларга биргән шигъри бәясен гражданлык пафосы белән сугарыла торган мәгънәви үзәк ролен үти. Ильич туган төбәккә биографик мөнәсәбәте дә булганга күрә, аның әсәрләрендә бу тема күбрәк биографик фактлар аша ачыла. Җырларында ул юлбашчы туган шәһәрне олылап телгә алса («Әй, Сембер, Сембер, тудырдың бөркет...»), шигырьләрендә, Ленин тормышына бәйле фактлар аша, илнең революцион үткәненә лирик экскурс ясый. Бу темага очрактан-очракка гына кагылмыйча, шагыйрь аны максатлы рәвештә күтәрә. Шигырьләренең исеме үк шагыйрьнең шул максатка ирешү юлында гаять зур географик араларны иңләвен күрсәтә. «Җыр белән яңа очрашу» (Казан), «Шушь елгасы буенда» (Себер), «Тауларга менү», «Сулар төшә таш алып», «Диңгез күзе» (Польша) кебек шигырьләрендә ул юлбашчы турындагы кичерешләрен төрле ил һәм төрле халыклар язмышына бәйләп күзалларга омтыла.

Һәр өлгергән шагыйрьнең шигъри дөньясында туган илнең кайсыдыр почмагы, туган ил табигатенең нинди дә булса бер үзенчәлеге чагылучан була. Берәүләрдә — мәгърур уйчанлыгы белән чал түбәле таулар, икенчеләрендә — тынгысыз стихия белән мәһабәт диңгез, өченчеләрендә халкының киң күңеле сыман иксез-чиксез дала... Зәки Нури иҗатына шундый колоритны урман бирә. Чөнки шагыйрь тормышының һәм шагыйрь эшчәнлегенең байтак өлеше урман белән бәйләнгән. Мунчәли җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, Зәки Нури Лубян урман техникумына укырга керә. Аны бетергәч, сугышка чаклы ук инде Ерак Көнчыгышта урман эшендә эшли. Амурдагы Николаевск шәһәрендә диңгез порты төзүдә катнаша.

1941 елда язган «Яшь фронтовик җыры»нда шундый юллар бар:

**Алда юлларның,**
**Семафорларның**
**Утлары яна.**
**Үзем үстергән,**
**Яшәреп килгән**
**Урманым кала...**

Әлеге юлларда шагыйрьнең үз яшьлеге чагыла.

Зәки Нуриның сугышчан юлы да үзенчәлекле. Ул да урман белән бәйле. Сугыш башланган елдан алып, Белоруссия азат ителгәнче, шагыйрь легендар Заслоновның партизан отрядында хезмәт итә. Татар шагыйрьләренең совет халкы, Совет Армиясе кичергән барлык сынауларда өлеше бар. Гадел Кутуй, Шәрәф Мөдәррис, Фатих Кәрим, Әхмәт Фәйзи, Салих Баттал, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур кебек шагыйрьләр поэзиягә фронт вакыйгаларының эпик күренешләрен һәм героик лирикасын алып килсә, Муса Җәлил, Хәйретдин Мөҗәй кебек шагыйрьләр фашист тоткынлыгында, концлагерьларда кешелек һәм гражданлык горурлыгын саклап калган героик характерлар тудырдылар. Зәки Нури исә татар поэзиясенә партизан учаклары ялкынын һәм партизан чынбарлыгының дәһшәтле романтикасын алып килде.

Тыныч тормыш шартларыннан үтә кырыс сынауларга килеп кергән яшь егет кайвакыт сугышчан бурыч һәм шәхси бәхет хисе арасындагы драматик тартышлар уртасында кала. Шушындый чакта дуслык, мәхәббәт кебек кешелек хисләре, төнге урман уртасындагы учак ялкыны сыман, яктырак булып, яңача ачылып китә. Кирәк булса, сугышчан бурыч хакына шәхси мәнфәгатьләрен ул онытып тора һәм, ниһаять, сугышчан бурыч үзе шәхси мәнфәгатькә әверелә. Егет хәтта төшендә дә сугышчан бурычын исеннән чыгармый:

**Үпмә әле, иркәм, үпкә каты,**
**Иреннәрем кирәк, каплама.**
**«Атакага!» — кычкырырга вакыт —**
**Әнә дошман каршы ташлана.**
(«Озакламый атака башланды».)

Тыныч тормыш күренешләре, туган як табигате, тылдагы хезмәт аның күз алдына сөйгән яр образы аша килә. Халык поэзиясе традицияләренә таяну шагыйрьгә кичерешне самимирәк, лирик нәфисрәк итеп ачып бирергә ярдәм итә. Ватан сугышы чоры татар поэзиясенә хас булганча, традицион образларны куллану шигырь һәм җырларына романтик рух бирә.

Шагыйрь сугыш чынбарлыгының үзеннән алынган реалистик тасвир чаралары да таба. Сугышта хат алуның солдат өчен ничаклы зур шатлык булуын, мәсәлән, ул шундый чагыштыру ярдәмендә ача:

**Ләкин килгән! Хат ташучы егет**
**Сумкасына минә эләккән!**
**З у р б е р ш ә һ ә р с у г ы ш ы п а л г а н к е б е к —**
**Аны алу якын йөрәккә.**
(«Зур бер шәһәр алган кебек».)

Халык, сугыштагы улларын кайгыртып, меңәрләгән посылкалар сала. Шуларның берсе партизан отрядына килеп төшә. Һәм шагыйрь акбүз яулык җибәргән билгесез кызга шушындый җавап яза:

**Көт. Кайтырмын, таныш түгел кызым,**
**Җиңү алып сиңа бүләккә!..**
(«Бүләк».)

«Акбүз яулык» образы да, бүләккә бүләк белән җавап бирү йоласы да халык поэзиясеннән алынган. Әмма шагыйрь аларны, сугыш чынбарлыгы аша үткәреп, солдат бурычының гуманистик мәгънәсен ачуга хезмәт иттерә. Халык иҗатындагы егет белән кыз мөнәсәбәтенә кагылышлы шигъри детальләр, шулай итеп, солдат һәм халык бәйләнеше яссылыгына күтәрелә.

**һәр көрәштә бул син батыр җанлы,**
**Батыр көрәш, матур сөя бел!**

Әлеге шигырьдән күренгәнчә, аның яшь кешесе мөһим ике сыйфатны — солдат батырлыгын һәм кешенең әхлакый матурлыгын үзендә туплаган лирик герой булып күз алдына баса. Шагыйрь үзенең Ватан сугышы чоры поэзиясенә шушы идеал югарылыгыннан йомгак ясый. Фидакарь көрәшенең җиңүне якынайтуын күргәнгә, ул киләчәккә оптимистик карый. Сугыш уты эчендә табылган идеалын шагыйрь тыныч тормыш шартларында тагын да үстерә, камилләштерә төшә:

**Җиңү килер, безнең учакларны**
**Салют итеп күккә чөяр ул,**
**Кем көрәшә сагынып шул чакларны,**
**М а т у р я ш ә р, м а т у р с ө я р у л.**

(«Ял иткәндә җырла, партизан!»)

Шагыйрьнең сугыш чоры эзләнүләреннән торган беренче китабы, шигырьләре, фронт сызыгы аша үтеп, Казанга килеп ирешә. һәм 1945 елда Гомәр Бәшировның сүз башы белән «Шигырьләр» исеме астында басылып чыга. Җыентыктагы аерым шигырьләргә ритмик төгәллек һәм эмоциональлек җитми, образлы тел эзләп, кайвакыт автор салкын техницизм юлына кереп китә. Әмма шундый кимчелекләре булса да, ул татар халкы каршына кыю сугышчан юл узган шагыйрь сыйфатында кайта. Шагыйрьнең сугыштан соң чыккан әсәрләрен дә әдәби тәнкыйть җылы бәяләп уза[1]. Зәки Нури, соңрак партизанлык еллары истәлегенә кире әйләнеп кайтып, «Дан юлы» поэмасын һәм «Үлгәннәр дә үч алды» дигән хикәяләр җыентыгын чыгарды.

Белоруссияне оккупантлардан азат иткәч, шагыйрь Орша шәһәр Советы башкарма комитетында председатель урынбасары хезмәтен башкара. 1946 елда, Татарстанга кайтып, язмышын яңадан урман белән бәйли: Татарстанның Буа һәм Тархан районнарындагы урман хуҗалыгына җитәкчелек итә. Озакламый шагыйрьгә «үзе үстергән, яшәреп көлгән урманы» белән бөтенләйгә саубуллашырга туры килә. Әмма бу юлы инде шагыйрь, аны җырга күчереп, үзе белән мәңгегә алып китә. Ул инде, тормышның һәм иҗатның яңа биеклегеннән торып, урман белән рухи тиңнәрчә сөйләшә:

**Урманым — җырым оясы!**
**Килде шундый уй миңа:**
**Син йөрәгемә сыясың,**
**Ә мин — синең куеныңа.**

(«Урманым — җырым оясы».)

Шулай итеп, урман шагыйрьнең әсәрләренә тапкыр метафора («Җырым оясы») булып килеп керә.

Урман Зәки Нури шигырьләренең бәрәкәтле оясы булып чыкты. Аның шигырьләренең аеруча олысы, халыклар дуслыгын данлый торганы, чын мәгънәсендә шушы «ояда» үскән. Шагыйрь иделдәшләребез, күршеләребез булган мукшылар, чувашлар белән яшьтән аралашып үсә. Төке татарлары салып биргән җылы өйләрдә яшәүче күрше Төке мукшылары яхшылыкка шундый ук яхшы һөнәр белән рәхмәт әйтүчән. Шымыршы юлының салкын карын нинди итекләр шыгырдата дисәң, Төке мукшылары басып биргән җылы итекләр шыгырдата икән!

Алатырь урманнары борын-борыннан Идел буе халыкларының туганлык бишеге булып килгән. Монгол басып алулары чорында Урта Идел урманнары болгар бабаларыбызны, мари, удмурт, чуваш, мукшы күршеләребезне үзенә сыендырган, Аксак Тимер афәтеннән саклашкан. «Кара урман» җырының яшәүне һәм дуслыкны раслаучан аһәңе Алатырь урманнары уртасында да үзенә кайтаваз тапкандыр. Зәки Нури-

---

[1] Л. Җәләй. Поэзиябезгә караган кайбер фикерләр. «Совет әдәбияты» журналы. 1948 ел. 8 сан.

ның «Чавай чишмәсе», «Чабаксарда очрашу», «Эрзя күргәзмәсе» кебек шигырьләрендә күрше халыкларга дуслык хисе искиткеч матур һәм мәгънәле яңгырый.

Халыклар дуслыгы темасын шагыйрь киң планда ала. «Кәләпүш» шигырендә ул үзбәк кардәшләребезгә дуслык хисен җырласа, «Арарат» шигырендә әрмән халкының читләрдән күргән җәбер-золымнарына әрнүле теләктәшлек белдерә. Рус халкына мәхәббәт Ленин һәм революция темасы аша ачыла. Шагыйрь илебез халыкларының дуслыгын күп кенә шигырьләрендә әдәбиятлар һәм мәдәниятләр дуслыгы рәвешендә чишә. «Мәхтүмколый», «Йөрәкләр күрешә» кебек шигырьләрдә төркмән һәм казакъ әдәбиятларына поэтик бәя бирелә һәм ул әдәбиятларны иҗат иткән халыкларга ихтирам хисе җырлана.

Интернациональ дуслык темасы халыкара күләмгә күчерелгәндә, үзәккә Советлар Ватаны өчен горурлык хисе куела.

**Кул бирә дуслар — поляклар:**
**Син Совет иленнән,— дип,—**
**Җилферди безнең байраклар**
**Сезнең ил җиленнән,— дип.**

(«Күкрәүле яңгыр».)

«Салют-букет» шигырендә совет патриотизмы, социалистик Ватанның бөтен дөньяга үрнәк көче һәм безнең илдә башкарылган эшләрнең гомум кешелек әһәмиятенә ия булуы аерым бер лирик җылылык белән сурәтләнә. Туплар һәм чәчәкләр темасы поэзия өчен һәр вакыт актуаль тема булып кала. XX йөзнең 60 нчы еллары туплар белән чәчәкләрне килештерергә омтылуның үтә фаҗигале нәтиҗәләрен дә күрде. Демонстрантларга төбәлгән көпшәгә гөл чәчәге тыгарга теләгән Америка студенткасының асфальтка аккан ал каны кешелек күңелендә әле дә кипмәгән. Империалистик илнең туплары гөл чәчәген үзләренә якынайтырга теләмәделәр. Солдатларның салкын канлы залпы яшь пацифистканың гомерен кисте. Зәки Нуриның «Салют-букет» шигырендә әнә шушы килештергесез сангалган ике күренеш органик берлектә бирелә. Тыныч илнең бәйрәм салютын шагыйрь чәчәк букетына тиңли һәм шундый теләкне белдерә:

**Атсын иде шундый чәчәк кенә**
**Барлык илнең барлык туплары!**

Шагыйрь иҗатында халыклар дуслыгы кебек зур теманың күтәрелүен татар поэзиясендәге бай традицияләрдән һәм коммунистлар партиясенең сәяси-тәрбияви эшчәнлегеннән башка күз алдына китерергә мөмкин түгел. 1948 елдан бирле Зәки Нури шушы эшчәнлектә коммунист булып, партиянең идея көрәшчесе булып катнаша.

Зәки Нури иҗатының колачы, аеруча халыклар дуслыгы темасы, аның күпкырлы иҗтимагый эшчәнлеге белән дә бәйләнгән. Шагыйрь күп еллар буе Татарстан язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре булып эшләде, берничә ел язучылар союзы идарәсенең председателе булып торды. Хәзер ул «Казан утлары» журналының баш редакторы вазифаларын башкара. Татарстан АССР Верховный Советы депутаты буларак, ул һәр вакыт республика җәмәгатьчелеге, хезмәт ияләре белән тыгыз аралашып яши. Илебезнең төрле республикаларында, чит илләрдә күп булу аның иҗат колачын, аралашучан табигатен, көләч, киң күңелле холкын тагын да ачып җибәрә. Нәтиҗәдә, безгә кояшлы үзәннәрнең киң сулышын, карлы тауларның мәгърур ямен, ерак кырлар хуш исен туплаган «шигырь бәйләмнәре» кайта тора.

Зәки Нуриның дуслар яныннан беркайчан да буш кул белән кайтканы юк. Ул кимендә бер уч яңа чәчәк орлыклары алып кайта. Ел дәвамында ул орлыклардан әйбәт шытымнар чыга. Зәки Нуриның тугандаш республикалардан: казакълардан, белоруслардан, әзербәйҗан һәм таҗиклардан алып кайткан тәрҗемәләре зур әдәбиятыбызга әнә шундый шытымнар булып өстәлә. Шагыйрь тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегенең төп мәгънәсен үзе шулай ачып бирә:

**Кыскарсыннар юлның ераклары,**
**Очрашсыннар җырда халыклар!**

СССР халыкларының барлык әдәбиятларына якын торып, алар арасындагы бәйләнешләрне ныгыту юлындагы игелекле хезмәте шагыйрьнең җәмәгать эшчәнлеген тагын да киңрәк мәйданга алып чыкты. Зәки Нури — СССР Язучылар союзы идарәсенең секретаре.

*
* *

Сугыш шартларыннан тыныч тормышка күчү Зәки Нури лирикасында, тасвир чарасы буларак, антитезаны активлаштырып җибәрә. Антитеза тыныч көннең ямен, мәгънәсен аеруча калку итеп ачарга ярдәм итә.

Чәчәк ата кебек үзе күңел,
Таң шикелле хис саф, уй якты.
Мине бүген б о м б а ш а р т л а п т ү г е л,
С а н д у г а ч л а р с а й р а п уятты!

Тәрәзәмне тулы итеп ачтым:
Таныш урман, камыш, күл әнә...
Ничек рәхәт, җәйнең җиле керә
Б л и н д а ж ы м а т ү г е л, б ү л м ә м ә...

(«Ачык тәрәзә».)

Лирик герой тыныч тормышка хозурланып кына калмый, әлеге хис аңарда тыныч тормышка хас матурлыкны яклау теләге дә уята. Антитеза алымын шагыйрь сугышның иләмсез күренешләрен тулырак ачуга, тыныч тормыш, табигать матурлыгын сурәтләүгә хезмәт иттерә. «Днепрга» шигырендә бу хис аеруча көчле чагыла:

Мин яшь коеп, син кан агызып,
Аерылышкан идек бервакыт.
Үтәр юллар булды бик озын...
Очрашабыз менә җырлашып!

. . . . . . . . . . . . . .

Бүлдермәскә тиеш кошлар моңын
Мәңге монда бомба шартлавы.

Зәки Нуриның 50 нче еллардагы иҗатына тематик киңлек хас. Аның әсәрләренә хезмәт пафосы, төзелеш дәрте килеп керә, эпик башлангыч көчәеп китә. Соңгысының исә тискәре нәтиҗәләргә китерүен дә әйтеп китәргә кирәк. Кайбер шигырьләрдә лирик дулкынны салкын рационализм күмеп китә. Илнең хуҗалык тормышындагы вакыйгалар кайвакыт факт буларак кына саналып узыла. («Зур юл ачык» шигыре.) Аерым белгечлеккә, һөнәр ияләренә багышланган шигырьләрдә («Агроном», «Монтер», «Бригадир» һ. б.) технологик процесслар кеше хисләрен күләгәдәрәк калдыра.

Хезмәт иясе массаларының төрле катлауларына мөрәҗәгать итсә дә, шагыйрь асылда стильләштерү юлы белән бара, еш кына аларның индивидуальләштерелгән образларын тудыруга ирешә алмый кала. Һөнәр төрләре, төрле белгечлек ияләре шигъри шартлылык буларак кына кабул ителәләр. Нинди генә һөнәр иясе турында сүз бармасын (геологмы, чик сакчысымы, экскаваторчымы ул), һәр очракта лирик конфликт үзәгендә егет белән кызның аерылу сагышы тора. Башта шушы хис ерак төзелешкә барыргамы-бармаскамы дип икеләнү рәвешендә гәүдәләнсә, аннары кавышу өчен хезмәт темпын арттыруга кайтып кала. Бу хәл лирик конфликтны схемага, шаблонга әйләндерә. Моның сере, безнеңчә, сугыштан соңгы төзелеш рухына һәм характерларның катлаулылыгына төшенеп җитә алмаудан килә. Яңа гына сугыш утында булып, кешеләрне кискен аерылып торган ике төркемдә (дошман яки сафташ) танып белергә өйрәнгән яшь кешегә катлаулы яңа чынбарлыкны үзләштерү ансат булмый, әлбәттә. Лирик конфликтлар артында шагыйрьнең сугыш чорындагы үз лирик каһарманы төсмерләнә. Ул да бит, кызы белән кавышу өчен, бар көчен биреп, җиңүне батырларча ашыктыручы егет иде. Шуның өстенә, бу хәл бер Зәки

Нурига гына хас булмыйча, сугыштан соңгы бөтен поэзия кичергән күренешкә барып тоташа.

Ләкин ун елга сузылган бу эзләнүләрнең уңай нәтиҗәсе шагыйрь өчен ифрат зур була. Лириклыкка килүне бу үсешнең төп нәтиҗәсе итеп санарга кирәк. Дөрес, шагыйрь сугыш чоры поэзиясендә дә лирик булып башлаган иде. Хисләре самими булса да, ул чорда әле сәнгать чараларының ярлылыгы күзгә ташлана. Яңа унъеллыкта исә шагыйрь бик күп шәхесләргә өләшенгән, төрле һөнәр ияләренең «мин»нәре аша, ягъни халык вәкиленең лирик монологы аша, шигырь техникасын камилләштереп һәм арадаш рифма культурасын үзләштереп, лириклыкка әйләнеп кайта. Аның шигъри «мин»е, ниһаять, миллионнарның уртак сыйфатларын, кичерешләрен үзендә туплаган җыелма лирик характер булуга юл ала.

Шагыйрь Ватанны сөюче, тынычлык өчен көрәшүче миллионнарның уртак дәртен, уртак омтылышын чагылдыруның уңышлы алымын таба. Ул — илдәш белән ихлас әңгәмә алымы.

**Мин яшим тынычлык илендә,**
**Шатлыкны ник җырга салмыйм соң!!**
**Уйларың шундый ук синең дә,**
**Син, илдәш, бу хисне аңлыйсың.**

. . . . . . . . . . . . . . .

**Эшебез бөек һәм намуслы,**
**Әйтик, син заводта эшлисең,**
**Ләкин ил һәм дөнья язмышы**
**Өчен дә җаваплы кеше син.**

(«Мин яшим тынычлык илендә».)

Шагыйрьнең идея һәм сәнгать ягыннан җитлегүе әсәрдә гәүдәләнгән эшче-гражданин идеалында күренә. Аның сугыштан алып чыккан «матур яшәү» турындагы идеалы батыр хезмәт булып күз алдына баса. Иҗат кешесенең гражданлык идеалы эшче гражданин идеалына тиңләштерелә.

Батырлык һәм матурлык төшенчәләре Зәки Нуриның күп шигырьләрендә янәшә йөри. Валентина Терешковага багышланган шигырендә, мәсәлән, шундый юллар бар:

**Юлы — ерак йолдызларга**
**Күп тапкыр барып кайтырлык.**
**Шундый ул безнең кызларда**
**М а т у р л ы к белән б а т ы р л ы к!**

(«Галәм акчарлагы».)

Муса Җәлил турындагы шигыре дә «Матур җырлаган батыр» дип атала. Кыскасы, замандашның рухи йөзен, әхлакый гүзәллеген шагыйрь шушы төшенчәләрнең гармониясендә күрә.

Зәки Нури иҗатын эчтән бөтен иткән нәрсә — ул аның әсәрләрендәге идея эзлеклелеге. Бу, барыннан да элек, аның иҗтимагый идеалының, кеше идеалының камилләшүендә күренә. Шагыйрь сугыш чорында ук гармонияле үсешкә ирешкән шәхес мәсьәләсен күтәргән иде. «Ялкын» шигыре аның бөтен мәхәббәт лирикасына мәгънәви кереш булып тора. Анда «матур яшәп, матур сөю» идеалы лирик геройның үз шәхесендә болай гәүдәләнә:

**Шуңа мин шат: йөрәктә саф**
**Ялкыным яши.**
**Илем өчен, синең өчен**
**Талпыну яши.**

Йөрәкнең ике талпынуын үзендә бер итеп яшәүне ул чор таләбе итеп саный, җырдагы идеалы итеп хисаплый.

**Чорыма хас, җырыма хас**
**Йөрәк бүген ул.**

**Шул ялкынсыз, ул — салкын боз,—**
**Кирәк түгел ул!**

Шул ук фикерен шагыйрь үз әсәрләрендәге башка каһарманнардан да кабатлата. Төзелешкә геологлар һәм грунт үрнәкләре ташучы пилот, мәхәббәттә кыюсызлыгын җиңеп, болай ди:

**Юк, хәзер инде оялмыйм,**
**Тартынып йөрү нигә!**
**Илем приказы дип аңлыйм**
**Яр сөя белүне дә!**

(«Кыю да, кыюсыз да».)

Зәки Нуриның мәхәббәт шигырьләре фәлсәфи юнәлеш алганда, сөю дигән үтә интим хис башка олы мәсьәләләр, гражданлык бурычы һәм җаваплылык хисе белән үрелгәндә уңышлы чыга. Бу — асылда Тукай традициясеннән килә торган күренеш. Югарыда телгә алып киткән «Ялкын» кебек шигырьләрдә Дәрдмәнд эшләп калдырган строфика кулланыла. Әмма мәхәббәт лирикасында схемалаштыру сыман бер кимчелек тә күзгә чалынып уза. Кайвакыт хиснең үз байлыгын бирү урынына, аны вакыйга санауга кайтарып калдыру очрый.

Зәки Нуриның 50 нче еллар иҗатында юмористик ерганак юл ала башлый. Юмор башлыча шагыйрьнең лирик шигырьләрендә балкып-балкып китә. Югарыда китереп үткән («Илем приказы дип аңлыйм яр сөя белүне дә») юмористик деталь — лирик шигырьләрдәге бетемнең характерлы бер үрнәге.

Тормыштагы кимчелекләргә карата килешмәүчәнлек алга таба лириканың җылы куенындагы юморны ирониягә, иронияне сарказмга үстереп җибәрә. Нәтиҗәдә сатира-юмор шагыйрь иҗатында мөстәкыйль тармак булып аерылып чыга.

Шагыйрь үз иҗатының тәмам җитлегү чорына 60 нчы елларда килеп керә. Бу чорга хас иң төп үзенчәлек жанрлар дифференциациясеннән гыйбарәт. Ягъни Зәки Нури иҗатындагы ике башлангыч — лирика һәм сатира-юмор — мөстәкыйль тармаклар, аерым-аерым жанрлар булып аныклана. Шагыйрь егерме ел буена туплаган бөтен иҗат тәҗрибәсенә синтез ясый, лиризм аңарда фәлсәфи төсмер белән байый. Бу чорда шигъри тасвирның, поэтик гомумиләштерүнең аллегория, синекдоха, метафора кебек чаралары активлаша.

Шагыйрь күбесенчә табигать аллегориясенә мөрәҗәгать итә:

**Иделдә, тулып хуш исләргә,**
**Чәчәккә күмелсә бакчалар,**
**Беләбез, бу исне иснәргә**
**Дунайда тәрәзә ачалар.**

(«Мин яшим тынычлык илендә».)

Иделнең бөтен Советлар илен, Дунайның көнбатыш чикләребез буйлап сузылган социалистик илләрне гәүдәләндерүен әйтеп тору артыктыр. Ә тәрәзә ачып чәчәкләр иснәү өчен аралар ничаклы якын булырга тиеш! Әлеге мисал 50 нче еллар поэзиясендә туган матур бер үрнәк. Табигать детальләре аша җәмгыятьнең зур күренешләрен гәүдәләндерүгә хезмәт итүче мондый шигъри алым шагыйрьнең соңгы еллардагы иҗатында бөтен мөмкинлегенә ачылып китә.

«Килдең, яз!» шигырендә ул органик бер рәвешкә кереп, сәнгатьчә камиллеккә ирешә.

Пейзаж лирикасында, табигать аналогияләрендә поэзиянең чорга хас үзенчәлеген дә, шагыйрьнең үз индивидуаль йөзен дә абайларга мөмкин. Җәмгыятькә, мәсәлән, табигать күзе белән карау бар. Ягъни табигатьнең сафлыгын, гармониясен җәмгыятьтән таләп итеп, изүче җәмгыятьнең кешелексез якларын табигатькә ят итеп күрсәтү бар. Бу — иҗтимагый фикернең мәгърифәтчелек дәверенә хас күренеш. Бозык җәмгыятькә каршы табигать гармониясен идеал итеп кую романтизмга хас. Моның мисалларын Галимҗан Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында һәм романтик Сәгыйть Рәмиевтә күрергә мөмкин. Тукайда, табигать — шагыйрь өчен илһам чыганагы, Дәрдмәндтә — кешенең яшәү хозурлыгы, кайгы-хәсрәте, сагыш-моң гәүдәләнеше,

Туфанда исә кешенең фәлсәфи күз күремен мәңгелек киңлекләргә алып чыгу чарасы, яшәү мәгънәсе турында уйланулар җирлеге булып тора.

Зәки Нури шигырьләрендә табигать үзенчәлекле урын тота. Ул үзенчәлекнең нигезендә шагыйрьнең иҗтимагый фикерләвенә хас темперамент, активлык ята. Шагыйрь табигатькә һәр вакыт иҗтимагый тормышның эре күренешләре аша карый. Нәтиҗәдә җәмгыять тормышы якты, оптимистик рухта тәсмерләнә, ә табигать үзе ашкын бер симфония рәвеше ала, үзгәреп, яңарып, тәзекләнеп торган мәгънәви күренешкә әверелә. Шушы күренешне үзенең йөрәге аша кичерүче лирик каһарманга табигатьнең һәм тормышның мәһабәт яңарышы, тыелгысыз көч белән камиллеккә омтылышы матур бер өлгегә әйләнә. Лирик каһарман шушы процесстан үзенең тынгысыз иҗат омтылышына куәт, гыйбрәт ала.

Шагыйрьнең «Килдең, яз!» әсәре табигатьнең мәһабәт бер тантана чорын тасвирлый. Анда шигъри чаралар, катлаулы метафора төсенә кереп, зәвыклы синтез дәрәҗәсенә ирешәләр:

**Килдең, яз! Нур сиптең сөенә-сөенә,**
**Күңелле очынып бакчада сайрадың,**
**Элдең, яз, сукмаклар һәм юллар буена,**
**Күп итеп элдең син яшь гөлләр байрагын.**
**Карларны агыздың еракка-еракка,**
**Уяттың бакчалар һәм урман бөресен.**
**Син һәрбер үләнгә, син һәрбер куакка**
**Әйтерсең ямь-яшел ут төртеп йөрисең...**

Күрүебезчә, шигъри сулышны киң итеп алырлык үлчәм сайланган. Шушы уникешәр иҗекле юллар образлы тел белән тыгызланган. Рифмалар юл азагында гына түгел, борынгы төрки шигырь традициясен хәтерләтеп, анафора рәвешендә юл башында да килә. Ялгам һәм кабатлаулар мәгънәви тоташлыкны тәэмин итә һәм тасвирның эпик колачын киңәйтә. Шигырьнең образлы теле, метафора һәм аллегорияләре артында, бөтен интонациясендә «Октябрь адымнары» шигыренең рухы тәсмерләнә:

**Нурга күм син, кояш, безнең юл киңлеген,**
**Кояшка очынып җилфердә син, комач!**
**Дәвернең балкышы — Октябрь, син бүген.**
**Син — безнең зур адым, син — безнең киң колач.**
**Иллардән илләргә җилкенеп атлыйсың,**
**Ишәя һәм ныгый азатлык постларың...**

Шагыйрь табигатькә дә, җәмгыятькә һәм аның тарихына да бер үк күз,— дөньяны яңарту, төзү, бизәү күзе белән карый. Ул карашны гражданлык горурлыгы сугара. «Күп итеп байраклар элеп йөрүче» яз безнең Октябрь яки Май бәйрәмнәребезне хәтерләтә. Табигать темасы шагыйрьнең иҗат бурычы, аның иҗтимагый-эстетик мәгънәсе, гуманистик вазифасы турында уйлануларына яңадан-яңа этәргеч биреп тора. «Чәчәкле этюд» шигырендә табигатьнең зирәк хуҗасы да, игелекле дусты да булган кешелекле кеше, иҗат иясе күз алдына килә. Лирик герой, үзенең учында ачылып киткән язгы чәчәк бөресенә карап әсәрләнгәннән соң, аның үзендә дә изге бер омтылыш кабынып куя:

**...Зур яз туа нәни бөредән,**
**Язның аның җиңел йөреше.**
**Талма, аяк, туйма йөрүдән,**
**Син яз тудыр, күңел бөресе.**

Үзенең полемик шигырьләрендә дә шагыйрь табигатьтән образлы аналогияләр эзли. Заманның төрле тенденцияләре, төрле агымнары бар. Шуңа күрә «агымга иярү», «агымга карау» халык тарафыннан көлкегә алынучан. Ә менә шагыйрь агымга иярүне яклап чыга. Ләкин шаукым мәгънәсендәге агымга түгел, бәлки чорның әйдәүче, тынгысыз агымына иярүне яклый. Алай гына да түгел, ул иярүне шагыйрь иҗат өчен зарури шарт итеп куя.

**...Йөгереклеген суның яратсаң,**
**Яратасың юллар шатлыгын,**
**Авыр юлны җиңел үтәсең,**
**Шул ярату булган чагында.**
**Белсен күңел кибеп бетәсен,**
**Кушылмаса ярсу агымга.**

(«Агымга карап».)

Шагыйрь заманны бүгенге көн мәгънәсендә генә түгел, ә «заманнар бәйләнешы» төсендә ала. Зур тормыш һәм иҗат тәҗрибәсеннән чыгып, ул шундый хакыйкатьне ачыклаган: үткәннәрне тоташ каһәрләү бүгенге көнгә ямь бирми генә түгел, бәлки киләчәкнең дә нигезен корыта. «Заманнар бәйләнешына» кизәнгән кеше бәлане, бәрыннан элек, үз башына ишә.

**Узган юлга, үткән көннәреңә**
**Ыргытасы булсаң әгәр ташлар,**
**Киләчәгең синең өсләреңә**
**Дөбердәтеп таулар ишә башлар.**

Бу кисәтүчән юллар шәхеснең үткәннәренә булган мөнәсәбәткә дә, бөтен бер халыкның тарихын бәяләүгә дә бердәй туры килә.

Табигать күренешләрендә тормышка аналогия үткәреп, шагыйрь һәр вакытта да уңышка ирешә дип булмый, билгеле. Мондый шигырьләрнең кайберсенә мәгънәви эзлеклелек җитеп бетми, вакыт-вакыт образның логикасы бозылып куя. Мәсәлән, «Тамчылар» шигыре шул хакта сөйли торган бер мисал була ала. Киң мәгънәгә ия тасвирны шагыйрь кинәт кечерәйтеп, тарайтып җибәрә:

**Мисал өчен әйтсәң хәтта шул җитә:**
**Азлап тамган әләк безне хур итә.**

Шуннан соң ук шигырьне үтә гомуми мәгънәле юллар белән тәмамлый:

**Тамчыларның яратам мин һәммәсен,**
**Әмма ялган яз тамчысы таммасын.**

Табигатьтә шундый хәлләр була: әйтик, кышның чатнап торган суык көннәре. Ниндидер циклон җылы алып килә дә, түбә карлары эреп тамчы тама башлый, аяк аслары леперди. Кырларда уҗым өсте ачыла. Уҗымнар, моны язга юрап, яшәрергә керешә. Казлар муеннарын суга манчып каңгылдаша башлый... Менә шунда тагын суык китереп бәрә. Бүрәнәләр шартлап ярыла, уҗымнар харап була. Җанлана башлаган бар табигать алданып кала... Шуңа сәбәп булган беренче тамчыны мин «ялган яз тамчысы» дип аңлыйм. Соңгы юлларның да кисәтүчән кырыслыгы, барыннан элек, шагыйрьгә төбәлгән. Ягъни шагыйрьнең, литаврлар сугып, җәмгыятьне ялгыш җилкендерергә хакы юк, аның әсәре чын яз тамчысы булырга тиеш! Мондый шәрехләү Зәки Нуриның югарыда күреп үткән бүтән шигырьләренең дә рухына туры килә төшә. «Әләк»нең исә язгы тамчыга охшавы мөмкин түгел. Ул — кара, вак нәрсә.

Поэзиянең заман белән бәйләнеше, шигырьдә чор рухын, дәвер үзенчәлеген дөрес чагылдыру мәсьәләсе Зәки Нури иҗатында аңлы, максатлы рәвештә куела. Мондый куелыш партиянең заманны бөтен мәһабәтлеге белән сурәтләү таләбеннән килеп чыга. «Җыр белән кабат очрашу» шигырендә сөргеннән Казанга кайткан яшь Володя Ульяновның опера тыңлавы хакында сөйләнә. Геройның эчке монологында без шушындый юлларны укыйбыз:

**...Күзаллый күңелем**
**шушындый бер чакны:**
**Аваздаш булыр җыр**
**өр-яңа чор белән!**

Шагыйрь үзе дә бөтен иҗаты буена җырының заман белән аваздашлыгына омтыла. Заманнан илһам алып тудырылган әсәрләр шагыйрь тарафыннан заман хөкеменә

курыкмый куела. Чорның бер вәкиле булган лирик герой үзенең бар байлыгын кыләчәктә дә заманга багышлау өчен җилкенә:

**Бушамас келәт. Бушамас!**
**Булсын гына саулыгым.**
**Сиңа булыр, сиңа, заман,**
**Минем бөтен байлыгым!**

(«Байлыгым».)



Без шагыйрьнең лирик иҗатын күздән кичердек. Шул ук вакытта Зәки Нури — бүгенге поэзиябездә әйдәүче юмористларның берсе. Лирика һәм сатира-юмор аны иҗатта бердәй күтәрүче ике канат дияргә була. Шагыйрь үзенең чәнечкеле әсәрләрендә иҗат кешесенең әхлагы, җитәкченең гражданлык йөзе, яшьләрнең җәмгыять каршында җаваплылыгы, гаилә иминлеге һ. б. мәсьәләләрне куя. Ул сатираның бик күп төрле алымнарын үзләштергән. Аңарда Хуҗа Насретдин мәзәкләренә хас беркатлы булып көлүне дә, миниатюр мәсәлләрне дә, сүз уйнатуны да, пародия яки фельетон алымын да очратырга мөмкин.

Шагыйрьнең үзенә генә хас сатирик алымнарыннан көтелмәгәнчә тәмамлауны алыйк. Менә аның «Сыер сатып алганда» шигыре. Исеменә карап, үзәктә сатучы һәм алучы мөгамәләсе торадыр дип, берсе алдап, икенчесенең алдануын көтәсең. Товар бик шәптән түгел — сыер тибүчән икән. Шулай да сатучы түгел, алучы шулер булып чыга. Анда да сатучыга карата түгел, бәлки... үзенең хатынына карата:

**Шундук акча саный башлый алучы,**
**— Юк-бар белән баш катыру нигә ул!**
**Һәм җитәкләп алып китә сыерны:**
**«Мин саумыйм бит, хатын сава»,**

— ди дә ул.

Буяуны куерту да Зәки Нурида актив. «Өйләнүдән курыккан ирләргә» шигырендә ул татусыз гаилә тормышын тасвирлый да, аннары «юри генә яздым» ди. Хәлбуки, тасвир дөреслектән ерак түгел. Шуңа ук иш алымнардан читкә адреслауны күрсәтергә мөмкин. «Кыйммәтле кияү» шигыренә автор «иске заман мәзәге» дип искәрмә бирә, юкса, яңа заманда да андый хәлләр аз түгел.

Васыять — дөнья сатирик поэзиясе тарафыннан эшләнгән алым. Аның үтергеч үрнәкләрен Франсуа Вийон биреп калдырган. Зәки Нури шушы коралны бюрократка төби:

**Арагыздан киткән чакта**
**Шушы сүзем калсын минем:**
**Карамаска сезнең якка**
**Ике күзем калсын минем.**

**. . . . . . . . . . . . .**

**Телем калсын — «Ярый!» диеп**
**Уңай җавап бирмәс өчен.**

(«Бюрократ васыяте».)

Бюрократизмның бөтен начарлыгын, тормышка ябышучан әрсезлеген автор үткен эләктергән. Кечсез һәм җәмгыятькә ят була торып та, тормышка ябышуы аны көлке итә.

Сатира чараларын шагыйрь дүртьюллыкларында оста төрләндереп тора, аерым алганда, диалогтан актив файдалана. «Дөрес сүз» сатирик диалогында атаклы әйтем («Барлык юллар Римга илтә») нигезендә сүз уйнатыла һәм һөҗүм парадокс ярдәмендә (юл сораучыга гадәттә яхшы юлны күрсәтәләр) көчәйтелә:

**— Безгә район юл бүлеге кирәк,**
**Тотыйк икән юлны кайда без!**
**— Начар юллар бар да шунда илтә,**
**Иң начарын юлның сайлагыз.**

Үзенең булдыксызлыгын бөек шәхесләр мисалына яшерергә маташканда, «Буш вәгъдә» шигыренең сатирик герое башта беркатлы күренсә дә, асылда демагог булып күз алдына килә.

**— Эшең кайда! Юеш комга язып**
**Ник алдың син коры йөкләмә!**
**— Әйтәләр бит Пифагорны комга**
**Бөек закон язган дип әнә!**

Шагыйрьнең аерым дүртьюллыкларын «миниатюр мәсәлләр» дип атарга мөмкин. Аларны мәсәлчә итә торган төп шарт — тискәре күренешләрне хайваннар образында типиклаштыру, аллегория куллану. Аерма исә шунда гына, автор азактан гыйбрәт ясауны кирәк дип тапмый. Мәсьәләне үткенәйтелгән ирония хәл итә:

**Барган чакта Чуртан кырын эшкә**
**Һәр кыслага сәлам бирә икән...**
**Алга гына түгел, чөнки Кысла**
**Артка да бик яхшы күрә икән!**

Шагыйрьнең үзенчәлекле сарказмы күренешнең асылын күрмәмешкә салышуда чагыла. Тәнкыйтьләнә торган күренеш тышкы ягы белән әхлак тарафыннан хуплана торган хәлләргә туры килә. Мактау-хуплау рәвешендә язылган әсәр шул рәвешле зәһәр көлүгә әйләнә. Менә «Бала ярата» исемле дүртьюллык:

**Ул яшь әле, ләкин олылар**
**Шулай диләр аңа карата:**
**— Җиде җирдә җиде улы бар,**
**Баланы ул бигрәк ярата...**

Үзенең һөҗүм-сатира чаралары ягыннан «Яклау сүзе» фельетоны кызык. Персональ эшен тикшергәндә «Фәлән Фәләновны» «берәүләр әрләп, берәүләр кызганганнан» соң:

**...Ниһаять, тагын берәү торып,**
**Салмак кына башлый тамак кырып:**
**. . . . . . . . . . . . . .**
**Фикерем шул аңа карата:**
**Фәләновны күпләр ярата!**
**Эшкә кайчак соңга калганы**
**өчен түгел, әлбәттә,**
**Эштә кайчак аз-маз салганы**
**өчен түгел, әлбәттә,**
**Өстәп язып бүләк алганы**
**өчен түгел, әлбәттә,**
**Газетага язган ялганы**
**өчен түгел, әлбәттә.**
**Яратабыз без аны,**
**Ул безне яратканы өчен,**
**. . . . . . . . . . . . . .**
**Бездә озак эшләгәне өчен,**
**Посттан һич тә төшмәгәне өчен!..**

Ялагайның индивидуаль сөйләмен бирү өчен үлчәм үзгәртелә. Шагыйрь берьюлы ике типны көлкегә ала — яклаучының үзен һәм «Фәлән Фәләнов»ны. Озынга киткән санау «яклanучының» бернинди яклар нәрсәсе юклыгын күрсәтә. Аны чынлыкта «түгел... түгел» дип кабатланган тискәре сыйфатлары өчен яраталар булып чыга. Автор яклау нотыгын гротеск дәрәҗәсендә күпертә, юкса, яклау батыру кебек үк остарак, хәйләкәррәк эшләнә. Хикмәт тә шунда, автор яклаучыдан аның әйтмәгән һәм әйтмәячәк сүзләрен, күрә торып та дәшми калган хакыйкатьне әйттерә. Дөрес, фельетончы монологны «тормышка якынайту» өчен «кайчак», «аз-маз» сүзләре белән бераз йомшарта, әмма аны да көлү чарасы буларак эшли. Укучы моны «бик еш» һәм «күп» итеп аңлый.

Лирика һәм сатира-юмор Зәки Нури иҗатында кулга-кул тотынышып эшли. Лирикасы белән расланган идеалларга ят күренешләрне шагыйрь сатира ярдәмендә инкарь итә.

Хәзерге сатирик поэзиядә Әхмәт Исхак, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев һәм Гамил Афзал тоткан урын, бездә сатира-юмор поэзиясенең үзенчәлекләре кебек мәсьәләләр махсус тикшеренүне көтә. Без исә бу мәкаләдә Зәки Нури иҗатындагы кайбер үзенчәлекле моментларны, башлыча, аның лирикасындагы төп юнәлешләрне билгеләргә тырыштык.

# ТАҢ ШӘҺӘРЕ...

Бала чакта ерактагы тау сыртларында, урман буйларында рәшәгә күмелеп югала барган офыклар безгә нинди могҗизалар вәгъдә итмәгән, ә арыш басуы уртасыннан боргаланып сузылган юллар кемнең генә уй-хисләрен еракераклрга алып китмәде икән. Кемнең генә күңеле офыклар артындагы серле яңа җирләр белән хыялланмагандыр, дисез. Чөнки әллә кай җирләрдән килгән ак болытлар шул хакта искәртә, канатларында язны алып килгән кыр казлары гүя шул турыда хәбәр сала. Хыялдагы ул җирләрне кемдер «зәңгәр ил» дип атагандыр, кемдер «таң шәһәре» дигәндер, кемдер бәлки тагын да матуррак башка берәр исем тапкандыр...

Вакыт үтә. Китмәскә килгән кебек тоелган айлар-еллар бала чакның ялан тәпиләре белән бергә ялтырап каядыр артта кала. Кеше үсә, чыныга, үзгәрә. «Таң шәһәре»н биләп алган хыялый томаннар әкрен генә тарала бара.

Һәм шәһәр реаль кыяфәткә кереп якынлаша башлый. Баксаң, ул алай әле дөнья читендә үк түгел икән. Уйда, хыялда гына күренгән чалымнары Казаныбызның завод-фабрикаларында, шәһәрләребезнең зур төзелешләрендә бар икән ләбаса! Чулман, Идел буйларында яки туган илебезнең бүтән җирләрендәге бу яңа «таң калалары» күңелдә иң изге җирләр булып урын ала. Ул Кремль, Сөембикә манаралары, алардан да биегрәк булып күтәрелгән төзү краннары белән бергә күз алдына килеп баса.

Һәм иң мөһиме, хыялдагы шәһәрен яшьлек үз куллары белән төзи. Түбән Камалар, бөтен дөньяга даны таралган Чаллылар барлыкка килә. Бала чак хыялы яшьлек романтикасына әверелеп тормышка аша, чынбарлыкка әйләнә. Син туган җиреңне яңабаштан ача башлыйсың. Роберт Әхмәтҗановның яңа шигырьләр җыентыгына[1] кергән һәм яшь төзүчеләргә багышланган «Таң шәһәре» дигән поэмасы шул турыда сөйли.

Коймалар юк бирeдә, таш коймалар,
син рәхим ит,
ачык дүрт ягы!..
Кояш хуҗа монда һәм Азатлык,
һәм шуларга кушыла
җыр тагы...

(«Таң шәһәре».)

Туган җиребезнең йөзе көннән-көн үзгәрә. Республиканың төрле почмакларында яңа төзелешләр бара. Торак йортлар белән бергә, яңа завод-фабрикалар аякка баса. Алар яшьләр көче белән салына. Туачак көннәрнең матурлыгы яшьләр кулында. Киләчәгебезнең яктылыгы, гасырлар буе үсеп, баеп килгән традицияләрне, гореф-гадәтләрне яңа нигездә тагын да үстерү шул яшьләрдән тора, дип раслый автор үзенең шигырьләрендә. Чынлап та, һәркемгә мәгълүм ки, яңа, матур тормыш төзүче кешенең матди көнкүреше бөтен булу өстенә, аның рухи дөньясы да бай булырга тиеш. Кеше катлаулы автоматлар уйлап чыгара, галәмне гизә. Әмма аның күңел байлыгы, бәхете фәнни-техник революция казанышлары белән генә үлчәнми. Эш бүгенге буынның элеккесеннән һәм киләчәк буынның бүгенгесеннән рухи баерак, күркәмрәк булуында. Робертның байтак шигырьләре әнә шул яшь буынга адресланган.

Скептиклар әйтсен:
«Кала бар да —
яныш сөйгән яр да,
тал да, гөл дә,
йолдызлар да,
яңа калалар да...»
Калсын!
Офтанмыйбыз һич тә.
Бүген бездән
калулар түгел,

---

[1] Роберт Әхмәтҗанов. «Таң шәһәре». Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1974 ел.

калдырулар турында
яңа жыр тиешле
яңа заманга!..
(«Калдырабыз төзеп яңа шәһәрләр».)

Китапның беренче бүлеге «Гомер учагы» дип исемләнгән. Авторның лирик каһарманы уе-акылы белән балигъ булган кеше. Ул дөньядагы бар нәрсәгә дә җаваплы икәнен аңлый, иңнәрендә хакыйкать һәм вөҗдан йөген тоеп яши. Кешенең күңелен табигать белән бәйләп караганда бу балигъълыкны тагын да ачыграк сизеп була. Әнә төнге күкне йолдыз сызып үтә, әйтерсең еллар буе йөрәгендә йөргән тойгы иреннәрдән кинәт сүз булып ычкына. Әнә, соңгы өмет кебек өзелергә торган сары яфрак келт итеп йөрәкне телеп ала. Уйландыра... Болгар хәрабәләре өстендәге ярым ай ниләргә ишарәли икән? Нинди шом бар кара күләгәләрдә? Әнә, тәнен җуйган җан кебек, агач башларыннан җил йөри... шаулап алма коела... Әрни-әрни ни эшләргә тели икән соң ялкын теле?

...Учак яна! Кичелә бара
Күренмәгән сызык:
Тып-тын гына баш очыннан
Кояш бара узып!
(«Гомер учагы».)

«Учак яна, кичелә бара күренмәгән сызык» — менә шушы бер мәл кешенең өлгергәнлеген, гражданин булып үсеп җиткәнен билгеле дә. Геройны хәятнең төрле яклары уйландыра, борчый башлый. Аның кыйбласы ачыклана төшә. Әйе, ул кыйбла халкының уй-кайгыларыннан, илең алдында торган мөһим бурычлардан аерылгысыз булырга тиеш. Шагыйрьне нәрсәләр дулкынландыра, нинди утларда яна соң аның күңеле?

Менә «Төп йорт» дип исемләнгән шигырь. Ул күңелдә туган җиргә тирән мәхәббәт хисләре уята.

Төп йортым бу, төп йортым,
бабамнар сөйләшкән җир!
Чит җирдән бүрегә белән
кайтырга киңәшкән җир...

Сугыш бетүгә инде ничәмә еллар үткән. Бер карасаң, кеше ул яралар турында онытырга да тиеш сыман. Авылшәһәрләр күптән инде яңадан торгызылган, хәрабәләрне яңа, якты проспект-урамнар алмаштырган. Тик бернәрсәне генә — сабыйларга әтиләрен, аналарга улларын кайтарып булмый... Әле һаман да дөньяның тыныч булмавы, кемнеңдер тән, кемнеңдер күңел җәрәхәте хатирәләрне яңартып тора. Авторның «Илгә исән кайткан агайлар», «Азатлык мәгънәсе» дигән шигырьләре тынычлык-иминлекне сакларга өнди.

Автор шагыйрьләрнең җәмгыятьтә тоткан урыны, иҗат дөньясы турында да җитди уйлана:

Сез уйлыйсыз: чорның шагыйрьләрен
Кара елгаларда,
Машукларда,
Моабитларда, дип, атканнар?
Ә, юк әле!..
Бик зиннәтле сарайларда,
алтын тәхетләрдә
алар җанын элек — «сатканнар!»
(«Шәмнәр».)

Күргәнегезчә, Роберт Әхмәтҗанов әсәрләренең тема диапазоны киңәя бара. Әмма шагыйрь, тематиканы киңәйтү белән бергә, киләчәктә аны тирәнәйтү, конкретлаштыру, ил-халкыбызның рухи ихтыяҗларына якынайту юнәлешендә эшләсә, иҗаты тагын да отар иде. Югыйсә, Сонгми, Хиросималар турында ачынып яза алган шагыйрьнең әсәрләрендә үзебезнең алда торган кайбер әхлакый һәм башка проблемаларның да азрак күренүе беркадәр гаҗәпләнүгә урын калдыра.

Автор дөнья әдәбияты белән танышып бара, әдәби мирасыбызны җентекләп өйрәнә, ерак гасырлардан килгән бай традицияләребезгә таянып иҗат итә, кыю эзләнә. Аның эзләнүләре күбрәк ассоциатив юнәлештә алып бара. Гомумән, соңгы чорда бу юнәлеш татар шигъриятендә алгы планга чыкты. Моның сәбәпләре дә мәгълүм. Хәзер безнең күпчелек укучы урта һәм югары белемле, аның интеллектуаль дәрәҗәсе дә югары.

Роберт Әхмәтҗановның иҗатында фикерләр тирәнәюе белән беррәттән сурәтләү чаралары байый, образлылык яңа куәтләр ала бара. Һәм шунысы әһәмиятле, авторның кайсы гына шигырен алма, аларның кешелекле лирик аһәң белән өртелгәнен ачык сизәсең. Аның иҗатында күңел җылылыгы бер фон булып бара. Шагыйрь йөрәгендә туган тойгыларны сүзләрнең мәгънәви гармониясе аша укучы күңеленә җиткерергә тырыша. Нәтиҗәдә, хис һәм фикер калку итеп сурәтләнгән образлар аша күз алдына басарлык картинага әверелә. Шигырьдәге образ-сурәтне син акылың белән генә кабул итеп калмыйча, үзеңчә күрә дә башлыйсың. Авторның әйтәсе фикерен тулысынча ачыклап бетермәвен аның үз укучыларына

ышануы дип, аларның фантазиясенә урын калдыру дип аңларга кирәк. Бу хәл укучыны яңа кичерешләргә этәрә, уйланырга, хыялланырга мәҗбүр итә. Шагыйрь һәм укучы күңеле менә шулай иҗади бәйләнешкә керә. Роберт Әхмәтҗанов шигырьләренең тәэсир көче шунда да инде. Ләкин сурәтләү чаралары, образлылык турында сөйләгәндә кайбер кимчелекләрне дә әйтмичә үтеп булмый. Бер-ике мисал китерик.

Күтәрелә җир пультына игенчеләр —
дирижерлар,
илһам биреп иң бөек сәнгатьләргә.
(«Игенчеләргә мәдхия».)

Сине ташлар таный. Аяк астыңа
җырлап керә күпер, ксилофондай.
(«Таш йортлар...»)

«Игенчеләр — дирижерлар», «ксилофондай күпер» кебек ясалма, шапырынулы чагыштырулар әлеге яхшы гына шигырьләрне дә ямьсезлиләр. Әбит чагыштыру, никадәр генә сәер һәм көтелмәгән булмасын, ул иң әүвәл тәэсир көченә ия булырга, шигырьнең рухына, гомум аһәңенә буйсынырга тиеш.

Әдәбият сөючеләр Роберт Әхмәтҗановның бу китабын яхшы кабул итәрләр дип уйларга кирәк. Алар анда күңелгә хуш килә торган шигъри яңгырашлар табарлар, шигырьләрне укып уйланырлар, һәрхәлдә, битараф калмаслар...

**Рөстәм ФӘЙЗУЛЛА.**

# ШАГЫЙРӘНЕҢ «ФАЛ КИТАБЫ»

„Фал ачам, бәхет ачам", икенче сүзләр белән әйткәндә, «якты киләчәкне ачам, бәхет ачам»,— дип яза Саҗидә Сөләйманова «Фал китабы» исемле шигъри җыентыгында[1]. Ни сөйли соң С. Сөләйманованың «Фал китабы», укучыны шатландыра һәм канатландырамы, яисә борчулы уйлар эчендә янарга мәҗбүр итәме?

«Фал китабы»н ачам. Һәм беренче шигырь үк фәлсәфи эчтәлеге, тирән фикерләре белән игътибарны җәлеп итә.

Алтын диләр,
бик кирәгем чыкса, куштаннар,
алтын булсам, бер сатылыр идем.
Мин — кеше!
Ярага — тоз, арага ут сала
дошманнар,
корыч булсам да бер эрер идем.
Мин — кеше.
(«Кеше».)

Үз язмышыңны кешелек дөньясының моң-зарлары белән бәйли белү, язмышның ачы җилләренә карамастан, үзеңдә кешелек горурлыгын хис итә алу — бу сыйфат җыентыклары күп шигырьләргә хас. «Фал китабы» үзенең иң яхшы битләрендә шигърият теле белән Кешенең кешелек бурычы, аның җирдә тоткан урыны турында сөйли; шул фикер лейтмотив булып шигырьдән-шигырьгә күчә:

Сулар ага, күлләр күккә бага,
Кояш карый дөнья күгеннән.
Яз килсә дә җиргә, боз яуса да —
Күкрәп уза кеше күңленнән.
(«Сулар ага, күлләр күккә бага...»)

Җыентыктагы шигырьләрнең барысын да нәкъ шул үзәк тема берләштергән. Аларда героиняның йөрәк тибешен, дөньяга кайнар мәхәббәтен тоясың. Ә шагыйрә тасвирлаган серле дөнья шигъри бизәкләргә, уй-кичерешләргә бай. Ул һәр вакыт хәрәкәттә, туктаусыз үзгәрештә. Табигатьтәге бәйләнеш, кеше белән табигать арасындагы мөгамәлә дә «Фал китабы»нда ачык чагылыш тапкан:

Кояш тирәсендә җир әйләнә,
Төн артыннан якты көн туа,
Яңа язда җирне яңартырга
Кыз туа да илгә, ул туа.
(«Җисми дөнья...»)

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, С. Сөләйманова үз шигырьләрендә хатын-кыз психологиясен, аның эчке дөньясын тирән итеп ачып бирә. «И кызлар, и хатыннар» шигыре моның ачык дәлиле була ала:

Без шатлансак,
Керфекләрдән нур тама, нур сирпелә,
Кем очраса, шул күрә,
Кайгыбызны кем белә?
Керфекләр җиргә иелә,
Күз яше җилгә сибелә,
(«И кызлар, и хатыннар».)

[1] Саҗидә Сөләйманова. «Фал китабы», Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1974.

«Фал китабы» жанр ягыннан да бик үзенчәлекле. Җыентыкта лирик поэзиянең башка төрләренә урын бирелсә дә, беренче планда интим лирика тора. Шулай булуы табигый да: кешенең эчке дөньясы, нечкә хисләре интим лирикада тулырак ачыла.

Тагын бер моментка басым ясыйсы килә. С. Сөләйманованың «Кыр казлары» исемле беренче шигъри җыентыгы дөнья күргәнгә ун елдан артык вакыт үтеп китте. Хәзер әдәбият сөючеләр аны дистәгә якын китап авторы буларак беләләр. Шагыйрәнең иҗатында үзгәреш бармы соң? Җыентыкны укып чыккач, һич икеләнмичә: «Әйе, бар»,— дип әйтә алабыз.

Шагыйрәнең үз-үзенә ышануы, шигърият юлыннан ныклы адымнар белән баруы китапта ачык күренеп тора. Һәм шигырьләрдә яңгыраган мотивлар авторның иҗади үсешен, аның романтик сурәтләү чараларына корылган шигъри хис дөньясы белән генә чикләнмичә, тормыш тәҗрибәсен үзенә сеңдергән образлар тудыруын күрсәтә. Кыскасы, «Фал китабы»ның башка җыентыклардан аермасы да шушы шигъри үсештә, авторның әдәби тәҗрибә туплавында һәм үзенчәлекле әдип булып формалашуында.

Бүгенге татар шагыйрәләренең иҗатында мәхәббәт темасы зур гына урын алып тора. Бу тема С. Сөләйманова шигырьләренә дә чит әйбер түгел. Алар зур фикергә ия булулары, аерым шәхес тормышына кагылган мәсьәләләрне җәмгыять таләп иткән югарылыкка күтәрә алулары белән әһәмиятлеләр.

Хәлбуки, «Фал китабы»нда укучыны гашыйк итәрлек, кыска юллар аша тирән фикерләр әйтеп биргән, үзенчәлекле шигырьләрнең күп булуына карамастан, беркадәр таләпчәнлек җитмәү аркасында, «Ирек», «Хәсән Туфанга», «Таякка мәдхия» кебек күп сүзлелеккә корылган, фикер ягыннан сай әсәрләр дә очраштыргалый.

Зур булмаган бәяләмәмне тәмамлап, «Фал китабы»н укучының фикердәше һәм сердәше булыр, тормышка шигърият биеклегеннән торып карарга ярдәм итәр, дигән ышаныч белән ябам. Хөрмәтле укучылар, «Фал китабы»н ачарга Сезнең чират.

**Әмир МӘХМҮДОВ.**

## Зәки Нури

### Тун трагедиясе

САТИРИК ӘКИЯТ

Мәсәл дә күп, мәзәк тә аз түгел
Бүре белән Куян турында.
Сөйләргә без бүген тагын берне
Тиеш булдык шушы урында.

...Кышкы көндә урман аланында
Куян белән Куян очраша.
Тезләнешеп юлга, бер-берсенең
Хәл-әхвәлен алар сораша.

Ирең ничек? Бала-чага нишли? —
Бер-бер артлы тезелеп китә сүз.
Ачыклыйлар ашау-эчү ягын
Һәм... модага килеп җитә сүз.

Күзләреннән очкын сибә-сибә:
— Беләсезме, кәбәм,— ди берсе,—
Күккә чөеп хәзер мактала бит
Бүре мехы, бүре тиресе.

Мин үземә бүре тун тектерәм!
Ирем китте бүре ауларга!
Әйттем: миңа соры кирәкми, дип,
Сарырагын куштым сайларга...

Икенчесе шунда, дер-дер килеп,
Сөртә башлый дымлы күзләрен,—
Як-ягына карангалап сөйли,
Аңлау кыен хәтта сүзләрен:

— И ахмагым, безнең ирләргә ул
Бүре тоту каян килгән, ди?!
Кичә картым бер Бүрене күргән —
Куян бүрек тегеп кигән, ди.

Ә бәлки ул... синең Куяныңдыр?..
Хаталансам, гафу итсәнә!
Ә тегесе ачулана:— Юкны
Сөйләп йөрмә, кит лә, китсәнә.

Уйлама да, кәбәм, андыйны син,
Җилләр, диген, алсын авыздан!
— Алай димә. Чөнки бөтенесен
Көтеп була Бүре явыздан...

Гәп өзелә... Дуслар бик күңелсез
Аерылышты. Алан тын калды.
«Куян бүрек!» Нинди куркыныч сүз,
Йөрәккә ул кара шом салды!

Ник күзләрдән көн-төн яшь коела,
Ник өмете сүнде бу җанның?!.
Куян бүрек — ире булып чыкты
Бүре мехы көткән Куянның.

Бу фаҗига, әйе, җан тетрәткеч...
Бик гыйбрәтле аның морале:
Сүздә генә батыр Куяннарда
Дөньяларга караш тар әле.

## Киресенчә теләкләр

### ӨЧЕНЧЕ БӘЙЛӘМ

Инде язылган шигырьләр
Һәм туа торганнары
Булмасын иде берсе дә
Тик мактау корбаннары.

Кайчакта яман төшләр дә
Яхшыга булсын иде —
Башлык булган кайберәүләр
Башлы да булсын иде.

Тик кычыткан җирне генә
Кашысын иде кеше:
Үз өстеннән үзе... әләк
Ташысын иде кеше.

Булсын иде юл казуны
Күз буяуга тиң итеп:
Киңнәрен тарайтып түгел,
Тар урамны киң итеп.

Трамвайлар игълан йөртәләр
Күпләр, дип, укысыннар:
«Этешкән-төртешкән затлар
Чиратсыз утырсыннар!..»

Ник ире эшсез икән дә
Хатыны эшсез түгел?
«Алтын куллы» сатучылар
Ник алтын тешсез түгел?

Ул балык тотты. Ә балык
Уылдык чәчә иде.
Кармактан алды да кире
Җибәрде: «Яшә!» — диде.

Гаҗәп хәл: ул шаулап кайта,
Ә хатыны шып тына —
Соңга калган өчен! диеп,
Бер уч чәчәк тоттыра.

Чөйсеннәр иде борынны
Бары баштүбән йөреп.
Кипсеннәр иде диңгезләр
Безнең саз-күлдән элек.

Ун билет алды да ертты —
Мин акча кызганмыйм, дип
Һәм әйтте: кичә трамвайда
Билетсыз узганмын... дип.

Кем беренче әйтер икән:
Гариза бирим,— диеп,—
Эштән чыгарыгыз, чөнки
Тик урын билим...— диеп?

Килер көн: без теләмәсәк,
Кунмаган таплар булыр.
Урманга барып та куак
Утырткан затлар булыр!

Коры су белән бокаллар
Ташып ла тулсын икән.
Намус турында язганнар
Намуслы булсын икән.

Башлыкны бозмыйм дигәннәр
Аңа бүләк бирмәсен,—
Кулларына бүләк тотып
Хәтта төшкә кермәсен.

Безнең авылда шундый бер
Изге зат туар микән:
Халыкны мәчеткә түгел,
Клубка куар микән?

Әйдәгез телик идарә
Отчетлар бирмәсен дип,—
Карарлар үтәлсен дигән
Карарга килмәсен дип!

Язмыйк әле, язмыйк әле,
Язмыйк әле туйганчы,—
Нәшрият безгә «Яз!» диеп
Катгый таләп куйганчы.

1974

# МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

**Ике хатын очрашкан ди.**
**— Улыгызның хәлләре ничек? — дип сорашкан ди аларның берсе.**
**— Эшләре шәп,— дигән икенчесе.— Циркта эшли. Көне буе тик тора. Юлбарысның авызына өч тапкыр башын тыгып ала да калган вакыты гел буш.**

**Петер Чабафи (Венгрия) мәзәкләреннән.**

Шундый бер ярыш үткәреп карыйк, ди. Аңа сәламәт йөрәкле, корыч нервлы, ләкин «ташка басканны» укый белә торган теләсә кем катнаша ала. Теләүчеләр бармы?

Микрофон алдына утырыгыз да газетагызны ачып куегыз, тирән итеп тын алыгыз һәм... Башладык! Кычкырып укыгыз! Күп укымагыз, биш кенә минут...

Ә хәзер мәзәк бер хәлгә әзерләнегез: пленкага язылган тавышыгызны тыңлыйбыз.

Ишеттегезме, сузык авазлар ничек чыга? Ә нигә йөткереп куйдыгыз әле? Көтелмәгәндә туктап калдыгыз. Ә-ә-ә... чит ил сүзенә юлыктыгызмы? Менә хәзер басымны ялгыштыгыз... Тагын йөткердегез! Әйе, Левитан чыкмый сездән.

Тыңлаучылар диктордан яңалыклар, әңгәмәләр, күзәтүләрне генә ишетеп калмыйлар, бик еш кына аннан уку логикасына, сүзләрнең дөрес әйтелешенә, тәэсирле сөйләмгә өйрәнәләр.

Әмма, һәр эштә булган кебек үк, тәҗрибәле дикторларның үзләре дә кайвакытта микрофон алдында утырганда мәзәк я күңелсез хәлләргә юлыгалар. Тавыш үткәрми торган студияләрнең тишекле стеналары шундый хәлләрнең байтагына шаһит була. Мин бу язмамда шуларның кайберләренә тукталырга телим.

Казан телевидение студиясенең эшли башлаган көннәре генә иде әле. Режиссер ассистентлары халык алдына сәхнәгә чыккан кебек дулкынланалар. Кнопкаларны ялгыш басалар, планны бутап бетерделәр, пленканы кирәгеннән артык алда, я шактый соң боралар.

Ул кичне Иркә Сакаева белән без студиядә тапшыруга әзерләнеп утыра идек. Әле камералар да эшләми, звонок та бирелмәгән.

Тапшыру болай башланырга тиеш: элек Иркә «Исәнмесез» дип әйтәсе. Ә мин: «Хәерле кич, иптәшләр!» — дип ялгап китәргә һәм шуннан соң сюжет башланырга тиеш.

Менә без өстәл артында утырабыз, ә монитор ничектер җайсыз торган кебек, берни дә күренми. Мин аны төзәтеп куймакчы булдым. Өстәл аша иелүем булды, безне эфирга чыгардылар. Шунда мин үземнең бик озак итеп мониторга үрелүемне күрдем. Моны Иркә дә һәм, билгеле, тамашачылар да күрделәр. Экранга үрелеп җитә алмыйча катып калдым, бераздан тураеп утырдым да, куркынган тавыш белән: «Хәерле иртә, иптәшләр!» — дип куйдым.

Бервакыт яңа магазин ачылу тантанасын пленкага язып алдык. Ни генә юк иде бу магазинда: сырлар, консервалар, яшелчәләр... һәм

бик күп сатып алучылар. Мин аларның сүзләрен, теләкләрен язып алам, күргәннәремне үзем сөйлим. Ләкин сөйләп өлгерә алмыйм, пленкам бетә. Чөнки аны студиядә репетиция ясап караган вакыттагыдан кызурак әйләндергәнмен икән.

Кайвакыт бездән, дикторның халык арасында танылган булуы аның эшенә комачау итәме, дип сорыйлар.

Уңайсызлыклар була, әлбәттә.

Кайвакыт үзеңә төбәп карап торуларын сизәсең. Үзләре шикләнгән кешеләргә милиционерлар гына шулай карый торгандыр бәлки.

Укучы балалар... Дикторны күрсәләр, пышын-пышын сөйләшәләр, үзләре алдыңа йөгереп чыгалар, я сине күрмәгәнгә салынып яныңнан киләләр, ә үзләре юк-юк та кызыксынулы караш ташлап алалар.

Кайвакыт картлар, карчыклар очрый... Алар күбрәк тапшыру турында сорашырга яраталар, тапшырулар программасын дикторлар үзләре төзи дип уйлыйлар, күрәсең. Кайберләре, бик таныш кешеләр белән очрашкандай, тартынусыз, эч серләрен сөйләп бирәләр.

Бервакыт Боровое Матюшинога дачага барганда яныма илле яшьләр тирәсендәге бер ханым килеп утырды. Ул сеңелесе белән Зеленодольскида яши һәм шуннан башка бер туганы да юк икән. Дөнья белән дә ул телевизор экраны аша гына танышып бара, ахры. Ул кемнәрне яратуын, кемнәрне яратмавын һәм ни өчен яратмавын миңа иренмичә сөйләп барды. Ата-аналарым турында кызыксынды, үземнең ничә яшьтә булуымны, өйләнгәнме икәнлегемне сорашты.

Яки мәнә троллейбуста барасың. Шунда бер хатын күршесенә иелә дә: «Хәзер үк карама, безнең артта диктор бара»,— дип әйтә. Бераз вакыт үтүгә аның күршесе башын күтәрә дә күзен тутырып сиңа карый башлый. Бу караштан шундый уңайсыз хәлгә каласың, хәтта үзеңне Париж галереясындагы шәмнән ясалган фигуралар хәлендә сизә башлыйсың. «Иптәшләр, зинһар аңлагыз, музей экспонаты хәлендә калу бик кыен»,— дип әйтәсе килә үзләренә.

Дикторларга кызык кына хатлар да килә. Тамашачыдан беренче тапкыр хат алуымны әле дә хәтерлим. Мин ул көнне бик бәхетле булган идем һәм бу билгесез кешегә рәхмәтемне әйтеп бетерә алмадым. Шуннан соң тагын, тагын хатлар килә башлады. Баштарак җавап яза бардым. Соңыннан хатлар бик күбәеп китте һәм мин аларга студиядә яхшы эшләвем белән җавап бирергә тырыша идем. Кайбер кешеләр дикторлар бар нәрсәне дә эшли ала дип уйлыйлар һәм төрле үтенечләр белән хат язалар. Мәсәлән, безгә мәнә шундыйрак хатлар да килә: «Су бөрки торган үтүк табып җибәрә алмассызмы?» «Көне буе телевизор карый торган Фил баласы» дигән кино күрсәтегез әле». Хатларның бик мәзәкләре дә була:

«Мин беренче класста укыйм. Без язарга, укырга, хисап чыгарырга өйрәндек. Укытучыбызны телевизордан күрсәтегез әле».

«Хөрмәтле диктор иптәш! «Бриллиант кул» киносындагы җырны башкаруыгызны үтенәбез».

«Әни белән концертка барган идем. Янәшәмдә утырган малай миңа бик ошады. Әйтегез әле, зинһар, аны ничек табарга?»

«Телевизордан биргән әкиятегездә тычкан баласы үлә. Шуны булдырмас өчен әкиятнең дәвамын җибәрәм».

«Безнең кызыбыз Казанда эшли. Күптән күрешкәнебез юк. Телевизордан гына булса да үзен күрсәтегез әле».

«Алтмыш яшькә җиткән тутый кош үзе дә кеше кебек сөйләшә башлый дип әйтәләр, дөресме?»

«Ни өчен бер җирдә дә Иван Грозныйның фамилиясе күрсәтелми?»

«Хөрмәтле иптәш Дубин! Көнчыгыш Европа этләренең көчеген кайдан алырга киңәш итәсез?»

Төрле тапшыруларда катнашу өчен студиягә күп кенә кешеләр дә килә. Студиянең гаять зур павильоннарына беренче кат кереп, көчле яктырткычлар алдына утырган һәм телетапшырулар барган ыгы-зыгылы минутларның шаһите булган бу кешеләр нык дулкынланалар, югалып калалар. Шул вакыт дикторга өстәмә мәшәкать туа: экранда ул үзе дә табигый булырга, беренче мәртәбә чыгыш ясаучыга да ярдәмләшергә тиеш була.

Бөтендөнья хатын-кызлар көне 8 Мартка багышланган тапшыру бара иде. Шул тапшыру вакытында чакырылган кунакларның берсе «игътибарлы» ир-атларның котлау телеграммаларын укырга тиеш. Ләкин бәйрәм алды ыгы-зыгысы беләнме, әллә каушавыннанмы, телеграммалар язылган кәгазьне ул онытып калдырган. Ни эшләргә? Тапшыру башланырга торганда өйгә кайтып булмый бит. Җитмәсә, телеграммалар укуны тапшырудан төшереп калдырырга да мөмкин түгел. Бөтен тынычлыгымны җыеп һәм барлык фантазиямне эшкә җигеп, кадрга кердем дә, «тамашачы ир-атлар кушуы буенча» дигән булып, язылмаган ак кәгазьдән «телеграммаларны» үзем укыдым. Болай ярыйсы чыкты шикелле. Әмма ул вакыттагы хәлемне бары тик үзем генә белдем.

Тагын менә шундый хәлнең дә булганы бар. Күчмә телевидение станциясе җәйге навигация ачылу турында Казан елга портыннан репортаж алып бара иде. Репортажны видеомагнитофонга язу өчен Мәскәүнең Үзәк студиясе кабул итә. Барысы да яхшы гына барганда, тапшыруга катнашучы бер кешебез юкка чыга. Катлаулы аппаратура эшләгәндә көтеп торып булмый. Шунда ук, репортер роленнән тыш, «хәбәрсез югалган кеше»нең эшен дә үз өстемә алырга туры килде.

Шулай бер көнне ике тапшыру арасында буш вакыт калды. Режиссер миңа: «Җиде минут вакыт бар. Ашыкмыйча гына программаны әйт. Әкренрәк укы!» — диде. Камера эшли башлагач, мин тамашачыларга карадым да: «Икенче тапшыруга кадәр бераз вакыт бар, мин сезне иртәгә булачак программа белән таныштырам»,— дип әйттем.

Укый гына башлавым булды, күрәм — оператор кулын селки. Күз кырыем белән аңа карадым, нәрсә әйтергә теләгән соң ул? Бәлки мин кирәкле текстны укымыймдыр? Бәлки мине экранда күрсәтмиләрдер инде? Укудан туктадым да мониторга карадым. Юк, мин әле һаман да экранда утырам. Тагын укый башладым, ә үзем һәр пышылдауга колак салам.

«Нәрсә дип әйтим инде мин аңа? Ул берни дә ишетми бит»,— ди оператор. Үзенең аңлаешсыз кул болгауларыннан мин нәрсә булса да аңларга тиеш дип уйлый булса кирәк. Төшенеп кара син аны! Аның үзен утыртырга иде шушы урынга... «Бар да бетте!.. Тапшыруны харап иттем»,— дип уйладым мин ул вакытта. Кинәт иртәгә булачак бәйрәм исемә килеп төште. Барысы да аңлашыла: кирәкле текстны укымыйм... Шул уй башыма килүгә программадан күземне күтәрә алмый башладым. Бер генә теләк калды: тиз генә укып бетерергә дә студиядән чыгып качарга. Тамашачының күзенә күтәрелеп карарга оят. Мин аларга бөтенләй башка нәрсә сөйлим бит, бөтенләй башка... Пулемет кебек ашыгып һава хәлен, белдерүләрне укып бетердем дә, тапшырулар тәмамлангач, ук шикелле атылып оператор янына килдем... «Я хәзер әйт инде, нинди ялгыш җибәрдем?» — дидем. Ә ул миңа тыныч кына җавап бирде: «Бернинди дә ялгыш юк. Ләкин өч тапкыр әкренрәк укырга кирәк иде. Ә син борчак сипкән шикелле укыдың. Шуңар кул болгаган идем...» Борчылудан хәлсезләнеп креслога аудым.

**АБДУЛЛА ДУБИН,**
**Казан телевидениесе дикторы.**

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## НӘШРИЯТЫБЫЗ 1975 ЕЛДА

...334 яңа китап бастырып чыгарачак. Тематик план исемлегендә — марксизм-ленинизм классиклары һәм КПСС җитәкчеләренең әсәрләре татар телендә, фәнни-популяр, фәнни-техник һәм тарихи тема, авыл хуҗалыгы темасы китаплары, дәреслекләр... Аннары — ноталы җыр китаплары, альбомнар, плакатлар, листовкалар, лозунглар һәм, ниһаять, сукырлар укысын өчен дә дистәгә якын татарча китап. Һәр елдагыча, арада иң күп урын матур әдәбият әсәрләренә бирелә. Өлкәннәр һәм балалар өчен тагын 111 китап чыгачак.




Татарстан китап нәшриятының 1975 ел тематик планы илебездә барлык республика, край һәм өлкәләрнең китап сәүдәсе оешмаларына һәм потребсоюзларга инде күптән таратылды. Китапханәләр һәм мәктәпләр кирәкле китапларны шулар аша заказ бирен соратырга тиешләр. Аерым укучылар соравы буенча китапларны почта белән җибәрә торган кибет Казанда бар. Адресы: Октябрьская урамы, 18, магазин № 14, «Книга-почтой».

## БУ КИТАПЛАР БЫЕЛ МӘСКӘҮДӘ РУС ТЕЛЕНДӘ ЧЫГА

**«Художественная литература» нәшрияты:**

1. Фатих Әмирхан. «Повесть һәм хикәяләр».

**«Советский писатель» нәшрияты:**

2. Габдрахман Әпсәләмов. «Яшел яр» (роман).
3. Гомәр Бәширов. «Туган ягым — яшел бишек» (повесть).
4. Нәби Дәүли. «Иртә. Көн. Кич» (шигырьләр).

**«Советская Россия» нәшрияты:**

5. Габдрахман Минский. «Беренче симфония» (хикәяләр).
6. Мәҗит Рафиков. «Ишгилде» (повесть һәм хикәяләр).
7. Муса Җәлил. «Батыр егет турында җыр» (балалар өчен шигырьләр).

**«Современник» нәшрияты:**

8. Әхсән Баянов. «Кышкы чәчәкләр» (шигырьләр һәм поэма).
9. Диас Вәлиев. «Картлар, ирләр, малайлар» (повестьлар һәм хикәяләр).
10. Мөсагыйть Хәбибуллин. «Сәгъди» (проза китабы).
11. Флүн Мусин. «Тормыш координатлары буенча» (проза проблемалары турында тәнкыйтьче уйлanулары).

**«Молодая гвардия» нәшрияты:**

12. Рөстәм Кутуй. «Зов» (шигырьләр һәм поэма).

**Конкурста катнашыйк**

СССР Культура Министрлыгы һәм СССР Язучылары союзы эшчеләр сыйныфының һәм авыл хезмәтчәннәренең батыр хезмәте, югары патриотик хисләре һәм рухи матурлыклары турында иң яхшы бер пәрдәле пьесаларга конкурс игълан иттеләр. Конкурста профессиональ драматурглар белән бергә үзешчән авторлар да катнаша ала. Әсәрләрне җибәрү өчен адрес: Москва, ул. Куйбышева, 10, Министерство Культуры. Хатка «На конкурс одноактных пьес» дигән билге куярга кирәк.

*

* *

Филология фәннәре докторы, профессор Г. Ломидзеның «Ленинизм һәм милли әдәбиятлар язмышы» дигән китабының тулыландырылган икенче басмасында (Мәскәү, 1974), башка милләт әдипләре белән беррәттән, татар әдәбиятының күренекле вәкилләренә дә югары бәя бирелә. Мәсәлән, анда Шәриф Камалның «Матур туганда» романына җентекле анализ бар. Автор романның исеме үк аның язылган чорына лаек дигән фикерне әйтә. Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романыннан Әбүзәр Таһиров образына ул аеруча басым ясап туктала, аның кешеләргә күбрәк игелек эшләү теләге белән янып яшәвен, тормышның авыр йөкләрен җиңел санап, шатлык белән һәм илһамланып күтәрүен хуплый.

*

* *

«Лауреаты России» дигән беренче китапта (Мәскәү, 1973) 14 әдипнең тормыш юлы, иҗат биографиясе һәм әдәби осталык турында уйланулары басылган. Шул авторларның берсе — шагыйребез Сибгат Хәким.

*

* *

Волгоград китап нәшрияты совет һәм чит ил язучыларының Ватан сугышы елларында Сталинград һәм аны яклаучылар батырлыгына багышлап язылган әсәрләрен «Баш неп» дигән китап итеп чыгара. Җыентыкка Әхмәт Фәйзинең «Сталинград стенасы» һәм Самат Шакирның «Бер җырда өчәү» дигән әсәрләренең тәрҗемәсе кертелгән.

*

* *

Мәскәүдә театр институтының милли студиясенә нигез салучы актриса, режиссер һәм педагог О. И. Пыжкованың «Призвание» исемле китабы чыкты (Мәскәү, 1973). Анда татар студиясендә укыган студентларның үз профессияләре киләчәгенә җитди ышаныч белән караулары әйтелә. Китапта Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисткасы Асия Әхмәтшина (Харисова) турында бик җылы һәм уңай фикерләр шактый күп.

## МӘКТӘП КЛУБЫ ЮБИЛЕЕ

«...Татарстанның безгә хөрмәтле бөтен язучылары! Сезгә Муса Җәлил исемендәге клубыбызның ун еллыгы юбилееннән бернечә фоторәсем җибәрәбез.




Тантана бик зур булды. Сезнең котлау телеграммагыз өчен шундый ук зур рәхмәт! Бәйрәмебезгә бик күп кунак килде, аны Львов шәһәре телевидениесе күрсәтте. Ул чын мәгънәдә интернациональ дуслык кичәсе булып истә калачак. Чөнки бит ул кичәдә Җәлил шигырьләре рус, украин һәм татар телләрендә яңгырады. Ә татар телендә аны украин балалары укыдылар».

Бу коллектив хат Татарстан язучылар союзына Львов өлкәсенең Пустомыжовский районы, Старое село исемле авылы мәктәбеннән «Җәлил исемендәге клуб» имзасы белән килде. Укучылар һәм укытучылар коллективы Татарстан әдипләреннән аларга Мусаның 70 еллыгы юбилеенә әзерләнгәндә ярдәм итүне сорый: «Җәлил турында теләсә нинди телдә язылган яңа материал безгә бик кадерле булачак... Клубта газеталар, открыткалар, значоклар да җыела. Бүгенге Татарстан, аның төзелешләре һәм кешеләре турында татар әдипләренең китапларын җибәрүне үтенәбез. Күрше



авыл мәктәпләрен дә таныштыру өчен клубны киңәйтергә телибез».

*Рәсемнәрдә: 1. Җәлил исемендәге клубка яңа кабул ителгән членнар. 2. Укучы Чемерис Ольга Муса портретын агачка кисеп үзе эшләгән. Ул шуны клубка бүләк итә. 3. Әзербәйҗан ССРның атказанган артисты, Украина ССРның халык артисты, СССР Дәүләт премияләре лауреаты Борис Михайлович Чипкин кичәдә чыгыш ясый.*



## УЛ БЕЗДӘ БУЛГАН

«СССР Язучылар союзы чит илләр комиссиясенә Палестин Язучылары һәм журналистлары союзының генераль секретаре Нажи Аллюштан хат килде. Ул XX гасырның беренче яртысында Казанда һәм Бакуда яшәгән һәм эшләгән күренекле Палестин язучысы һәм галиме Бандали Җузи турында билгеле булган материаллар турында хәбәр итүне сорый. Җузи гарәп һәм рус телләрендә язган. Хәзер Бейрутта аның әсәрләренең тулы җыелмасы чыгарыла... Шуларның Казан университетында язылганнары һәм Казанда басылганнарының күчермәләрен җибәрттерә алмассызмы икән?»

СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Зәки Нурига шундый эш кушылгач, Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең фәнни эшләр буенча урынбасары Н. Ә. Әхмәтҗанова ярдәме белән түбәндәгеләр ачыкланды: Пантелеймон Крестович Җузиның Казанда чыккан хезмәтләренең зур исемлегендә «Ислам һәм мәгърифәт» (1899), ике томлы «Русча-гарәпчә тулы сүзлек» (1903), «Мәккә Мөхәммәте һәм Мәдинә Мөхәммәте» (1906), «Иерусалим чиркәве тарихыннан» (1910), «Корьән» (1914), «Ханаанның тәүге тарихына карата» (1917) дигән һәм башка күп басмалар бар.

## ГОРЬКИЙ КАЛАСЫНДА МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

Биредә РСФСР композиторлар союзы һәм хор җәмгыятенең берләштерелгән пленумы узды. Анда Татарстан композиторларының зур делегациясе катнашты һәм яңа әсәрләрдән Фасил Әхмәтовның Фәрит Яруллин истәлегенә багышланган симфоник поэмасы, Анатолий Лупповның «КамАЗ яшьлеге» дигән увертюрасы тыңланып, яхшы бәя алды.

## БАЛАЛАР ФИЛАРМОНИЯСЕ

Казан шәһәренең музыка һәм художество мәктәпләре педагоглары һәм укучылары А. Гайдар исемендәге культура сараенда ай саен үткәрә торган лекция-концертлар программасы («Музыка — безнең дустыбыз») тышлыгына «Балалар филармониясе» дип язылган. Ә аның эчтәлегендә



менә нинди темаларга чыгышлар планлаштырыла: «Татарстан композиторлары музыкасы», «Совет композиторлары әсәрләре», «Союздаш республикалар музыкасы», «Совет композиторлары әсәрләреннән ансамбльләр», «С. С. Прокофьев һәм Д. Шостакович музыкасы». Концертны музыка мәктәпләре укучылары башкара, концерт барган бинаның бер залында художество мәктәпләрендә эшләнгән рәсемнәр күргәзмәсе оештырыла, сәхнәне дә яшь рәссамнар үзләре бизи.

## СОҢГЫСЫ БУЛМАС

Россия Федерациясендә үткән ел азатында «Театр һәм балалар» исемле бәйрәм үткәрелде. Татарстан театр җәмәгатьчелеге, Культура һәм Мәгариф министрлыклары, комсомол һәм пионер оешмалары да аны нәтиҗәле һәм истәлекле итү өчен күп көч куйдылар. Театр атналыгы дәвамында Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры балаларга Луиза Хәйретдинованың «Мәкерле песи» дигән әсәрен күрсәтте. В. Качалов исемендәге Зур драма, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия һәм Яшь тамашачылар театрларының да төп кунаклары ул көннәрдә балалар булды. Бәйрәм Казан курчак театрының 40 еллыгына туры килү сәбәпле, «курчакчылар» аны икеләтә бәйрәм иттеләр: яшь тамашачылар конференциясендә аның спектакльләре турында фикер алышынды, театр артистлары үзешчән курчак коллективлары белән 90 нчы мәктәптә очрашты. Беренче мәртәбә шулай киң күләмдә үткәрелгән театр бәйрәмнәре киләчәктә дә уңышлы кабатланыр дип ышанырга кирәк.

## ЛАУРЕАТ ЯУЛАГАН ҮРЛӘР

1971 елны ул Татарстанда комсомол җырларын башкаруга үткәрелгән фестивальдә беренче урынны яулый. 1972 елда «Кышкы эстрада» дигән республика фестивалендә җиңеп чыга. 1973 елда исә студентлар һәм яшьләрнең X Бөтендөнья фестиваленә багышлап Белоруссиядә уздырылган Бөтенсоюз ярышында яхшы җырлап, тагын лауреат исемен ала. Ә үткән ел азагында эстрада артистларының Мәскәүдәге бишенче Бөтенсоюз конкурсында тагын беренче урынга чыкты.

Үрдән-үргә менүчебез кем дисәгез, ул — Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының яшь солисты Ренат Ибраһимов булыр. Хәзер Ренат эстрада җырчыларының быел үткәреләчәк Бөтендөнья конкурсында чыгыш ясарга әзерләнә.

## ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘР ҺӘМ БҮЛЕКЛӘРДӘ ЯҢАЛЫК

* * *

**Чаллы:** «Ләйсән» берләшмәсе бюросының яңа составына яшь әдипләребездән Р. Вәлиев (председатель), Х. Хөснуллин һәм М. Газизов сайланды.

**Чаллы:** Язучы Эдуард Касыймов берләшмә членнарына үзенең КамАЗ төзелешенә багышланган «Дулкын» исемле яңа романын ничек язуы турында сөйләде. Совхоз эшчеләре яшәячәк яңа поселокны төзүчеләр хезмәтен һәм мөнәсәбәтләрен, уйхисләрен өйрәнер өчен, әдип «Металлургстрой» трестының Александр Пигелев бригадасында күпмедер вакыт сантехник булып та эшли — буласы поселокта трубалар сузыша. Әдәби осталык «серләре» турында әңгәмә тыңлаган яшьләр аңа булачак әсәрне камилләштерер өчен кирәкле тормыш «серләренең» дә үзләре белгән хәтлесен әйттеләр.


**Әлмәт:** Клара Булатованың Татарстан китап нәшриятында чыгачак яңа китабының кулъязмасы тикшерелде. Берләшмә членнары җыентыкны камилләштерү буенча файдалы киңәшләр бирделәр.

**Әлмәт:** бүлек язучылары «Казан утлары» журналы укучылары белән күп санлы очрашулар үткәрде. Мәсәлән: Юныс Әминов — Баулы һәм Бөгелмә районнарында, Сәет Кальметов — Ижевск шәһәрендә һәм Чаллының «Энергетик» культура йортында, Шамил Бикчурин — Лениногорск нефтьчеләре алдында, Рафаил Төхфәтуллин һәм Гамил Афзал Әлмәт радиосыннан чыгыш ясадылар.

**Лениногорск:** биредәге әдәби берләшмә членнары белән берлектә, Әлмәт бүлеге язучыларының күчмә утырышы үткәрелде. Яшь язучы Әсрар Галиевнең «Җиргә иңгән нурлар» исемле очерклар җыентыгының әдәби эшләнешен әле тиешле югарылыкка күтәрү кирәклегенә басым ясап әйтелде.

**Әлмәт:** Шагыйрә Сажидә Сөләйманова башлап язучылар белән очрашты һәм аларга поэтик образлар турында сөйләде.

**Лениногорск:** Прозаик Шамил Бикчурин берләшмә утырышында әдәби очерк жанры турында фикерләрен уртаклашты.



*ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ Тарас Шевченко кабере янында. 1914 ел.*

*МАНСУР РӘХИМОВ*
*рәсеме.*

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210